ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

9.2002



# 30 AVGUST—RESPUBLİKA KӨNE









*Н. Исмәгыйлев фотолары.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2002

9

(959)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

### ШИГЪРИ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Дөнья базары яхуд яңа «Америка фаҗигасе» *(Лирик-публицистик поэма)* ........ 5
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Һәрнәрсәгә—акчалата. *Роман* ........ 23
Асия ЮНЫСОВА. Сөенче. *Шигырьләр* ........ 84
Әхмәт ГАДЕЛ. Өрәк һәм аучы. *Хикәя* ........ 87
Сафуан МУЛЛА ГАЛИ. Үлемсез булыйк. *Шигырьләр* ........ 95

### ПУБЛИЦИСТИКА

Айдар ХӘЛИМ. «Яңа сагыш китабы» ........ 98

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XIV КОРЫЛТАЕ

Факил САФИН. Гыйбрәт алыйм дисәң ........ 131
Татарстан язучыларының XIV корылтае резолюциясе ........ 141
Равил ГАБДРАХМАНОВ. Татарстан Язучылар оешмасы тарихыннан ........ 143

### ТАРИХ

Булат ХӘМИДУЛЛИН. 1552 ел фаҗигасе тарих битләрендә ........ 152
Сергей КЛЯШТОРНЫЙ. Татарларның Үзәк Азиядәге дәүләтләре *(Монголларга хәтле чор)* ........ 173

### КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

29—Ганкәбут (Үрмәкүч) сүрәсе ........ 165
30—Рум (Рум) сүрәсе ........ 169

### ХӘТЕР

Хисам КАМАЛОВ. Заман кешесе ........ 178
Nuri ARSLANOV. Tərle yıllardan. *Şiğerlər* ........ 183

### ЮМОР-САТИРА

Илфак ШИҺАПОВ. Юмористик хикәяләр ........ 185
Ринат МӘННАН. Үртәмешләр ........ 187

### ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Розалина ШАҺИЕВА. Казанны сагыну ........ 191

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 193

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Р. МИР-ХАЙДАРОВ. Продолжение романа «За все—наличными», рассказ А. АДЕЛЯ «Призрак и охотник»; поэма Л. ШАГИРЗЯН, стихи А. ЮНУСОВОЙ, С. МУЛЛА ГАЛИ.
«Публицистика»: А. ХАЛИМ. «Новая книга печали».
«XIV съезд писателей Татарстана»: доклад Ф. САФИНА о состоянии прозы; резолюция XIV съезда и статья Р. АБДРАХМАНОВА об истории Союза писателей республики.
«История»: статья Б. ХАМИДУЛЛИНА «Трагедия 1552 года на страницах истории» и статья С. КЛЯШТОРНОГО «Государства татар в центральной Азии».
Коран на татарском языке.
«Память»: воспоминания Х. КАМАЛОВА о Г. Ахунове.
«Юмор-сатира»: юмористические рассказы И. ШИГАПОВА и пародии Р. МАННАНА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: работа Н. Латфуллина "Ностальгия по Казани"; поэт Р. Идиатуллин.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": R. MIRKHAIDAROV'S novel «Cash for anything», A. ADEL'S story "The ghost and hunter", L. SHAHIRZIAN'S poem; the verses A. UNOUSOVA, S. MULLA GALI.
"Journalism": A. KHALIM "New book about sorrow".
"XIV congress of Tatarstan's writers": F. SAFIN'S report about prose; resolution of XIV congress; R. ABDRAKHMANOV'S article about history of Tatarstan writers congress.
"History": B. KHAMIDULLINS article "The tragedy of 1552 year on history pages"; S. KLIASHTORNIY'S article "The states of Tatars at the Central Asia".
Koran in Tatar language.
"Memory": H. KAMALOV'S reminiscences about G. Akhunov.
"Humor and satira": parodoes of R. MANNAN and stories I. SHIGAPOVA.
The diary of social and cultural life.
In our covers: "The sorrow about Kazan"—the work of Latfullin; poet R. Idiyatullin.


★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 2.09.2002 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9134. Заказ Б—507
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълумат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2


© «Казан утлары», 2002 ел.



## Лена Шагыйрьҗан

### ДӨНЬЯ БАЗАРЫ ЯХУД ЯҢА «АМЕРИКА ФАҖИГАСЕ»

#### ЛИРИК-ПУБЛИЦИСТИК ПОЭМА

*«...Җавап бирегез миңа! Җавап бирегез сез!*
*һәркемне—җавапка! Уятыгыз, йокласа!*
*Беркем дә качарга җөрьәт итмәсен!*
*Озак яшәрбезме икейөзлеләнеп,*
*кабахәтлек кылып?..»*

Уолт Уитмен[1]

*(Марс Шабай тәрҗ.)*

**I**

**Төп героең кайда? Кем ул?—диеп**
**йөдәтмәгез!—Боздым мин йоланы.**
**Сюжет сызыгы да—уйлап тапкан—**
**тәшкил итмәс ошбу поэманы.**

**Бик кирәксә, әнә—үзем герой,**
**үзем утырдым мин бүген рульгә.**
**Үзем шаһит чорга—Вакыйгага,**
**үзем керәм образга вә рольгә.**

**Уйлап чыгаралмас идем мәллә,**
**фантазияләргә чынны ялгап?..**
**«Сюжет» калсын—тамашалар өчен,**
**укучыга—Сүз һәм Фикер алдан...**

Лена ШАГЫЙРЬҖАН—*шагыйрә, «Ышанам йөрәгемә», «Иман әлифбасы», «Шагыйрьләр һәм поэма», «Канатлы ат» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

[1]Уолт Уитмен—Американың бөек шагыйре. XIX гасыр.

Ялган сюжет һәм чын уйдырмадан
чынбарлыкка кайта халык барыбер.
«Сугыш һәм Тынычлык» сагаларын
эшкәрталмый сыек эчәк-бавыр:

Телевизор «китабыннан» укып
кызу-кызу «гасыр әсәрләрен»,
Чәйнәмичә генә йота гавам,
утырмый ул уйлап, әсәрләнеп.

«Алхимиклар» формуласы гына
ясый алмый «яңа» кеше канын...
...Язучысы булса, укучысы
табылмыйча калмас—гадел канун...

Мин бер гади шагыйрәсе Илнең,
дөнья хәлен ишетеп, белеп торган.
Ишеткәнчүк, сизенгәләп торган,
фикер кырларында чәчкән, урган...

Рифмаларга тезәм сүзләрне мин,
шигырь фәнен яратучы өчен.
Күп сынаган инде безнең халык
публицистик поэманың көчен...

Сорыйм гаеп итмәвегезне мин,
җитсәм хөкем чыгаруга хәтле:
Пәрдә читен ачып, бераз гына
«ача» алсам... ачык хакыйкатьне...

Сюжет әзер: яңа гына мичтән
пешеп чыккан «Америка бәлеше».
Конфликт иске: кара көчләр
белән ак көчләрнең бәрелеше.

Вакыйгалар шундый үсеш алган,
күз алдында—кульминациясе!
Халыкара сүзләр белән әйтсәк,
чишелеше—террор акциясе...

Лирик-нәфис сүзләр куркып качар...
Лира, арфа—тынып торган ара.
Төссезләнә бара шулай пейзаж,
сурәтләрдә кала—Ак һәм Кара...

Мин бер адәмчекмен шул җирлектә,
караганда, АКШ күзлегеннән.
Язмыш күзлегеннән караганда—
шагыйрь булып киткән үзлегеннән...

Яшәп ятам Җирдә инде байтак,
хәерче дә түгел, шөкер,—бай да.
Байлык түгел, чынлык эзләдек без,
кайда соң ул чын Гаделлек, кайда?!

Сүздә генә йөргәнен дә беләм,
белә-белә күп нәрсәне, бөләм.
Дөньялыкның коры сүз базары
булуын аңлап, каһкаһәләп көләм.

Мин көлгәннән, үзгәрәме «тәртип»?—
сафсаталар тыңлап үтте гомер.
Үзәгемә үтте ялган кумир,
йөрәгемдә яна утлы күмер.

Хөсет, ялган, хәйлә, мәкер, гайбәт,
бозыклык вә битлек ярминкәсе—
Борынгы бик—«Дөнья базарының»
күргәзмәгә элгән «кәртинкәсе»...

Дәүләтләр дә, нәкъ бәндәләр кебек,
кукырая, гел үзләрен мактап.
Кыланышы кырга сыймагандай,
«айга сикерәләр», Айны таптап.

Узыналар, без ул—оҗмах, диеп,
әләм җилфердәтеп, битлек киеп.
Һәр мәмләкәт, имеш, һәр тарафтан
торсын аңа табынып, башын иеп.

Гел биетеп торсаң уч төбендә,
котыра башлый тәмам, ул Җен аза.
Киләчәге мәгълүм—имансызлар
үзенә үзе укыр бер җеназа...

Кемдер әйткән—оныткамын исемен—
истә фәкать шомлы сәер сүзе:
«Бик дәү демократик империя
җитәчәк, дип, үз башына үзе...»

## II

*«Кылынган явызлык өчен җәза бирү фәкать шул золымга бәрабәр булсын. Аллаһ гаделсезләрне сөйми. Үзләренә карата кылынган җәбер-золым өчен үч алучылар чамадан узып эш итәргә тиеш түгел.»*

«Коръән» китабы, «Шура» сүрәсе, 40 нчы аять.

Без әйтәбез, сез тыңлагыз
Америка «бәетен».
Хәрабәләр арасыннан
җыйды күпме мәетен.

Тарих ике мең дә бернең
тугызынчы аенда,
унберенче вә көнендә—
киртләп куйдым каенга:

Зур һәлакәт булып узды
бик дәү АКШ илендә...
Тетрәндерде яман хәбәр
моңсу «аккош» күлен дә.

Ә, дигәнче килеп җитте,
Иделне дә айкады.
Сөембикә манарасы
чал башкаен чайкады.

Салаларга, калаларга,
урман-кырга таралды.
Кеше фаҗигасен аңлап,
ак каеннар каралды.

Татар җирен генә түгел,
ил-дәүләтләрнең барын
урап чыкты шомлы хәбәр,
сискәндереп Җир шарын.

Кем сөенде, кем көенде...
Хәлне аңлаудан элек,
басып алды бар дөньяны
тоташ киеренкелек:

Инде хәзер нәрсә булыр,
сугыш чыкмасмы, диләр.
Сугышның беткәне дә юк,
гүя шуны белмиләр...

Бу хәлдән соң, имеш, Җирдә
зур көрәш дәвам итәр...
Кемгә—сугыш, кемгә—җиһад,
Ходай үзе хәл итәр...

Америка башлыклары
яман тузынган, диләр.
«Бу тик Ислам динендәге
затлар узынган», диләр...

**Изге Коръән сүрәләрен
бер ачып карасыннар—
Җинаять вә коткы чыкмас
мөселман арасыннан!**

**Кем кылса да бу афәтне,
хак мөселман түгелдер.
Нахактан тагын кемнәрнең
каны, яше түгелер?..**

**Эзлиләр гаеплеләрне
гел бер генә тирәдән:**

**Ислам дәүләтләре инде—
нәкъ үзләре теләгән...**

**Җәзасыз калырга тиеш
түгел, әлбәт, җинаять.
Тик гадел булырга тиеш
һәрбер җәза, ди Аять.**

**Җәза бирү—үч алуга
кирә микән, и, Китап?—
Бу сорауга да Җавабың
бардыр әле бәлки,—тап!?.**

## III

*«—Коткарыгыз!.. коткарыгыз... Ай, аллам,
батам ич! батам! коткарыгыз!...»*

Теодор Драйзер. «Америка фаҗигасе».[1]

**Кай заманнан бирле дәвам итә
мәгълүм «Америка фаҗигасе»?—
Сере аның ятмый артык тирән,
кирәк булса әгәр фаш итәсе.**

**Һиндаларның ачы күз яшеннән
шыткан мәллә аның фаҗигасе?
Демократик җәннәт иленең дә
баскынчылар кылган «баш догасын»...**

**Җирле халыкларның кан-каргышын
күмми «комлар», юмый яңгырлар да...
Поль Робсонның тамагыннан агылып,
кара сагыш Җиргә яңгыраган.**

**Канлы террор кылып почмак саен
поскан ку-клукс-клан өрәкләре.
Тигезлеккә сусап баш калкыткан
адәмнәрнең ярып йөрәкләрен.**

**Фаш ителде Америка «рухы»
Драйзерның кырыс романында.
Уелып калды шомлы фаҗигасе
буыннарның хәтере һәм аңында.**

**«Демократик империя» кошы
бу кыйтгада киереп канат җәйде.
Америка фаҗигасе—иске,
һәр вакыйга бер-берсенә бәйле.**

**Дога итеп, дастан итеп монда
укыйлар, ди «доллар мәҗмугасын».
Баш очында болыт куергандай,
куера Америка фаҗигасе.**

**Булса икән бер аныкы гына!
Тарала бу вирус бар дөньяга.
Җилгә ябышып күчә һәр тарафка,
мәгълүматлар болыты булып ява...**

---

[1]Теодор Драйзер—Америка язучысы, XX гасыр.

**Иммунитет житмәс—саклагыч көч,**
**ул ташкынга каршы торып кара!—**
**Сатыламы Дөнья базарында**
**бу афәткә каршы дару, чара?!.**

**Чаба гына дөнья машинасы,**
**әнә, СПИД-ометрга кара:**
**ничә чакрым узган инде Кешелек?**
**торган саен тизлек арта бара...**

**Доллар базарында сатыла дөнья,**
**сатыла телләр, милләт, мәдәният.**
**Печән базарында мөгри Сыер:**
**«Савылып бетәсең бит, адәмият!..»**

**...Сатылып бетәсең бит, Намус, Вөждан!!**
**Нәрсә калыр Дөнья базарына?!**
**Кемнәр килер дога кылыр өчен**
**үләксәлегеңә-мазарыңа?!.**

**Җир шарының сыймый гөмбәзенә,**
**иблис-кошмы киереп җәйде канат?**
**Америка фаҗигасе—иске,**
**Америка фаҗигасе—яңа...**

## IV

*«Таралабыз, кардәшләрем,*
*китеп барам ерак юлга.*
*Җиңел каен каегыма*
*юлдаш булыр көмеш елга...»*
*Шулай диде дә Һайават,*
*буйсынгандай язмышына,*
*йөзеп китте Көнбатышка,*
*карап кояш баешына.*
*Кичке шәфәкъ нурларында*
*янган офыкларга карап...*
*Туган җире ярларына*
*кул болгады, борылып, кабат:*
*«Хуш, бәхил бул, туган илкәй,*
*хуш, бәхил бул, бәйсез җилкәй,*
*китеп барам бик еракка,*
*мәңгелеккә—теге якка...»*

Генри Лонгфелло[1]. «Һайават турында Җыр»

**...Бу хәерле сәфәр түгел,—**
**төнгә каршы юлга чыгу...**
**Китеп бару—бетеп бару,**
**акрын-акрын юкка чыгу...**

**Бар да мәгълүм, кабат-кабат**
**«Америка ачасы» юк.**
**Демократик күзлек киеп,**
**пәрдә артына качасы юк!..**

**«Җилфер-җилфер җилләрдә лә,**
**хәлләр хәтәр илләрдә.**
**Күгәрченем, Өмми-кошым,**
**хәлең бармы гөрләргә?»—**

**Шулай җырлый җирле халык—**
**мескен абориген инде.**
**Тамыр-халык тәкъдиренең**
**баскан авыр йөге инен...**

**Таш-тәтиләр, муенсалар**
**биреп, аны алдаганнар**
**Комагайлар... Ил уллары**
**соңга калып аңлаганнар.**

[1]Генри Лонгфелло—Америка шагыйре, XIX гасыр.

**Чын ирекtә яшәп яткан
бу борынгы кабиләләр
«Һинда халкы» исемен алган—
хәзер тарихтан беләләр...**

**Көн иткәннәр үзләренчә,
саклап кайнар учакларын,
Уклар атып, киек аулап,
сөеп бала-ончакларын.**

**Яшәсә дә хезмәт сөеп,
дус-туганнар тату гына,
Коткармаган шул, бергәләп
«ил челемен» тарту гына...**

**Гореф-гадәт саклап кына,
алар имин гомер сөргән.
Әмма беркөн оҗмах-якка
чит-ят тулган «Иске җирдән»...**

**«Алтын-алтын» дип килгәннәр,
халкын кырып бетергәннәр.
Ил угланы Һайаватның
нәселенә төкергәннәр.**

**«Җилфер-җилфер җилләрем лә,
кулдан китте илләрем лә.
Күгәрченем, Өмми-кошым,
аңлый кеше телләрен лә...»**

## V

*«Әй, илләр! Әй, көннәр!
гомум сатылулар белән буылгансыз сез...*
______________
*сезне кумә иксез-чиксез
вөҗдансызлык, әй, көннәрем, әй, илләрем!..»*

Уолт Уитмен

**...«Күктерәргә» каршы әллә инде
бар кыйтгалар явыз ният корган?..
Кителгән, ди «Дөнья түгәрәге»,—
әйтерсең лә, гел дә бөтен торган...**

**Җимерсәләр рухны таран белән,
вакытыннан алда үлүең бар...
Җиһандагы фаҗигадән хәтта
яшь аралаш усал көлүең бар...**

**Күп терәтте күкне «сары шайтан»—
җиргә терәк табар вакыт җиткән.
Үз эчеңдә азса иблис-җеннәр,
эзләмәгез аны фәкать читтән...**

**Яшәешнең рухи Манарасын
таран белән көн-төн бәрдерделәр
тормыш кануннарын гел үзенчә
болгатучы каты бәгырьлеләр.**

**Кем ул анда изге бер кыйбласыз
яшәмәкче узып бар дөньядан,
байлык арты байлык кына куып?—
Җаны фәкыйрь килеш, рухы—надан.**

**Онытмыйлар тагын, дога кылып,
Алланы да бераз юмаларга.
Гәрчә «бизнес храмына» үткәч,
кагылгысыз берни юк аларга.**

**Үзе генә, имеш, «кагылгысыз»,
чебен тисә, чер-р итәргә тора.
Дөрес сүзгә җавап эзләми ул,
үч алырга шундук әмәл кора...**

**Мең кат сыналгандыр бу җиһанда:**
**бәхетен тудыралмый рухи бушлык.**
**Череп бетсә эчәк-эчтәлеген,**
**саклый алмый аны алтын тышлык.**

**Имансызлар тыныч яши белми,**
**иминлекне аңлый алар ялгыш.**
**Тынчу күлгә женннәр иялэшә,**
**«Тынлык океанында» сүнә балкыш.**

**Уйлый күрмәсеннәр: көнләшүдән,**
**этләшүдән, диеп, бу афәтне.**
**Монысы әле бер «чәчәге» генә,**
**дөнья талап җыйган мең рәхәтнең.**

**«Доллар динен» тотучылар белән**
**яшисем дә килми уртак Җирдә...**
**«Әссәламе-галәйкүм!» дип алар**
**әйткәне юк әле безгә бер дә...**

**Ягъни—«Иминлек телим, дип сезгә,**
**Йортыгызга һәм дә Илегезгә...»**
**...Бер Ходайның үзенә инде хәзер**
**ярдәм итәр вакыт килде безгә.**

**Кызыл сүзләр язмыйым... Язмадым да!**
**Кызык сүзләр әйтәм, кызып китеп.**
**Дәшми кала аламы соң Шагыйрь—**
**кайчан «дөнья түгәрәге» китек...**

## VI

*«... Американ, европалы, азиат һәм африкалы*
*кан дошманга әйләнсеннәр, коралласыннар!*
*хәтта йокларга ятсыннар тик корал белән!*
*бер-берсенә һич кенә дә ышанмасыннар!...»*

Уолт Уитмен

*«О, великий Аллах!*
*Ты с высот высоты*
*Видишь горе и страх...»*

Эдгар По[1]

**...Бер экият-мәзәк чыккан, диләр**
**бу арада шундый эчтәлектә:**
**(Язып куйдым әле көндәлеккә,**
**калсын диеп үземә истәлеккә.)**

**«Күктерәре» күккә очкан илгә**
**якут бае ярдәм итәм, дигән:**
**Янәсе дә, җире тулы алтын,**
**асыл ташлар таккан, кеш тун кигән...**

**Тик «Күктерәр-патша» каршы килгән:**
**«Рәхмәт инде, без бай үзебез дә,—**
**Ямау өсте ямау өстегездә,**
**алтын-алмаз калсын үзегезгә...»**

---

[1]Эдгар По - Америка шагыйре, XIX гасыр. *(Топоров тәрж.)*

Су төбеннән энҗе эзләсәләр,
тел төбеннән мәгънә табу фарыз...
...............................
«Үч алганчы, башта гыйбрәт ал», дип
әйтеп килгән фәлсәфәле гаруз...

Үч алырга анысы бик тиз хәзер,
көл итәргә була һәр кыйтганы.
Карап торып була Күктерәрдән
берәм-берәм барсын җир йотканын.

Үч аласы «душман»—бик еракта,
үч аласы «душман»—янәшәдә.
«халыкара террор» булгач, булсын—
катнашсыннар дәһшәт-тамашада!..

Бар җиһанга таралган ул дошман,
курка-курка, эзлә син аларны!
Тик онытма: бик четрекле халык—
Шәрык «әбүгалисиналары...»

...Үч аласы дошман бик әчкәре—
Әфган тауларына яшеренгән...
(Ничек түзә бу ил дистә еллар
сугып торган сугыш яшененнән?!.)

Халыкара сагыш иңгән Җирне
халыкара сугыш дәваларны?!
...Кәгазь торналарның каңгылдавы
ярып үтте зәңгәр һаваларны...

Хиросимасыннан ерак түгел,
әнә, күренеп тора Вьетнам халкы:
Тыныч кына булсын—көн итәрләр
сәүдә итеп, укып, дөге талкып...

Бакчы, куркып карый Күктерәргә
ерак Австралия көнгерәсе.
Бүксә-букчасына улын салып,
тагын күпме калган йөгерәсе?..

Үч алырга була һәр куыштан,
һәр түбәдән... корал бар ул барын—
Эйфель манарасын аударырлык,
җимертерлек Кытай диварларын...

Күрче!—Джунгли сыман серле—
тынган вулкан, димсең Африкасын?..
«Кемгә генә төзәп атарга соң?
«дошман» диеп мөһерләргә кайсын?!.»

Ә-ә-ә-нә, чәй яфрагы җыя-җыя,
биеп йөри кызы Һиндстанның...
Курку-шөбһә басты Күктерәрне:
кем—дошманы, кем соң—дусты аның?!.

Үч алырга була үзеңнән дә...
үч алырга була Күктән, Җирдән,
Үч кайтарып кына булса котылып
әләмеңә үрмәләгән чирдән...

Шик-шөбһәләр кимерә Күктерәрне,
дошман эзләү бара төрле яктан:

Берсе—кызыл, берсе—көрән япкан,
берсе тоташ киенгәндер актан...

...Балыкчыны, мәгълүм, балыкчылар
бик ерактан шәйләп, белеп ала:
«Карасаң да болай өстән генә,
Мәскәүе дә шактый биек кала...

Аңламассың аны акыл белән—
«сәер» Иван белән Петр илен...
Үзе бик бай, үзе никтер фәкыйрь,
ә бит куены тулы—петролиум...

Заманында, ай-һай, бик күп иде
чын дуслары һәм дә куштаннары:
«Ә» дигәнче, «җә» дип тора иде,
үтәр өчен бөтен кушканнарын...

Иксез-чиксез кызыл империя—
бер ягында—Кытай эстинәсе...
Бер ягында терәк—Каф таулары,
дәүләт дисәң, дәүләт!..—күз тимәсен...»

...Һәм—«күз» тиде!
Күктерәрдән очкан
күз уклары, сүз уклары тиде!
Тарихта бу—туп-ядрәсез генә
озак барган «салкын сугыш» иде...

Террор дисәң «Октябрьне», аннан
«халыкара үч» алынды бугай...
«Хөрлек сыны»—әлегә исән-аман,
интер-каза җибәрмәсә Ходай...

«Хөрлек баганасы» аумый әлегә,
чәчәк аткан АКШ абагасы...
Кызыл империя геройлары
үкси кочып «хурлык баганасын»...

Үч дигәнең яман, кара-каршы
ул дөрләтеп тора үчлек утын.
Сылтау барда, өстәргә дә мөмкин
үчлек учагына янә утын.

«Ата демократ» дип атап үзен,
таптап бөтен халыкларның сүзен,
каплап вак-вак милләтләрнең күзен,
«Сукыр Үгез» күрми үз мөгезен...

Халыкара мәйдан әзли Мөгез,
нинди төстән отыры котыра ул?..
...Рейтинг үсә, имеш... Чеп-чи ялган!
Күрәлмаган алдан—отыла ул...

Үз баласен алдан күреп торса,
афәтләргә алдан киртә корса,
үсәр иде абруй...
Зур бер халык
шуны да аңламыймы?!—
димәк, авыру...

Халыкара сагыш баскан Җирне
халыкара сугыш дәвалармы?!

**...Кәгазь торналарның каңгылдавы**
**ярып үтте зәңгәр һаваларны...**

**Җир тирәге—корал түгел—Сүздә,**
**иярүдә изге Мөхәммәдкә.**
**Бөтен терәк бүген—халыкара**
**ышанычта, Дуслык-Мәхәббәттә...**

## VII

*«Алтын—аурум—Д. И. Менделеев*
*таблицасында 79 нчы урында торган бу металлның*
*график символы—Аи, төсе—сары...»*
Мәктәп дәреслегеннән

*«Нур чәчтең дә миңа, сүндең,*
*Алтын мираж...»*
Эдгар По

**Алтын—«аурум»... «Авыр» дигән сүздән**
**яралган күк исеме аның хәтта...**
**Авыр металл... Авыруга сабыша,**
**күп уйласа бәндә аның хакта...**

**Сабыр төбе—сары алтын да бит,**
**сары алтын төбе сабыр микән?**
**Зиннәт, файда, табыш, риба колы**
**һәлакәттән сабак табыр микән?**

**...Биегәеп китте мәллә күкләр?..**
**котылдыммы доллар алласыннан?**
**«Сиңа тагын доллар!» диюче дә**
**табылыр укучылар арасыннан...**

**Әйе, мин доллардан ерак торам,**
**«алтын бозау» тирәсеннән качам.**
**Көн итәргә җитә миңа, шөкер,**
**эшләп тапкан хәләл сумым-акчам...**

**Көнем өчен генә түгел, денем**
**өчен дә ул хәләл—кан-тир хакым.**
**Галәмдәге йолдыз үлчәүләрен**
**басып китсә, харам җирдә алтын.**

**Ил котыла башлар сыман бүген**
**канлы, ертлач доллар тәэсиреннән.**
**Көләм аннан—җанын сатып бөлгән**
**доллар колы—доллар әсиреннән.**

**Иркенәеп китәр сыман сулыш,**
**пакьланыплар китәр—уртак һаваң.**
**Ничек җиңел булыр иде җанга,**
**шул иблистән азат булса гавам...**

**Шул бит аны баскан, сыткан, изгән,**
**Күктерәрдән булмый күккә ашып.**
**«Доллар» диеп теле ачылганнар**
**яшим, диеп йөргән була, шашып...**

**«Доллар динен» тотучылар белән**
**яшисем дә килми уртак Җирдә...**

**Шул вирус бит җимерә табигатьне,**
**шул юлыга җыен шакшы чиргә...**

**Ак кәгазьдә каләм кыштырдавын**
**басар микән акча кыштырдавы?..**
**Сандугачлы әрәмәләр моңын**
**күмәр микән әрсез базар шавы?..**

**Яшәү мөмкинме соң чын инсанга,**
**доллар почмагына көн-төн табынып?**
**Үләчәк ул гади Кешелекнең**
**гүзәл төшләр күргән чагын сагынып.**

**...Мескен адәмчек син, утырасың**
**бер «гөнаһсыз» шул долларны сүгеп.**
**Күпме нервы, күпме күз нурларын,**
**дәфтәреңә күпме кара түгеп...**

**Кем кулына эләгә бит доллар...**
**Шул-шул менә!—Ертлач ятьмәсенә**
**эләгүчән никтер, алтын корбан,**
**«очраклы хәл» диеп әйтмәсәнә!..**

**Ә ертлачның бирер кулы саран,**
**күрми дә ул җиһан җимереген.**
**Авызы майда—дәвам итә бирә**
**симез күркә ботын кимерүен.**

**Халыкара дуслык күперләрен**
**төзергә дә җитәр иде юкса—**
**шул алтынның «асылын» үзгәртерлек**
**бер «алхимик» икән Җирдә чыкса!..**

**Җыелышып фикердәшләр белән**
**Бөтендөнья Татар Үзәгенә,**
**Хат язмыйча булмас—адрес мәгълүм—**
**Бөтендөнья Сәүдә Үзәгенә...**

## VIII

**Борынгыдан килгән гадәт**
**Хәл белешү хат аша.**
**Хәзергеләр бу йоланы**
**Онытырга маташа.**

**Безнең халык—һәвәс халык**
**Такмак, җырга, бәеткә.**
**Кайбер сүзләр ошамаса,**
**Алмагызчы гаепкә.**

**Җырга салып хат җибәрәм,**
**Дәфтәр битем шакмаклы.**
**Арасына кушып барам**
**Башка килгән такмакны.**

**Бисмиллаһи—хат башы,**
**Мөмкин булса, яз каршы.**
**Әссәламе-галәйкүм дип**
**Башласак, булыр яхшы.**

**Сәлам сиңа, Америка**
**Ерак Татар иленнән!**

**Сәлам сезгә халкыбыздан,**
**Җәелеп аккан Иделдән.**

**Сәлам соңра сүзгә күчәм,**
**Ничек, диеп, хәлләрең,**
**Сорап тормыйм, беләм инде—**
**Бик борчылдык, җәлләдек.**

**Сезгә аңлашылыр микән**
**Безнең бу җыр-такмаклар?**
**Уйлый күрмә, Америка,**
**Болар, дип, чат ахмаклар...**

**И, Америка, Әмрикә,**
**Хәлләрең авыр икән.**
**Бу башыңа төшкән бәла**
**Бер Ходай әмере микән?..**

**Таңнар ата, сайрый былбыл,**
**Моңлы җырларын суза.**
**Артык кайгырмагыз инде,**
**Кайгы кемнән дә уза.**

Төннәр үтәр, таңнар атар,
Вакыт җитәр торырга.
Сез күнекмәгән шул әле
Сугыш белән террорга.

Без үзебез яратабыз
Барча халык, милләтне.
Безнең өчен кешеләрнең
Иманлысы кыйммәтле.

Телевизор безгә сезне
Көн дә күрсәтеп тора.
Сезнең җәфа чигүегез
Безнең эчләрне бора...

Тéлектан карап туймыйбыз
Әмерикә кинасын.
Көн тәртибенә куябыз
Әмерикә темасын.

Безне хәзер өйрәтәләр
Гел сезнеңчә яшәргә.
Америка—үрнәк ил дип
Картларга һәм яшьләргә.

Безнең яшьләр Әмрикәне
Аеруча ярата.
Чөнки үз карашлары юк
Чит-ятларга карата.

Саесканча йөрим, диеп
Үз йөрүен оныткан—
Шулар инде. Ә без бүтән,
Үзгә безнең орлык-кан.

Кич утырып хатлар яздым
Йөзле лампа кабызып.
Бик яратып чәйни халык
Америка сагызын...

Яңалык дип яна бәндә,
Тиз оныта искене.
Тавык ботын кимерәләр—
Американскийны.

Аны ашап бетергәчтен,
Пепси-кола эчәләр.
Аны эчеп бетергәчтен,
«Макдональдска» күчәләр.

Америкача биергә,
Җырларга өйрәнәләр.
Сезнеңчә айрылышалар,
Сезнеңчә өйләнәләр.

Минем җаныем мине ташлап
Китте Америкага.
Исемә төшсә, исем китә,
Дөп-дөп йөрәгем кага.

Америка уеннарын
Уйнап үсә балалар.
Сезнең телне өйрәнәм, дип
Ана телсез калалар.

Хәер, онытмый өлкәннәр
Рузвельт бабай ярдәмен.
«Ул җибәргән пичинҗәнең
Әле дә авызда тәме»,—

Дип сөйлиләр сугыш чорын
Күреп-белеп торганнар.
Сезгә дә ярдәм итәргә
Без әзербез, туганнар!..

Дөрес, күрмәгән сез черек
Бәрәңге кәлҗемәсен.
Болар көнләшә мәллә, дип
Уйлама, рәнҗемә син...

Террор дигән сүзнең дә без
Беләбез тәрҗемәсен.
Бу уртак бәла алдында
Утырмыйк мәлҗерәшеп.

Бездә дә ул эреле-ваклы
Террорчылар бер көтү.
Максатлары шул ук инде—
Куркыту да, өркетү.

Кашыңның каралары ла,
Йөрәкнең яралары.
Әллә ничә төрле була
Куркыту чаралары.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр чөгендер.
Иблис белән Сатананы
Әфсен укып, чигендер.

Кулымдагы балдагымның
Исемнәре кем икән?
Безнең илләр гасыр буе
Ник ярышты, ник икән?..

Бер заманны сезне почти
Куып җиткән идек без.
Кайбер өлкәләрдә хәтта
Узып киткән идек без.

Партиянең ал байрагын
Кем очырды җилләргә?
Хәзер инде ул чакларны
Калды сагынып сөйләргә.

Искене җимереп аттык,
Яңа тормыш корабыз.
Үз юлыбыз белән алга
Барырбыз дип торабыз.

Алтын алка—колакта,
Алтын балдак—бармакта.
Без акыллы балык хәзер,
Эләкмәбез кармакка.

Хатны яздым утырып,
Ак кәгазьне тотырып.
Инде хәзер белеп булмый,
Укырсызмы утырып?..

Барып җитеп, кулыгызга
Керсә ошбу хатыбыз,
Тышына ук язып куям:
«Курыкмыйча ачыгыз!..»

Әнә килә ак парахут,
Төягән ак парашук.
Сездә дә «шок», бездә дә «шок»,
Тик торабыз карашып...

Сездә дә бар ул байлар,
Бездә дә бар ул байлар.
Гади халык хәлен белми
Буш йөрәкле бушбайлар.

USA—АКШ дип язылган
Самалют канатына.
Теләктәшлек белдермибез
Террор аппаратына!

Ал чәчәкле илебез лә,
Гөл чәчәкле илебез.
Террор сугышы беткәчтен,
Кунак булып килегез!

Безнең башкалабыз—Казан,
Белмәсәгез, белегез.
Мең еллыгын каршыларга
Җыенып йөргән көнебез.

Барча халыкларыгызга
Татарстаннан күп сәлам.
Бетте-китте вәссәлам,
Хатны язды Әпсәләм...

## IX

*«Невидимо летит в потоках света*
*Под скудным солнцем скудная планета,*
*Божественный презревшая закон,—*
*За что сей мир в пучину погружен*
*Отчаянья, мучения, позора,*
*Изведал ужас пламени и мора...»*

Эдгар По, «Аль-Аараф»

Территорияләр, илләр буйлап
террор өрәгеме анда йөри?—
Яңа «бүки» уйлап тапты заман,
кабатлана тарих гүя юри...

Элеп куйсаң җиһан харитасын,
Җир үлчәве сыман—Ярымшарлар...
Тигезлегеп җуя «тәлинкәләр»,
җәһәннәмгә Дөнья авыша бара.

Өреп туктадылар әле генә
«шомлы коммунизм» өрәгенә.
Инде хәзер «Ислам терроры» дип
дәү Үрмәкүч тозак үрә генә...

Әнә, очып йөри баш очында
бер Кош серле—күрмисезме әллә?!
Иман кошы—шомлы өрәк түгел,
һәрбер иңгә кунсын төшеп, әйдә...

Иңләп-буйлап бар кыйтгалар күген,
һәр тарафка Ислам нуры агыла...
Байрак итеп тәре йөртүчеләр
кытыклана шуңа, күзе чагыла.

Яшәргә шул алар теләми бик
Ислам дине кануннары белән:
ничек тигезләмәк Хезмәт халкын
капиталның каруннары белән?..

...Террор, дәһшәт тетрәндерсә бүген
йолдызланган буй-буй әләм күген,—
Егерме беренче гасыр белән
шаярулар, димәк, хәләл түгел...

Гыйбрәт өчен Егерменченең дә
белү кирәк көчле-йомшак ягын:
Нидән яралганын «Октябрьнең»
һәм кемнәрнең аны ошатмавын...

Владимир бине Илья белән
уйлавымча, сез таныштыр бераз:
«Теге» Ленин инде... Халык дусты,
белмәүчеләр исемен булыр бик аз...

Яши торгач, күрдек—ул да кеше—
кай тирәдә ничек ялгышканын.
Иблис тозагына эләккән шул,
кирегә ага башлап, ялгыш, каны...

Буташтырган Галәм кануннарын,
күңеле изгелектә иде гәрчә...
Фаш итсә дә черек патша тәхетен,
баш итмәгән динне—менә нәрсә!..

Берәүләргә ул юлбашчы булса,
берәүләргә ул юлбасар иде...
Террор белән революциягә
анализны ул тиз ясар иде...

Террор бит ул үзе иске нәрсә,
Ләкин
һәрбер заман аны яңарта...
Ник кешеләр тапмый бер чарасын
шушы вәхшилеккә карата?!

«Тышкы» террор белән «эчке» террор
үзара бик үрелгән ул тыгыз.
Качалмабыз барыбер бер-беребездән,
уртак—Кояш, уртак—Җир-Йортыбыз.

Төп сорауны кую мөһим түгел
«Кемнәр алар, диеп террорчылар?»—
Төп сорауны кую мөһим бүген
«Нәрсәдән ул, диеп, террор чыга?!»

Кысуларның, коткы, мыскылларның
мең дә бердән ашкан ысулларын
Татыганнар белә—җилкәсендә
уйнаганын нинди мускулларның...

Террор бара дингә, телгә каршы,
террор бара мөстәкыйльгә каршы.
Куркып торсын бар да—кем дә кем ул
баш күтәрә «патша илгә» каршы...

Кешеләрдән машиналар ясап,
машинадан кабат «кеше» ясап,
Тилертәләр мескен адәм затын,
өстәвенә, салып «милли ясак»...

Бәйрәм итә Җирдә байтак инде
байгуралар «демократиясе».

Гади халык түзә—нихәл итсен,
юк әлегә, димәк, партиясе...

Кычкырасым килә бар дөньяга,
«андый партия ул бар!»—диясем...
Нигез ташы итеп уставының
игълан итәм ИМАН хартиясен:..

Ирек, Мәхәббәт ул, Акыл, Намус—
булмас артык мең кабатласам да.
Шушы мәгънә ятсын калебеңә,
мең доганы тоташ ятласаң да...

Иксез-чиксез космос-Галәм аша
Мәңгелек нур Җиргә якынлаша.
Аллаһ кануны ул—изге бүләк,
Низам-тәртип төбе—шул лабаса...

## X

Уйларымны тотып өлгерәлмыйм,
сүзгә әйләндереп бетерәлмыйм.
Күрдегезме, «теге» вакыйганы?!—
өермә күк ничек бөтереп алды...

Әкиятләр уйлап чыгарырга
кирәктер ул, бәлки, үлмәс өчен,
Шаһрезадә сыман...
Үз-үзеңне
коткарырга—шайтан көлмәс өчен...

Әкиятләр үтте инде баштан,
чынбарлыклар әкияттән дә ашкан.
...Ничек юатырга юашларны,
ун әрсезе каныга бер юашка...

Ун козгыны чукыр бер бәбкәне,
ун төлкесе буар бер аккошны.
Ун патшасы торыр ун дәүләтнең
авызына карап бер АКШның...

Бәндәләр дә нәкъ дәүләтләр кебек,
белем, намус белән генә түгел—
Ертлач булган саен, чыгар алга,
күләгәдә калыр садә күңел.

Умыручы була «умырткасыз»,
кая инде аңа идеаллар!
«Кем төкерә ала ераккарак?»—
шулай ярыша күптән инде алар...

Нәрсә генә калды икән анда—
сатылмыйча бизнес базарында,
Киек казларына кадәр—күктә,
бакасына кадәр—сазларында.

Бәхәсләшмә америкән белән,
чүптән дә ул табыш ясый белә.
Казынмый ул күңел коесында,
файда коесын тапса, канәгать көлә.

**Китап урынына—бокс, хоккей,**
**ун сүз урынына—бер сүз: «О,кей!»..**
**(Бездә киң таралган «нормально»га**
**туры килеп тора бу сүз шактый...)**

**Аяз күкне камикадзе айкый,**
**американ куркып, башын чайкый.**
**Һавалардан террор исе аңкый—**
**нормаль түгел бу хәл, түгел «О,кей!»..**

**Агуланса каның эфьюн белән,**
**тазартырга нинди әфсен белән?**
**Дөнья белән түгел—идарә ит**
**иң әүвәле туймас нәфесең белән...**

**Колак салдыңмы бер, Америка?!—**
**бөек шагыйрьләрең кисәткәннәр**
**кайтачагын бумеранг булып**
**комсыз денсезлекнең—кичә әйткәннәр...**

## XI

*«Атыш-кырыш, орыш, кан коештан*
*Ләззәт таба адәм нилектән,*
*Табигатьнең гармониясен ул*
*Җимерергә мәллә күнеккән?*

*Җитте! Туктат сугыш музыкасын,*
*Бир тынгылык, оял Күгеңнән!*
*Мәхәббәтнең изге җыры фәкать*
*Яңгырасын җирдә бүгеннән...»*

Генри Лонгфелло

**...Куркытырга тагын чыкты бүки,**
**юатырга Җирне кирәк бер Көй—**
**Тирбәтерлек булсын иде бу көй**
**Кешелекне—яңа Моң-Бәллүки...**

**Җыелдылар милләт аналары**
**күк гөмбәзле бик дәү биек Өйгә:**
**Яңартырга Идел-Ил йоласын,**
**Бишек җырын—Идеологиясен...**

**Кемнәр икән талбишеген үргән?—**
**Ил атасы булыр—дөнья күргән.**
**Вата күрмә бәллүр Бәллүкине—**
**ак биләүгә төргән милли Көйне...**

**Тик...**
**Шигырь әнкәләре ник юк монда?!**
**Кемнәр кул селтәгән шигъри моңга?**
**Кемнәр күрми калган баламны?—**
**Күргәне бар мәллә Алланы?!.**

**Шагыйрьнең иҗат бишегеннән**
**сикреп төшкән һәрбер шигырь—бала.**
**Йөрәкләргә юшкын булып каткан**
**курку хисен нәрсә җиңә ала?!**

**Хәрабәләр арасында йөргән**
**үксез мәхәббәтне кем коткарыр?**

Моң, Музыка, Шигырь аналарын
танымаган—мең бәлагә тарыр...

Тирә-юньдә бөтен нәрсә көйли:
һава, аһәң, мелодия, аваз,
ритм, рифма, ташлар, гөрләвекләр,
алсу гөлләр көйли, шаулы агач...

Чиртелмәсә, тирбәлмәсә кыллар,
арфа нервын кузгатмаса куллар,—
Ишетә белмәүчеләр җил көйләрен
музыкасыз калдык, диеп уйлар...

Бал кортлары баллы чәчәк эзли,
шуңа алар татлы итеп безли...
Йолдызлардан тып-тын тамчы тама,
Галәм көе—колак салчы аңа...

Һәм һәммәсе тоташ музыкага
әүрелә дә, кабат күккә аша.
Мәңгелек Моң—Күңел-Маңлай хисен
аңламыйча, Кеше кая ашыга?..

Мәңгелек Моң, әнә, күлгә кергән,
камыш көпшәсенә тынын өргән,
көй чыгарып... Бөек Рәссам аны
сурәт итеп Җир иңенә элгән...

Тыңлап торсаң өнен Табигатьнең,
бертуктаусыз гүзәл симфония
агылып тора Җирдән, Күктән, Судан—
бер Аллаһның моңлы сулышы гүя...

Таң атканда, былбыл сагышына
кушыла дәртле әтәч тавышы да...
Көтүченең көтү какканы
ачып керә һәрбер капканы...

Ул авазлар минем балачактан
мәңгелек моң булып агыла һаман.
Яңгыр шыбырдавы, карның шыгырдавы—
үзгәрталмый аны «яңа» заман...

Шул авазлар гына җиңәр—җанга
оялаган кыргый курку хисен.
Бөек юатучы—ул моң-шигырь,
гакыл үзе таный аның көчен...

МоңСаралар, фәйләСуфиялар...
шул авазлар аша көй җыялар...
Ул моңнарның кайтавазын җирдә
тыя алмый биек таш кыялар.

Ул авазлар кисәтәләр Җирне:
«Кала күрмә җырсыз, моңсыз, көйсез!»
Кала күрмә берүк Ай-түбәсез,
гармониясез һәм Илсез-Өйсез...

Ул авазлар кисәтәләр: Җирдә
сатылмыйча калса тик бер «тауар»—
Кеше намусы—фәкать шунда гына
Аллаһыдан безгә рәхмәт явар...

## XII

Иман нуры... Киек Каз юлыдай,
һәр күңелгә иңәр яктысы...
Тигезләнер дөнья... һич югында
Иман белән тулса яртысы...

Иман нуры—Бәхет нуры сыман,
һәр кешегә су күк кирәк ул.
Гомер узган саен ачыла бара
бәхет төшенчәсе киңрәк ул...

Берләштерсә шул нур адәмнәрне,
һәммәсенең саклап үз төсен,
Болындагы һәрбер чәчәк-гөл күк,
аңкып торыр аерым хуш исе...

Барча милләт үсәр, тамыр җәяр,
орлык биргәнгәчә өлгерер.
Кеше өчен күптән ясап куйган
даһи Рәссам рухи өлгене...

Юк, җыенмыйк әле өмет өзеп
яшәү бәхетеннән бизәргә.
Динне тормыш белән җанландырып,
тормышны Дин белән бизәргә

Ашкынмыйк без, сөю серен саклап,
онытмыйча Аллаһ вәгъдәсен.
Җир астына төшеп ятканда да
яшәвеңнең җуйма мәгънәсен...

Территорияләр, илләр буйлап
агыла бер нур—Иман нуры ул.
Җиһандагы һәр адәмнең җанына
кагылып үтә турыдан-туры ул...

Тормыш бакчасына язлар кайткан,
өмет бөреләре тулышкан.
Яз һавасын сулыйк Аллаһ белән,
күкләр белән гел бер сулыштан,—
Бик бәхетле буласыбыз килсә,
чын бәхетле—туа-тумыштан...

*2001 ел, сентябрь-ноябрь.*

Рауль Мирхәйдәров

# ҺӘРНӘРСӘГӘ—АКЧАЛАТА

РОМАН

«Граверлар» аулаучы

## I

Карлен Татлян әкренләп Мәскәүне аерым бер ярату белән ярата башлады. Россия башкаласын шулай сөя башлавының сәбәбе бик гади иде—Лондондагы «Лейнсборо» отелендә үтерелгән чечен егетләренен саквояжындагы акчалар америка журналистының, бер унайдан ЦРУның Норман кушаматлы агентының дип тә өстик, тормышын кискен генә үзгәртте дә куйды.

Ниһаять, Карлен Мәскәүдә бер кыз белән дә ныклап танышты. Билгеле, төрле премьераларда, презентацияләрдә һәм яшьләр жыела торган башка урыннарда (аларны хәзер «тусовка» дип кенә йөртәләр) даими булып торгач, чибәр хатын-кызлар элек тә ана игътибар итми калмый иде. Кайбер кызлар исә аңа башка сәбәпләр белән дә сылана: «чит ил кешесе, американ, житди газетта эшли, димәк, бай кеше, өйләнеп, хыялындагы Америкага да алып китәргә мөмкин. Ләкин Карлен андыйларны бик тиз танып ала һәм үзеннән биздерә белә иде. Аннары, монарчы ул, финанс ягы такыр булганлыктан да, сөяркә-пассияләр эзләп йөрмәде—Мәскәүдә тормыш бик кыйммәт: икәүләп берәр жиргә барып утырырга йә йөреп кайтырга уйласан—берничә йөз долларын очты диган сүз. Ә хәзер алай кысынкы яшәү мәжбүрилеге юк һәм ул гөрләп торган плейбой ир-егетләрчә яши ала. Шулай итеп, вакыты да, акча ягы да Татлянның житәрлек иде хәзер, урыс башкаласының мәдәни тормышы аңа хезмәт итәргә генә тора—аны һәркайда теләп кабул итәләр, ул һәр жиргә чакырулы, хәтта кайсысына барырга, кайсысыннан баш тартырга дип сайланырга да була.

Ул әкренләп «Золотой петушок» ресторанына иялəште. Анда аны тәүге мәртәбә Абрек белән Крис алып килгән булгач, димәк, үз кешегә әверелде. Әгәр дә аның өстәле янына килеп утырмаса да, Карлен үзенен

---

Дәвамы. Башы 7-8 саннарда

яна танышы Оля белән яки ялгызы гына булганда да, Хавтан үтеп барышлый гына ана сәлам биреп китә: берәр ягымлы сүз кыстыра яки ара-тирә берәр шешә яхшы шампан шәрабе дә җибәртә—мондый хөрмәткә һәр кереп йөрүче дә лаек була алмый. Аннары Карлен әкренләп кенә официантларны да үзенә иярләштерә башлады, әле мул гына «чәйлек» төртә, әле, зур булмаса да, зәвыклырак сайланган берәр бүләк бирә—киләчәктә бу «баш өсте, әфәндем!» дип торучы ялагайларның һәрвакыт кирәге чыгарга мөмкин. Разведчиклар мәктәбендә аны юкка гына: официант—мәгълүматлар алу өчен иң яхшы чыганак, дип өйрәтмәделәр. Кыскасы, «Золотой петушок» Карлен Татлян өчен бар яклап күңелле дә, кирәкле дә урын булып чыкты, бер уйлаганда, ул анда кәеф-сафа корып утыра, шул ук вакытта үз эше белән дә мәшгуль—бик сирәк тәңгәллек бу. Карлен очрашып йөри торган кыз, Оля Харитонова, Мәскәү дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлап йөри, күршедә генә, шул ук Ямской кыры урамында яши иде. Оля әллә инде егерменче буын нәселдән бирле килгән бик борынгы мәскәүле гаиләдән бер профессор кызы иде. Үзгәртеп кору дигән афәт нәкъ менә шушы катлам кешеләрнең һәм социаль, һәм матди хәлен кискен үзгәртте дә куйды—алар яңа тормышның читендә торып калды. Профессор Харитоновны реформаларның беренче елында ук, юк кына пенсия билгеләп, «лаеклы ялга» озаттылар, үзенең беркемгә дә кирәге калмаганлыгын аңлагач, ул моны бик авыр кичерде.

Оля, Карлен кебек үк, театр яратучы булып чыкты, икесе бергә караган һәр спектакльне, концертны, балетны ул шатланып кабул итә иде. Тумыштан Мәскәү кызы булган Оляга башкаланың әйтеп-сөйләп бетермәслек гаҗәеп кечке-төнге тормышын да Карлен ачып бирде. Әтисе шикелле үк, бөтен дөньяның асты өскә килде, барысы да җимерелде, дип уйлап йөргән кыз андый тормыш та бардыр дип башына да китерми иде, баксаң, янәшәдә генә тулы канлы, кызык тормыш кайнап-гөрләп тора икән. Карленны ни өчен нәкъ менә шушы ресторан үзенә тартып торганын аңлап бетермәсә дә,—юкса Мәскәүдә моннан да күңеллерәк урыннар да бар,—Оляга «Золотой петушок»та бик ошый иде. Карлен аны «Золотой петушок»ка чакырганда, ул һич каршы килми, егетнең, өстәлгә нинди генә ризык китереп куйсалар да, тәмләп ашаганын карап утыра, ә Карлен Россиядә сый-нигъмәтне Петровичтан та оста әзерләүче юктыр, дип ышандырмакчы була.

Хәзер инде, кирәк булганда, үзенең «Золотой петушок»ка еш йөрүен Карлен рус ризык-ашларын яратуы белән дә аңлата ала иде. Бирегә ашарга даими килеп йөрүчеләр шактый күп, ресторанның «үз кешеләре» булып беткән бу катлам күптәннән оешкан, кемнәрдер көндезге ашны ашарга да һәр көнне диярлек шунда бара, кемнәрдер исә кич кенә килеп керә—концерт программаларын һәм музыкантларны Хавтан меню белән эчемлекләр ассортиментына караганда да ешрак алыштырып тора иде.

Менә шундый кичләрнең берсендә, Карлен Хавтанда Оля белән ашап-эчеп утырганда, «Трефовый туз» казиносына беренче барып кергәч танып калган Картьены күреп алды. Картье да ялгызы гына килмәгән, яртысы кызлардан торган кечкенәрәк бер төркем белән иде. Аның тирәсендә метрдотель һәм официантлар йөгерешеп йөри башлагач, Карлен монда да Картьеның очраклы кеше генә түгеллеген аңлап алды. Ә аның турындагы мәгълүматларны Карленга үзәктән дүрт айдан соң гына җибәрделәр, аның оешмасы өчен артык озак вакыт иде бу, әмма, күрәсең, очрагы шундый мөһим-әһәмиятле булгандыр. Вячеслав Михайлович Неделин ике ел Ерак Көнчыгышта десант гаскәрләрендә хезмәт иткән икән, ә соңрак, икенче елында аны махсус бурычлар үтәргә тиешле гаскәрләргә күчергәннәр, анда исә теләсә кемне алмыйлар, бик сайлап, җиде кат иләктән үткәреп кенә алалар. Анда Неделин диверсион һәм диверсияләргә каршы тору мәктәбен үткән, чит телләр өйрәнгән, радиотапшыруларны тотып алу һәм эфирда эшләү серләренә төшенгән,

аннан тыш та байтак кына яшерен фәннәрне үзләштергән. Үзе Мәскәүдәге зыялы бер гаиләдән икән. Үзгәртеп кору елларында унышлы гына итеп бизнес белән шөгыльләнә башлаган, үз эшен оештырган: Россиядә күпләп туа башлаган банклар, бигрәк тә Мәскәү банклары өчен зур-зур партия компьютерлар һәм оргтехника сатудан башлап җибәргән. Билгеле бер инглиз фирмасы белән хезмәттәшлек иткән, түлиселәрен вакытында түләп барган, ул фирма белән әле хәзер дә элемтә тота. Көнбатышта сирәк була, нигездә Лондонда гына. Җинаятьчел элемтәләре турында—ләм-мим! Бер сүз дә юк.

Мәгълүматның ахырында Карленнан Картье Неделинның КГБ белән бәйләнеше юкмы икәнлеген ачыклауны сораганнар, аның эзләре бигрәк тә ярылып, ачык булып өстә ята, һич тотынырлык урыны юк, әмма артык исрафчыл булып акча туздыруы шикләндерә дә, дигәннәр.

Карлен үзәккә җавабында соңгы вакытларда Картье турында кайбер нәрсәләрне ачыклавын әйтеп язды. Үзе тикшергән һәм әле тикшерелмәгән белешмәләргә караганда, Неделин «яңа руслар» төркеменә керә, җинаятьчел дөнья белән дә тыгыз бәйләнештә, хәер, әлегә суд җаваплылыгына тартылганы, хөкем ителгәне юк. Үзенең әлеге нәтиҗәсен раслау өчен Карлен үзәккә Картьеның «Пекин» ресторанында икенче мәртәбә төшереп алынган фоторәсемен җибәрде, аның янәшәсендә Мәскәүнең җинаятьчел «генералитеты»—Шаман, Дантес һәм әлегә шәхесен ачыклап булмаган ниндидер чандыр гәүдәле бер әфәнде утыра, анысы купшы-көяз твид тройка костюмнан икәнлеген дә әйтергә онытмады. Ә менә Неделинның ялган долларлар ясауга яки аларны таратуга мөнәсәбәте булу бик мөмкин, Карлен бу вариантны ныклап өйрәнәчәк әле. Үз чиратында Норман үзәктәге коллегаларыннан, Картье-Неделин Көнбатышта булганда, аның һәр адымын микроскоп астына алгандай күзәтергә, бигрәк тә кайда гына, нәрсә генә сатып алмасын, ул биргән долларларга җентекле тикшерү үткәрергә, ул сатып алган югары сыйфатлы төсле ксерокcларны һәм башка катлаулы аппаратураларны махсус исәпкә алырга кирәк, дип үтенде. Чөнки андый аппаратуралар яшерен акча сугу урыннарында файдаланылырга бик мөмкиннәр.

Отчетының азагында Карлен, инде Мәскәү тормышына күнеккән кеше буларак, Россиядәге җинаятьчел дөнья, бигрәк тә аның житәкче даирәләре, фикерләү үзәге, башка илләрдәгеләрдән аермалы буларак, үзенә генә хас сыйфатларга ия: алар тулысы белән югары белемлезыялы, имин-мул тормышлы һәм хәтта элита саналган гаиләләрдән чыккан, армиядә махсус өйрәнүләр-күнегүләр үткән яки спортчылар арасында танылган шәхесләр икәнлеген раслап язды.

Россиядәге бу яңа җинаятьчел дөнья, Норман фикеренчә, ашыгыч һәм житди фәнни тикшерүне-өйрәнүне сорый, чөнки җинаятьчел элементлар турында моңа кадәр ЦРУда булган катып калган стереотиплар руслар мәсьәләсендә житди хаталарга китерергә мөмкин. Шунысы сәер, үзәккә Картье турында шундый тулы мәгълүмат бирсә дә, Норман Лондондагы «Лейнсборо» отелендәге үтерүләрне яшереп калдырган шикелле, Неделинның өй телефонын тыңларга берничә мәртәбә махсус аппаратура куйса да, бернәрсә дә барып чыкмаганын хәбәр итмәде. Картье-Неделин өеннән бик сирәк чылтырата, гомумән, Кутузов проспектындагы квартирасында аз була. Хәзер, үзәктән Картье турында шундый тулы мәгълүмат алгач, ул Неделинның алдан саклану чаралары күрүен аның махсус бурычлар үтәргә әзерли торган гаскәрләрдә өйрәнүе белән бәйле икәнен аңлады, әгәр дә Картье-Неделин радиотапшыруларны тотып алырга, эфирда эшләргә өйрәнгән икән, аның, әлбәттә, башка ышанычлырак элемтә чыганаклары да бар, димәк. «Россия бандитлары да хәзер гади генә түгел икән, аларга хәтта ЦРУ агентларының да теше үтми»,—дип үз-үзенә елмаеп куйды Карлен Татлян.

## 2

Шулай итеп, Карлен белән Ольга залның сул ягындагы калын мәрмәр багана артында утыра, аларны ишек ягыннан да, Неделиннар утырышкан урыннан да күрерлек түгел иде. Карлен: «Бу кичтә өстенлек минем якта»,—дип уйлап алды. Картье да «Золотой петушок»та булгалый, әмма, биредәге аш-суларның тәмлелеге хакында, билгеле, ишеткәне булса да, сирәк—анда-санда бер генә кергәләп чыга иде. Неделинны Хавтан белән Дантес таныштырды, Картьеның Лондонга китәргә җыенып йөргән көннәренең берсендә, алар өчәүләп «Метрополь»дә әбәт ашап утырганда булган иде бу хәл. Кунакханәдән алар икәүләп китеп барган иде. Хавтанның «Золотой петушок»ны тәртипкә китереп, җиһазлап-ремонтлап йөргән чагы булгач, ул Неделиннан үз бухгалтериясе өчен ышанычлырак берәр компьютер алып кайтуын үтенде. Хавтан ул көнне машинасыз гына булганга күрә, Картье аны ресторанына илтеп куйды. Машинада тегесен-монысын сөйләшеп бара торгач, зиһенле Хавтан Неделинның техника белгече икәнен аңлап алды һәм, ыкы-мыкы килмичә генә, туп-туры сорады:

—Ә син миңа берәр телевизорны шундый итеп көйләп бирмәссеңме икән: аның аша, үз кабинетымнан чыкмый гына, залны да күзәтеп торырлык булсын, ә кайбер өстәлләрне тыңлап-ишетеп торырлык та булсын иде. Безнең тормыш куркыныч бит, кемнең синең хакта ни-нәрсә сөйләгәнен белеп тору комачауламас иде, ә?

Бу фикер Неделинның күңеленә дә хуш килде: Хавтанга шундый система ясап бирсә, ресторандагы хәлләрне ул үзе дә белеп тора ала, моны хуҗаның үзенә әйтеп маташмыйча һәм рөхсәт сорап тормыйча гына да эшләп була ич! Ике арага тагын бер компьютер куясың да, ресторандагы сөйләшүләрне һәм күренешләрне шуның дисплеена күчереп бара торган өстәмә тапшыргыч җайланма гына ясыйсың.

Алар, бу эшне озын-озакка сузып тормыйча, Хавтанның кабинетын һәм залны карап чыктылар, ресторан директорының уйлаганын гамәлгә ашыру җиңел генә эшләнә иде. Неделин бу хикмәтне әмәлләп бирү өчен кирәк булачак саллы гына сумманы әйтте дә, Англиядән аппаратураны алып кайткач, беркемгә дә белдермичә генә, өч-дүрт төндә үзе көйләп бирергә дә булды. Шулай килешеп, кулга-кул сугышып алдылар...

Шуңа күрә, «Золотой петушок»та үткәргән әлеге кичтә, Картье иптәшләренә ашау-эчү ягын кайгыртуны карый торырга кушып, үзе Хавтан бүлмәсенә кереп китте, хуҗа белән килешү буенча ул анда рөхсәтсез-нисез кереп йөри ала иде, керде дә утыз ике дюймлы гап-гади япон телевизоры «Сони»ны кабызып та куйды. Аннары, ерактан идарә итү пультының Хавтан белән үзе генә белгән кнопкаларына баскалап, экранга ресторан залы күренешен китереп чыгарды. Экрандагы сурәтләрне пульт ярдәмендә бер өстәлдән икенчесенә җиңел генә күчереп була һәм, үзеңне кызыксындырган өстәл очраса, шунда тукталып та калдырасың. Картьеның иң әүвәл залны карап алуы саклык йөзеннән эшләнде: ресторанда ул бүген очратырга теләмәгән «авторитетлар» да булырга мөмкин иде. Әгәр дә алар Хавтанда кәеф-сафа корып утырсалар, Картье үз төркеме белән башка берәр ресторанга да китеп бара ала бит. Әмма кунаклар шау-гөр килеп кәефләнеп утырган матур залда аның өчен куркыныч кешеләр күренмәде, шулай да Картьены «кавказ милләтеннән булган» бер зат сагаерга мәҗбүр итте. Игътибар беләнрәк карагач, Картье «Пекин» ресторанында үткәрелгән туган көн мәҗлесендә үзен фотога төшереп алган егетне таныды. Әйе, бу нәкъ шул үзе, Мәскәүдә «Лос-Анджелес таймс» газеты хәбәрчесе булып саналучы ЦРУ агенты Карлен Татлян иде. Бу хакта Неделинга аны КГБ белән яшерен хезмәттәшлеккә кодалаган Виктор Королев сөйләгән иде инде.

«Димәк, бу кош та Хавтанның «Золотой петушок» ресторанына сукмак салган икән»,—дип күңелле генә уйлап алды Неделин. Виктор

Степановичның Лубянкада алтынчы катта эшләп утыручы коллегалары әйткән фараз раслана: Мәскәүдә инде елдан артык яшәүче Карлен Татлян даими рәвештә башкаланың җинаятьчел элементларын эзли һәм алар белән бәйләнешкә керергә тырыша. Күрәсең, аның максаты Россиядәге җинаятьчелекнең шундый зур тизлек белән үсә-күтәрелә баруын җентекләп өйрәнү һәм шулар ярдәме белән, билгеле бер вакытта, көтмәгәндә генә илдәге вәзгыятьне тотрыксызландыру мөмкинлеген чамалап караудыр. Әллә соң американнар җинаятьчел братваның миллиардлары дөнья буйлап таралып бетмәсен, бары тик АКШка гына аксын дигән бурыч куеп, шуны аулауларымы икән? Безнең аналитиклар хаклы булып чыга: Татлян бик җитди рәвештә бандитлар белән кызыксына. «Золотой петушок»— башкалада братваның иң яраткан урыннарыннан берсе бит. Кыскасы, Хавтанның рестораны Америка шпионына үз алдына куйган бурычны үтәр өчен иң унайлы урын булып чыга. Әгәр дә, әлбәттә, ЦРУдагы хуҗалары ана шундый максат куйган булсалар.

Бүген Карлен Татлян гадәттәге арзанлы пинҗәген киеп түгел, ә көяз-купшы кыйммәтле костюмнан килгән иде, кулында да саллы гына алтын сәгате ялтырап китте. Картье шундук уйлап алды: мондый үзгәреш нәрсә белән булса да бәйләнгән булырга тиеш, каяндыр американга акчалар килеп кергән. Журналист янында утырган чибәр кыз да төнге клуб һәм рестораннарда «яна руслар» белән еш типтерүче тәтәйләргә охшамаган, йөзендә зыялылык, ягымлылык, нәзакәтлелек чагыла. Неделин хәтта бер мизгелгә генә американга көнләшеп карап куйды.

Бу кичне «Золотой петушок»та үткәрергә дигән тәкъдимне дусларына көтмәгәндә генә Неделин үзе ясады, аның якын киләчәктәге уй-ниятләрен беркем дә белми иде, хәер, андый уйлары юк та иде шикелле. Димәк, бу американ Хавтан ресторанына аны эзләп килмәгән, юллары очраклы гына кисешкән, чөнки аларның уртак мәнфәгатьләре дә аз түгел икән ич. Аннары, журналист үзе дә бирегә бүген анык бер максат белән килмәгәндер: җинаятьчел дөнья, аларның максатлары, алдагы перспективалары, финанс мөмкинлекләре турында тулырак һәм дөрес мәгълүмат җыю—озакка сузыла торган, четерекле эш. Моның өчен «Золотой петушок»ка даими килеп йөрү генә җитми, ә бик эредән кубып, зур суммалар «тәгәрәтүче» кәрт уенчыларының нинди дә булса бер ябык катранында үз кешe булырга, танылган казиноларга йөрергә кирәк—анда да кайчакта бер кичтә берәр «лимон» бакс шудыралар. Виктор Степанович бу журналистның Мәскәүдәге «майлы-җайлы» урыннарны яхшы белүе, һәркайда булуы һәм аны башкаланың күп кенә яшерен ишекләрен ачтыра ала торган кемсәләрнең озата йөрүе турында да сөйләгән иде.

«Ничектер сак кына, куркытмыйча гына Хавтанга шундый фикерне сеңдерергә кирәк—ул американның килгән-киткәннәрен исәпкә алып барсын,—Картье көтмәгәндә генә шундый уйга килде.—Кемнәр белән биредә була ул, кемнәр белән аралаша, ул барында залда «авторитетлардан» кемнәр була? Бәлки, нинди дә булса берәр әһәмиятле нәрсә калкып чыгар. Хәер, полковник Королев журналистның бик чиста эшләвен әйтә, бәйләнерлек, казынырлык җире күренми, ди».

Картье әле үзенең бизнесын башлап кына җибәреп, әти-әниләре белән бергә яши, әле үз офисы да юк чак иде. Көннәрнең берсендә ул универсам кибетендә очраклы гына үзенең сыйныфташы булган бер кызны очратты. Аларның күрешмәгәненә алты еллап булган икән инде, кызлар өчен, бигрәк тә мәктәп тәмамлаганнан соң, бик озын гомер инде бу. Нәкъ шул арада алар тормышында зур үзгәрешләр була бит. Татьяна белән дә шулай килеп чыккан. Институтка укырга кергән, өченче курстан ук бик яратып кияүгә чыккан, биш айдан баласы туган, академик ялдан соң ук укуын ташлаган, тагын бер ел ярымнан иреннән аерылган, ә тегесе, алимент-фәләннәр түләп тормыйча гына, җинел кулдан икенче кат өйләнгән дә, яңа хатынының әти-әниләре белән бергә Америкага китеп олаккан. Нәтиҗәдә Татьяна ялгызы калган—ни акчасы, ни эше,

ни белеме, ни киләчәге юк—әти-әнисе җилкәсендә утырган көне. Ул вакытта әле Неделин үз эшенең ничек җәйләнып китәрен дә белми, артык байлыгы да юк иде, әмма сыйныфташ кызын да шундый өметсез хәлдә ялгызын ташлап калдыра алмый иде ул—холкы-табигате андый түгел. Шуңа күрә ул тотты да Татьянага өйдә утырып эшләргә—үзенең секретаре булырга тәкъдим итте: «Әлегә телефон төбендә утырырсың, аннары соңрак факс куярбыз»,—диде.

Беренче уе шул иде: Кутузов проспектындагы өй телефонын бераз бушатырга кирәк, һәр шылтыраган саен карт әтисе сикереп тормасын, ә иң мөһиме—картларны төнлә шылтыратып бимазаламасыннар. Россиядә туып килгән яңа бизнесның үзенчәлеге запас телефон һәм факсның да булуның уңайлы якларын бик тиз төшендерде. Беренче зур уңышлы эшен майтаруга ук, Неделин, әлбәттә, пейджерлы да булды, спутник элемтәле кесә телефоны да алды, секретаршалары, референтлары, ярдәмчеләре, эш телефоннары, факслары да озак көттермәде—барысы да җайланды. Баштарак ул Татьянаны да штатка хезмәткәр итеп алмакчы иде, һәрхәлдә ышанычлы, үз кеше бит, ләкин эчке тоемы-интуициясе: ашыкма, анысы кайчан да соң булмас, диде.

Беренче финанс уңышларыннан соң ук Неделин Татьянаның хезмәт хакын арттырды, хатынга да тормыш ул кадәр үк өметсез күренми башлады. Билгеле, Цветной бульварда Татьяна торган йорттагы телефон яшерен иде, Неделин аның номерын теләсә кемгә биреп тә йөрмәде. Иң элек бу адресны ул үзенең чит илдәге партнерларына һәм банкирларга, чит шәһәрләрдән заказ бирүчеләргә аңлатты, ә телефон номерын исә бары тик бик ышанычлы кешеләре генә белә иде. Бик ашыгыч очракларда, Неделинга кем белән булса да кичекмәстән элемтәгә керергә кирәк булганда, Татьяна аны тиз генә пейджер яки кесә телефоны буенча эзләп табып тоташтыра, сөйләшүчеләрнең берсендә дә шик тумый, алар эше гөрләп барган бизнесмен Неделин белән үзләрен аның рәсми кабул итү бүлмәсеннән тоташтырдылар дип кенә уйлый. Эшлекле элемтәбәйләнешләр киңәя-үсә барган саен мәшәкатьләр дә арта торды, шуңа күрә Картье Цветной бульвардагы йортка компьютер да куйдырды, Татьяна кирәкле мәгълүмат-белешмәләрне шунда терки барды. Хәзер инде үзе өчен әһәмиятле һәр яңалыкны Неделин аңа кереп тормыйча гына, йә офисындагы компьютерыннан, йә өендәгесеннән укып белә ала иде. Үзенең бу яшерен элемтә чараларының әһәмиятен ул, КГБ шефы полковник Королев кавказлыларга охшаган кыяфәтле егетнең Картьены «Пекин» ресторанында фотога төшереп алганын белгәч һәм ул егетнең ЦРУ агенты икәнлеген әйткәч кенә, чын мәгънәсендә аңлады. Күрәсең, ни сәбәпледер, Картье-Неделин белән Америка разведкасы да кызыксына икән. Ләкин Карлен Татлян, Картьеның Кутузов проспектындагы йорт адресын һәм телефон номерын белеп алса да, ул телефоннан ара-тирә генә сөйләшкәләгән сүзләрдән бер генә җитди-юньле нәрсә дә тота алмады. Шул ук вакытта, ЦРУның Картье-Неделин белән ныклап кызыксына башлауларын төшенгән Королев аңа ышанычлы ышыклау-яклау чараларын да күрде: икенче очрашуда ук ул аңа берничә чит ил паспорты да алып килде. Болар йә хезмәт буенча, йә дипломатик паспортлар һәм, үзеннән-үзе билгеле, чит фамилияләргә тутырылган иде. Алар, чит илгә чыккач, аэропортта ук Картьеның койрыгына утырмасыннар өчен эшләнде. Шуңа күрә дә Неделин турында шактый соңлап килгән белешмәдән Карлен-Норман бары тик аның Көнбатышта сирәк, нигездә Лондонда гына булганлыгын белә алды. Юк, Картье Көнбатышта еш була иде, тик полковник Королев бу юлы үзенең американ коллегаларын алдан ук адаштырды—Неделин Лубянкадагылар өчен бик кирәкле агент иде, шуңа күрә нык сакладылар да үзен.

«Золотой петушок»та утырган кичтә Картьеның кәефе әйбәт иде, Хавтанның серле телевизорын сүндергәч, ул күңеленнән генә шаяртып та алды: «Без сина, кадерле журналист, үзебезнең миллиардлы братвабызны

алай бик җинел генә бирмәбез әле. Шаярма! Без әле көрәшеп карарбыз. Ни генә дисәң дә, ул җинаятьчел акчалар да безнеке, Россиянеке, каныбыз-тиребезне түгеп тапкан акчалар бит!»

Әмма, үз иптәшләре янына килеп утыргач, Картье янадан Карлен-Норман турында уйлана башлады: «Ә бәлки, үзен шпионнарча тотмавы белән бер елдан артык инде Лубянкадагы безнең кешеләрнең башын әйләндереп, аптырашта калдыручы бу егетнең башка берәр җитдирәк максаты бардыр? Ә братва, тамырдаш-корешлар бары тик игътибарны читкә юнәлтү, ышыклану өчен генә кирәктер ана? Юк, барыбер аны үземнән дә күз унымнан ычкындырмау хәерле, полковник Королевның хезмәттәшләренә генә ышанып торып булмас, бу журналист кисәге бигрәк еш минем юлда очраштыра башлады бит әле...»

### 3

Оля белән бергә «Золотой петушок»та утырганда, Картьены да очраткач, Норман ул киченнән канәгать калды. Карлен Татлян Неделин белән чынлап торып җитди шөгыльләнергә кирәклегенә көннән-көн ныграк ышана барды. Ул нәкъ менә ана кирәкле кеше булырга тиеш. Әйе, Картье саф бандитларның берсенә дә—ни төрмәләрдә утырып, тәннәрен татуировкалар белән сырлап-бизәп бетергән «күксел-ләргә» дә, ни хәзерге рәхим-шәфкатьсез, чиген-чамасын белмәс башкисәрләргә дә охшамаган. Андыйлардан булса, аның Норманга кирәге дә юк—үз башкисәрләре кул астында гына, дүртенче катка гына төш. Сөйләп тә торасы юк, ЦРУдагы шефлары Неделинның КГБ белән бәйләнеше булу мөмкинлеген аңлатырга тырышуларыннан башка да, Татлян үзе интуитив тоеп тора: Картьеның үзен тотышында ниндидер сер бар, әлбәттә. Ләкин Норман ул сер, ул табышмак барыннан да бигрәк ялган долларларга бәйле дип ышана, кемнәрдер ялган долларларны Россиягә тутыра тора бит. Ә бәлки, Неделин Россиядәге бихисап алдашу-афералардан сон җыелган астрономик суммаларны Көнбатышка, беренче чиратта Израильгә, Швейцариягә, Германиягә, Кипрга озатып торучы бер «шүре» генәдер, ул акчаларның бөтенләй калдык-постыклары гына АКШка барып ирешәдер? Бу очракта да, әгәр дә Неделин Россиянең үз «граверларын» яки Көнбатыштан китерелгәннәрен һәм аларның югары сыйфатлы ялган долларларын үз күзәтүе астында тотмаса да, ул барыбер кызыксыну тудыра. Көнбатыш белгечләре бәяләгәнчә булса, бөлгенлеккә төшеп килгән Россиядән ел саен егерме-утыз миллиард доллар суырып алыну турында сүз бара. Мондый фантастик суммалар ни ЦРУны, ни АКШның үзен битараф калдыра алмый, әлбәттә.

Карлен белән Оля ул кичтә «Золотой петушок»тан иртә киттеләр, әле ресторанда чынлап торып типтерү башланып кына килә иде. Ә Неделин, сизелеп тора, нык сыйланды ул кичне, алар өстәле мәрмәр багана артыннан әйбәт күренә иде: ул өстәл янына әледән-әле ниндидер яшьләр килеп утыра, ә Картье исә һәрвакыт игътибар үзәгендә, артында, бер дә китмичә, кырык яшьләрдәге җитди ике ир дә басып тора иде.

Карлен Ямской кыры урамындагы йортына ничек кенә соңлап кайтса да, ул һәрвакыт факстагы хәбәрләрне, телефон язып алган язуларны караштырып чыга, шуннан соң инде үзенең махсус ясалган «шпион» компьютерында ныклап эшкә керешә. Күләме белән әйтеп-сөйләп бетермәслек, дөньяда әле моңа кадәр күрелмәгән галәмәт мәгълүмат революциясе булды, ул кешеләр тормышының һәр тармагына кагылды һәм, әлбәттә, разведка эшен дә бик җиңеләйтте. Россия бу революциядә йоклап калса да, ул теләсә кайсы көнбатыш илләреннән дә иркен-ирекләрәк ил булып чыкты: теләсә принтерлы иң катлаулы компьютерларны да исәпкә алып теркәп куймый ичмаса. Ә бит ул аппаратураларда паспорттан башлап шофер таныклыгына кадәр теләсә нинди дәүләт документын, акцияләрдән башлап дәүләт займы облигацияләрен—теләсә

нинди эш кәгазьләрен җиңел генә эшләп алып була. Шул исәптән, долларларны да. Таможняда ачыктан-ачык шпион кирәк-яракларын: төнлә күрә торган приборларны, теләсә нинди телефоннарны тыңлый ала торган «жучок»ларны—кыскасы, берсен дә теркәп тормыйлар. Моны Карлен Татлян үз тәҗрибәсеннән чыгып та әйтә ала: аның гаять куәтле компьютерын да дипломатик каналлар аша яшереп алып кермәделәр, ул аны бер тикшерүсез-тоткарлыксыз үзе алып килде. Мондый әйберләрне АКШка иркен алып керү һич мөмкин булмаган хәл, шунда ук эш судка кадәр барып җитәчәк: кайдан, ни өчен, нинди максат белән?.. Көнбатыш үзенең финанс мәнфәгатьләрен яклый һәм иленең куркынычсызлыгын да саклый белә шул ул.

Ул кечтә компьютер искитәрдәй әһәмиятле бер яңалык та бирмәде. Гадәттәге эчпошыргыч көндәлек мәгълүмат: кайчан, кайсы илдәге бер «гравер» төрмәдән чыга, камерасына утырткан безнең кешегә киләчәктәге уй-ниятләрен сөйләгәнме?.. Инде утырып иреккә чыкканнарына аерым игътибар ителгән, аларның профиль һәм анфас алынган фоторәсемнәре теркәлгән, чөнки ул чукынчыклар, иреккә чыккач, хирурглардан бик оста файдаланып, пластик операция ясата—төс-кыяфәтен үзгәртә. Кайбер гомере буе пеләш берәрсе, башына парик-фәлән киеп җибәрсә, кем әйтмешли, үз әнисе дә танымаслык затка әйләнә. Бер мәртәбә «янган» һәм утырып чыккан «гравер» америка долларлары йөрештә булган барлык илләрдә дә үзен исәпкә алып, теркәп куйганнарын да бик яхшы белә,—ә долларлар йөрмәгән илләр юк диярлек,—шуна күрә мондый кемсә бик сак һәм сизгер була.

Бик үк гадәти булмаган бер яңалык та бар иде: Аргентина төрмәләренең берсендә ялган долларлар ясаучы атаклы оста испанлы Сесар Ди Стефано үлеп киткән. Норман шәп мыеклы, аристократларча тәкәллефле бу әфәндене шундук күз алдына китерде—гадәттә дон Сесар үзе ясаган долларларны кыйммәтле казиноларда шудыра торган булган. Аның фоторәсемнәрен Карлен әле разведмәктәптән үк хәтерендә яхшы калдырган иде. Дон Сесар Ди Стефано 1986 елда үзе яраткан Буэнос-Айрес шәһәрендә эзенә басканчы американ агентларының канына аз тоз салмаган. Мөгаен, дуслары һәм көрәштәшләре бу испанлыга бик күркәм итеп җирләү-озату оештырыр, яңгыравык фамилияле маэстро үз эшендә бик талантлы булган—типтерергә һәм хатын-кызлар артыннан сөйрәлергә яратучы бу донжуан тирәсендә бик күп кешеләр дистә еллар буе юмарт туенып яшәп килгән бит.

Аннары кайда һәм кайчан зур суммада кулда йөргән долларлар турындагы хәбәрләр китә. Соңгы бер-ике ел эчендә мондый хәлләр, элекке шикелле, гарәпләр белән бәйләнмәгән, ә «яңа руслар» белән бәйләнгән була башлады. Бу әфәнделәр әле саллы-саллы кредит карточкаларына күнегеп җитмәгән, чөнки үзләрендә ашык-пошык оештырылган банкларга ышанычлары юк. Үз янында, кейсында яки «дипломат»ында булган акча ничектер ышанычлырак һәм гадәтләнелгәнрәк тоела. Аларның җиңел кулыннан килеп кергән «кеш» (русларда «нал» гына диләр) Көнбатышны да кызыктыра башлады, бу хакта ни генә сөйләмәсеннәр һәм язмасыннар, кулдан-кулга турыдан-туры кергән акчага салым түләп торасы юк бит. Кайбер очракларда компьютерда чит илгә чыгып зур сумма исраф иткән россиялеләрнең паспорт мәгълүматлары күренә. Нигездә, болар кыйммәтле ювелир кибетләрендә яки югары мода йортларында түләнгән счет-квитанцияләр була, андый чакларда Россия гражданнары кием-салымны берьюлы бөтен гаиләсенә һәм елның һәр дүрт фасылына яраклы итеп тектерә, акчасын да шунда ук чыгарып түли—биш-алтышар нульле суммалар һушларыңны алырлык була шул, Карлен беренче мәртәбә уйлап куйды әле: казнага салым түләмичә генә шулай акча туздыручы урыс нуворишлары—яна байларның бәйнә-бәйнә исемлеген төзеп куйсаң да комачауламастыр. Кирәге чыга-нитә калуы бар. Хәер, мондый исемлек, мөгаен, дәүләт өчен генә түгел, аның дүртенче

катта яшәүче дуслары өчен дә кызыклы булыр иде. Бу белешмә бай Неделинны да кызыксындырмый калмас, ә алмашка анардан үзенә кирәкле тагын да кызыклырак мәгълүматлар алырга була. Көтелмәгән бу авантюристик фикер Татлянны үсендереп җибәрде: кара әле, һөнәри серләрне шәхси файдана да юнәлтеп була икән бит, менә монысына аларны Иллинойста өйрәтмәгән иделәр шул.

Ә кайчагында нинди таныш фамилияләр очрап куя иде, бигрәк тә Париждан алынган белешмәләрдә! Бирелә хәтта җитди тикшеренүләрсез дә ачык ярылып ята: иң зур акчалар сарыф итүчеләр эшмәкәрләр яки банкирлар түгел, шоу-бизнес йолдызлары яки законлы караклар да түгел, ә министрлык һәм төрле ведомстволарның түрә-чиновниклары, дәүләт аппараты хезмәткәрләре, лоббист депутатлар. Кыскасы, рәсми оклады айга өч йөз-дүрт йөз доллардан артмаган кешеләр, менә шулар үзләре яки хатыннары һәм бала-чагалары бер булып кайтканда да йөзләрчә мең бакс туздырып кайта да инде. Карлен тагын шунысын да юк мыегына чорнап куйды: әгәр дә Мәскәүдә аның үзе белән кинәт кенә ниндидер көтелмәгән хәлләр килеп чыкса да, мондый исемлекнең бик файдасы тияргә мөмкин иң. Ул аз-маз окладта утыручы түрә кисәкләре, үзләренең тынычлыгына һәм имин-мул тормышына кагылсаң, күп нәрсәләр майтара ала.

Әмма иң гаҗәбе шул иде, Россиядән акчалата теге якка чыгып киткән зур суммалар арасында бу юлы бер генә ялган банкнотлар булуы теркәлмәгән, юкса, аларның кайдан алынганлыгы бик тә шикле иде. Ләкин Көнбатышка тәшвишкә-васвасәгә төшәрлек яки декларациядә теркәлмәгән валюталар кертүне тыю өчен сәбәп тә түгел иде бу. Россиядә бу унай белән борынгы рим мәкале йөри: акчаның исе юк—Көнбатыштагы талымчан бәндәләр дә, эш үз мәнфәгатьләренә килеп терәлгәч, шулай уйлаганга охшый.

Компьютер ялган валюталар тотылган илләр турында да белешмә бирде. Алар барысы да өч илдә: Гарәп Әмирлекләрендә, Кытайда һәм Төркиядә теркәлгән икән. Ләкин шунысы бар—соңгы елларда бу илләргә, элекке СССР дәүләтендә яшәп, хәзер бәйсез дәүләтләргә әверелгән төбәкләрдән ташкын-ташкын вак алыпсатарлар ябырылды. Аларны Россиядә «челноклар» дип кенә йөртә башладылар, ягъни әрле-бирле йөреп торучы «шүреләр-сосалар». Алар югарыда санап кителгән илләрдән арзан хакка күпләп-күпләп товар сатып алып кайта да, кайткач, шуны табышлы хакка сата—шуның белән тамак туйдырып яши. Яңа бәйсез дәүләтләр: Литва, Белоруссия, Казакъстан, Молдова, Грузия, Әзербәйҗан, Төрекмәнстан гражданнарыннан алынган ул ялган долларларның тарихы Американың ялган акча ясаучылар белән көрәшү үзегенә яхшы билгеле була. 1991 елны Польшадагы Вроцлав шәһәрендә ФБР хезмәткәрләре яхшы оештырылган цех-лаборатория-типографиянең өстенә баса. Әмма анда инде, янәсе, 1990 елда чыккан долларларның бер сериясеннән берничә миллион ялганын бастырып өлгергән булалар. Ә ул 1990 елгы йөз долларлык акчаларда, саклану чарасы буларак, беренче мәртәбә металл тасма кулланыла. Ялган долларларны Польшада бастырып чыгарырга бик ашыгалар, чөнки аны әле моңа кадәр долларларның ни тасмалысын, ни тасмасызын юньләп күрмәгән Россиянең иксез-чиксез киңлекләренә кертеп өлгерергә кирәк була. Бу уй-ният дөп-дөрес булып чыга: чөнки дөньядагы бер генә илдә дә әр-яңа долларларга, СССРдагы шикелле, ышанып карамыйлар. Польшадагы «граверлар»га Франклин сурәте төшерелгән үз «долларларын» тулысынча камилләштереп бетерергә ярты ел вакыт җитми кала. Алар хәтта уртача гына сыйфатлы детекторда тикшергәндә дә сизелә торган магнитлы караның серен ачып бетерә алмыйлар, әмма ул чорда әле СССРда ни яхшысы, ни начары, дигәндәй, бертөрле дә тикшерү детекторы булмый. Берничә миллион ялган банкнотны шулай да Россиягә озатып, уңышлы гына таратып өлгерәләр. Акчаларның калган өлешен, акча басу җиһаз-корылмаларын һәм бер төркем «граверларны»,—алар арасында бер итальян, бер француз, бер

ливанлы да була,—тотып алалар. Менә бу юлы теге таралып өлгергән беренче партия ялган долларларның калдык-постыкларын жыеп алганнар икән. Ул акчалар барысы да бай Американың финанс куәтенә зыян китерергә уйлары да булмаган әлеге дә баягы шул мескен «челнок»-«шүре»-«сосалар» кулында гына булган. Вроцлавта басылган ялган доллар-лар турында Карлен-Норман белә иде, Мәскәүдәге валюта алмаштыру пунктларында алар әле дә очраштыргалый, ләкин аларны беркем дә конфискацияләп тормый—иясенә кайтарып бирәләр дә—шуның белән вәссәлам! Һәм ул акчалар, янадан Көнбатышка барып эләккәнче, Россия кинлекләрендә әйләнештә йөри тора, ә тегендә барып чыксалар, аларны шунда ук каптырып та алалар.

Татлян хәтерли әле: разведка мәктәбендә укыганда бер курсант лекция вакытында укытучыдан кызыксынып: «Барлык ялган акча ясаучыларны тотып бетерү бурычы кайсы елга куелган?»—дип сораган иде. Күрәсең, ул бичара үз өлешенә эш калмас дип борчылгандыр инде...

Укытучы аңа уфтанып җавап биргән иде:

—Без долларның сыйфатын никадәр генә яхшыртсак та, фән һәм производствоның иң яхшы, иң соңгы казанышларын файдалансак та, кәгазь һәм полиграфия буяуларын әзерләгәндә нинди генә яшерен технологик алымнар куллансак та, тикшергәндә тоту өчен нинди генә хәйләкәр-серле элементлар өстәсәк тә, ялган долларлар елдан-ел арта гына барачак. Кайбер пессимистлар аларның саны геометрик прогрессия белән үсә барачак дип саный, ә безне иң борчыганы шул—без күзәтеп, үз кул астыбызда тотарга тырышкан ялган доллар ясау үзәкләре җир шарының иң ерак почмакларында, без бер дә көтмәгән төбәкләрдә калкып чыгачак. Болай фараз кылу өчен төп ике нигез бар: беренчесе—фәнни-техник прогресс, алга китеш, һәркемнең кулына кирәрлек югары технология; икенчесе—доллар планетада төп акча берәмлегенә әверелеп бара. Хәтта дөньяның алтыдан бер өлешен биләп, кайчандыр СССР дип йөртелгән һәм әле күптән түгел генә анда безнең валютаның хуҗа булу мөмкинлеген күз алдына китерүе дә кыен булган ил-дәүләт тә хәзер тулысынча АКШның финанс йогынтысы үтеп кергән зонага әверелде, «агач рубль» дип йөртелгән валютасының конверсияләнү сәләтен—проценты киметелү, түләү вакыты озайтылу кебек башка төрле шартларын бөтенләй югалтты шикелле инде. Менә шуңа күрә дә бу афәт белән көрәшү өчен оештырылган безнең разведка мәктәбебез эшләп тора, әле бик күп укып чыгучыларга, шул исәптән, сезгә дә, эш муеннан булыр һәм ул озак елларга җитәчәк,—дип, нотыгын ниндидер гаҗизлек-өметсезлек белән тәгәлләгән иде педагогик эшчәнлеккә күчкән карт шпион.

...Һәркөнне мәҗбүри эшләнергә тиешле компьютер яңалыкларын карап-укып бетергәннән соң гына Карлен үзенең яшерен тынлый торган җайланмаларын эшкә җикте. Неделин-Картьеның Кутузов проспектында өй телефоныннан автомат кына җавап кайтарды: «Хуҗа өйдә юк, хуҗа өйдә юк...» Шулай булырга тиеш тә—хуҗа «Золотой петушок»та кәеф-сафа корып, типтереп калды бит. Әле янарак кына Карлен үзе дә Хавтан ресторанында Оля белән күнелле генә утырып, Лайма Вайкуле концертын тыңлап кайткан иде. Хавтанның телефонында, хуҗага авыз ачып сүз әйтергә дә ирек бирмичә, ниндидер бер мужик катлы-катлы сүгенеп тора иде. Бу ямьсез кычкырыну нәрсәдән башланып киткәндер, Хавтанның ни өчен шулай тетмәсен тетәләрдер—Норман тәки аңлый алмады, югыйсә язып алганын ике мәртәбә тыңлап караган иде. Телефон шылтыратуларга атаклы кәрт уены шулеры Городецкий-Аргентинлы ешрак җавап биреп утыра, ләкин аның әллә телефоны төзек түгел, әллә Норманның тыңлый торган җайланмасы көйсезләнә башлады—язып алганы сыйфатсыз булып чыкты, Карленның кәефе китте. Соңгы вакытта ул Абректан Городецкий-Аргентинлының Мәскәүдәге җинаятьчеләр арасында иң карт «авторитет-лардан» берсе һәм яшерен дөньяның тере энциклопедиясе икәнен ишеткән

иде инде. Менә ул карт башкалада зур-зур акчаларның кайларда, кемнәр кулында икәнлеген белә дә белә, әлбәттә.

Төнге эшенә йомгак ясагач, Карлен шундый фикергә килде: Неделинның өйдәге телефоныннан башка тагын нинди элемтә чаралары бар икән—шуларны эзләп табарга кирәк, ә Аргентинлының телефонын тикшертмичә-рәтләмичә булмас, Мәскәүнең бөтен җинаятьчел дөньясын биш бармагы кебек белгән бу чыганакны һич югалтырга ярамый.

4

Крис белән Абрек Лондоннан кайтканнан соң, алардан алып менгән акча эреде дә бетте, аның бетеп киткәнен Карлен сизми дә калды. Хәер, соңгы айларда кайларда һәм нәрсәләргә туздырганын санап карагач, Карлен акчасының шулай тиз бетүе бик урынлы икәнен аңлады, әлбәттә.

Хәзер аның Мәскәүдә үзенчә яшәү рәвеше барлыкка килде дип әйтергә була, элек булмаган гадәтләре калкып чыкты—тәмле һәм сыйфатлы ризыклар ашый, соңгы мода белән киенә, комфортлы яшәргә өйрәнде, кызларга чәчәкләр-бүләкләр ташый—болар һәммәсе дә акча сарыф итүне сорый, әйтергә кирәк, зур акчалар... Карлен инде күптән инанды, мондый иркен тормыш алып бару өчен Россия башкаласы Мәскәү—дөньядагы иң кыйммәтле шәһәр.

Ереванлы дуслары кабат кунакка чакыргач, аның чытык йөзен күреп, америкаң журналистының ни өчен кәефе юклыгын шундук аңлап алды. Гадәтенчә, башы белән гардероб ягына ымлап, Армен иптәшенә күз кысты да:

—Ашыга төш, Каро кадерлем, юкса без тиздән саквояжларны бушатып бетерәчәкбез. Әллә нинди бик тиз эри торган акча булды ла, күз алдында эри дә тора,—диде. Аннары алар шаркылдап көлеп җибәрделәр.

Карлен, унайсызланып кына, гардеробка таба атлады. Ике саквояж да элеккечә янәшә тора иде, әмма аның берсе, башта кул тыкканы буш булып чыкты, аңа «Шлезингер» теннис туплары тутырып куелган иде, икенче саквояж да сизелерлек «ябыккан». Хәзер инде Карлен Арменның «бик тиз эри торган акчалар, таңдагы томан кебек оча да бетә» дигән сүзләренең мәгънәсен бар тирәнлеге белән аңлады. Күренеп тора, Карленга иң кыю хыялларын һәм теләкләрен тормышка ашырырга ярдәм иткән тылсымлы сумканың монысы да икенче кергәндә бушап калган булачак—ул дусларының нинди колач белән яшәгәнлекләрен белә, аннары, алар Англиядән өйләнеп кайткач, тирәләрендә әрәмтамаклар да сизелерлек арткан иде, юкса Лондондагы «Лейнсборо» отелендә булган хәлне кемгә булса да тишеп йөрмәгәннәрдер инде.

Шунысы сәер, дүртенче каттагы акча чишмәсе көннән-көн корыйкибә барганын белеп торса да, Карлен соңгы айларда күнеккән гадәтләреннән аерыла алмады. Аналитик акылга ия, Американың булдыклы эшлеклелеген татыган егет үзен-үзе танымый башлады, зиһене аның икегә аерыла баруын тойды, хәер, разведка мәктәбендә укыганда ук ул үзе сайлап алган бу четерекле-куркыныч һөнәрнең кеше шәхесенең бөтенлеген вату мөмкинлеге барлыгын аңлаган иде инде.

Даими куркып һәм икейөзләнеп яшәү аркасында шпионның психикасында кире кайтарып ала алмаслык үзгәрешләр барлыкка килә һәм алар актерларда була торган үзгәрешләрдән шактый тирәнрәк, һәлакәтлерәк була бара. Актерлар да гел уенда, әмма иң мөһиме шул—аларның тормышларына куркыныч янамый. Карлен, әлбәттә, үзенең икегә аерыла баруын эшенә бәйләп карамый—әле моның өчен бик аз вакыт үтте бит, куркыныч тәвәккәллеккә тару мөмкинлеге дә бик чикле. Алай-болай тота калсалар, иң начар дигәне шул булыр—аны Россиядән сөрерләр. Ул бит дәүләт серләрен ауларга, яшерен галимне урлап алып

китәргә яки Тын океан флотындагы корал складларын шартлатырга килмәде—алар болай да анык бер эзлеклелек белән шартлап кына тора.

Карленның үз шәхесе икегә аерыла баруын тоя башлавыннан соң бер атна, ике атна үтте, холык-табигатендәге бу үзгәрешкә ул күнелленнән генә мондый бәя бирде: бер үк вакытта үзен ул шымчы да, бандит та итеп тоя башлады шикелле. Сәер, бер-берсе белән һич яраша алмаслык бу ике төшенчә-сыйфат анарда бик яраша, эшләргә һәм хәтта тормыштан тәм табып яшәргә дә комачауламый. Ул атнага ике тапкыр бик төгәл рәвештә «Лос-Анджелес таймс»ка гына түгел, планетаның мәдәни тормышын яктырта торган башка журналларга да хәбәрләрен-мәкаләләрен җибәреп тора. Журналларга ул заказ булганда гына яза, мәсәлән, Юрий Башметның камера оркестры турындагы мәкаләсе шулай язылды, андый мәкаләләр өчен каләмхак-гонорар да кайвакытларда газеттан алган айлык хезмәт хакыннан артып китә иде. Ул ниндидер эчке бер тоем белән акча эшләп алуның яна чыганакларын капшап таба, дүртенче каттагы акча чишмәсе кипсә яки юмарт дуслары белән бер-бер хәл була калса, үзенең яшәү шартларын начарайтмас өчен юллар эзли.

Дөньяви тормыш, бигрәк тә Оля белән торган саен ешая һәм озакка сузыла башлаган очрашулар аның бик күп вакытын ала һәм көннәрдән бер көнне ул үз газетына материалларны вакытында җибәреп өлгерә алмавын, заказга алган мәкаләләрен дә озакка сузуын, гадәтенчә, спецкомпьютеры янында да кич саен утыра алмый башлавын таныраг мәҗбүр булды. Ә иң мөһиме, нинди техник төгәлсезлек-җимереклекләр аркасында Городецкий-Аргентинлының телефоннан сөйләшүләрен тыңлый алмаганын ачыклап бетермәде. Шуннан соң Карлен, үзен төп башына утыртмау, аптырап калмауның бер әмәлен тапты...

Тотты да бер көнне туп-туры плагиатлык белән шөгыльләнә башлады Карлен, ягъни башка газет-журналларда бер үк темага яки бер үк вакыйгага багышланган материалларны бергә җыеп, шулардан күчереп үз материалын әвәләргә тотынды. Ни сәер, мондый «винегрет» яңа булып күренә, ә кайчакларда чәйнәлмәгән фикерләр дә чагылып китә, бәлки, шунлыктандыр, аның язганнары Америкада уңыш казана иде. Шул рәвешле, ул, бик җилле шәхси тормыш алып баруы аркасында, Мәскәүдәге үзе күрә алмый калган мәдәни вакыйгалар турындагы материаллары белән «Лос-Анджелес таймс» сәхифәләрендәге үз урынын тотырып тора иде әле.

Калын музыкаль һәм театраль журналлардан заказлар алып эшләү тагын да гадирәк булып чыкты. Ул үз мәкаләләрен башкалада танылган башка журналистлар белән соавторлыкта, ягъни ике фамилия белән бастыра башлады, ул аларның кайберләрен төрле очрашуларда күреп шәхси белә, икенчеләрен Россия матбугатында басылып чыккан житди мәкаләләре буенча сайлап ала иде. Андыйлары янына ул американнарча ап-ак тешләрен балкытып килә, бик ягымлы гына итеп туп-туры сөйләшә, менә шундый театр яки симфоник оркестр турында материал әзерли башлавын әйтә, әмма эш дәвамында ул шуны аңлаган—аларның элекке репертуарларын, чишмә башларын, тамырларын, беренче состав артистларын, иҗат принципларын һәм башкаларын, һәм башкаларын аз белә икән,—мондый сәбәпләрне күптән табарга була һәм барысы да ышандырырлык килеп чыга: «Бәлки, икәү бергә эшләрбез, тәрҗемә итеп, көнбатыштагы калын журналга урнаштыруны үз өстемә алам»,—ди Карлен. Ул мәкаләгә Көнбатышта түләнәсе каләмхак-гонорарның күләмен биш мәртәбә киметеп күрсәтсә дә, Россиядә андый акчага да чиксез шатланалар, ә инде Америкада танылган журналда басылып чыгу—үзе зур дәрәҗә. Озакламый ана соавторлар эзләп йөрергә дә туры килми башлады: юмарт американ журналисты турында кайдандыр ишетеп, исемле сәнгать белгечләре, ана үз хезмәтләрен тәкъдим итеп кенә калмыйча, бик кызыклы темалар да әйтә иделәр. Бу тәкъдимнәр шул кадәр мавыктыргыч һәм көтелмәгән булып чыкты ки, Карлен, андый авторларга акчаны үз кесәсеннән түләп, мәкаләләрен җыя барырга карар кылды. Еллар буе

тикшереп-өйрәнеп язылган ул мәкаләләр Карленга чын-чынлап танылу китерергә. Көнбатышта исемен янгыратырга мөмкин, чөнки анда доктор, профессор дәрәҗәләре—буш сүз генә түгел.

Шулай итеп, Россиядәге мәдәни тормыш турындагы мәгълүматларны бер даими агымга салгач, Карленнын күнеле күтәрелеп китте. ЦРУдагы хуҗалары, әлбәттә, анын «Лос-Анджелес таймс»тагы язмаларын игътибар белән карап бара, мәкаләләренен һәрберсен компьютер хәтеренә салып куя, анализлый һәм вакыт-вакыт белгечләргә биреп бәяләтә дә иде. Дөньяви хроника репортерның «түбәсе» саф-чиста булырга, журналистлыгы турында шик тудырмаска тиеш—бу хакта аны катгый кисәтеп куйган иделәр инде.

Әмма Мәскәү тормышы Карленны, рус мәкалендәгечә, уттан алып суга салырга әзерләнеп кенә торган, диярсен. Бервакыт, Оляны озатып куйгач, төн уртасында бик әйбәт кәеф белән өенә кайтып керде ул. Күнеленнән ташып чыккан матур-татлы хисләреннән квартирасында үзенә урын таба алмый, әрле-бирле йөренә башлады, юкса «ябалак»—төн кошы да түгел үзе. Әмма йокысы килми иде. Бурыч үтәү өчен дип түгел, вакытын бушка уздырмас өчен генә, инде өч көн янына да килеп карамаган компьютерын кабызып җибәрде Карлен. Һәм, инде моннан ике тәүлек диярлек элек килгән беренче хәбәр үк анын кәефен шундук кырды да төшерде. Үзен аңгырайткан мәгълүматтан айный алмыйча, урынына барып ятса да, күзенә йокы кермәде. Бу гадәттән тыш сенсацияле хәбәр, әйтерсен лә, нәкъ менә Норман-Карленга турыдан-туры адресланган шикелле булды—юкса, һич алай түгел иде. Бу мәгълүмат бөтен кыйтгалардагы «граверлар»ны аулаучы яшерен агентларнын меңнәрчә компьютерларына барып ирешкән. Гадәттән тыш зур текст белән әле тулысынча танышып чыкмаса да, Карлен сүзнен нәрсә турында барганын анлап алган иде инде...

Хәбәр мондый иде: бернichә ай элек Лондонның зиннәтле-купшы «Лейнсборо» отелендә ике чечен егете агалы-энеле Цуцаевлар, генерал Дудаевнын ышанычлы кешеләре үтерелгән. Бу чеченнәрнен Лондонга беренче генә килүләре булмаган, хосусый фирмалардан яшерен рәвештә корал сатып алып, җирдән дә, һава транспорты белән дә шуларны үз ватаннарына, Ичкериягә ташып торганнар.

Таулы кечкенә генә республика өчен зур күләмдә корал сатып алулар шактый сәер күренә. Мондый запаслар бары тик сугыш була-нитә калган очракта гына эшләнә. Англиядән ин камил кораллар, мәсәлән, «стингер» ракеталары, космик элемтә чаралары алынган. Тикшерү барышында шунысы да ачыкланды, агалы-энеле Цуцаевлар исеменә Лондондагы билгеле банкларда зур-зур суммаларда валюта счетлары ачылган булган, коралга исәп-хисап шул суммалардан алып барылган. Белгечләр миллионлаган суммалар акчалата кулдан гына түләнгән булырга да мөмкин дип исәплиләр.

Генерал Дудаев эмиссарлары яшәгән номердан алай күп акчалар табылмаган, ләкин һәр икесенен дә кесәләрендә, берничә йөз долларлык банкнотлардан тыш, бөтен дөньяга билгеле банкларнын әллә ничәшәр йөз мен долларлык кредит карточкалары булган...

Алга таба язылганнары турыдан-туры Карлен Татлянга да кагыла иде.

...Эш шунда ки, үтерелгән чеченнәрнен бумажникларыннан табылган долларларны, берничә ай җентекләп тикшергәннән сон, аларнын ялган икәнлекләре ачыкланды. Моны бары тик ялган акча ясаучылар белән көрәшү фәнни үзәгендә, тәҗрибәле белгечләр, лаборантлар катнашында, йөзләрчә структур һәм химик анализлар үткәргәннән сон гына белә алдылар. Лондонда җинаять булган урында—банкларда, кибетләрдә, полициядә барлык детекторлар да акчалар чын дип күрсәтеп килде. Агалы-энеле Цуцаевларнын долларлары, кайчандыр Татлян үзе чеченнәрнен акчаларын тикшереп торырга кинәш биргәнгә күрә, тикшерү үзәгенә китерелгән иделәр. Детекторларда тикшерү унай нәтиҗә биреп торуга карамастан, ул банкнотларнын чит-ят икәнен бары тик белгечләрнен

интуициясе-эчке тоемы аркасында гына белә алдылар. Бу ялган акчалар супербанкнотлар дип танылды, чөнки моңа кадәр әле беркайчан һәм беркайда да андый югары сыйфатлы долларлар очрамый иде. Кемдер АКШның милли валютасындагы өч дәрәҗәдәге саклану чараларының өчесен дә кабатлый алган—житмеш биш проценты мамык һәм егерме биш проценты житеннән булган чын долларлар басыла торган кәгазь файдаланылган, шундый ук магнитлы каралар уйлап табылган, кәгазьләргә бары тик ультрашәмәхә яктылыкта гына күренерлек ефәк жепнең дә шул ук структуралысы кушылган. Бу супербанкнотның чын банкнотлардан бөтенләй юк дәрәҗәсендәге микроскопик аерымлыгы бик нык сер итеп саклана. Шул унайдан, ЦРУның дәлилләп соравын искә алып, АКШ хөкүмәте бөтен дөньяда әйләнештә йөри торган иске йөз долларлык купюраларны иң якын арада жыеп алу һәм аларны, Америка валютасын киләчәктә ялган итеп ясамаслык итү өчен, тагын да ышанычлырак һәм нәтижәлерәк саклану чаралары белән баетылган яңа долларларга алыштыру турында карар кабул итәчәк.

Әлеге супербанкнотларның килеп чыгуы, аларның номерлары һәм серияләре хакында Американың Федераль резерв банкы мәгълүмат таратмаска дигән карарга килде. Аны бары тик дәүләтнең иң югары берничә житәкчесе, кайбер ышанычлы шәхесләр һәм шулай ук үзәкнең «граверлар» аулаучы Татлян кебек кешеләре генә белә. Юкса, дөньяда көчле ыгы-зыгы башланачак, һәркайда тизрәк долларларын алмаштырып, алардан котылу юлын эзләүчеләр булачак һәм нәтижәсе ничек булып бетәсен әйтеп булмый торган гомумпланетар күләмдәге финанс коллапсы—димәк, үлем белән бер диярлек хәл килеп чыгачак. Андый хәл була калса, доллар икенче мәртәбә бервакытта да дөнья валютасы дәрәҗәсенә менә алмаячак. Дәүләтнең югары мәнфәгатьләре бу мәгълүматларны бик яшерен итеп саный һәм танышып чыгу белән үк юк итәргә кирәклеген искәртә.

Шуннан соң текстта агалы-энеле Цуцаевлардан табылган ялган банкнотларның номерлары һәм серияләре китерелә. Долларлардагы номерларның сигез урынлы саннарын ахырына кадәр укып тормыйча да, Карлен Татлян аларның Мәскәүдә үзе шулай юмарт туздырган акчалар икәнен аңлады. Ул шулар белән түләп «Мерседес» вәкиллегеннән машина, «Обвиос» һәм «Дормей» кибетләреннән менә дигән кыйммәтле киемсалым, «Ягуар-стиль» салонынннан да кайбер нәрсәләр алды, ул акчаларны Хавтанның «Золотой петушок»ында да һәм башкаланың атаклы башка ресторааннарында да күп туздырды. Әле күптән түгел генә Карлен «Пурпурный легион» музыкаль кибете аша француз фирмасы «Мутон Ротшильд»тан заказ белән «хай-энд» класслы аудиоаппаратура комплекты кайтартты, ул инде иң бай, иң югары зәвыклы меломаннар-музыка сөючеләр өчен генә эшләнә. «Хай-энд» авазы—чын коллекцион шәрабләр тәменә тиң, дип юкка гына сөйләнмиләр шул. Бу аппаратурасы өчен дә ул шул ук ялган акчалары белән түләгән иде.

Карлен өчен күңелсез мәгълүматлар болар белән генә бетмәде әле. Чечен егетләренен бумажникларыннан табылган долларларның ялган икәнен үзәк ачыклагач, Лондонда шундый ук серияле шактый суммаларны сөзеп алганнар икән. Хәтта кайсы сәүдә ноктасыннан банкка шундый зур күләмдә акчалата долларлар килеп кергәнен дә ачыклаганнар. Даунингстриттагы ювелир кибетеннән инглизчә начар сөйләшүче ике егетнең швейцария фирмасы «Франк Мюллер»ның бик кыйммәтле өч сәгатен һәм шунда ук «Шопард» фирмасының алсу һәм ак алтыннан ирләр өчен эшләнгән ике авыр чылбырын да сатып алганлыгы беленгән. Кибетчеләргә үтерелгән агалы-энеле Цуцаевларның фоторәсемнәрен күрсәткәннәр, ул егетләрнең дә кулларында, күрәсең, очраклыдыр инде, шул ук «Франк Мюллер» сәгатьләре булган, сатучылар бу егетләрне үзләренә кергән бай сатучылар итеп танымаган. Бары тик тегеләрнең инглиз дә, европалы да түгел икәнлекләрен генә әйткәннәр. Бу хәбәр, ниһаять, Карленны чыгырыннан чыгарып, алга таба компьютер дөньяда яна ялган супербанк-

нотлар килеп чыгу унае белән ниндидер кирәкмәс кинәшләр бирә башлады, «ул ялган доллалар барыннан да битәр һич аңлап бетереп булмаслык Россиянең берәр почмагында сугылып ятмыйлармы икән?»— дигән шик тә белдерде. Карлен артык түзеп тора алмады, компьютерын сүндерде. Сәгатенә карап алды да, кинәт куркынып, затлы сәгатен салып ташларга ашыкты. Батып баручы саламга да ябыша, дигәндәй, ул да язу өстәле тартмасыннан төргәге белән долларларын алып карады, котылыр мөмкинлек калмаган—акчаларның номер һәм сериясе теге ялган долларларныкы шикелле үк иде. Хәер, Татлян ул саннарны Лондон отеле «Лейнсборо»да булган хәлләрне ишеткән кичтә үк үзеннән-үзе ятлап алган иде инде.

Башына килгән иң беренче уе шул булды: инде төн танга авышып баруга да карамастан, дүртенче катка йөгереп төшеп, әрмән дусларында җәнҗал чыгарырга кирәк. Ялган доллары өчен, юмартлыклары белән аның үзен дә бу пычрак эшкә тартып керткәннәре өчен—ул үзен-үзе белештермәслек ярсу хәлгә килгән иде. Ләкин бер-ике минуттан ул үзен кулга алды, разведка мәктәбендәге педагогларының кинәшләрен исенә төшерде, боз кебек салкын сулы душта юынып чыкты, су кушып-нитеп тормыйча гына бер рюмка «Баллантайн» вискиен эчеп куйды. Шуннан соң аның үлеп ашыйсы килә башлады,—ярсыган мизгелләрдә андый хәлләр була,—һәм ул, төн-таң дип тормыйча, үзенә ашарга әзерләргә чыгып китте, «Золотой петушок»тан китеп барганда, үзенә берәр тартмага азык-төлек салып бирүләрен дә үтенгән иде—анысы хәзер бик ярап куйды әле. Ашап утырганда Петровичтан алган яхшы аракыны Карлен тагын бер рюмка җибәреп куйды, шуннан соң тормыш ул кадәр үк өметсез булып күренми башлады.

Ашап туйгач, Карлен үзенең бая салып ыргыткан яраткан сәгате «Франк Мюллер»ны кулына киеп куйды, аннары тагын бер рюмка Петрович аракысын түнтәрде. Тәмам акылы ачыклангач, ул теге мәгълүматларны, танышып чыгу белән юк итәргә, дигән фәрманны исенә төшерде. Ихтимал, ЦРУдагы компьютер белгечләре үтә яшерен текстларның юк ителүен үзәккә шунда ук хәбәр итә торган берәр хәйлә уйлап тапканнардыр әле, шуңа күрә, Карлен, текстны укып бетерде дә, Америка Федераль резерв банкының серен, инструкциядә әйтелгәнчә, юкка чыгарды, сөртеп ташлады. Бу фәрманны үтәмәү үзәктә борчылу тудырырга да мөмкин иде, ул бит компьютеры янына берничә көн килеп тә карамаган иде. Йокысы бөтенләй качты аның, үзе дә тынычланды, залга чыгып, хай-энд стилендәге «Мутон Ротшильд» аудиосистемасын әкрен генә кабызып җибәрде, төн таңга авышканда «әрмән» йортының соңгы катында Владимир Спиваков оркестры башкаруында Вивальдиның гүзәл музыкасы яңгырый башлады. Парижда яздырып алган яңа компакт-дискын маэстро аңа култамга-автограф белән үзе бүләк иткән иде. Юк, ничек кенә әйтмә, тормыш матур!

Һәм кинәт кенә Карленның йомшап киткән миеннән бер уй йөгереп үтте, ул шундук айнып китте. Бу бары тик ЦРУның өметле агенты Норман башына гына килә алырлык уй иде, әйтерсең лә, аны Мәскәү үзгәртә дә башламаган, шәхесенең бернинди икегә аерылуы да юк. Ул әлеге искиткеч супербанкнотларның кайда басылганнарын кинәт аңлап алды шикелле. Болай көтмәгәндә зиһене ачылып китүе янә дә Иллинойстагы разведка мәктәбен исенә төшерүгә бәйле иде. Анда бер бик карт һәм хөрмәтле остаз укыта иде, элек үзе дә «граверлар» аулаучы булган, планетаның ялган долларлар басыла торган барлык кайнар нокталарын диярлек йөреп чыккан. Ул үзе әле полиглот та иде—әллә егерме бер, әллә егерме икеме чит тел белә, кытай, япон телләре өстенә хинди теленең бик күп диалектларын су кебек эчә иде. Нәкъ менә шул карт бервакыт пошынып: «Чын-чынлап сыйфатлы долларлар бары тик Америкага ачыктан-ачык яки яшерен каршы торучы илдә генә ясалырга мөмкин. Хакимият институтларының ярдәменнән тыш, безнең милли

валютабызны аерып ала алмаслык охшаш һәм күп күләмдә бастырып чыгарып булмый»,—диган иде.

Ләкин бу элекке тәҗрибәле агентның шәхси фикере генә иде, курсантлар әле соңыннан бу унайдан озак бәхәсләштеләр һәм бер уртак фикергә килә алмадылар. Күпчелек картның сөйләгәне белән килешә алмый, бу мәсьәләдә алга этәрүче көч дәүләт түгел, ә шәхси инициативалар кенә була ала, ди. Әмма менә хәзер генә, берничә ел үткәч, Мәскәү үзәгендә утырган Норман остазының хаклылыгын аңлады, ул аңа акылы белән барып җитмәде, ә бөтен җаны-тәне белән сизендетойды шикелле. Бу ышаныч шуннан да килә иде, ул бит хәзер Россиядә яши, бала чагыннан ук Чечняның нинди җир икәнен дә, чеченнәрнең кемнәр икәнен дә күреп-белеп үсте...

Әле иске Россиядә губернаторлар идарә иткән чорда ук Кавказда рус патшасының наместнигы—үзенә күрә вәкиле утырган, шул чакта ук инде тау халыклары арасында чеченнәрнекеннән дә биегрәк папаха киюче булмаган, алар беркем алдында да бил бөкмәгән, тирә-яктагы күршеләре аларның баскынчылык һөҗүмнәреннән җәфа чиккән—бу әле ерак булмаган тарих. Мөгаен, шундый горур-көчле булуларына таяныптыр, алар Россия белән йөз ел буена сугыш алып барганнар. Юкса Россиянең дә көчле чагы булган, урыс гаскәрләре французларны, төрекләрне тар-мар иткән, дөньяда җиңелмәс куркыныч көч булып саналган. Октябрь революциясе чеченнәрнең хокукларын күршеләре белән генә тигезләп калмаган, ә горур Чечнягә дә Россия Федерациясе составында автономия статусы гына биреп, аларны түбәнсеткән. Чөнки Ленин һәм аның көрәштәшләре союздаш республика булу өчен күрше чит дәүләтләр белән чиктәш булу кирәк дип санаганнар. Большевиклар юлбашчысының менә шундый нигезсез фикерләве алга таба бик күп халыкларның язмышын хәл иткән: чеченнәр, татарлар, башкортлар, Идел буе немецләре һәм башкалар, бер сәгать эчендә дигәндәй, икенче сортлы кешеләр булганнар да калганнар, аларның барысын түбәнсетеп рәнҗетә торган бер өердәге «милли азчылык» дигән рәсми атама белән генә атап йөртә башлаганнар. Әмма чеченнәр бервакытта да үзләрен икенче сортлы халык дип танымаган, борынгы ата-бабаларыннан калган җирләрендә яшәгән хәлдә, алар үз хокукларын кисү белән һич тә килешергә теләмәгән. Шулай итеп, ленинчыл большевиклар салып калдырган бомба сиксән ел буе пыскып яткан-яткан да, беренче мөмкинлек чыгу белән Чечня баш күтәргән, Россия кул астыннан ычкынырга тырыша башлаган.

Кремльдәге кайбер кешеләр Чечняне котыртып, сугышка этәреп торганнар, Советлар Союзы таркала башлагач, 1991 елда анда тау-тау корал калдырганнар. СССРны таркаткач, Кремльнең ул «геростратлары» шундый ук үрнәктә Россиянең үзен дә җимерергә, бүлгәләп бетерергә хыялланганнар. Һәм менә хәзер Чечня инде ничә ел үзен суверен бәйсез дәүләт дип игълан итеп, Россия белән ачыктан-ачык сугыш алып бара.

Чечнянең бәйсезлек сәясәтен алып баручылар үз уй-ниятләрендә ялгыштылар: алар Ичкериянең Россиядән аерылып чыгуын Көнбатыш хуплар дип уйлаган иде. Зур сәясәттә һәм дипломатиядә артык тәҗрибәләре булмаган чечен житәкчеләре бөек дәүләтләр арасында кайда, ничек үз йогынтыларын үткәрү турында тавыш-тынсыз гына килешүләр барлыгын белеп тә бетермәгәннәрдер, бәлки. Бер генә зур дәүләт тә Чечня аркасында Россия белән арасын бозмаячак. Җыелышкан-шаулашкан булырлар, гаепләп, төрле белдерүләр ясаячаклар, әмма эш шуннан ары узмаячак. Россиянең сәбәбен бик аңлатып-нитеп тормыйча гына, һәрвакыт теләсә кайсы илнең койрыгына басарлык мөмкинлеге бар. Чечен җитәкчеләре хәтта шуны да исәпкә алмады: Америка, Англия, Франция кебек дәүләтләр белән дустанә мөнәсәбәттә булган бик бай һәм абруйлы Япония дә ил үзәгеннән әллә кайда-еракта, Тын Океанда Россия флагы астында калган кечкенә генә дүрт утравын да кайтарып ала алмый. Ә болар Россиянең үз җиреннән,—әле кайдан диген?—Кавказдан бер өлешен кисеп алмакчы булалар.

Беркем, беркайчан һәм бер генә режим да Россия империясендә мона юл куймаячак.

Шушы вәзгыятьне сонга калыбрак аңлагач, кире-үҗәт Чечня Россия белән сугышырга кирәк дигән ин начар юлны сайлады, бер очтан, Чечнянен бәйсезлеген рәсми рәвештә танымыйча, гомер буе астыртын гына котыртып-өстереп торучы Американы да күрәлмәс булды.

Әгәр дә Чечня, хет хәзер, хет йөз ел элек булсын, беркайчан да Россия алдында кан калтырап тормаган икән, Америкага төкереп кенә карый да карый инде ул.

Карленга хәзер барысы да ачыкланды: Американы дошман санаган көчле-куәтлерәк һәм хак бәйсез дәүләтләрнең берсе дә эшләргә кыймаган гамәлгә—гасырның иң зур авантюрасына—АКШка каршы тәвәккәл этлек эшләргә Чечня нәкъ менә шул сәбәптән алынган да инде. Анда үзен бөтен дөньяның хуҗасы итеп тойган Американың ялган долларларын суга башлаганнар, берочтан беркем танымаган кечкенә ил—Ичкериянең финанс куәтен дә күтәрергә уйлаганнар. Чечнянең язмышына битараф булганы өчен Америкадан үч алу иде бу. Шуны да әйтергә кирәк, бик үткен-хәйләкәр, икеләтә үч бу—аның икенче башы бер үк вакытта Россиягә дә суга. Ялган долларлар кайда сугыла? Россия биләмәләрендә. Иртәмесоңмы, бу хәл Американың ачуын китерәчәк, ә ул үз мәнфәгатьләрен яклый белә торган ил. Россия исә чеченнәрнең бу финанс диверсиясенең тискәре йогынтысын Америкадан алданрак сизәчәк әле, чөнки бүген аның кинлекләрендә «рубль» түгел, ә доллар бәйрәм итә.

Көтмәгәндә башына килгән бу фикерләр Карленның аның яктыртып җибәрде, хәзер инде аны беркем дә ялган супербанкнотлар кайда да булса башка җирдә басыладыр, дип ышандыра алмый иде. Хәзер аның иманы камил: яшерен валюта цехы Терек елгасының аръягында—Ичкериядә! Кечкенә халыкның залим һәм битараф бар дөньяга даһиларча үче бу! Карлен кайсыдыр бер мизгелдә чеченнәргә хәтта сокланып та куйды...

Әлбәттә, ул ялган акча басуны нәкъ менә берәр чечен үзе оештыргандыр, дип бәхәсләшә алмый, гел әле киресенчәдер, әмма һичшиксез, алар күзәтүе астында, алар акчасына эшләнә бу эш. Чечнядәге «граверларның» Ливаннан, Иорданиядән, Сүриядән, Төркиядән килгән кешеләр булуы да ихтимал, ләкин барыннан да ышанычлырагы—алар үзебезнең берәр рус даһиен эзләп тапкан булырга тиеш, азмыни бу илдә танылмаган талантлар!

Карлен, мәсәлән, белә, әле күптән түгел генә Әзәрбайҗан наркомафиясе наркотик матдәләр әзерләүдә революция ясаган. Казандагы талантлы студент-химикларны эзләп табып, аларга шундый бурыч куйганнар: тиз әзерләнә торган, арзанлы һәм моңа кадәр билгеле булган наркотиклардан да куәтлерәк өр-яңа препарат-дару ясарга кирәк. Бу җәһәттән мәгълүматы булмаган кешеләр, әлбәттә, дөньяда инде дистәләрчә ел меңләгән яшерен экстра-лабораторияләр барын, алардагы катлаулы аппаратларда иң талантлы, әмма намуссыз галимнәр эшләгәнлеген белмиләр дә. Казан студентлары үз максатларына билгеләнгән вакыттан алданрак та ирешә—дөньяның иң күренекле белгеч-химиклары да, мондый препаратны, гомумән, ясап булмый дип расләп торганда, ясап та куялар. Кешелек дөньясының бәхетенәдер инде, КГБ хезмәткәрләре тырышлыгы белән яшь даһиларны тотып алалар, тегеләр зур-зур галимнәргә үз ачышларының серен сөйләп бирергә мәҗбүр була. Әгәр дә егетләрнең бу ачышы башка максатлар өчен ясалган булса, Нобель премиясенә лаек булыр иделәр, ә болай... аларга наркомафия нибарысы ике мең доллар чамасы акча бирә дә, аннары ашатулары бар инде.

Менә шундый ул Россия, атлаган саен даһилар анда... Чеченнәр дә, үз заманында байлыкларыннан симергән американнарның борынына чиртергә хыялланган Левша шикеллерәк, берәр яңа остаңы табып алган булырга мөмкин. Урысларның холык-табигатен алдан һич әйтеп бетереп,

аңлатып булмый аларның, монысын Карлен Мәскәүдә аңлады инде.

Шушы уй-фикерләреннән соң, Карлен, «граверлар» аулаучы башкалардан аермалы буларак, яшерен ялган акча сугу цехына үзенең бик нык якынайганын төшенде, әле супербанкнотлар турындагы хәбәрне алганчы ук дөрес юл сайлавын, эзләүне җинаятьчел дөнья аша башларга кирәклеген эчке бер сиземләү белән сизенүе өчен сөенеп тә куйды. Чечнягә юлны ул бирედә, Мәскәүдә дә эзләп тапкан булыр иде, ул чеченнәрнең банк һәм нефть бизнесын, автомобильләр базарын, бигрәк тә Көньяк портта автомашиналарны сату-алуны үз кулларында тотуын белә иде. Чит ил машиналарына сервис хезмәте күрсәтә торган үзәкнең хуҗасы да Хоза кушаматлы Николай Сөләйманов иде, ул исә чечен мафиясенең Мәскәүдәге лидерларыннан берсе. Карлен аңа нииндидер йомыш белән үзенең «мерседес»ында сугылып та чыккан иде әле.

Дүртенче каттагы дуслары сөйләвеннән белә, Чечнянең җинаятьчел дөньясы караклар законына буйсынмый икән. Чечен яшьләре төрмә һәм лагерьлар аша менәрләп үтеп торсалар да, Абрек сүзләренә караганда, алар анда да караклар гореф-гадәтен санга сукмый, ә яхшылык белән яманлык төшенчәсен үзләренчә, тау халыклары аңлаганча, аңлап яши икән. Мәскәүдә дә чечен җинаятьчеләре башкалардан аерылып тора: кыланмый-кәперәйми, юкка акча туздырмый, шау-шулы җәнҗаллар оештырмый, ләкин бик кыю, үтә тәвәккәл, яшен кебек житез, кансыз-мәрхәмәтсез һәм һәрвакыт беренче булып һөҗүм итә. Чеченнәрнең тагын бер мөһим сыйфаты, аларның, хәзергечә әйтсәк, аерым менталитеты бар, анысын Карлен башкаланың мәдәни элитасы белән аралашканда белде. Анда да мәскәүле чеченнәрнең танылганнары—мәсәлән, халык артисты биюче Мәхмүт Әсанбаев, шагыйрь һәм философ Вахит Итаев, академик Айдашев кебекләр үз куышын алып тора. Туган көненнән алып чеченның гомере, иң беренче чиратта, Аллаһы Тәгалә кулында, аннары халкыныкы, бары тик шуннан соң гына тудырган ата-анасыныкы һәм үзенеке исәпләнә икән. Бу һәр балага ана сөте белән керә, шунлыктан аларда ишетелмәгән-күрелмәгән бердәмлек, милләте, ватаны хакына һәрвакыт үзен корбан итәргә әзер тору бар. Рухани-дини шәех сүзе, аксакаллар шурасы сүзе—закон һәм аны тикшереп, бәя бирергә ярамый. Кызганыч ки, бик күп халыкларга житенкерәмәгән асыл сыйфатлар болар.

Әмма, теләгәндә, әгәр максатың һәм үҗәтлегең-ныклыгың булса, чеченнәр күнеленә дә юл салып була. Автосервис хуҗасы Хозаның Крис һәм Абрек белән ничек итагатьле сөйләшкәнен Карлен үзе күреп торды. Үз вакытында легендар Сво агай яраткан бу энекәшләрен Хоза белән үзе таныштырып калдырган, әйтерсең лә, чечен мафиясенең Мәскәүдә тиздән бик югары күтәреләсен алдан сизенгән, диярсең.

Ләкин Карлен Татлян, Хозага яки башка чеченнәргә якыная алса да, Чечняга юл әлегә барыбер ябык булачак, чеченнәрдән бер көч белән генә бернәрсә дә алу мөмкин түгел, моны ничектер башкача эшләргә кирәк. Сугыш юлы белән, әйтик. Россия белән арасын бөтенләй өзгән һәм каты каршылыкка кергән хәзерге шартларда, анда башкача берничек тә керә алмыйсың, чит-ятларны анда бер чакрымнан күреп торалар. Карлен уйлаган максат-миссия белән Ичкериягә барып тыгылсаң, исән әйләнеп кайтуыңа өметенне өз...

Вакытның ничек узганын да сизмичә, Карлен фетнәле Чечнягә үтеп керү юлларын озак эзләде, анда үткәч, ялган долларлар суга торган яшерен цехны да эзләп табасы бар бит әле. Һәм шунысы сәер, үзенең ялган акча сугучыларның кайда икәнлеген ачуы, әгәр барыр юлын табып булса, анда ничек үтеп керергә кирәклеге турында ЦРУдагы шефларына хәбәр итүне Норман уйлап та карамады. Мондый уй аның башына да кереп чыкмады. Ул бу цехны, андагы Левшаны бары үзе өчен генә эзләп табарга теләи, чөнки ялган супер-банкнотларны бернинди хәвефсез туздырырга мөмкинлекне язмыш аңа үзе бирде, ул Американың Федераль резерв банкы серен белгән бик аз кешеләрнең берсе булып чыкты.

Хәзер аның уңышы бары тик үзеннән генә тора, ә ярдәмгә ул дүртенче катта яшәүче дусларын теләсә кайчан чакыра ала—кулга төшергән акчалар барысына да гомер буена житәрлек булырга тиеш...

## Кутузов проспектындагы дәрт-теләкләр

### I

Париждан әйләнеп кайткач, Мәскәү кышы Тогларга элекке елларын хәтерләтте. Гыйнвар карлы һәм салкын, кӧтелмәгән жепшетү-тамчыларсыз, тигез-тыныч кына булды. Коммуналь хужалык хезмәткәрләренең «гөнаһларын» кар көртләре каплап киткәч, шәһәр матурланып, ничектер яшәреп калды шикелле. Ул бигрәк тә иртәләрен, төнлә кар явып үткәннән соң, саф һәм ак булып кала иде.

Кутузов проспектындагы ремонт, бүлмәләрне үзгәртеп кору, Георгий-Эйнштейн фаразлаганча, шактый озакка сузылды. Сузылуының сәбәбе—галәмәт зур «сталинка»ның баскыч алды мәйданчыгында өчтән ике өлешен ныклап торып яңадан эшләргә кирәк булудан килеп чыкты.

Шулай да Константин Николаевич моңа борчылмады: «Булгач, булсын инде...»—дип кенә фикер йөртте. Аның Кутузов проспектына күчәргә ашыкмавы, ремонтка да тыныч мөнәсәбәте шуннан да килә иде: ул «Метрополь»дә менә дигән итеп оялады, рәхәтләнеп яшәп ята. Мәскәүнең иң яхшы отеленең икенче катындагы номеры Тоглар өчен ожмах кебек иде инде. Бай кунакларга тәгаенләп эшләнгән биш йолдызлы отельләрдә тормыш бик тиз халыкара стандартларга яраклаштырылган иде. Бәлки әле, Парижга сәяхәтләре дә, Тогларга тормышның яңа офыкларын ачып, ремонт һәм күченүне бик ашыктырмаска этәреш биргәндер. Ул бит Натальясы белән тагын кая да булса очып барып кайта ала—дөнья, баксаң, шулкадәр гүзәл һәм төрледән-төрле икән, аңа юллар да хәзер бик жиңел ачыла, Константин Николаевич бу кадәресенә хәтта берара күнегеп бетә алмый да торды. Әмма Парижда үткәргән көннәрен, «Леди-Астор»дагы кичәне исенә төшерә дә, алда нинди гүзәллекләр ачарга мөмкинлеген күреп, куана—акчаң гына булсын! Хәзер ул, мәсәлән, белеп тора, әйтик, бүген, февраль ае башында, Россиядәге кышның әле очы-кырые күренмәгән бер мәлдә, тотасың да Тын Океандагы берәр утрауга яки Һинд Океаны ягына—ел буе жәй булган экваторга очасың. Әлеге дә баягы, бөтен совет халкы бары тик телевизордан Юрий Сенкевичның «Сәяхәтчеләр клубы» тапшыруында гына күреп белгән, яки, күп дигәндә, диңгез сәяхәтләре һәм пиратлар турындагы китаплардан гына укыган һәм исемнәре үк колакны иркәли торган утрауларга: Фиджи, Таити, Тасмания, Сейшель, Мальдив... Океаниянең дистәләрчә эреле-ваклы утрауларына барып чыгасың... Болар һәммәсе дә күңелдә матур бер көй булып яңгырый, әмма хәзер инде гомергә дә анда аяк басып булмас әкият булып күренми. Әлбәттә, гашыйк Тогларның бу гүзәл дөнья читләрен үзенең мәгъшукасына күрсәтәсе, ул жирләргә рәссам күзе белән карыйсы килә, анда бит бөтенләй башка төс-буяулар, башка яктылык, башкача чынбарлык! Ләкин Наталья, Тоглар белән көн саен диярлек телефоннан сөйләшеп торса да, Ростовын бер атнага да ташлап, авыру әнисен ялгыз калдырып китә алмый шул. Аннары, үз сүзләренә караганда, эшендә дә мәшәкатьләр житәрлек икән. Мода—бик иркә-каприз нәрсә бит ул: февральдә аларның кибет-салонына тикшерү өчен яңа Париждан Робер Платт килүен көтәләр, ул яңа кием үрнәкләре дә алып киләчәк, имеш. Кыскасы, түземсезлек белән көтәргә дә көтәргә генә кала. Юкса, Тоглар Натальяга Кристиан Лакруа фирмасындагы эшен ташлап кит, дип берничә мәртәбә әйтеп карады. Кайбер көннәрдә, бигрәк тә сагыш-моң баскан мәлләрдә, Тоглар үзе генә Ростовка барып кайтырга талпына, әмма Наталья аны тыеп кала, уңайлырак вакытларны

көтик инде, ди. Константин Николаевичның бер генә юанычы бар: Париждан кайтып, Натальяны Ростов рейсына утыртып җибәргәндә, ул аның яраткан сумочкасына, үзенә сиздерми генә, шактый саллы долларлар төргәге салган иде—алар, мөгаен, әнисе авырып ятканда, хәзер бик тә ярап куйгандыр әле.

Парижда йөреп кайтканнан соң, Тоглар иске тамырдаш-корешлары белән бик аз очраша башлады, хаҗәте дә чыкмый иде. Дөрес, ничектер бер мәртәбә ул шунда, «Метрополь»дә үк үзеннән ике кат өстәрәк яшәп яткан Дантеска сугылып чыкты. Париж өчен рәхмәтен дә әйтте һәм, әгәр мөмкин булса, Наталья белән үзе өчен чит илләргә эш белән чыгып йөрерлек хезмәт паспортларын да булдыруын үтенде. Андый ксиваларның чит илләргә еш йөрүче кешеләр өчен нинди өстенлекләр бирүен ул бик тиз аңлап алган иде инде. Кутузов проспектындагы квартирасына күчеп, Натальяга өйләнеп тә җибәрсә, дөнья белән ныклап танышырга кирәк дигән ныклы карарга килгән иде ул. Бу фикере бигрәк тә Франциядән соң ныгыды.

Тоглар шактый еш, даими дип әйтергә дә була, бары тик Городецкий белән генә очрашып тора. Аргентинлы да «Метрополь»гә Дантес янына еш килә, алар шунда кунакханәнең берәр номерында яки Дантесның үз апартаментларында тәүлекләр буе кәрт сугалар. Кайвакытларда Аргентинлы, көтмәгәндә генә ишелеп килеп керә—анысы үзенең даһи компаньоны Эйнштейнны эзләгән чакларында була. Городецкий Тогларны өенә дә еш чакыра: ул кунаклар җыярга ярата, үзе әйтмешли, бер компания булып, бәйрәмчә матур итеп кәеф-сафа корып утыруга ни җитә! Нәрсә әйтмәк кирәк, тынгысыз Аргентинлы, дөньяның артына тибеп яшәүче шат күңелле кеше күз алдында картаеп килә шул, еллар хәзер аны тыныч, җайлы-уңайлы йортына күбрәк тарта, ә үз йортын һәм гаиләсен бик тә ярата иде ул.

Городецкий Тогларның ремонтланып-үзгәртелеп яткан квартирасын да карап чыкты, дустының колачына хәйран калды, әмма көнләшминитми генә әйтеп куйды:

—Әйе, туган, зурдан купкансың син! Минем мактаулы квартирам синеке янында мескен алачык шикелле генә булып кала инде. Сиземәм, «чехларны» төп башына бик каты утыртып киткәнсең, молодец!

Ул күреп-белеп тора иде, Тоглар Кавказ әсирлегеннән соң үзенең иске һөнәрен ташлады, кем әйтмешли, аны «бәйләп-төйнәп» куйды. Шушындый зур ремонтка тотынган икән, димәк, житәрлек байлыгы бар, аннары күнелендә дә рәсем-картиналар һәм күргәзмәләрдән башка нәрсә юк шикелле. Хәер, Городецкий моның шулай булуына куана гына, ул үзе дә хәзер һәртөрле уйлап житкерелмәгән авантюраларга тармагаем дип курка, саклана. Картлык көненә кадәр тыныч кына яшәренә ышанып, ул хәзер зурдан кубып кәрт уйнарга бик бай томана мокытларны гына сайлый, андыйларны аңа ышанычлы кешеләре,—яңадан гомергә дә кулларына кәрт алмаска ант иткән элекке картежниклар табып бирә, бушлай түгел, билгеле, өлеш чыгарырга туры килә аларга да.

Бервакыт зур гына отыш китергән шундый уеннарның берсеннән соң, төшенкелеккә бирелүне белмәс Аргентинлы көтмәгәндә генә көрсенеп:

—Их, кызганыч, юләр мин, тормышта берәр түрә-чиновник булып утырасы урында, шушы кәрт уйнау белән мавыгып киткәнмен, ә мин бит чит телләр институтын тәмамлаган кеше...—диде.

Тоглар гаҗәпләнеп кашларын җыерды, Аргентинлыга кызык булып китте бу:

—Әйе, әйе, нәкъ шулай! Дәүләт хезмәте буенча китәргә кирәк иде миңа. Акча дип әйтерлек акчалар шунда гына әйләнә, ә чын чиновниклар миллиардларны көрәп ала. Син ничек уйлыйсың, бюджеттан яки президент указы белән бүлеп бирелгән акчаны алу бик җиңелдер, дипме? Менә белмәдең. Сиңа тиеш дигәне—ул әле буш сүз. Бүлеп бирелгән сумманың унбиш-егерме процентын түрәләргә кире кайтарып бирмәдеңме, син үз

акчаларынны беркайчан да ала алмаячаксын. Хәтта синең өлкәңдә, төбәгеңдә шуның аркасында заводларың туктасын, эш хакы ала алмыйча, кешеләрең ач утырсын—барыбер. Алларына сораганнарын китереп салсаң—алырсың, ә инде тибенергә итенсәң, хакым бар, фәлән-төгән, дисәң, яки сораганнарыннан бер генә тиен аз бирсәң—үзеңне юләргә чыгарып куячаклар: бөтен халык алдында бюджеттан бүлеп бирелгән акчаны да ала алмыйсың бит, диячәкләр. Ә триллионнардан алынгач унбиш-егерме процент, Тоглар кадерлем, миллионнар гына түгел ул, ә миллиардлар! Россиядәге бүгенге демократик түрә-чиновник менә кем ул, менә нинди ул!

—Шундый хәлләр чынлап та буламы?—Тоглар яңа тормышның андый кискен борылышларына һаман да гаҗәпләнүеннән арына алмый иде әле. Ләкин Городецкий да юкны сөйләмәс. Чынлап та, шулайдыр шул, хәзерге тормыш—анасын ормыш!

—Әйе, туган, тормыштан бик нык артка калгансың син...—Городецкий, бокалындагы очкынланып торган шәрабне учларында җылыта-җылыта, кәнәфиенә җәелеп утырды.—Син минем кемнәр белән кәрт тәгәрәткәнемне беләсеңме? Банкирлар, эшмәкәрләр, нефть магнатлары, сәүдәгәрләр, законлы караклар, аферистлар яки ювелирлар беләнме? Юк, ялгышасың... Андыйлар җитди уеннардан төшеп калдылар, алар белән мин ике-өч ел уйнамыйм инде. Мин хәзер бары тик дәүләт чиновниклары белән генә тәгәрәтәм-шудырам. Хәер, минем үземне дә шундый чиновник дип таныштыралар.—Ул канәгатьлек белән көлеп җибәрде.—Мин бюджетны ягу-энергия ресурслары хисабыннан суырам—казнадан иң симез калҗа шунда төшә хәзер, шуңа күрә дә мин алар компаниясендә көтелгән кунак саналам. Дөрес, моның өчен миңа вакыт-вакыт акыллы кыяфәт белән тиешле министрлыкларда булгаларга, иртәгә уйныйсы кешеләремнең күзләренә чалынып калырга туры килә. Бу эштә минем спектакль куючы режиссерларым Мейерхольд белән Таиров ишеләр генә түгел... ассистентларым да даһилар. Син күрсәң икән, иң кирәкле мизгелдә бер хезмәткәр пәйда була да, бар кварталга ишетелерлек итеп пышылдап, миңа хәбәр итә: сезне ярты сәгатьтән министр көтә яки сезгә «Инкомбанк»тан Владимир Виноградов очрашу билгеләде, яки «Кредобанк»тан Юрий Агапов, ди. Мондый сүзләрнең тәэсире, мин сиңа әйтим, кирәгеннән дә артык була, бигрәк тә чиновниклар арасында—алар дәрәҗәле кешеләрне хөрмәт итә, алар өчен кәнәфи—акча синонимы ул. Мин үземнең режиссер һәм ассистентларыма да һәр отышымнан егерме процентны чыгарып салам, нәрсәдер яшереп калдырудан яки онытудан Аллам сакласын! Икенче уенны күзләрен күгәргәнче көтәрсең әле, җитмәсә, үзеңнән штраф түләтергә дә мөмкиннәр. Ай кыеңга китә башлады бу кәрт уеннары, тизрәк пенсиягә чыгып, процентларга гына яши башлыйсы иде,—дип хыялланып, көрсенеп алды Аргентинлы.—Ләкин тиздән, эшемне һәм бер сынык икмәгемне югалтмас өчен миңа чит илдә йорт сатып алырга туры киләчәк—Кипрдамы, Англиядәме яки. Болар, кабахәтләр, шул якларга күче-күче белән күченергә җыенып, йорт-җир алалар инде, оешып-укмашып утыралар, ул-бу була калса, бер-берсенә тотыныр-ышыкланыр җай эзлиләр, аннары аракыны да бергәләп эчү күңеллерәк бит. Алар мине дә үзләре яныннан урын эзләргә өндиләр, үз итеп инде—чыгымнар тотмый булмас шул. Син күз алдына китерә аласыңмы аларның анда нинди акчалар күчергәннәрен?!

—Сиңа ярап булмас: урлашмасалар—уйнар кешең юк. Урлашсалар—Россияне талыйлар, дисең,—дип шаяртты Тоглар һәм икесе дә чын күңелдән кычкырып көлеп җибәрде.

Тоглар көн саен диярлек Георгий Эйнштейн белән дә очрашып тора. Парижга фестивальгә барып кайткач һәм бигрәк тә Георгий үзенең балет белән мавыгуларын да сөйләгәч, алар бик якынаеп киттеләр, юкса Константин Николаевич аңа үзенең элекке тормышы турында—ләм-мим!—бернәрсә дә сөйләгәне юк. Аларның аннан башка да сөйләшер сүзләре күп иде.

Кайвакытларда Фешинны табигать тарта, кышкы урман-кырларны күрәсе килә аның. Һәм ул йә ялгызы гына, йә шул ук Георгий белән Переделкинодагы йортына китеп бара. Переделкинодагы ул аерым йортлар кайчандыр Сталин приказы белән язучылар өчен салынган, алар әйбәт итеп, яхшы архитекторлар проекты буенча эшләнгән. Тоглар сатып алган йорт күренекле архитектор Шехтельнең яраткан укучысы Курбатов проекты буенча төзелгән, диләр.

Язучылар шәһәрчеге тирәсенә зур-зур хәрби начальниклар, маршаллар, адмиралларның да дачалары урнашкан, шуңа күрәдерме, шәһәрчек үзәктән жылытыла һәм анда ел дәвамында яшәргә була иде. Ул кышын да, яз-жәй-көз айларындагы кебек үк, гүзәл-матур иде. Тоглар, икенче катның почмак бүлмәсендәге каминны ягып жибәреп, учактагы биешкән ялкыннарга карап, эңгер-меңгердә озаклап утырырга ярата—бу жанга рәхәт сәгатьләрдә, сумалалы нарат утыннарның күңелле четердәп януын күзәтеп утырганда башка шундый жиңел һәм якты уйлар килә. Кышкы урманның берәр борылыш чатыннан көтмәгәндә генә әкрен атлап поши килеп чыгар төсле тоела. Әтисенең әллә кайчан инде район Пионерлар йортында биргән дәресләреннән соң, шушы Переделкинода Тоглар беренче мәртәбә майлы буяу белән язып карарга тырышты. Ләкин саф һавада, карлы урманда этюдлар язу аңа бик авыр бирелә иде, мөгаен, күз алдында һәрвакыт бабасының картиналары торганга күрәдер инде. Бабасы бит кышкы табигать күренешләрен киндергә төшерүдә беркем кабатлый алмаслык оста булган. Нәкъ менә шунысы Тогларга шатлык китерми дә: акылы-зәвыгы белән ул бабасының иҗатын аңлар дәрәҗәгә барып житте житүен, әмма ничәмә еллар буе кулына пумала тотып карамаган килеш, үз эшләрендә камил уңышка ирешү мөмкин түгел иде, билгеле. Шулай да ул тоя-сизә: аның уңышлары алда әле...

Булачак гаилә оясын рәткә кертеп бетерү мәшәкатьләре, ыгы-зыгылар, кар күмеп киткән Переделкинога барып кайтулар, һәр кич саен диярлек телефоннан Натальяга шылтыратып сөйләшүләр белән февраль ае да үтеп китте. Һәм көннәрдән бер көнне ашыкмас дизайнер Виленкин, Сигезенче Март бәйрәменә йорт әзер булачак, дип белдерде. Ә сөйләшенгәнчә, мебель, савыт-саба тезеп, тәрәзәгә ак ефәк ламбрекеннар элеп, бөтенләй жиһазлап-бизәп бетерү өчен ана әле тагын бер ай кирәк булачак икән, чөнки бар кирәк-яракны әзерләү төрле фирмаларга бирелгән иде. Әзер әйберләр килә, урыннарына урнаша тора торгач, квартиралар бөтенләй башкача сулыш ала башлады. Итальяннар ике квартирада да искиткеч матур яктырткычлар көйләп куйды, немецлар ике кухняны жиһазлады, финнәр исә ванна бүлмәләрен һәм санузелларны... Кыскасы, йорт хәзер хуҗабикәсен генә көтеп калды...

Шул көнне үк Тоглар Натальяны Мәскәүгә өч кенә көнгә булса да килеп китәргә килештерде, аны зур сюрприз көтә дип вәгъдә бирде. Наталья өч көнгә килеп китәргә риза булды—әнисе әле һаман да хастаханәдә ята иде.

## 2

Шул кичтә, мәгъшукасы белән сөйләшкәннән соң, Фешин, шатланып кулларын уа-уа, бүлмәсендә әрле-бирле йөренеп, бу озак көтелгән вакыйганы ничектер билгеләп үтәргә кирәк, дип баш ватып торганда, телефон шылтырады. Гыйнвар аенда Фешин Мәскәү елгасы аръягындагы бер кечкенә антиквар кибетенә кереп чыккан иде һәм кибет хуҗасына: «Николай Иванович Фешин картиналарын таба алмассызмы?»—дип, үтенеч калдырган иде.

Шул кибет хуҗасы шылтырата икән,ул ышанмаслык хәбәр әйтте: «Бүген,—диде,—бер үк көнне Идел буендагы дүрт шәһәрдән, шул исәптән, Казаннан да, дүрт кеше академик Фешинның картиналарын китерде. Ике ай элек салынган ау юмарт табышлы булды»,—диде.

Тыныч холыклы, үзен һәрвакыт кулда тота ала торган Константин Николаевич дулкынлануыннан хәтта лып итеп кәнәфигә утырды, телдән калды, аннары, һушына килеп, антиквар карттан, соң булуга да карамастан, аның өенә хәзер үк барырга рөхсәт сорады. Тоглар Фешиннар өчен тарихи булачак бу төндә барыбер йоклый алмаячагын белде. Антиквар карт шул үз кибетенең бишенче катында гына яши икән: «Инде түземегез төкәнсә, берәр сәгатьтән килегез»,—диде.

Билгеләнгән вакытта, минутка-минут, Тоглар каралмаган, ташландык йортның әллә нинди сасы исләр килеп торган бишенче катындагы караңгы һәм пычрак баскыч мәйданчыгына күтәрелде һәм кыршылып беткән ишекнең кыңгырау төймәсенә дулкынланып басты. Әгәр дә Тоглар инде ярты еллап «Метрополь»дә яшәмәсә һәм Аргентинлыныкы кебек зиннәтле-матур квартираларда булгаламаса, ул мондагы пычракка да, сасы исләргә дә игътибар итмәс иде; кеше яхшыга да, начарга да бик тиз күнегә—Фешин моны үз тәҗрибәсеннән чыгып белә иде инде.

Картның квартирасы кибетенең дәвамы шикеллерәк, төгәлрәк әйткәндә, экспонатлары ара-тирә бер киштәдән икенчесенә күчерелеп йөргән музейны хәтерләтә икән. Башка вакыт, башка шартларда килгән чагы булса, Константин Николаевич антикварның бу хәзинәләрен, һичшиксез, игътибар беләнрәк карап та чыккан булыр иде, ләкин бүген аны тик бер нәрсә генә—бабасының картиналары гына кызыксындыра. Кунагының Казан рәссамы картиналарын тизрәк күрергә ашкынганын тоеп, хуҗа аны яп-якты зур гына залга алып кереп китте. Тәрәзә пәрдәләре ябык, шунда—арадагы биек диван аркасына ике картина сөяп куелган, тагын икесе сул як дивар буендагы сырлап ясалган зур комод шкафы янында тора иде. Дүртесе дә—иске рамнарда үзләре.

Константин Николаевич башта кайсысына барып тотынырга белмәде, аяклары аны алга да, сулга да тарткандай, бераз таптанып торгач, кинәт куанып китеп, ул тәрәзә буена атлады. Күзләре картиналарның берсендә сурәтләнгән чибәр яшь хатын йөзенә текәлде, бу хатын, ихтимал, очрашуга яки кунакка барырга әзерләнәдер, ә бәлки, сөйгәнен көтеп бизәнә-ясанадыр. Гасыр башында еш кына шундый алым кулланылган бит: рәссам сурәтне көзгедә күренә торган итеп язган, яки көзге аша төп сурәт артында тагын ни-нәрсәләр барын да күрсәтергә теләгән. Фешин шундук Эдуард Маненың «Фоли-Бержердагы кафе-бар» дигән атаклы картинасын исенә төшерде. Биредә дә рәссам шул ук алымны файдаланган. Константин Николаевич бай, үз гореф-йолалары белән яшәгән йортның ерак калган тыныч еллары сулышын тойган кебек булды. Үзенең тойгыларын раслагандай, ул авторның иркен, ачык итеп язылган фамилиясе янында картинаның язылган елын да укыды—1913. Картинадан сизелер-сизелмәс кенә импрессионистлар йогынтысы күренеп тора, анысы гаҗәп тә түгел: ул елларда аларның иң дан тоткан, төрле фикерләр уяткан заманнары, әмма игътибар беләнрәк караганда, төсләрдә булсын, композициядә булсын, шулай ук язу техникасында булсын, урыс мәктәбе традициясе тоела, ә сизелер-сизелмәс кенә француз серлелеге рәсемгә тагын да сокландыргыч төсмер өсти иде.

Икенче картина Константин Николаевичка таныштрак-гадәтләнелгәнрәк күренешне сурәтли, мона охшаш эшләрне ул Казан музееның Николай Фешинга багышланган залында күргән иде инде. Матур кышкы табигать, ялган классик стильдәге багана-колонналары булган сәүдәгәр йорты, каралты-куралары белән мәңгеләштерелгән. Йортның калай түбәсе кызгылт төстә, түбә кыекларыннан янгыр сулары агып төшәргә куелган нәфис торбалар һәм очып китәрдәй җинел челтәрле болдыр баскычлары... авыр тимер капка, өстенә бераз гына кар яуган зур чыршы... Якындагы киртәгә ике ат бәйләнгән—мәңгелеккә югалган, әмма рәссамнең ышанычлы буяу пумаласы белән гасырларга сурәтләп калдырган заман... Мондый картина-рәсемнәр бер үк вакытта куандыра да, моң-сагышка да сала. Мөгаен, натурадан күчереп алынган шушы сурәт-күренешне без, яратып,

туган ил, Ватан, Россия дип атыйбыздыр да...

Калган ике картина уеп-сырлап эшләнгән кара комод янында, идәндә иде. Константин Николаевич аларны күтәреп, диванга күчереп куйды—анда яктылык әйбәтрәк, отышлырак иде. Бер рәсемдә ялангач яшь хатын сурәтләнгән, сәнгатькярләр теле белән әйткәндә—«ню». Монысы шундук Ренуарның французларга хас булмаган тулы, хәтта безнең хәзерге зәвык өчен дә артык юан гәүдәле хатын-кыз сурәтләрен хәтерләтә. Әмма җәйге жете кояш яктысы белән балкытылган мунча алдында басып торган бу хатыннан яшьлек дәрте ташый, рәссам аның тышкы төс-кыяфәтенә артык тукталмаган да, ә сыгылмалы матур гәүдәсен, бераз кыланчыкландырып, баш түбәсенә саксыз гына төйнәп куйган куе матур коңгырт чәчләрен, баш артына күтәргән, очып китәрдәй җинел кулларын тәфсилләп сурәтләгән. Картинадан гаҗәеп сафлык-тотнаклылык бөркелеп торуы таңга калдыра, хәер, гасыр башында хәтта шушындый тыйнак кына рәсем дә артык кыю булып тоелырга һәм сәнгатькә ортодоксаль бәя бирүче кемсәләр тарафыннан тәнкыйть утына тотылырга мөмкин булган бит. Рәссам Фешин һәрвакыт алсу-сирень һәм ак төсләрне сизгер тойган, шуна күрә гүзәл хатынның яшь-таза тәне төсен ул бик оста язган, ә гүзәл исә рәсемне тутырып тора, мөгаен, шунлыктан картина уңышлы килеп чыккандыр да.

Константин Николаевич карый башлаган соңгы картинада шулай ук гасыр башында бик модада булган һәм Россиягә Европадан импрессионистлар тарафыннан кертелгән шәһәр күренеше иде. Казан, бигрәк тә аның үзәге, тарихи өлеше, Рим шикелле үк, калкулыкларга урнашкан бит. Бу юлы рәссам бик үзенчәлекле алым сайлаган. Шәһәр күренеше югарыга—тауга табан күтәрелеп менгән йортлар-биналарны сурәтләмәгән, ә киресенчә, үзәк урамнан аска, чокырлыкка төшеп киткән ноктадан алып эшләгән, түбәндә—иң төптә дә, тау битләрендә дә искиткеч архитектуралы йортлар, төрле төстәге түбәле корылмалар бакчаларга күмелеп утыра—мәңгелеккә китеп югалган тормышның күңелне айкап ала торган күренеше...

Бу рәсемнәрнең дә авторның ачык имзасы янында язылган еллары бар: 1912 һәм 1911 еллар. Дүрт картина да кешелекне көткән гарасатлы вакыйгалар алдыннан, әмма әле Россиядә дә тыныч заманнарда, беркем дә беренче бөтендөнья сугышын, революцияләрне, гражданнар сугышын көтмәгән чорда иҗат ителгән. Николай Иванович Фешин үзе дә ул чакларда гомере чит-ят илдә үтәр һәм шунда үлеп калырмын дип күз алдына китерә алмагандыр. Константин Николаевич, карашын бер картинадан икенчесенә күчерә-күчерә, диванның әле бер башына, әле икенче башына таба атлап йөри дә йөри иде, ниһаять, хуҗа карт ана утырырга бик яхшы сакланган венский урындык тәкъдим итте. Хәзер инде ул бабасының картиналары алдында, аның теге яки бу рәсемне язган чагында күңелендә туган тойгыларын чамаларга тырышып утыра. Көтмәгәндә башында шундый уй туды: рәссам Фешин ул вакытта, беренче бөтендөнья сугышы башланганчы, Костяның әбисе Елизавета Матвеевна белән таныш булдымы икән инде, елларны исәпләп карагач, юктыр дигән фикергә килде—ул вакытта аның әбисе әле консерватория студенткасы булган. Константин Николаевич тагын шунысын да уйлап утырды: Елизавета Матвеевна бу хезмәтләрне күрдеме икән, ул аларны ошаттымы икән?.. Кайсыдыр мизгелләрдә Константин Николаевич үзенең кайда һәм ни өчен утырганын да онытты, вакытның үткәнен дә сизмәде. Шулай онытылып утыруыннан аны картның тавышы айнытып җибәрде—кара, ул бик озак утырган ич, тышта төн уртасы, март башы булуга карамастан, ябалак-ябалак кар ява.

—Йә ничек, ошадыларамы бу эшләр сезгә?—Картның соравында борчылу да, өмет тә бар иде. Күрәсең, ул бу картиналарны эзләүчеләрнең барысына да клиент житди кеше: алдамас, дип вәгъдә биргән булгандыр.

—Рәхмәт,—диде Тоглар дулкынланган тавыш белән.—Бик-бик

ошадылар. Сезгә нинди рәхмәтләр әйтергә дә белмим, Кузьма Митрофанович. Гомерем буе сезгә бурычлы булырмын...—Ул кесәсеннән «Картье» фирмасына визиткалар белән бергә заказ биреп, алтыннан монограммасын сугып ясаткан портмонесын чыгарды.—Сезнең мәшәкатьләрегез һәм хезмәтләрегез өчен күпме түләргә тиешмен?

Антиквар карт, каушый-курка гына үз бәясен әйткәч, Тоглар ана тагын шактый гына акча өстәде дә:

—Ә монысы миннән шәхсән үзегезгә рәхмәт йөзеннән,—диде. Гадәттә акчаларны санап ала торган карт, бу юлы санарга да кыймыйча, сорап куйды:

—Әгәр дә бу рәссамнең тагын башка хезмәтләре табылса, нишләргә, сезне эзләргәме?

—Әлбәттә, Кузьма Митрофанович. Бабамның күпме генә картиналары табылса да,—мин хәзер бу хакта әйтә алам инде,—мин бик шатланып сезгә бурычлы булыр идем...

Шулай килешеп, алар төн уртасы авышкач кына аерылыштылар.

Константин Николаевич ул төннең калган өлешен дә йоклап үткәрә алмады. Үзе әйтмешли, Ходай Тәгаләдән иңгән бу картиналарны номерына алып кайткач, ул аларны үзенең өч бүлмәле люксының әле бер бүлмәсенә, әле икенчесенә элеп куя-куя, аларга сокланып карап йөрде. Иртә таңнан, инде уятырга вакыттыр дип, Эйнштейнга һәм дизайнер Виленкинга чылтыратты, аларны тиз генә үзенә килергә чакырды. Тоглар алар белән шатлыгын уртаклашырга ашкына иде: аңа нәселдән мирас булып калган картиналар Фешинның яңа йортына туплана башлады бит...

## 3

Наталья хатын-кызлар бәйрәме көнендә беренче рейс белән үк килеп төште. Сигезенче Март алдыннан аларның кибетендә төнгә кадәр Кристиан Лакруаның сәүдә йортыннан Робер Платт алып килгән соңгы мода язгы кием-салым сатканнар, халык кырылып алган. Французлар урысларның бер мәкален яхшы үзләштергән икән: кашык әбәт вакытында кыйммәт. Сәүдәдә моны белеп эш итү, әлбәттә, төшемле, уңышлы була. Тоглар үзенең сөйгәнен Георгий белән бергәләп аэропортта каршылады. Голландиядән махсус кайтарткан зур матур чәчәк бәйләме Домодедовадагы һәркемнең күзенә бәрелеп тора иде, юкса ул көнне бик күпләр үз якыннарын каршыларга чәчәкләр тотып килгән—ни әйтсәң дә, хатын-кызлар көне, бәйрәм ич! Бу юлы багажларны гадәттәгедән шактый озаграк көттергән аэропорттан туптуры «Метрополь»гә кайтып керделәр, анда озак юанмыйча,—Наталья төзәтенеп-бизәнеп, үзен рәткә китергәнче генә!—Городецкийларга көндезге ашка киттеләр—анда аларны бәйрәмчә бизәлгән табын көтеп тора иде инде.

Аргентинлыны Константин Николаевич Натальяга элекке дусты һәм бизнес буенча кулдашы дип тәкъдим итте, ә хуҗаның йорты исә кызның һушын китәрде. Ул мондый күркәмлек-зиннәтлелекне күрергә һич өмет итмәгән иде: иркенлек, квартираның бүленеше, аның җиһазлары, камин залы, верандадагы кышкы чәчәк-гөлләр бакчасы—оранжерея—барысы да әкияттәгечә иде. Йорт хуҗасы:

—Йә, ничек? Кунакка минем бунгалом ошыймы?—дип сорагач, Наталья шулай җавап бирде дә:

—Нәкъ әкияттәгечә!—диде.

Аргентинлы канәгатьләнеп елмайды, әмма, шулай да Тогларга күз кыры белән генә карап алса да, аның иске дусты үзенең сөеклесенә нинди апартаментлар әзерләгәнен әйтми калдырды.

Городецкийларда озаклап, иркенләп кәеф-сафа корып утырдылар—җылы, рәхәт, Константин Николаевичның дуслары Натальяны чын күңелдән үз-якын итеп кабул иткәне тоела. Тәкәллефле һәм сүзгә бер дә

кесәгә кермәс үткен телле йорт хуҗасының Тоглар белән дуслыгының кадерен белүе, аны бәяләве сизелеп тора, шушы хәл Натальяның да күнелен горурлык белән тулыландыра, аңа, үзен килеп керә-керешкә үк, Мәскәүдә бик югары абруй-дәрәҗәле кешеләр арасына алдылар кебек тоела иде. Аргентинлы яшәгән төбәк тә, аның квартирасы да, дөньяда андый квартиралар барын ишетеп-күреп белмәгән Натальяга, болар һәммәсе дә бары тик күктәге фәрештәләр өчен генә булырга тиештер шикелле тоела иде.

Городецкийларга килеп җитәрәк, Константин Николаевич күршедәге шундый ук, әмма бинаның алгы өлешенә истәлекле такта кадакланган йортка күрсәтеп, әйтеп куйган иде: «Биредә Брежнев яшәгән. Ә аның янәшәсендәге йортта Андропов вафат булган...» Городецкий яшәгән йортның алгы өлешендә дә Наталья граниттан һәм авыр бронзадан коелган берничә такта күреп узды: аларга да кемнәрнеңдер исем-фамилияләрен һәм туган-үлгән елларын язып куйганнар, ләкин кыз: «Монда кемнәр яшәгән?»—дип сорарга уңайсызланды, соңгы мәртәбә килүләре булмас, әле сорарга өлгерермен, дип уйлады. Аларны менә шундый атаклы-абруйлы йортта кунак иттеләр.

Алар «Метрополь»гә бик соңлап кайтты һәм бу кичтә башка бер җиргә дә бармады, юкса, Натальяны каршы алган чакта Константин Николаевич Городецкийлардан соң берәр төнге клубка да кереп чыгу турында уйланган иде—аның мәгъшукасы биергә бик ярата икән бит, анысын Тоглар үзе өчен әле Парижда ук ачып кайткан иде. Кунакханәгә кайтып, бәйрәм концертын телевизордан карар өчен, икәүләп диванга җайлап утыргач, Наталья, мөгаен, кунакчыл Городецкийлар йортында күргәннәре тәэсиреннән арынып җитмичәдер, бер үк вакытта көнләшеп тә, моңсуланып та, һәрхәлдә Тоглар өчен һич көтелмәгәндә әйтеп куйды:

—Синең дусларыңда миңа нинди рәхәт булганын белсәң иде... Ул йортлары, дисеңме, ул гаиләләре... Алар ничек матур итеп бер-берсен сөя...

—Чык миңа кияүгә, без дә шулай яшәячәкбез. Уйлавымча, безнең балаларыбыз да начар булмас, әниләре коеп куйган бер гүзәл бит,—дип, Тоглар аны кысып коча төште.

Ләкин, күрәсең, Городецкийлардагы рәхәт-бәхетле тормыш яшь кызга шул кадәр тәэсир иткән иде, ахрысы, ул, яшерми-нитми, ачынып әйтеп ташлады:

—Ә без синең белән кайда яшәрбез соң?.. «Метрополь»нең шушы номерындамы? Минем үз йортымны булдырасым, шунда кунаклар кабул итәсем килә... Мин бит бер тапкыр кияүдә булган идем инде, чит-ят фатирларда яшәп изаланган идем. Шуннан соң йорт-җирсез кешегә гомергә дә кияүгә чыкмам, дип ант иттем, гомер бит бер генә, анысы да аккан су кебек ага да китә...

—Соң, без бу мәсьәләне, мөгаен, ничек тә булса чишәрбез. Беләсеңме, бу очракта икебезнең дә уй-ниятләребез, Аллага шөкер, бер икән. Минем дә үз йортымда гаиләм белән яшисем, кунаклар кабул итәсем, балалар үстерәсем килә...—дип җавап бирде Константин Николаевич һәм шул ук вакытта беренче мәртәбә Натальяның йөзендә ниндидер ерткычлык, усаллык, гел үз мәнфәгатен акыл белән генә башкарасы килү теләге чагылып киткәнен тойды. Бу хис-уйлар аның сөйгәне турында инде күз алдына китереп уйлаганнарыннан шактый аерылып тора иде шикелле. Ләкин башында туган бу уе тамыр җибәреп өлгерә алмый калды, чөнки шул мизгелдә мәгъшукасы, аны иркә кочаклап, тәкъдимнәре өчен рәхмәт әйтә-әйтә, үбә башлады. Бу гамәл Тогларның күңелендә туган шикле уйларын куып та җибәрде. Шулай да Константин Николаевич Кутузов проспектындагы әзер апартаментларының серен ул көнне тәки ачмады, юкса берничә мәртәбә,—аэропорттан кайтканда да, Городецкийларда кунакта утырганда да,—шуны әйтеп ычкындырырга теле бик кычытып торса да, ниндидер үзенә буйсынмас эчке бер тыю туктатып калды шикелле.

Иртә белән ресторанга төшеп ашап-эчеп утырганда, Тоглар күнелле генә итеп:

—Ә мин бит сине Ростовыннан Мәскәүгә ымсындырып чакырганда, бер сюрприз-бүләк вәгъдә иткән идем, ә син шуны искә дә төшермәден,—дигән булды.

—Мин исә синен дустын Городецкийларда кунак булуны шул сюрприз дип уйлаган идем,—дип, жилкәсен генә сикертеп куйды Наталья.—Мин аларда үткәргән кичебездән бик канәгатьмен, рәхмәт сина. Әгәр дә мине бүген дә шундыйрак бәрәр шатлык көтә икән, димәк, син мина икеләтә сюрприз әзерләдем, дип уйла.

—Ну, анысын үзен хөкем итәрсен инде,—дип бераз томанлы гына жавап бирде Тоглар.—Әгәр ошаса, шул сина ин төп сюрприз булыр. Һәрхәлдә, тырышмадым түгел, тырышкан идем...

Кунакханә каршысындагы автомобильләр арасыннан үзенен «порше»сын кузгатып, Константин Николаевич Натальяны янә Кутузов проспектына алып китте. Городецкийлар яши торган йортка бик охшаш икенче йортка килеп житкәндә, Наталья бу йортнын да алгы ягында кара һәм соры граниттан куелган ике барельеф һәм тагын вакытлар узу белән яшелләнә төшкән өч бронза истәлекле такта барлыгын искәртеп, ясалма соклану белән:

—Димәк, без янә кунакка киләбез?—дигән булды. Үзенен күзе биек парадный баскычта униформадан басып торган сакчыда иде.

—Сюрприз кунакта гына да булмаска мөмкин, түз бераз,—дип көлемсерәде Тоглар һәм тиз йөрешле лифтнын чакыру төймәсенә басты.

Алар алтынчы катнын иркен баскыч алдына чыктылар. Анда бары тик ике генә квартира ишеге бар һәм икесе дә Константин Николаевичныкы булганга күрә, дизайнер Виленкин аны бик әйбәтләп тәртипкә китереп куйган иде инде. Тәртип дигәнен катгый-нәзәкатле, озак елларга житәрлек итеп эшләнгән: ин сирәк очрый торган кара мәрмәр төсендәге эре шакмак плиткәләр түшәмгә кадәр ябыштырылган, диварлары менә дигән итеп шомартылган имән такталардан, идәннәре мәнге купмаслык-кипмәслек тыгыз паркеттан. Ике квартира да Тогларныкы булса да, аларга керү ишекләре килеш-килбәте белән дә, йөзлекләренен төсе белән дә, бигрәк тә шомартылган-ялтыратылган тотка-фәләннәре, йозак тишекләре белән дә аерылып тора иде. Салон-ашханәгә керәсе ишек калын гына чикләвек агачыннан ясалган булса да, анын өсте түгәрәкләндереп пыяла белән капланган, көн яктысында ут яндырмыйча да квартираны танымаслык итеп яктыртып тора һәм ул остаханә-салонның шулай булуы рәссам өчен бик тә кирәк иде.

Әлбәттә, Городецкийларнын да баскыч алды мәйданчыгы да, ишек төпләре дә бик чиста һәм пөхтә, ләкин Тогларныкы белән барыбер чагыштырырлык түгел, халык әйтмешли, жир белән күк арасы иде инде. Мәйданчыкка чыгып баскач, Константин Николаевич әүвәл кайсы ишекне ачып, Натальяны кайсы квартирага алып керергә белмичә, бер мәлгә аптырап калды. Ниһаять, ул остаханә-салонга керә торган ишеккә караганда тыйнаграк күренгән, әмма барыбер ике якка ачыла торган итеп, тоташ имәннән ясалган һәм эре калибрлы пулеметтан да атып тишмәслек сигез миллиметрлы калын корыч каплама куелган ишек янына килде—бу ишекне Англиядә ясатып кайтарганнар иде. Ишекне ачкач, Тоглар кин күнеллелек белән Натальяны өйгә чакырды.

—Кем сарае бу?—дип югалыбрак һәм нәрсәгәдер куркып сорап куйды Наталья. Аны шундый күркәм зиннәтлелек чорнап алган ки, ул, нәрсәне булса да бәрелеп ватармын дигәндәй, кая басарга да белмичә аптырап тора иде.

Анын югалып калуын күргәч, Константин Николаевич күнелле генә итеп:

—Син кичә үз өен, үз кухнян турында нидер сөйләнгән иден бугай. Менә, мина шушындый квартира тәкъдим итәләр, ә мин синен

ризалыгыннан башка ничек җавап бирергә дә белмим,—диде.—Карап чык әле, зинһар, кухнясын гына булса да, бәлки, берәр җирен үзгәртергә, нәрсәләрдер өстәргә кирәктер, ә?

Иркен алгы бүлмәдә чишендергәч, ул аны кулыннан тотып, ялтырап торган паркет идәннән атлата-атлата, кухня дип аталган егерме биш квадрат метрлы бүлмәгә җитәкләп алып керде. Наталья болай җиһазландырылган кухнялар булганлыгын хәтта күз алдына да китерә алмый иде—зур гына чит ил суыткычы, микродулкынлы электр миче, сигез комфоркалы һәм табалар тыгып пешерешле газ плитәсе—ул әле, җитмәсә, хром-никелле әллә ничәмә төрле кнопка-фәләннәр белән эшләнгән!—шуңа күрә космик аппаратларга охшашы булган мондый әкәмәтләрне гомергә дә күргәне булмаганлыктан, кыз бөтенләй югалып кала язды. Әле тагын шунда ук савыт-саба юк машинасы һәм ни өчен куелганлыгын әлеге Тоглар үзе дә белмәгән әллә нинди башка нәмәрсәкәйләр дә бар иде. Наталья бары тик бер нәрсәгә генә игътибар итә алды—боларның һәммәсендә дә бер фирма—«Сименс» тамгасы тора иде. Константин Николаевич теге зур суыткыч янына килде дә, аны ачып җибәреп:

—Сина азык-төлегеңне сакларга җитәрдер бу,—диде. Аннары газ плитәсенең кабызгычына бер генә басты, плитә үзеннән-үзе кабынып китте. Әмма кызның андый пьезоэлементлар куеп эшләнгән газ плитәләре турында ишеткәне бар иде инде.

Наталья кыюлана төште, хромланган боргычлы югыч янына килеп, аның ике боргычын да ачып карады—гөжләп салкын һәм кайнар су ага башлады.

Константин Николаевич биек аркалы авыр дүрт урындыкның берсен тартыбрак куйды да:

—Менә бу урындык минеке булыр, каршы килмисенме?—диде.

—Ә мин, сине яхшырак күрер һәм плитә янына якынрак булыр өчен, менә монысына утырырмын,—дип шукланып җавап бирде Наталья. Ул инде Тогларның күңелле кәефен абайлап, уенга кушылып киткән иде.

Аннары алар залны, камин мичле бүлмәне карап чыктылар. Соңгысы кызга бигрәк тә ошады: хатын-кызга һәрвакыт нәрсә житми?—Җылы! Тән һәм җан җылысы кирәк аларга. Аңа бигрәк тә төсле венециан пыяласыннан әкияти кошка охшатып эшләнгән люстра, бүлмә почмакларына шуңа ук яраштырып куелган торшер—кыскасы, итальян дизайнерлары югары зәвык белән җиһазлаган бу бүлмә тулысы белән ошаган иде һәм йортның булачак хуҗабикәсе боларның барысын да сокланып кабул итте—сокланып таң калуларын күзәтеп торган Константин Николаевичка да бу үзенчә бер рәхәтлек бирә иде. Камин мичле бу залдан, әле тулысынча җиһазланып бетмәгән булса да, Натальяның һич тә тиз генә чыгып китәсе килмәде. Ләкин Константин Николаевич: «Әле бу йортта син күрәсе шактый нәрсәләр бар»,—дип, аны икенче бүлмәгә алып чыгып китте. Анысы исә китапханә—эш бүлмәсе булып чыкты. Бу бүлмә башкаларына караганда күбрәк җиһазландырылган булса да, Тоглар монда әле ике бүлекле авыр язу өстәле, утырып эшләрлек кәнәфи һәм күн диванлы, журнал өстәлле тулы бер җиһаз куелып житмәгәнен әйтеп узды.

Завод микрорайонындагы эшче гаиләсендә туып үскән Наталья Зиминаның ни үзләрендә, ни дус кызларында бу кадәр күп китаплы бүлмәне күргәне юк иде әле. Авыл китапханәләрен әйткән дә юк инде, шәһәр китапханәләренең дә һәрберсе мондый байлык белән мактана алмас иде. Сүз хәтта бик сайлап җыелган сирәк китаплар—раритетлар турында да бармый, гап-гади сан ягыннан да бу китапханә таңга калдырырлык иде. Шул кадәр күп фолиантлы китапханәдә ни өчендер Натальяга күңелсез-унайсызрак булып китте һәм, түшәмгә кадәр китап киштәләре арасындагы бер бушрак диварны, андагы өсте түгәрәкләнеп килгән ишекне күреп, кыз сорап куярга ашыкты:

—Ә бу ишек кая алып чыга? Тагын бер бүлмә бармыни әле?—диде.

Ул инде ал бүлмәләр, кунак бүлмәләре һәм башка бүлмәләрнен санын югалткан иде...

—Ә без хәзер кереп карарбыз,—дигән булды Константин Николаевич, серле генә итеп һәм кызны култыклап алып шул яшерен ишеккә таба алып китте—яшерен булса да, кызыксынучан һәм бар нәрсәне күрүчән хатын-кыз халкыннан нәрсәне яшереп калып була соң? Алдагы бүлмәнең тавыш-тынсыз гына ачыла торган ишеген ачып килеп кергәч, алар тагын бер тылсымлы, камин мичле бүлмәгә барып чыктылар. Ләкин бу камин миче кечкенәрәк тә һәм гадирәк тә иде, күренеп тора: ул кунаклар чакырып, гәпләшеп утырыр өчен түгел, ә ялгызың гына калып, сәгатьләр буе уйланып утырыр өчен ясалган иде.

—Без тагын бер квартирага барып кердек, дип уйлыйм мин. Шулай түгелме?—дип, Наталья Константин Николаевичка сорау бирергә дә өлгермәде, тегесе аны алгы бүлмәгә чакыра иде инде.—Йә, Ходаем!—дип аһылдап куйды Наталья, алгы бүлмәгә кереп, андагы бөтен диварны ине-буе белән каплап торган бер рәсем-картинаны күргәч. Ул исә Эдуард Шаһиевның Константин Николаевич сатып алган «Эстет төше» дигән эше иде.

Рәсем чынлап та игътибарны үзенә тарта—бик зур зәвык белән рамланган, менә дигән итеп яктыртып куелган бу әсәр искиткеч гүзәл булып күренеп тора иде.

Ишек алдына карап торган тәрәзәне дүрт мәртәбә кинәйткәннәр һәм бөтен кырый дивар тоташ тәрәзә булып калган: тәрәзә рамнарын шундый итеп үреп ясаганнар ки, алар кояш әйләнеше буенча һәр сәгатьтә остаханәне тигез яктыртып тора иде. Шуна күрә, бу бүлмәнең гадәти яшәү бүлмәсе түгел икәнлеген Наталья да аңлап алды һәм үзенең рәссам остаханәсенә килеп кергәнлеген төшенде. Мәскәүдә яшәүче атаклы татар сюрреалисты Эдуард Шаһиев картинасыннан көч-хәл белән аерылып, Наталья кинәт кенә әле мольбертка беркетеп кенә куелган ялангач хатын-кыз сурәтен күрде һәм ирексездән шунда таба атлады, аннары барып житкәч кенә, анда тагын җәйге вә кышкы табигать күренешләрен абайлап алды. Рәсемнәр кызга бик ошады, әмма ниндидер эчке бер тойгы белән картиналарның остаханәгә юкка гына эленеп куелмаган икәнлеген аңлады, аларның шулай икәнлеге әллә кайдан күренеп тора, бирелә һәр калак уйлап кагылган—һәм кыз, дәшми-тынмый гына, башка картиналарны карарга кереште, бәлки, алары мондагы серләрне ачар дип уйлады булса кирәк. Ул күргән бу борынгы рәсем-картиналарның әлеге йорт хуҗасына ничектер берәр катнашы-мөнәсәбәте бардыр дип уйларга аның башына да килмәде. Шулай да рәсемнәрне карап йөргәндә, ул бер үк останың кулы икәнлеген тойды, әйтергә кирәк, Наталья, рәсем сәнгатен бик үк аңлап бетермәсә дә, Константин Николаевичның да рәссам булганлыгын сизенә башлаган иде инде. Карап йөргән рәсемнәрнең читенә язып куелган «Фешин» сүзен укыгач, кинәт кенә кызның башына барып житте: Константин Николаевичның да фамилиясе Фешин бит! Наталья «Н. И. Фешин» дип имзаланган бер рәсем каршысында тукталып калды: «Фешин... Фешин... Фешин... Россиядә сирәк очрый торган фамилия бу»... Шуннан соң Наталья иң башта караган рәсем янына янадан әйләнеп килде дә, тын гына үзен күзәтеп торган Константин Николаевичка борылды:

—Синең әтиең шушындый матур рәсемнәр ясый алганмы?—дип сорамыйча булдыра алмады ул.

—Юк,—диде кызны кочагына алган Тоглар тыныч кына итеп.—Болар—минем бабамның иҗаты, академик рәссам Николай Иванович Фешин эшләре. Ә рәсемне ясамыйлар—язалар! Исеңдә калдыр: я-за-лар... Рәссамнар телендә һәм рәсем сәнгатендә ул шулай әйтелә.

Унай вакыттан файдаланып:

—Ә синең әтиең кем булган?—дип сорады Наталья.

—Ул да рәссам булган. Чын рәссам,—дип җавап бирде Константин Николаевич.—Ул безне, рәсемнәрен базарга чыгарып сатып, ашатып-

туендырып торды. Сугыштан соңгы бик авыр еллар иде бит... Бик кызганыч, ул нибары кырык яшендә үлеп китте... Сугышта алган яраларыннан мантый алмады...

—Син миңа бу хакта бер дә сөйләмәгән идең,—дип, ризасызлык белдереп, Наталья инсәләрен сикертте дә, аның кочагыннан чыкты.

—Сөйләргә сәбәбе чыкмый торды бит. Үпкәләмә. Бүген менә җае чыкты... Мин сиңа кичә өйләнергә тәкъдим ясаганымны онытмадыңмы?

—Сина элек бабаңнарныкы булган квартираны кайтарып бирделәрмени?—дип, Тогларның соравын читләп үтмәкче булды Наталья. Аның өчен барысы да бик көтелмәгәндә килеп чыкты бит: бу йорт та, рәсем-картиналар да, зәвыклы һәм бай итеп эшләнгән ремонт та, әле куеласы җиһазлар да—карап йөргән унайга Константин Николаевич кайда нәрсәләр куеласын сөйләп барды ич.

—Алай түгел, Наташа,—дип башын чайкап алды Тоглар.—Кутузов проспектындагы бу йортлар Сталин заманнарыннан калган, ул чорда шулай иркенләп, гомерлек итеп төзегәннәр. Ә Фешиннар тумышлары белән Казанныкы булган, шунда минем бабам да, әбием дә, әтием дә туган. Шунда үскәннәр, яшәгәннәр. Хәзер Казанда исән-сау калган беркемем дә юк инде... Әмма Казандагы Татарстан дәүләт музеенда махсус Фешин залы бар! Без ничек тә бер анда икәүләп барырбыз әле, яме? Ә мин Казакъстанның көнбатышында, Мартук дигән бер ерак шәһәрчектә туып үскәнмен. Әтием белән әниемнең дә каберләре шунда... Менә минем бөтен шәҗәрәм шул,—дип, күрсенеп куйды ул. —Бөтенесен дә янадан башларбыз. Мин ышанам, синең белән бергә икәүләп кайчандыр Россиядә атаклы булган Фешиннар токымын яңадан аякка бастырырбыз әле без: әлбәттә син риза булсаң гына...

—Мин әле Ростовта чакта ук синең тормышыңда ниндидер сер барын тойган идем, әмма аның фамилияңә, шәҗәрәңә кагылышы бардыр дип уйламадым,—дип, күңел төбендәгесен әйтеп бирде Наталья. Константин Николаевичка сарыла төшеп.

—Әйе, шулайдыр шул. Мин дә үземдә рәсем сәнгатенә омтылыш сизәм, рәсемнәр язасым килә. Элекке тормышым башкачарак булды шул, киндерләр, мольбертлар кайгысы юк иде анда. Хәзер менә үз мөмкинлекләремне сынап карыйсым килә, бәлки, берәр юнь килеп чыгар, ә? Син каршы түгелме?—дип шаяртып куйды Тоглар соныннан.

—Юк, әлбәттә,—дип житди жавап бирде Наталья, болар анын өчен бөтенләй көтелмәгән хәлләр иде.—Күңелең ята икән, рәхәтләнеп яса-яз! Шундый нәселдән килгән сәләтең булгач, нигә аны сынап карамаска, ди?—Ул тирә-ягына күз йөгертте.—Остаханәң дә миңа бик ошый, биредә шундый уңайлы, матур, яп-якты!

—Алайса, квартираны карап бетерик инде, ошармы-юкмы—син хәл итәсе бит,—дип шаярткан булды Тоглар мәгъшукасына.—Күп калмады инде, хәер, биредә дә кухнясы, ваннасы, йокларга калырга теләсәләр, кунаклар өчен йокы бүлмәсе дә бар. Кем белә, көтмәстән синең туганнарың килеп төшәргә мөмкин. Ә минем американ туганнарны, әгәр дә алар була калса, эзләп табасы бар әле...—дип, сүзен моңаеп кына йомгаклап куйды Константин Николаевич.

—Кухня—минем яраткан урыным инде,—дип кабынып китте бу зиннәтле-гүзәл йортның булачак хуҗабикәсе.—Әйдә, күрсәт!—дип, күңелле генә итеп боерып та куйды әле хәтта.

Студия-остаханәнең кухнясы теге бүлмәдәгенекеннән шактый кайтышрак—ни бары уналты-унжиде генә квадрат метрлы булса да, Натальяның әле моңа кадәр күреп үскән кухня бүлмәләреннән ике мәртәбә зуррак иде. Ванна бүлмәсе дә, кухнясы да, кунаклар кабул итү бүлмәсенә дә бу якта башка төрле төсләргә буялган һәм башкача җиһазландырып, яктыртылган икән. Мәсәлән, кухнясы немец фирмасы «Бош» җиһазларыннан тора. Константин Николаевич Германия техникасына, Италия мебельләренә, Англия савыт-сабаларына, Швейцария сәгатьләренә,

Франция шәрабләренә һәрвакыт өстенлек бирә һәм булачак хуҗабикә Наталья моны исендә тотарга тиеш иде.

Натальяга бигрәк тә матур итеп яктыртылган алгы бүлмә ошады, яктылык бирегә өсте түгәрәкләнеп ясалган ишек өстеннән төшә, архитектор-дизайнерның шулай уйлап эшләве нәтиҗәсендә, квартира һава һәм яктылык белән тулып тора иде. Һәм, әлбәттә, әле кичә генә үзенең исен-акылын китәргән Городецкийлар квартирасы моның белән чагыштырырлык та түгел иде. Константин Николаевич аны нәкъ шулай булсын дип уйлаган да иде. Наталья, ниһаять, соңлап булса да, һаман-һаман сюрприз турында ни өчен шулай сөйләнгәнен аңлады шикелле: мондый сюрпризлар кызыйның хыялында да тумас, төшенә дә кермәс иде... Ә биредә—барысы да күз алдында. Кайсыдыр бер мизгелдә Наталья үзен шушы йортта кунаклар, үзенең дусларын, туган-тумачаларын кабул итүче буларак хис итте. Үзенең туачак балаларын да шушы йортта тәрбияләп үстерәчәген күз алдына китерде. Аңа Константин Николаевич юкка гына:

—Борынгы Фешиннар нәселен без икәү дәвам итәчәкбез,—дип әйтмәде ич.

Ул исә, шунда ук куанып, хәйләсез-нисез генә әйтеп ташлады:

—Эш миннән генә тора икән, биредә барысы да миңа бик ошый, бер генә нәрсәне дә алыштырасым, урыныннан кузгатасым килми. Рәхмәт, кадерлем, минем өчен бу, чынлап та, көтелмәгән искиткеч сюрприз булды, моңа кадәр мине әле берәүнең дә бу кадәр куандыра алганы юк иде,—диде.

—Бәйрәм көнегездә күңелеңне күтәрә алганым белән мин бик бәхетле, минем бүләгем сиңа хуш килгән икән—мин бик шатмын,—дип, Константин Николаевич, картларча итеп, аның алдында тәкәллефле генә башын иеп куйды.—Әйдә, кунакханәгә кайтыйк та, машинаны шунда калдырып, җәяүләп кенә Мәскәү буйлап йөрик әле. Мин сиңа бер гаҗәеп антиквар кибетен күрсәтермен, аның хуҗасы Кузьма Митрофанович белән таныштырырмын, аннары без бер испан ресторанында ашап чыгарбыз, син ничектер бервакыт Ростовта, Испания нәрсәсе беләндер үзенә тарта, дип сөйләгән идең шикелле...

Алар тагын бүлмәләр буйлап китте, Наталья янә үзенә ошаган картиналар, гравюралар каршысында озаклап тукталып торды, камин мичле зур залның галәмәт тәрәзәсе янына барып, биек түшәмдәге искитәрлек люстраларын бер кабызып-бер сүндереп дигәндәй, урам һәм ишегалдын күзәтеп торды, тагын бер мәртәбә кухняга кереп чыкты—дөресен әйткәндә, аның моннан һич чыгып китәсе килми иде әле... Кайсыдыр мизгелләрдә аның «Бу минем йортым! Бу минем йортым!»—дип, буш бүлмәләрдәге тынлыкны бозып, куанып-сөенеп кычкырып куясы да килде.

Ишек төбендәге бүлмә алдында, Парижда французларны таң калдырган алтынсу манто тунын кигезгәндә, Тоглар аны кочаклап алды да, колагыннан үбеп сорап куйды:

—Йә, әйт, миңа кияүгә чыгасыңмы? Үзең күрдең, квартира мәсьәләсе хәл ителгән...—диде.

Наталья аңа бәхетле елмаеп борылды да, оялып кына:

—Әйе, сөеклем, мин Фешиннар нәселен дәвам итәргә ризамын...—диде.

Испан ресторанында «Реал»да соңлап башлаган әбәт ашлары әкренләп кичке ашка әйләнде, әмма Тоглар белән Наталья вакытның узганын да, урамда караңгы төшеп, юеш кар ява башлаганын да сизмәделәр—алар икесе дә бәхетле, чөнки Натальяның туган көненә—егерменче апрельгә туй көнен дә билгеләп куйган иделәр.

Ырым-шырымнарга ышанучан Наталья кайсыдыр гороскоптан укып белгән: килененнең туган көненә билгеләнгән туйлар әкәмәт бәхетле була икән, имеш. Ул бит инде бер мәртәбә май аенда кияүгә чыгып караган да, шул ышануларга фараз кылсаң, бәхетле була алмаган—аерылышканнар... Хәзер инде ул икенче мәртәбә уйламыйча гына, андый башсызлыкка

бармаячак. Константин Николаевич аның бу дәлилләрен елмаеп кына тыңлап торды һәм Наталья кайсы вакытка билгеләсә дә, шуңа риза икәнлеген белдерде.

### 4

Һәммәсе дә булачак киленкәйнең уйлаганынча барып чыкты, тик вакыты һәм купшы-бай туй үткәрү уй-ниятләре генә шактый үзгәрде. Март ае азагында, Наталья «Астория» кибетендәге эшләрен тапшырып йөргәндә, табиблар авыру рәтләнү ягында, дип ышандыруларына карамастан, әнисе шул хастаханәдә үлеп китте. Константин Николаевичка да ашыгыч кына очып барырга—кайнана була алмый калган карчыкка матур гына күмү һәм искә алу үткәрергә туры килде—носари динендәге гадәтләрне ул гына боза алмый иде бит инде. Хәзер мәрхүмнең кырыгы тулмыйча һәм шул көнне искә алу мәҗлесе үткәрмичә торып, туй турында авыз ачып сүз дә әйтергә ярамый, бу гамәл һәр икесенә дә гөнаһлы булып күренәсе көн кебек ачык иде. Хәер, бик ул кадәр ашыгырлык эш тә күренми: бергә ашый-эчәләр, бергә йоклыйлар—тагын нәрсә кирәк? Шулай итеп, Наталья Кутузов проспектындагы йортына, алдан уйланганга каршы килеп булса да, никахлашмыйча гына килен булып төште. Әнисенең өчесе, җидесе, кырыгын да Ростовта, үзләре яшәгән «Редиссон-Ростов» кунакханәсендә, үзләре тәүге бәхетле көннәрен-төннәрен үткәргән бүлмәдә уздырдылар, нәкъ шул бүлмәгә, чечен әсирлегеннән бик ансат котылып, Тоглар кайтып төшкән иде бит.

Үзе туып үскән, шунда егерме тугыз елын яшәгән Ростовыннан Наталья кызгану-офтанусыз гына аерылды. Әнисе дә үлеп киткәч, аны бу шәһәр белән бәйләп торган соңгы җеп өзелгән иде инде. «Без хәзер синең белән икебез дә ятимнәр...»,—дигән иде Наталья Тогларга, әнисен җирләп кайткан көнне.

Апрельгә билгеләнгән туй көнен, әнисен җирләгәннән соң, кырыгы якынлашкан май аен да үткәреп җибәрә башлагач, алар икесе дә ныклап уйга калды. Бетеп килә торган май аена булачак килен кеше тешетырнагы белән каршы төште, чөнки нәкъ май аенда чыгып, аның бер мәртәбә авызы пешкән иде бит инде. Җәйге айлар исә үзеннән-үзе төшеп кала, чөнки, Наталья уйлавынча, җәйге айлар һәрвакыт бәхетсез була икән. Шулай итеп, алар өйләнешүне августның икенче яртысына, көзгә табарак күчерергә булдылар. Анда инде кешеләр дә ял итеп, яныппешеп, каралып, җегәр җыеп кайткан чак була. Бу юлы да Эйнштейн-Георгий үзенең акыллы киңәше белән бик үзенчәлекле юл тапты: туй сәяхәтен киресенчә эшләргә—башта дөнья күреп, кайда булса да, диңгез буенда ял итәргә, аннары берәр чиркәүгә кереп, Ростов килене теләгәнчә, никахлашып чыгарга, дигән фикер әйтте. Бу көтелмәгән уй-фикер булачак килен белән кияүнең һәр икесенең дә йөрәгенә май булып якты. Алар, бергәләшеп, рәхәтлекне файдалы итеп үткәрерлек сәяхәт кылырдай урыннарны өйрәнә башладылар.

Ике атна дигәндә, кая барасыларын тәгаенләп, виза-билет мәсьәләләрен, барып төшкәч, кайсы кунакханәгә урнашасыларын да хәл иткәч, июнь башларында Тоглар белән Наталья Испаниягә китеп бардылар. Кутузов проспектындагы квартираларында вакытлыча Эйнштейнны калдырдылар—ул, чираттагы аерылышуыннан соң, йорт-җирсез калган һәм, кайда туры килсә, шунда куноп йөри, адресын алмаштырырга җыенган чагы иде. Үз квартирасының ачкычларын биргәндә, Тогларның бердәнбер үтенече генә булды: бу йортта беркайчан да кәрт уйнамыйсың, диде. Баксаң, шундый ырым бар икән—акча-фәләнгә кәрт уйнаган йорт бәхетсез була, анда кайгы-хәсрәт, күз яшьләре килеп тула икән.

Испаниядән башланган ике айлык сәяхәтләре, нәкъ үзләре Мәскәүдә уйлаганча ук, Фиджи утравында тәмамланды. Анда аларга шул тиклем ошады ки, һичшиксез, бирегә кышын—гыйнвар аенда да килергә кирәк

икән, дигән карарга килделәр һәм ташкала-башкалага Дакар аша түгел, Париждан кайтырга булдылар.

Килен буласы Наталья барыбер үзенең элекке фирмасы Кристиан Лакруада туй күлмәге тектерәсе һәм тагын хатын-кызлар өчен кирәкле нинди-дер вак-төякләр аласы итте. Сәяхәт-сәфәр вакытында ул төрле хатын-кызларның ничек киенеп йөргәнлеген күргәндер дә, үз киемсалымын да янартасы килгәндер—хатын-кыз күнелендә ни-нәрсә барлыгын ир-ат гомергә дә анлап бетерәсе түгел. Парижда да алар шул элек килеп төшкән кунакханәдә тукталдылар, аннары, телефоннан чылтыратып, мсье Жак белән сөйләшеп алдылар, тегесе, үз туганнарын күреп сөйләшкәндәй, бик шатланды, билгеле. Парижда Яна ел кичен матур итеп үткәргәннәрен исләренә төшереп, яңадан шул «Леди Астор» ресторанына барып чыкмакчы булдылар. Натальяның чәчәк аткандагы болындай балкып китүен күргәч, үзе дә бәхетле Константин Николаевич, булачак хатынын тагын ни белән дә шатландырырга белмичә:

—Әгәр сиңа Париж бик ошый икән—без бирелә дә абруйлы берәр районда квартира сатып ала алабыз бит,—алар бирелә Мәскәүдәгеләрдән шактый арзанрак та,—дип әйтеп салды.—Теләгәндә, кил дә тор шунда...

Аның бу сүзләрен көтмәгән Наталья, ашыгып һәм курку беләнрәк, Тоглар көтмәгәнчәрәк җавап бирде:

—Юк, Парижда гына була күрмәсен, мин Францияне яратмыйм,—диде.

Константин Николаевичның йөзендә гаҗәпләнү билгеләре күргәч, ул анлатырга ашыкты:—Париж елдан-ел Мәскәүнең өч вокзалы мәйданына әйләнә бара—кемнәрдер килә-китә, узып барышлый, тукталып кына ала шикелле. Аннары, Парижның үзендә чын французлар да кими бара төсле, гел негрлар да гарәпләр, африканлылар да марокканлылар, филлипинлылар да вьетнамлылар, ә хәзер исә безнең Рәсәй фәхишәләре меңләгән бандитлар белән бергә ябырылды. Кайдадыр Испаниядә, мисалга, Марабельеда йорт сатып алсак, ул миңа куаныч булыр иде. Һавасы менә дигән, дингезе аяк астында, меңләгән яшеллек һәм тирә-юнендә гел байлар гына, юк, кадерлем, Парижда безгә квартира да, йорт та кирәкми. Бергә йөреп кайтырга, музей-күргәзмәләрен карап чыгарга, яки, менә хәзерге шикелле, кайдандыр ерак сәяхәтләрдән кайтып барышлый, кибетләренә кереп чыгарга ярыйдыр...

Соңыннан бу сөйләшүне Тоглар еш исенә төшерәчәк... Ләкин соң булыр. Ә ул чагында Тоглар кызның ышанычлы дәлилләре белән килешкән һәм Европа үзәгендә дә бер квартира сатып алу уеннан кире кайткан иде инде...

## 5

Алар Мәскәүнең иң матур һәм халык иң күп йөри торган Елоховский чиркәвендә никахлаштылар, бирелә хәтта еш кына дәүләтнең иң абруй-дәрәҗәле зур түрәләре дә, ә пасха һәм раштуа көннәрендә Президент үзе дә булгалый икән.

Булачак никахлашу һәм туйны оештыру мәшәкатьләре Эйнштейнга йөкләнгән булса да, башкаланың шундый атаклы чиркәвендә шундый тантана башкаруны ул, әлбәттә, Аргентинлы ярдәменнән башка бер үзе генә ерып чыга алмас иде. Тамырдаш-кореш һәм братва соңгы елларда руханиларга да юл таба алды, юккамыни күренекле чиркәүләрдә аларны иң яхшы поплар чиркәү хоры җырлатып соңгы юлга озата, ә шәһәр исә гади мәетләрне җирләү өчен күптән ябык, бары тик Россиянең иң күренекле шәхесләре өчен генә калдырылган зиратларда аларга иң хөрмәтле урыннарны бирә. Ә бу юлы, сүз легендар Тоглар никахы һәм туе турында барганда, братва, әлбәттә, инде бик тырышты.

Тоглар туй мәҗлесен, артык зурдан купмыйча, тыйнак кына итеп, дуслар белән генә үткәрик, дип ничек кенә карышмасын, ни Арген-

тинлыны, ни Дантесны, ни башкаларны күндерә алмады.

Һәммәсе бер авыздан:

—Син бит, братан, беренче мәртәбә өйләнәсең, беренче туең бу синең. Хатының да гүзәлләрнең гүзәле, нигә качып-посып кына, тыйнакланып маташырга, ди? Яратышып никахлашасыз ич!—диде.

Туйны «Пекин» ресторанында үткәрергә булдылар—күнегелгән урын, заллары зур-иркен—ду китереп биергә дә, җырлашырга да була, кунакханәнең машиналар куя торган урыны да үзенеке, автомобильләр белән шыплап тутырылган шәһәрдә монысы да бик житди дәлил.

Шуннан соң Тоглар, һич кирәкмәгән бу бәхетле купшы-бай мәжлесне «Пекин»да өч йөз кунак чакырып үткәрү бик кыйммәткә төшәчәк, дигән сылтау белән финанс ягына да басым ясап карады.

Бу юлы да аңа:

—Курыкма, анысына тыкшынып та торма—законлы никахыңа гына житәрлек акча табылыр,—диделәр.

Яшьрәк «яңалардан» кайсысыдыр, ресторанны ике көнгә арендага алып, хакын алдан ук түләп куйды, Дантес табындагы сый-нигъмәт бәясен үз кесәсеннән каплады, Хавтан үзенең өйрәтелгән иң яхшы официантларын мондагыларына ярдәмгә өстәде, чөнки аныкылар килгән кунакларның барысын да таный, кемнең кем икәнлеген белә иде. Туй мәжлесенә иң кадерле кунак итеп чакырылган Виленкин Константин Николаевичка үзенең бер дизайнер иптәшен тәкъдим итте, анысы бик тантаналы-купшы мәжлесләр үткәргәндә залларны бизәү-жиһазлау белгече икән—хәзер шундыйлар да бар, имеш. «Пекин» ресторанының болай да зиннәтле залын ул шундый тырышып бизәде ки, бирегә көн дә килеп кунаклар да залны башта таный алмый тордылар. Ә ресторан хужалары дизайнер егет белән шундук «Пекин»ны Яңа елга һәм Сигезенче март бәйрәмнәренә бизәү өчен килешү дә төзергә ашыктылар, чөнки ул көннәргә өстәл алырга теләүчеләр бихисап була һәм өстәлләр инде бер ай алдан сатылып та бетә.

Иркен-зур зал чәчәкләргә күмелгән, өстәлләр шундый оста куелган: кунаклар, бер-берләренә комачауламыйча, утыручыларга бәрелмичә, залда иркен йөри ала. Биегәндә дә, бер тирәгә өелешмичә, һәр жирдә биеп була, музыка залның иң аргы почмакларына кадәр ачык ишетелеп тора.

Ресторанны юкка гына ике көнгә алмаганнар: икенче көннең урталарына кунаклар янә бай табын артына җыелыштылар, борынгы урыс йоласы буенча «баш төзәттеләр», кияү белән киленгә сәламәтлек һәм озын гомер теләп, янә туйганчы ашап-эчтеләр.

Эйнштейн «Мосфильм»ның танылган, әмма хәзер эшсез калган өч операторын яллаган икән. Менә дигән кино төшергәннәр тегеләр! Тоглар, үз туеның шулай шаулап-гөрләп үтүенә сокланып-куанып утыра-утыра, «тыйнак туй» дигән сүзләрен дә оныткан иде инде. Ә килен! Анардан да бәхетле кеше булдымы икән ул көнне? Ә бит Наталья туй алдыннан борчылды-гасабыйланды:

—Туй ничек булса, тормышың да шулай узачак, дип сөйлиләр...—диде. Шуны кат-кат тукып торды.

Шушындый менә дигән туй мәжлесеннән соң, димәк, аларны киләчәктә дә гел бәйрәмчә күңелле көннәр, елмаю-көлүләр, чәчәкләр һәм бүләкләр көтә булып чыга...

## Париж серләре

### I

Карлен Татлянның Оля Харитоновага булган мәхәббәте көннән-көн көчәя, аралары якынайганнан-якыная бара, егетне инде атаклы профессор өендә бары тик кияү генә дип кабул итә башлаган иделәр. Шымчының үзенә дә бу хәл бик ошый. Бу гаиләнең гореф-

гадәтләре, йолаларыннан ук зыялы икәнлеге сизелеп тора, соңгы елларда фәнни-гыйльми хезмәткәрләрнең бик авыр хәлдә калуларын күрсә дә, Карлен бу гаилә белән танышлыгыннан бик канәгать иде. Аннары шунысы да бар: булачак кайнатасы Олег Даниловичның элек телдән-телгә тар даирәләр арасында чыштын-пыштын гына укылып йөргән, цензура тыеп килгән лекция-мәкаләләрен дә Карлен, курыкмыйча, Көнбатыш журналларында бастырып чыгара алды бит. Аларда югыйсә берниндн сер-фәлән дә юк, шул замандагы совет хакимиятенең куркуы-шикләнүе генә бар иде. Үзенең бер-ике мәкаләсе көнбатыш журналларында басылып чыккач, илендә күптән онытылган вә ярым хәерче хәлендә яшәп яткан профессорыбыз ул мәкаләләре өчен саллы гына каләмхаклар алып, фәннәр докторы Харитонов үзе белгән мәсьәләләр турында тагын да яза алмасмы, яки үзенә унайлы вакытта Американың берәр абруйлы университетына килеп, лекцияләр укып китә алмасмы, дигән тәкъдимнәр дә килгәләгәч, Харитоновларның өметсезлек-хәерчелеккә төшеп барган гаиләләрендә янадан өмет уты кабынды, ягымлы-мөлаем америкал егетен хуҗабикә карчык, яратып-үз итеп, Каро дип кенә йөртә башлады һәм ул киләсе көннәрдә аның яраткан ризыкларын—гөмбәле кәбестә пирог-фәләннәрен пешереп куя иде. Шымчы Карлен Норман, Россиядә өйләнә-нитә калса, ул бу хакта, әлбәттә, ЦРУ җитәкчелегенә хәбәр итәргә тиеш була. Өйләнү башка ил кызы белән булган очракта—бигрәк тә. Америка разведкасы гына түгел, башка илләр—итальян, немец, яһүд разведкалары да бик яхшы белә: көч-куәтле, хәйләкәр КГБ, аларның шымчыларын чибәр маржа кызларына өйләндереп, үз якларына аударып куйган очраклар да булгалый иде. Америка президенты Джон Кеннедины үтерүче Харви Освальдның хатыны, Минск шәһәре кызы Марина КГБ шымчысымы-юкмы, дигән бәхәсләрнең әле һаман да тынганы юк ич. Дөньядагы иң көчле-куәтле ил булган Америка президентын көпә-көндез, урам тулы халык басып торганда, атып үтерсеннәр дә—ничек ис-акылың китмәсен, ди?

Шуңа күрә, Карлен Норман да ЦРУ дагы хуҗаларына профессор Харитоновның гаиләсе һәм үзе өйләнергә теләгән Оленькасы турында бик тәфсилле хат язып җибәрде. Үзәккә ул булачак кайнатасының Америка журналларында мәкаләләре басылып чыкканын, аны АКШның элекке берничә президенты тәмамлаган абруйлы университеты студентларга лекцияләр укырга чакырганын хәбәр итәргә дә онытмады. Шулай ук ул Харитоновлар гаиләсенең өйдә, дачаларында, театрда төшереп алынган бер дистәләп фоторәсемнәрен дә озатты—анысы да Карлен Татлян кул куйган килешүдә мәҗбүри пункт итеп күрсәтелгән иде.

Җавапны озак көтәргә туры килмәде, ул Карлен уйлаганнан да тизрәк килеп җитте. Әле шунысы да бар: аңа разведканың иң югары җитәкчесе кул куйган, димәк, шымчының өйләнергә җыенуы ЦРУ хезмәткәрләрендә зур кызыксыну уяткан, дигән сүз. Баксаң, Америка разведкасы профессор Олег Данилович Харитонов белән күптәннән, җитмешенче еллар башыннан ук кызыксына икән, шул чорда ук фәнни каналлар аша ЦРУга профессорның химия өлкәсендәге ачышлары турында хәбәрләр барып ирешкән булган, ә ул ачышлар җитештерүдә югары технологияләр кулланырга файдалану өчен яраклы икән. Ләкин ул ачышларның кыйммәтле икәнлеген белеп алуга, КГБ аларны үтә яшерен иткән, профессорның үзен дә чит-ят күзләрдән яшергәннәр һәм ЦРУның сузылган җепләре профессорның фәнни карьерасы башында ук өзелеп калган. Һәм менә—шундый көтелмәгән күңелле хәл! Профессорның гаиләсе түренә үк үз шымчыңны кертеп утырту мөмкинлеге туа, мондый уңыш бик сирәк була ул! Җитәкчелек, үзенең яшь һәм талантлы шымчысын алдан ук котлап, бу мөмкинлекне кулдан ычкындырмавын үтенгән, аңа тиешле чыгымнар күләмен арттырырга да вәгъдә иткән: Америка кияве башкалардан ким-хур булмаска тиеш!

Карлен Татлян, үзәктән килгән бу күперенке стильдәге язманы укыганда, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды—АКШ мәнфәгатьләре,

патриотизм һәм йолдызлар чәпәгән буйлы-буйлы флагка мәхәббәт хисләре аны хәзер аз дулкынландыра иде инде. Мәскәү аның яшьлек һәм шымчылык романтикасын бик тиз суытты. Ольгага ул, әлбәттә, чынлап өйләнергә тели, бу гамәлдә чит күзләрдән бик тирән яшерелгән шәхси файда һәм нечкә исәп-хисап чагылгалап китсә дә, Карлен кызны яратам дип уйлый иде. Үзәккә үзенең башлы-күзле булырга җыенуын хәбәр иткәндә үк, ул хуҗаларына нинди тәэсир ясаячагын чамалаган иде инде. Ул моны Олег Даниловичның Америка журналларында басылып чыккан мәкаләләрен укыгач, алар йортында инглиз телендә сөйләшкән әңгәмәләрдән соң аңлады: аның булачак кайнатасы гаять талантлы галим бит. Нәкъ менә профессор Харитонов кебек кешеләр аның яңа ватанының бүгенге байлыгын һәм көч-куәтен тәшкил итә дә: Америка һәрвакыт дөньяның төрле якларыннан җыелган шундый талантлар хисабына яшәп килә. Карлен тагын шунысын да яхшы белә: хәзер АКШта яшәүче утыз Нобель премиясе лауреатларының дүрттән өчесе чыгышлары белән Кытайдан, Һиндстаннан, Пакьстаннан, Израильдән, Россиядән, латин Америкасыннан иде. Хәтта зур сәясәттә дә, кемгә тәртсәң дә, безнең төшенчәләр буенча—чит ил кешесе: Генри Киссинджер—немец, Збигнев Бжезинский—поляк, Спиро Агню—грек, Мадлен Олбрайт—яһүдә. Әлбәттә, күп еллар буе аңа ачкыч таба алмаганда, бигрәк тә профессор Харитоновлар кебек шәхесләр Америка разведкасын бик кызыксындыра иде. Ләкин Карлен, яшь булуына да карамастан, үз уенын җитди уйный башлаган иде инде. Харитонов турындагы хәбәре белән ул үзенә Мәскәүдә бик озакка, әгәр дә гомерлеккә булмаса әле, ышанычлы урын тәэмин итеп куйды, ә ташкала-башкаладан аның беркая да китәсе килми иде. Икенчедән, хәзер «граверлар» аулауда әлләни зур нәтиҗәләргә ирешмәгәндә дә, аның тору урынын алмаштырмаячаклар—профессор Харитонов үз янында даими шымчы тотарга лаек шәхес бит. Дөньяви хәбәрләр язгалап торучы журналистның өйләнергә җыенуын белдерүе, беренче карашка, гөнаһсыз тоелса да, аңарда әле тагын бер мәкерле хәйлә яшеренгән иде. Кияүләп йөрү, табигый ки, вакыт таләп итә һәм Карлен ярты ел-бер елга чагыштырмача иркенлек ала—шул вакытын ул ныклап торып «гравер»ны эзләүгә сарыф итәчәк. Карлен Татлян сизенә: теге оста кайдадыр янәшәдә—Россиядә, башкаланың үзендә яшәмәсә дә, һичшиксез, Мәскәүдә еш була, өлешчә барлык билгеләр шуңа ишарәли. Әгәр дә «гравер»ны эзләп тапса, Карлен гомерлеккә башкалада торып калачак, әкренләп елдан-ел шымчылык шөгылен киметә барачак һәм үзенең өметләрен акламаган, бу өлкәдә киләчәге күренмәгән бер файдасыз кеше рәвешендә отставкага чыгачак.

... Ничектер җәй ахырында, август аенда, ул үзенең ак «мерседес»ына Олясын да утыртып, «Пекин» ресторанына барып чыгарга ниятләде. Исәпләре—ашап-эчеп, биеп-күңел ачып кайту иде. Карленга да, Оляга да кытай рестораны бик ошый, аларны биредә беләләр һәм даими кунаклар буларак кабул итә иделәр.

Тверской урамыннан унга, «Ханжонков йорты» (элек ул «Москва» дип атала иде) кинотеатры каршындагы автомобильләр туктый торган якка борылуга, Карлен бихисап чит ил маркалы автомашиналар күрде, аларның һәммәсе дә «Пекин» рестораны каршындагы мәйданчыкка кереп туктарга тырышканын ул тиз генә абайлап та бетерә алмады. Мәйданчыкка керү юлында горур гына кыяфәтле бер кемсә, житез-оста гына итеп, һәр машинага кай урынга туктарга икәнлеген күрсәтеп тора иде; Карленның ак «мерседес»ын да ул тоткарлыксыз үткәрде, күрәсең, аны да бүгенге мәҗлескә чакырылган кунакларның берседер дип уйлады булса кирәк. Карлен белән Оля машиналарыннан чыгуга ук, каршы алучыларның тантаналы тавышларына күмелеп, туй машиналары төркеме килеп керде, аларның берсенә дә зәвыксыз кабартылган төсле шарлар һәм пластмасс курчак бәбиләр куелмаган, һәммәсе дә матур чәчәкләр белән бизәлгән иде. Егет белән кыз кемнендер «Пекин» залын туй мәҗлесе үткәрү өчен

алганлыгын аңлады. Иң алдагы зур кара «кадиллак» эчендә кияү белән кәләш утыра иде, каршы алучы кунаклар чәчәкләрен тотып аларга ташланды. Ольга да Карленны шул якка таба өстерәде—аның кәләш өстендәге туй күлмәген күрәсе килә, соңгы вакытларда Карлен белән алар да бит еш кына булачак туй, чиркәүдә никахлашу турында сөйләшәләр иде. Беренче кочаклашу-күрешүләр, котлау сүзләреннән соң, «кадиллак» тирәсенә өелешкән кунаклар читкәрәк тайпылды һәм, кияү белән кәләшкә ресторанга керү юлын ачып, аларның аяк асларына роза чәчәкләре ыргыта башлады—Россиядәге бай туйларның яңа йоласы иде бу.

—Әнекәй генәм! Күлмәге нинди матур!—дип сокланып пышылдады Ольга.—Мөгаен, Парижга заказ биреп тектергәннәрдер. Матур да, сөйрәлеп килә торган шлейфы—озын итәк очы да юк, биергә дә җайлы,—дип, ул дәртләнә-дәртләнә кәләшне тикшерергә тотынды.

Ләкин Карлен кәләшнең кием-салымнарын да, үзен дә күрмәде, дисәң дә була, аның бар игътибары кияү егете вазифасын үтәп озата килүчеләрдә иде—һәр икесе дә тазара төшкән тулы гәүдәләренә ятышлы, күкрәк турысы киң ачылып торган күркәм кара смокинг пинжәктән, борынгы урыс йоласы буенча икесе дә күкрәк аша кыйгачлатып киң ак атлас тасмалар бәйләгән. Ничектер, байтактан инде, әле Оля белән танышканчы ук, Крис һәм Абрек белән бергәләп «Пекин»да кәеф-сафа корып утырганда, Карлен бу мәгъръур әфәнделәрне үзләреннән ерак түгел бер күрше табын тирәсендә күргән һәм кушаматларын да исендә калдырган иде: берсе—Дантес, икенчесе—Шаман. Ул аларның якындагы сайлауларда үз кандидатураларын президентлык постына куярга җыенуларын да белә, ә Дәүләт думасы депутатлары мандаты ул вакытта ук аларның кесәсендә иде инде. Алардан аз гына арткарак калып, тән сакчысы урынында «Золотой петушок» рестораны хуҗасы Хавтан атлый. Карленга бары тик кияү генә таныш түгел, аны беркайчан һәм беркайда да очратканы булмады, югыйсә кияү белән кәләшне чолгап алган кешеләрне ул казинода, Хавтан ресторанында, ат чабышларында, чит ил машиналары автосервис үзәгендә, төнге клубларда, ниһаять, шушы ук «Пекин»да еш күреп йөри иде. Күрәсең, чәчләренә чал керә башлаган, яшьлеге үтеп баручы бу кияү бик абруйлы заттыр, туенда аның кияү егетләре вазифасын үтәүче ышанычлылары да әнә нинди әфәнделәр бит.

—Менә бу күлмәкне фоторәсемгә төшереп алсаң иде!—дип, һаман да сокланып хыяллануыннан туктый алмады Ольга, кәләшнең купшы-нәфис киемнәреннән ул бөтенләй сихерләнеп калган иде.

Әмма Карленның пинжәк кайтармасына яшерелгән микрокамерасы һәрвакыт әзер тора һәм ул хәзер бер-бер артлы кияү белән кәләшне дә, аларны урап алган кунакларны да, яңа гына килеп өстәлә барганнарның һәммәсен дә туктаусыз рәсемгә ала бара—Карлен бу рәсемнәрнең ана кайчан да булса бер бик кирәк буласыларын сизенә иде. Инде мәйданчык автомобильләр белән тулы булса да, машиналарның һаман килеп торуына караганда, бу туй мәҗлесе гаять зур һәм бай булырга охшый иде. Кияү белән кәләш инде «Пекин» ресторанының киереп ачып куелган биек ишекләре янына килеп җиткәндә генә, бераз соңга калган Аргентинлы күренде, ул үзе ак смокинг пинжәктән, янәшәсеннән кулларына бик нәфис-купшы чәчәкләр тоткан хатыны белән кызлары килә. «Димәк, һәркайда борынын тыга торган Аргентинлы кияүне яхшы белә»,—дип нәтиҗә ясады Карлен. Городецкийның телефонын Карлен күптәннән тыңлап бара иде инде, бер-ике көннән соң аның кемнәр белән, нәрсәләр турында сөйләшкәнен язып алган язмаларны яхшылап өйрәнергә кирәк булыр әле, кем белән булса да ул бу туй турында сөйләшми кала алмас, кытай ресторанында мондый бай туй мәҗлесе еш булып тормый бит.

Башка таныш-белешләре күренмәгәч, Карлен Татлян үзе чакырылмаган туй мәҗлесе белән артык кызыксынып торуны яхшысынмады, «Пекин» рестораны яныннан әкрен генә китеп барды.

Ул кичне Карлен белән Оля да «Хавтан» ресторанында, Петрович

сый-нигъмәтләрен ашап-эчеп, күңелле генә үткәрде. Анда ул көнне берьюлы өч туган көн мәҗлесе уздырыла иде: шампан шәрабе елга булып акты, оркестр бер генә минутка да тынып тормады, «Ромэн» театрыннан махсус чакырылган чегәннәр бу бәйрәмгә аерым бер төсмер өстәп, урысларга хас җилле-чая тәэсир калдырды. Карленга монысы бигрәк тә ошады.

Чит кешеләрнең туй мәҗлесе аркасында «Пекин» ресторанына керә алмау вакыйгасы тиздән онытылды, Карлен белән Оля ул вакыйганы яңадан телгә дә алмады. Шулай да Карлен Татлян анда төшереп алынган фоторәсемнәрне дүртенче каттагы дусларына күрсәтергә булды, кемнәрнең кем икәнлеген ачыклап бетерергә кирәк иде бит; ни өчен шундый абруйлы Дантес белән Шаман күпләр өчен таныш та булмаган кияү кешенең ышанычлылары—кияү егете вазифасын башкардылар икән? Һәм ни өчен ул туй шундый тантана-купшылык белән үткәрелгән? Кияү сәясәтче дә, банкир да, эшмәкәр-бизнесмен да, эстрада йолдызы да түгел ич. Крис белән Абрек, рәсемнәрне карап, туй тантанасында катнашкан барлык кешеләрне дә диярлек таныды. Шуннан Абрек дәртләнеп китеп акыл сата башлады:

—Калерле Каро, бу дөньяда бернәрсә дә очраклы булмый. Әгәр дә инде шундый бай туй үткәргән икән, димәк, кияү аңа лаек кеше. Син хаклы, дәүләттә иң абруйлы саналган Дантес белән Шаман теләсә кемнең туена барып йөрмәс. Ә синең карашыңча, тыйнак кына күренгән бу кияү картаеп баручы буынның иң легендар шәхесләреннән берсе. Мәсәлән, аны безнең Рафик Сво абзабыз да яхшы белгән. Ул, ничектер, бу кешене телгә алып: «Бөек кеше, алтын куллы кеше!»—диган иде. Әмма бу бөек шәхеснең нәрсә белән шөгыльләнгәнен сөйләргә өлгерә алмый калды, ни өченлер сүз икенче юнәлеш алды, ә бездә, үзең беләсең, төпченү-сораштыру әдәпсезлек санала, кирәк булса, вакыты житкәч, үзе әйтер иде әле. «Алтын куллы»—осталарның да остасы диган сүз. Житмешенче еллар башында кайбер рәссам-ювелирлар патша заманындагы иске алтын акчаларны сугу ысулын тапканнар бит—биш, ун сумлык алтын тәңкәләр ул елларда акчаны «тозлап» тотарга яратучылар өчен менә диган товар булган инде, андый саран гобсеклар хәзер дә буа буарлык. Бәлки, кияү дә шундый сирәк оста ювелирларның берседер—кем белә? Алар суккан алтын акчаларның ялган икәнлеген, СССР Гохранының Пробирная палатасыннан башка, бер генә тикшерү экспертизасы да белә алмаган. Чөнки барысы да төп-төгәл туры килә: үлчәме, дисеңме, алтын чыны, дисеңме—кыскасы, койган да куйган саф алтын инде! Ә алтын диганнен ул тәңкәләрдә уннан бер өлеш кенә булган. Менә шундый осталар инде ул алтын куллы хөрмәтле кешеләр! Ничек кенә булмасын, бу кияү бик тә абруйлы кеше, башымны кисәргә бирәм. Ул, күрәсең, әле без Мәскәүгә килгәнче үк, үз шөгылен ташлаган булгандыр, юкса без аның кем икәнлеген, нәрсә белән шөгыльләнгәнлеген төгәл белгән булыр идек. Ә хәзер, мөгаен, рәхәтләнеп, дөньяның артына тибеп яшидер, күрәсең бит—гаилә корырга уйлаган, димәк, элек башка канун-йолалар буенча яшәгән: элек бит андыйлар гаиләле, шәхси милекле була алмаганнар—ярамаган. Бүген андый кешенең абруйлы сүзе алтыннардан, бриллиантлардан да кыйммәтрәк. Берәр төрле мөһимрәк бәхәс чыга, үзара аңлашу кирәк була икән—ана мөрәҗәгать итәчәкләр. Кемгә булса да ошыймы-юкмы, ул ничек әйтсә, шулай булачак. Юристлар әйтмешли, хөкем карарының соңгысы шул һәм аны кире кагып булмый. Ләкин, әгәр дә ул ялгыша, бәхәсләшүчеләрнең берәрсе ягына авышса—ана бүтән мөрәҗәгать итмәячәкләр. Бәйсез һәм сатылмас хөкемдар зат гражданнар җәмгыятендә генә түгел, җинаятьчел дөньяда да бик кирәк: юкса, хаос—ата улны, ана кызны белми башлаячак.

—Әйе, безнең ул туйга чакырулы булмавыбыз кызганыч,—дип сүзгә кушылды Крис,—шундый күренекле затлар белән бер типтереп калыр идек. Тагын да кызганычрагы шул: теге чакта безгә Сво абзый әйткән

иде дә бит кушаматын аның, онытылган инде... Ярар, кадерле Каро, без үз дигәнебезне эшләрбез әле, бу алтын куллы останы үзебезнең туебызга чакырырбыз, әгәр дә андый көннәргә кадәр яши алсак, әлбәттә...

«Пекин» ресторанында үткәрелгән туй турында Карлен менә шундый көтелмәгән фикерләр ишетте.

## 2

Августта шаулап үткән ул туйдан соң, өч ай гына узган иде, Карлен белән Оля аны янадан исләренә төшерде. Ләкин бу юлы «Лос-Анджелес таймс» журналисты туйның төп хуҗаларына бик зур кызыксыну күрсәтте.

Ноябрь азакларында, Мәскәү көзенең, инде беренче кар төшеп, эреп бетәр-бетмәстән, кыш киләсен хәбәр иткән шыксыз юеш-салкын бер көнендә, Карлен Ольга янына барып керде, кызны бик сагынган, күрәсе килгән чагы, аннары Олег Данилович өчен дә күңелле яңалык бар иде. Ул киләсен алдан хәбәр итеп тормады—музыка белгечләре: «Давид Ойстрах, хәтта Иегуда Менухин даны көтә бу егетне!»—дип сокланып йөргән бер талантлы яшь скрипачтан интервью-әңгәмә алганнан соң, килде дә керде. Керсә—өстәлдә табын әзер. Ольга ярты сәгать элек кенә институтыннан кайткан икән, әзер табын өстенә кунак килеп керү һәр халыкта да бәхетле фал санала, моны Карленның да исенә төшереп алдылар. Шундый күңелле ыгы-зыгыдан соң, Карлен әйткән яңалыкны Олег Данилович Алланың бирмешедер дип кабул итте. Америка разведкасының еракка төбәлгән, оста уйлап эшләнгән гамәлен профессор каян белсен, ди инде? Вашингтондагы бөтен дөньяга билгеле бер университет (Колумбия округы) Олег Данилович Харитоновның СССР югары уку йортлары студентлары өчен моннан унбиш еллар элек язылган химия дәреслеген бастырып чыгарырга җыена икән. Бүгенге тормышны ничек аңларга да белмәгән профессор өчен американнар вәгъдә иткән каләмхак алга таба бөтен финанс мәсьәләләрен дә хәл итәрдәй зур булып тоелды.

Табын янынннан кузгалгач, Карлен белән Оля, бәхетле карт-карчыкны аш бүлмәсендә калдырып, гадәттәгечә, кыз бүлмәсенә кереп киттеләр. Карлен кызны кочагына кысарга да өлгермәде, Оля, язу өстәленнән тышлыгы күзгә бик бәрелеп торган бер журнал алып, аны егеткә сузды. Журналның исеме Карленга таныш түгел иде.

—Менә,—диде Оля, хәйләкәр елмаеп кына, кулыннан журналны әле ычкындырмыйча,—миндә синең өчен сюрприз бар. «Пекин» ресторанында үткән туйны хәтерлисеңме, анда миңа кәләшнең туй күлмәге бик тә ошаган иде. Мадам бик бай булып чыга шул, кара әле, ул үзенә нинди кыйммәтле әйберләр алган!

Кушбитнең астагы ике рәсеме Карленның колагын шундук торгызды, үзенең дулкынлануын кызга күрсәтмәскә тырышты ул.

Беренче рәсем Париждагы атаклы «Себастьян» автосалонында төшереп алынган. Ул салонда бик кыйммәтле, еш кына алдан бирелгән заказ буенча эшләнгән сирәк машиналарның берән-берен генә саталар. Туй күлмәге белән Ольганың һушын алган әлеге кәләш әнә шунда бик килешле генә басып тора. Бу юлы да ул бик күркәм-бай һәм зәвык белән киенгән, әмма Татлянның игътибары аның киемнәрендә түгел иде. Мадам очраклы гына янәшә туры килгәнме, әллә андый кибеттә байларны махсус сагалап торучы фоторепортер аны үзе «эләктереп» алганмы—әйтүе кыен. Әмма мадам, балдаклар, кыйммәтле асылташлар белән бизәлгән, йөзек-беләзекләр тезелгән сул кулын банк төргәкләре—ачылмаган долларлар өеменә куйган да, бәхетле елмаеп тора, ә аның алдына өелгән долларларның икенче ягында кибетнең әллә хуҗасы, әллә берәр менеджеры ике бармагы арасына шул ук өемнән алынган, әмма әле ачылмаган бер төргәк долларларны кыстырган. Рәсем ачыктан-ачык «яңа урыс байларының» чит илләрдә ни рәвешле кыланганлыкларын

сурәтли һәм аларның девизына ишарәли: «Һәрнәрсәгә—акчалата!»

Аскарак урнаштырылган икенче фоторәсемдә шул ук мадам искиткеч бай «мазерати» кабриолетының рулен тотып утыра: күзләрне камаштырырлык ханым, акылдан яздырырлык машина! Өсте ачылышлы итеп эшләнгән «мазерати»ның мондыйлары, Карлен уйлавынча, өч йөз мең доллардан да ким тормыйдыр. Әгәр фотожурналист халыкны «ah!» иттерергә теләгән булса, ул үз максатына тулысынча ирешкән! Ханым белән янәшә алгы утыргычта бер ир кеше дә шәйләнә, ләкин фотограф өчен кадрда аның булу-булмавы шул кадәр генә һәм ул бик томанлы чыккан. Шулай да Карлен ачык күреп алды, бу ир кеше кәләшен култыклап «Пекин» ресторанына кереп баручы чәчләре чалара башлаган кияү әфәнде түгел—ул шактый биегрәк һәм горуррак кыяфәтле иде.

Карлен журналны Ольгага кайтарып бирергә җыенган иде инде, ләкин кинәт аның күз карашы алтынсу төстәге купшы «мазерати»дан беренче рәсемдәге «Себастьян» кибетенең күрексез генә кыяфәтле менеджерына—төгәлрәге, аның кулындагы долларларга күчте. Менеджер ул акчаларны битенә үк диярлек күтәреп тоткан. Шунда гына Карлен фотожурналистның уй-ниятен аңлап алды: кадрда иң төп нәрсә акча төргәкләре—акча пирамидасы фотографның төп фикерен ачып сала һәм ул көнбатышның тар карашлы обывательләренә аңлашыла да. Журналдагы рәсемнәргә инде бер өч минутлап текәлеп карап утырган Карлен шул мизгелдә доллардагы номер һәм серияләрне күреп алды—болар нәкъ шул ЦРУ һәм Американың Федераль резерв банкы кисәткән ялган супербанкнотлар иде...

Көтелмәгән бу ачыштан Карлен чак кычкырып җибәрмәде, ләкин вакытында үзен тыеп кала алды. Ольга егетнең кәефе үзгәргәнен сизде, аның гадәттән тыш агарынып киткән йөзен, бер мизгелдә күзләренең ялтыравын күреп, аны иркә генә кочып алды да, хәленә керергә теләп сорады:

—Әллә берәр хәл булдымы, Каро? Бу рәсемнәр белән кәефеңне җибәрдемме әллә?

Карлен, үзенең хәлен яшерергә теләп, урыныннан күтәрелде һәм кызны кочаклап, битен битенә куйды:

—Мин сиңа мондый шәп машина яки бик кыйммәтле әйберләр бүләк итә алмам—анысы кызганыч, әлбәттә, ләкин мин сине бик яратам һәм кадерле бүләкләр алып бирә алырмын дип уйлыйм...—дигән булды.

—Рәхмәт, сөеклем! Ләкин мин аның ни машинасына, ни киемсалымына, ни йөзек-беләзекләренә һич кенә дә кызыкмыйм. Шунысы гына сәер, ул хәзер безгә икенче тапкыр очрады инде...

—Әйе, син хаклыдыр, мөгаен, монда ниндидер мистик сер бар шикелле. Ун миллион халыклы шәһәрдә бу ниндидер могҗизага охшый, әмма, сезнең Россиядә әйтмешли: нәрсә булса да, тик яхшыга гына булыр. Без дә шулай дип уйлыйк...

Профессор Харитоновлардан чыгып киткәндә, Карлен Олядан әлеге журналны сорап алды:

—Машина җене кагылган дусларым Крис белән Абрекка бу «мазерати» рәсемен күрсәтим әле,—диде.

Үзләренең «әрмәннәр йортына» Карлен кәефе бозылып кайтып керде, дөресен генә әйткәндә, ул болай тиз уңышка ирешергә әзер түгел иде. Ул әлеге «граверны» эзләү елларга сузылыр дип уйлаган, үзе шул ук вакытта бөтенесе дә бер тирәдәрәк, аның янәшәсендә генә бөтерелгәнен тоя, бу вакыйгага катнашы булган байтак кешеләрне, мөгаен, күреп тә беләдер шикелле иде. Кыш алдыннан була торган бу шыксыз, караңгыланып килгән эңгер-меңгердә аның башка беркая да барасы килми, шуңа күрә Карлен Мәскәүдә ияләшеп киткән «Баллантайн» вискиен урысларча тутырып салды да каплап та куйды.

Аннары ул кичкелеккә табын әзерләде, Петрович тәкъдим иткән яңа сорт урыс аракысын тагын бер чәркә җибәреп, аны гөмбә һәм тел

казылыгы белән бастырып, тәмләп ашарга тотынды.

Карлен Татлян шундый сирәк очрый торган кешеләрдән иде, аны спиртлы эчемлекләр йомшатмый, ә киресенчә, эшчәнлеген генә арттыра. Гаҗәттә, ике-өч чәркә каты гына спиртлы эчемлек эчкәннән соң, аның уйлары ачыграк, күп төрлерәк була бара, ул моны инде күптәннән, студент чакларыннан ук сизеп алган иде. Бүген ана акылының бигрәк тә саф булуы кирәк: үзенең очраклы гына рәвештә урыс «граверына» яки ялган долларларны бик оста шудырып торучы берәрсенә барып чыкканлыгына һич кенә дә шикләнмәде. Тегеләй дә, болай да—ул финиш алдында хәзер. Ул үзенең бу мөмкинлеген ычкындырмаячак, ничек кенә булса да, «кияүне» сындырачак һәм ялган доллларлар сугучы яшерен үзәккә барып чыгачак. Әгәр кирәк булса, Карлен дүртенче каттагы бандит дусларын ярдәмгә чакырачак. Бүгенге ачыш тиз хәрәкәт итүне сорый иде, шундук Карлен, һәрвакыт кул астында яткан кесә телефонын алып, дүртенче катка шылтыратты, әмма аңа җавап бирүче булмады. Шуннан соң ул туп-туры егетләрнең машинасына шылтыратты—шундук җавап та алды.

—Абрек,—диде Карлен, исәнләшеп тә тормыйча,—миңа бик тиз генә берәр атнага Парижга барып кайтырга кирәк. Сез миңа паспорт табуда ярдәм итә алмассызмы икән? Мин анда инкогнито—беркемгә белгертмичә генә барып килергә телим...

—Каро, кадерлем, скрэмблерсыз телефоннан андый эшләр турында сөйләшү ярамастыр, безнең бит «тегеләр»нең кармагында булуыбыз бар, ә бу синең абруеңа зыян китерергә мөмкин, белеп тор дип кенә әйтүем, үпкәләмә,—дип, Абрек аны бераз шелтәләп тә алды. Татлян риза булып баш какты, әйтерсең, дуслары аны күреп тора иде.—Теге элемтәләр сакланып калды әле... Тыңла, без кичне өйдә уздырырга булдык, салкын да, кар да ява башлады әнә. Димәк, безне кунакка көтәсең, бүре кебек ашарбыз...

Кич белән дусларча ашап-эчеп утырганда яшел тышлы дипломатик паспорт мәсьәләсе бик тиз хәл ителде. Карлен аңлатып бирде: аның тиз генә Парижга барып кайтуы хуҗаларына сизелмәскә тиеш, ә башкача ул Франциягә баруын бары тик Америка илчелеге аша гына эшли ала. Париждан йөреп кайту хаҗәтен ул шәхси мәсьәләләр белән бәйләде: кәләшенә туй күлмәге һәм башка кирәк-яраклар аласы бар бит—аның Ольга белән эшләре никахлашуга таба барганын Абрек белән Крис яхшы белә иде.

### 3

Парижга Карлен Татлян иртән-иртүк, «Эйр-Франс» авиакомпаниясенең беренче рейсы белән, үзенә электән таныш булган Орли аэропортына килеп төште. Парижда да, әле Франциядә кар күренмәсә дә, шулай ук юеш-шыксыз һава тора иде.

Парижга ул җиңелчә генә, ярым буш «дипломат» тотып кына килде, әгәр нәрсәдер кирәк була-нитә калса, биредә сатып алырга була—Карлен акчаны җитәрлек алып килгән иде. Дүртенче каттагы дуслары аңа янә бер мәртәбә Лондонның «Лейнсборо» отеленнән алган чечен саквояжыннан файдаланырга мөмкинлек бирде. Сүз уңаеннан әйтеп китик, саквояждагы акчалар соңгы ике ай эчендә бер дә кимемәгән булып чыкты, Карлен моңа бик нык гаҗәпләнде, юкса Крис белән Абрек акчаны ифрат күп туздыра иде, димәк, алар тагын кайдандыр шәп кенә зур сумма эләктергән, дигән сүз.

Аэропортта Карлен Татлян такси алды һәм Елисей кырларындагы иң кыйммәтле кунакханәләрнең берсенә—»Палас-отель»гә илтергә кушты—кайчандыр ул шунда Парижга гастрольгә килгән Элтон Джоннан интервью алган һәм андагы апартаментларның зиннәтлелегенә исе-акылы киткән иде. Ул вакытта Карленның «Франс суар» газетасында стажировка үтеп йөргән чагы иде.

Яшьлегендә үзе мөкиббән жырчы яшәгән каттагы бер номерга

урнашкач, Карлен ресторанга төште, урысларча шәпләп кенә иртәнге ашны ашап алды, хәтта ике чәркә яхшы француз коньягы «Реми-Мартэн» да эчеп куеп, абруйлы тыныч официантларны да шаккатырды. Ашап утырганда ул үзенең бүгенге эш көнен ничек үткәрергә, «Себастьян» кибетенә барып, сүзне кайданрак башларга, дип уйланып утырды, чөнки бүген иң беренче мөһим эш шул иде, аннары тиз генә уйларыннан арынып, урыныннан күтәрелде—вакыйгаларга карап хәрәкәт итәргә кирәк иде.

«Палас отель» ишеге төбендә бай кунакханәдән чыгучыларны көтеп торучы таксилар тезелеп киткән. Карлен күңеленнән генә чукынып алды да, үзен елмаеп кул изәп чакыручы беренче автомобильнең җылы утыргычына кереп чумды. Шымчылык гадәтләре, дөресрәге, шулай өйрәтелгән булуы бу юлы да үзен сиздерде: ул арттагы утыргычка утырды һәм «Себастьян» кибетенең үзенә түгел, ә аның янындагы кафега илтергә кушты. Ул: «Сакланганны саклармын»,—дигән мәкальне исенә төшерде. Бер дигән әйбәт итальян кафесы «Верона» автосалонга юл аша бераз кыйгачлап каршы якка урнашкан. Шофер килеп җитәрәк кайтарып сорады: «Верона»га дидегезме әле? Карлен: «Әйе»,—дигәнне белдереп, баш кына какты.

«Верона»да ул ярты сәгатьләп утырды, ике чынаяк куе кофе эчеп, артыннан бер чәркә коньяк өстәде. Җылы, рәхәт иде биредә, әмма эш дигәне дә бар бит әле һәм, Карлен, үзенең «Франк Мюллер» сәгатенә карап алгач, теләр-теләмәс кенә кафедан чыкты. Ишек төбендә бер-ике минут басып торды—янәсе, такси көтә. Аннары урамны тиз генә аркылы кисеп чыкты да тәвәккәл кыяфәт белән «Себастьян» кибетенә юнәлде.

Әле иртә булганлыктан, кешеләр күренми иде. Хәтта автосалон хезмәткәрләренең дә барысы да килеп бетмәгән иде бугай әле. «Себастьян»ның зәңгәр униформасын кигән ялгыз бер кеше генә ак «порше» автомобиленең алгы тәрәзә пыяласын сөрткәләп тора. Карлен ишекне ачып җибәрүгә, кибетнең аргы башында ук матур тавышлы кыңгырау чынлап куйды, залда клиент галиҗәнапләре күренде, дип сигнал бирү инде бу. Униформа кигән кеше «порше» яныннан кузгалып, тәрәзә сөртеп торган перчаткаларын салып куйды һәм, йөзенә елмаю кундырып, Карленга таба атлады. Димәк, эшне бусага төбеннән үк башларга туры килә.

Исәнләшкәч, сатучы, Карленны бай клиентка санап, ихтирам белән генә сорады:

—Сезгә нинди ярдәм күрсәтим? Нинди машина кирәк: Европаныкымы, Американыкымы, Япониянекеме? Бездә һәммәсе дә бар. Подиумга—машиналар куела торган мәйданчыкка игътибар итмәгез, кибетебез кечкенәрәк булганлыктан, хәтта иң соңгы супермодель үрнәкләрен дә күрсәтеп бетерә алмыйбыз.

—Әйе, «Себастьян» рекламага мохтаҗ түгел,—дип елмаеп җавап бирде Татлян.—Тик мин бүген машина алыр өчен килмәдем. Мин башка эш белән, зинһар, ярдәм итегез әле...—ул куен кесәсеннән алдан әзерләп куелган журналны тартып чыгарды һәм, кирәкле битен ачып, аны хезмәткәргә сузды.

Тегесе, Карленга илтифатын шундук югалтып, теләр-теләмәс кенә журнал битенә бакты, рәсемдә шефының таныш йөзен һәм кибет эчен күргәч, янадан йөзенә елмаю кунды.

—Әйе, бу безнең кибет, ә рәсемдә «Себастьян»ның баш менеджеры сурәтләнгән,—диде ул һәм, юк-бар сөйләшеп торырга вакыты юк икәнлекне белдереп, Карленга сораулы караш ташлады.

—Мин журналист,—дип аңлата башлады Карлен, аның ризасыз карашын абайлап.—Европа белән Американы, гомумән, бөтен дөньяны тутырган «яңа урыслар» турында язам. Язмаларым укучыларда зур кызыксыну тудырды. Шушы бик кыйммәтле «мазерати» кабриолетын сатып алган мадамның адресын әйтә алмассызмы икән мина? Бернинди мәкалә-

фәләнсез рәсеме басылып чыккан бу чибәр хатыннан беренче булып интервью аласым килә иде. Бигрәк гүзәл һәм нәзакәтле утырып тора инде ул үзе шикелле үк гүзәл «мазерати» эчендә—машинаны да ул, мөгаен, үзенең алтынсу-сары сокландыргыч чәчләре төсенә килештереп сайлагандыр.

Аның соңгы сүзләреннән сатучы бераз көлемсерәп куйды, ләкин ул кинәт, мөгаен, үзенең вазифаларын исенә төшереп булса кирәк, кырыс кына итеп:

—Гафу итегез, мсье, үз клиентларыбыз турында нинди дә булса мәгълүмат бирергә безнең хакыбыз юк, бигрәк тә мондый байлары турында,—диде һәм, сөйләшүне беткәнгә санап, «порше» ягына таба атлады.

—Ләкин мин бит журналист, менә таныклыгым,—дип, Карлен яңадан аның игътибарын үзенә җәлеп итмәкче булып карады. Юкса, җавапның шундый буласын алдан ук белеп тора иде инде.

Әмма вакыйгаларны ашыктырырга ярамый. Әгәр дә сатучы ана ышанмаса, куркып калса,—Россиядәге кебек үк, Парижда да аферист алдакчылар житәрлек,—ул Карленга ярдәм итү урынына, киресенчә, кибет житәкчелегенә матбугат әһеленең үзенә бәйләнеп торуын житкерәчәк. Ә житәкчеләр әлеге мадамга шылтыратып, кисәтеп куярга да мөмкиннәр—андый бай клиентлар белән Көнбатышта илтифатсыз кыланмыйлар, ә ана ярарга, ышанычын казанырга тырышалар: бер көн белән генә яшәгән кеше сирәк ота.

Униформалы кеше, әдәп саклау йөзеннән генә, үзе каршысында, чынлап та, «Лос-Анджелес таймс» газетасы хәбәрчесе басып торганын раслаучы таныклыкка күз ташлады. Татлян шунда ук алдан уйлап куелганча, бераз каушагандай, үтенгәндәй булып:

—Зинһар, ярдәм итегез инде, минем бик кирәкле репортажым яна. Аның уңышына минем дә алдагы уңышларым бәйле...—диде һәм сатучыга өч йөзлек долларлар сузды.

Сатучы, ничектер тиз генә як-ягына каракларча карангалап, үзенә сузылган долларларны күкрәк кесәсенә яшерде һәм аталарча йомшак кына:

—Башта ук шулай диләр аны...—дигән булды.—Яшь кешегә эшендә үсәргә ярдәм итү—изге гамәл. Ләкин сез дә минем хәлемә керергә тиешсез. Ярамый икән—ярамый инде ул. Әгәр алай-болай берәр хәл килеп чыкса, мин сезгә бер сүз дә сөйләмәдем дип белегез һәм шуны исегездә тотыгыз...—Бу үҗәт журналистны шулай кисәткәннән соң ул, хезмәтчеләр басып тора торган сату өстәле ягындагы сейфтан калын бухгалтер кенәгәсе тартып чыгарды. Ана, мөгаен, төрле исәп язулары язылгандыр. Аннары ул, ишек ягына карангалый-карангалый, «мазерати» сатып алган мадамның адресын һәм телефонын тиз генә Карленга әйтте. Карлен шундук «Себастьян»нан чыгып сызды—ана да артык шаһитләрнең кирәге юк иде.

Адресы күрсәтелгән йорт янына барып житкәч, Карлен үзе утырып килгән таксины җибәрде. Җылы машина эченнән чыгуга, аны сизелерлек салкын төньяк җилле шыксыз дымлы һава чорнап алды. Өслегә җылы мех булган пәлтә белән дә туңдыра иде. Биредә озак торып булмаячагын Карлен тиз аңлады. Унтугызынчы гасыр башында, бароккодан да өлеш чыгарып, готик стильдә салынган җиде катлы йорт бик күркәм күренә—Парижның матурлыгын һәм мәһабәтлеген нәкъ менә шушындый биналар күрсәтеп тора да инде. Әлбәттә, йортның баштагы кыяфәтеннән хәзер тышкы кабыгы, анысы да оста итеп яңартылганнан соң гына сакланып калган, эчтәге бүлмәләре барысы да күптән инде яңадан төзелгән һәм йорт үзе өр-яңа, заманча коммуникация һәм техник чаралар белән тутырылган булырга тиеш. Карлен Парижда эшләгәндә мондый йортларда булгалады, танылган кешеләрдән интервью алгалады. Шушындый ук йортта, әле биредән ерак та түгел бугай, чыгышы белән әрмән булган бөек француз җырчысы—шансонье Шарль Азнавур да тора иде. Ни

дисән дә, үз милләттәшең бит, Карленның Парижда язган беренче репортажы да аның турында булды.

Шулай истәлекләргә бирелеп, уйланып торганда, тәрәзәсендә консьерж-хезмәтче башы күренгән будкаларның берсе янына әллә кайдан гына бер пикап машинасы килеп туктады, андый машиналарны Россиядә «пирожковоз» яки «каблучок» дип йөртәләр. Машина кабыргасындагы реклама язуларына күз йөгертеп алгач, Карлен койма белән тотылган әлеге йорт янына сөт сатучы килгәнен абайлады. Алар шулай һәр йортта яшәүчеләргә эремчек-кефир, сөт-каймак, йогурт-тундырма ише азык-төлекләрне ишек төбенә үк китереп бирә. Бөтен дөньяда шундый хезмәт күрсәтүгә күчсәләр дә, Россиядә бу әле хыялга сыймас бер нәрсә генә булып кала бирә. Йорт хуҗасы вакыт-вакыт телефоннан гына заказ бирә дә азык-төлекне ишек төбенә чыгып кына ала, түләү кәгазьләре җыела төшкәч, аларны күрше кибеткә кереп түләп чыга.

«Каблучок»тан джинсы чалбарлы, күн курткалы, зифа гәүдәле бер кыз оста гына очып чыкты да, машина ишеген ябып та тормыйча, будка янына йөгерде. Консьерж белән нәрсәдер сөйләшеп алгач, ул саклана торган ишегалдына кереп китте һәм шундук күтәрмә әвеслек эченнән резин көпчәкле, хромланган ике күчәрле җинел арба тартып чыгарды. Каравылчылар аңа авыр тимер капканы ачты. Карлен аңлап алды, ишегалдына хәтта сөт сатучы кызга да машинасы белән керү тыела икән.

Арбасын тиз генә пикабының арткы ишеге янына тартып китергәч, кыз нindидер бер педальга басты, арбаның йөк төяләсе идәне машинаның төбе белән тигезләнде, кыз азык-төлек төялгән зур әрҗәне көчәнми генә, машина эченнән бер кулы белән шудырып тартып төшерде. Әрҗә утыртылган арбасын арттан җинелчә генә этеп, беренче ишек төбенә тәгәрәтеп алып китте. Капка шундук ябылды, күренеп тора—бу эш көн дә шулай минуты-минутка төгәл башкарыла һәм кыз да оста-житез эшли икән. Карлен, кызның иң якын ишек төбендә ничә минут тоткарланганын белергә теләп, сәгатенә күз салып алды.

Кыз нәкъ биш минут торды—мондый йортлардагы лифтлар тиз йөрешле, бушлар, аннары һәр квартира да сөт-фәлән алмый торгандыр. Карлен инде беренче очраган буш таксины туктатырга ниятләнгән иде, әмма кинәт кенә башына бер тәвәккәл уй килде: ә бәлки, нәрсә дә булса белешә алырмын? Һәм ул, пикап яныннан үтеп барышлый, җәлт кенә итеп шофер янәшәсендәге алгы утыргычка кереп тә утырды. Машина эчендә җылы, рәхәт, таныш булмаган хушбуй исләре күңелне кытыклый. Машинаның ачкычы да алынмаган иде. Карлен музыка уйнатып җибәрде, сигарет кабызды һәм бер мизгелгә эшен-йомышын да онытып, уйлап куйды: «Ә сөт сатучы кыз чибәр генә, зифа буйлы, хәрәкәтләре җинел-йөгерек, бәлки, үзен бүген кичкә берәр җиргә чакырыргадыр?» Бу фикердән аңа күңеллерәк булып китте, үзен иркенрәк тота башлады.

...Сөт сатучы кыз, аны машинасы эчендә күреп, бер дә гаҗәпләнмәде, ул шактый кыю-чая, әле җитмәсә шаян да булып чыкты. Беренче «бонжур» сүзеннән соң ук ул:

—Мин үземнең фонотекам белән кәефегезне бозмадыммы?—дип сораган булды.

Карлен да, елмаеп, шундый ук шук тавыш белән җавап кайтарды:

—Юк, хәтта киресенчә. Безнең зәвыкларыбыз бертөсле диярлек икән. Мин дә Патрисия Каасны, Далиданы һәм Иглесиасны яратам. Кызганыч, сездә Шарль Азнавур юк икән, мин кайчандыр анардан интервью алган идем.

—Ә-ә-ә, сез журналистмыни?—дип сорады кыз, кызыксынып һәм машинасын кузгатып җибәрде.

—Әйе, мин шул юньсезләр токымыннан,—дип җавап бирде Татлян һәм кызга сигарет тәкъдим итте. Аның үзенә унай карашын сизеп, танышырга кирәк тапты.—Минем исемем Карлен, дөньяви хәлләр хәбәрчесе

—Ә мин Колетт. Әллә сез миннән интервью алмакчы буласызмы?—дип сорады кыз, кыланчыкланып.

Бу егет аңа ошый иде: пөхтә киенгән, үзен ышанычлы тота, әдәпсезләнми-оятсызланмый.

—Ә нигә алмаска, ди? Сөт сатучы чибәркәйләр үз клиентлары турында әллә нинди серләр беләләрдер әле!—Ләкин Карлен шаян сөйләшүдән шундук житдигә күчте:—Дөресен генә әйткәндә, бик тә тунган идем, сезнең машинагыз мине катып үлүдән коткарып калды. Ә бердә мин сез сөт-фәләннәр китерә торган шушы йорттагы бер бай мадамны сагалый идем. Миңа аннан интервью алу яки аның турында мәкалә язу бик кирәк.

—Сер булмаса, әйтегез әле, кем ул?—дип сорады Колетт.

—Журналистның нинди сере булырга мөмкин! Киресенчә, үзен белгәннәрне бар дөньяга сөйләп бирәсе килә, үз героинян, аның сәер-кызык гадәтләре, дәрт-теләкләре, омтылышлары-кызыксынулары, зәвыклары, гөнаһлары—кыскасы, барысы турында да. Ә мин бер урыс хатын-кызын сагалый идем, ул бирегә ире белән күптән түгел генә күчеп килгән бугай. Сезгә аның хәтта фоторәсемен дә күрсәтә алам...

—Сезнең кем турында сөйләгәнегезне аңладым инде,—дип ашыгып бүлдерде аны Колетт.—Бу йортта бер генә урыс хатын-кызы бар—Натали. Чынлап та, соклангыч хатын, ягымлы, көләч йөзле, юмарт, күршесендәге карт ана каз кебек түгел инде,—дип, көтмәгәндә үртәлеп нәтижә ясап куйды ул.

Карлен шулай да үзен Парижга очып килергә мәжбүр иткән журнал битен ачып күрсәтте.

—Мин ялгышмаганмын, шул үзе,—дип баш какты Колетт,—рәсемнәргә карап.—Сез аңардан нәрсәләр сораштырмакчы буласыз инде?

—Барлык чибәр һәм бай хатын-кызларга бирелә торган сораулар: ни өчен ул торыр-яшәр өчен Парижны, Францияне сайлаган, ни өчен «мазерати» машинасын, әле житмәсә аның да кабриолет моделен сайлап алган, Булон урманы янындагы йорт аңа ошыймы, атка атланып йөриме, кем ана шундый матур кием-салымнар тегә, Раштуаны кайда каршы алырга уйлый, яраткан иренә нинди бүләк бирер икән? Россия турында да нәрсә булса да сорашырмын. Һи, шундый матур елмаючы яшь хатын-кыздан сорашыр нәрсәләр беткәнме соң? Әгәр минем урында булсагыз, сез үзегез аңардан нәрсәләр сорашыр идегез?

—Белмим шул,—дип аптырабрак җавап бирде Колетт. Аннары кинәт күңелле генә итеп әйтеп ташлады:—Ә мин сезнең кайбер сорауларыгызга үзем дә җавап бирә алам. Бәлки, алар эшегездә ярдәм итә алыр.

—Сезнең миңа күрсәткән игелегегез булыр иде ул,—дип кабынып китте Карлен.—Мин бит әле язасы мәкаләмә кайсы башыннан тотынырга да белмим. Ә сез сөйләсәгез, мин, мөгаен, башлап китә алыр идем. Әйтик, ул мадам сатып алган йортка нинди гүзәл кыз сөт-каймаклар китереп йөрүдән.

—Һәм укучыларны саташтырыр идегез,—дип бүлдерде Колетт, юлдан күзен алмыйча, тыз-быз чабышкан машиналар арасыннан оста гына уза барып.—Йорт, чынлап та, бик күркәм-бай, шәҗәрәсе дә кызыклы, анда бик күп атаклы кешеләр яши, әмма мадам Натали, икенче ишектән кергәч, бишенче каттагы алты бүлмәле квартирага түләп кенә яшәп тора. Алар бирегә күптән түгел, әле ай да юктыр, күчеп килделәр, ә квартира хокук фәннәре профессоры Огюст де Брессонныкы, дөресрәге, борын-борыннан ук алар нәселенеке булган—Франциядә бик билгеле нәсел—аның ата-бабалары әле Бурбоннар заманында ук патша сараенда хезмәт иткән. Профессорны Мексикага илче итеп билгеләгәч, ул танышлары аша квартирасын бөтен йорт җиһазлары белән ике елга арендага биреп калдырган. Хәзер Парижда мондый абруйлы районда тулы бер катны алып тору бик кыйммәт, ә Булон урманы тирәсендә буш квартиралар булмый диярлек, бирегә француз аристократлары—аксөякләр яши, мөгаен, мадам Наталины шунысы кызыктыргандыр да әле.

—Сез аның белән таныштыгызмы соң, аның өендә булганыгыз бармы?—дип, Карлен сөйләшүне үзенә кирәкле якка борды.

—Әйе, ул монда күчеп килгәннең икенчеме-өченчеме көнендә үк таныштык. Шалтыр-шолтыр йөрүемне ишетеп, ул үзе мине чакырып кертте дә, хатын-кызларча сораштыра башлады: бу райондагы кибетләр, көр юу урыннары, чәчтарашлар, косметика салоннары турында.—Егетнең йөзендәге гаҗәпләнү чалымнарын күреп, Колетт мактангандайрак итеп әйтеп куйды:—Безнең танышуыбыз, миңа калса, бер дә гаҗәп түгел: икебез дә бер яшьләр тирәсендәрәк, мин Париж кызы, аның миннән сораштырыр нәрсәләре шактыйдыр, мәсәлән, күршеләре турында... Әле мин сезгә аның кайсы салонда шулай матур итеп киенеп йөрүен дә сөйли алам.

—И-и-и, чибәр һәм атаклы хатын-кызларга бирелә торган сорауларның иң кызыклысы инде ул,—дип, Карлен кызны тагын да үсендереп җибәрергә тырышты.—Аның җавабы да безнең хатын-кыз укучыларыбыз өчен иң кирәклесе булыр...

—Бу мәсьәләдә Наталины бәхет баскан. Аның ире,—дөрес, мин аны алгы бүлмәдәге көзге янында эленеп торган фоторәсеменнән генә күреп калдым,—менә шул: аның ире атаклы кутюрье Кристиан Лакруада эшли, ниндидер югары урында утыра. Натали үзенең Россиядә Кристиан Лакруа сәүдә йортында эшләгәнлеген, мсье Робер фирма эшләре белән шунда баргач, танышканлыкларын да әйткән иде.

—Димәк, аның ире француз?—дип, гаҗәпләнүен яшерергә тырышып, ашыгып сорады Карлен.

—Ә сез кем дип уйлаган идегез, немец дипме әллә?—дип көлеп җибәрде Колетт.—Шуңа күрә дә Натали аның янына Парижга күчеп килгән дә инде.

Көтелмәгән бу хәбәрдән Карлен ирексездән утыргыч аркасына ауды һәм мангаена бәреп чыккан тирләрен сөртеп алды. Машина эчендә, чынлап та, бик җылы иде, әмма егет Колетт сүзләреннән соң тирләп чыкты. Бөтенләй көтелмәгән, алдан әйтеп булмый торган яңа хәл килеп туа түгелме соң? Гүзәл Наталиның ире кайчандыр законлы карак легендар Рафик Сво бик югары бәя биргән алтын куллы оста түгел икән, ә иң зәвыклы модаларга мөнәсәбәте булган Робер исемле ниндидер француз икән бит. Бу очракта үзеннән-үзе меңләгән сораулар кайный башлый: иң әвәл, алай булгач, Мәскәүдә күптән түгел шау-шулы туй үткәреп уйнау нигә кирәк булган? Нигә ул туйда үзләре тирәсендә ыгы-зыгы тудыруның һич хаҗәте юк бер вакытта—Россия тәхетенә дәгъва кылып йөргән Шаман белән Дантес та катнашкан? Һәм, гомумән, җинаятьчел даирәләрдә зур абруйлы, чәчләренә чал куна башлаган горур әфәнде кая киткән? Карлен бит аны урыс «граверы»дыр яки, һич югында, ялган долларларны шудырып ятучы берәр эре аферисттыр дип фараз кыла башлаган иде. Мәскәү чибәре янында ниндидер Робер пәйда булу Карленга нәрсә вәгъдә итә—супербанкнотларның яңа, француз эзенме? Гүзәлләрнең гүзәле супермодель Натали түгел, әйтерсең лә, ниндидер атаклы шымчы яңа Мата Хари: Мәскәүдә дә ирле, Парижда да ирле, туенда кияү егетләре җинаятьчел генераллар, калган кунаклары да шул өердән, француз ире иң атаклы модалар салонында—һич аңлашылмый, башка сыймый торган винегрет була бит әле бу, дигән нәтиҗәгә килде Карлен.

Серле Наталиның ирләре мәсьәләсен тәгаенләп бетерү ниятеннән, Карлен шаяртып сорады:

—Мөгаен, мсье Робер шактый өлкән яшьтәге, чал чәчле, әмма әле корсак үстермәгән Карл Лагерфельдка охшаш кешедер, ә?

Колетт рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

—Сез мине көлдереп үтерәсез бит! Мин хәзер күнелемнән генә мадам Натали янәшәсенә ягымлы юанбай Лагерфельдны куеп карадым—и көлке дә пар килеп чыгасы икән! Хәер, мин Лагерфельдның модельләрен дә югары бәялим. Ә мсье Роберга килгәндә, ул үзенең чибәр хатынына

бик тә лаек: яшь, төз буйлы, сөйкемле һәм талантлы. Мадам Натали әйтә, ул Кристиан Лакруадан бүленеп чыгарга тели, үз салонын ачып, анда иң күркәм модель сезне кызыксындырган урыс мадамы үзе булачак, имеш.

—Искиткеч кызык, баш әйләндергеч сюжет! Димәк, мин героинямны дөрес сайлаганмын. Булачак топ-модельне алдан белеп тору бик сирәкләргә генә эләгә,—дип, барлык артистлык сәләтен жигеп, сокланган булды Карлен. Ул үзенең тагын да буталыбрак беткәнен тойды, әгәр дә мсье Робер Мәскәүнен алтын куллы «граверы» булса, Карлен өчен бик әйбәт буласы иде дә бит...

Әйе, дулкынланырлык та, каушап калырлык та булды шул. Бу очракта Карленнның бердәнбер куанычы—ярый әле Колеттка Натальяның Мәскәүдәге туй фоторәсемнәрен күрсәтмәде. Ул рәсемнәр сөт сатучы кызда берсүзсез шик тудырыр иде. Карленга хәзер күп нәрсәләрне янабаштан уйларга кирәк инде, ләкин ул әсәрләнеп әйткән генә булды:

—Әйе, Кристиан Лакруа салоны соңыннан менә диген өстәмә реклама алачак, Натали, чынлап та, бик купшы-нәфис киенә бит...—Карлен кирәгеннән дә артык яңалыклар ишетте, хәзер тыныч фикер йөртеп, нәтижәләр ясарга вакыт иде, шуңа күрә ул сүзен йомгакларга ашыкты:—Мин сезгә бик рәхмәтлемен, Колетт, аннары сезнең белән танышуыма да бик шатмын. Әгәр вакытыгыз һәм теләгегез булса, мин бүген сезне рәхәтләнеп берәр жиргә чакырыр идем—күңел ачып, матур кич үткәреп кайтыр идек,—шулай дип, ул бит очлары алсуланып киткән кызга карады.

—Рәхмәт, мин дә сезнең белән танышуыма шатмын—көн саен журналистлар белән әңгәмә корып торалмыйсың бит. Ләкин бүген минем башка эшләрем бар—гаилә тантанасы,—дип, үкенечле тавыш белән җавап бирде Колетт.—Әгәр иртәгә чылтыратсагыз, бик теләп сезнең белән очрашыр идем,—ул үзенең визит карточкасын алып, Карленга сузды.

## 4

Колетт белән аерылганнан соң, Карлен бик озак шәһәр үзәгендә җәяүләп йөрде, ничек кенә сәер булмасын, ул хәзер, ни салкынны, ни юешне, ни жилне тоймый иде, ә бит юкса көн һич тә үзгәрмәде, һич тә жылынмады—аның уйлары һаман Наталья турында булды: бөтенләй көтелмәгән яктан ачылып китте бит әле ул мадам, аның турында хәзер теләсә ничек фараз корырга була. Кристиан Лакруа сәүдә йортында эшләүче ниндидер француз Робер Натальяның ире булып чыкты да, бөтен эшне чуалтып ташлады. «Франк Мюллер» сәгатенә күз салып алгач, Карлен гажәпләнүеннән хәтта сызгырып жибәрде: көн уртасы булып килә икән ич инде, ә ул Мәскәүдә вакытында шәплә п ашарга күнеккән, шуңа күрә бик нык тамагы ачканын да шундук сизде. Елисей кырларындагы отельгә кайтып ашап алырга, аннары жылы-рәхәт номерда, телефоны янында янача уй-ниятләр корып утырырга кирәк иде.

Кыскасы, Париждагы беренче көнен уңышлы санарга була: ана «Себастьян» кибетендә дә фарт килде, Колетт белән дә—алардан кирәкле мәгълүматлар алынды, ә шулай да килеп туган хәлне аңлап бетерү өчен бераз ял итеп алмый булмый иде.

Әбәт ашап утырганда, Татлянның башына кинәт һич ышанып булмаслык уй килде, ул кулындагы кашыгын чак кына шулпалы тәлинкәсенә төшереп жибәрми калды. Мәскәүдәге туй, җинаятьчел даирәләрдә танылган алтын куллы кияү, Парижда югары мода өлкәсендә кайнашучы француз ир, анысы Карленны бөтенләй таң калдырган иде—әгәр дә бу вакыйгаларның башында ир кеше түгел, ә хатын-кыз торса: Мәскәүдә—кәләш, Парижда—ир хатыны, әнә шундый сокландыргыч гүзәл маржа кызы Наталья торса,—ни әйтерсең?

Көлке хәтта, һәммәсе дә нәкъ французча килеп чыга: шерше ля фам—хатын-кызны эзләгез! Бу хакта әле разведка мәктәбендә үк тукыган идеяләр: хатын-кыз, аның сәер кыланышлары, көйсезләнү-холыксызланулары, зәвыклары, теләк-таләпләре һәм хәтта аның җинаятьләре дә кабатланмас үзенчәлекле һәм үзенә генә хас булырга мөмкин! Супербанкнотларны сугып яту үзәгенең башында хатын-кыз булу мөмкинлеге Карленның күңелен шундый айкап ташлады ки, ул ашавын да онытты, десерт биргәннәрен дә көтеп тормастан, тизрәк үз номерына күтәрелде.

Парижга Карлен озакка дип түгел, күп булса, берәр атнага гына дип килде, шунлыктан эшне тиз тотарга кирәк иде. Франциядәге тәүге көн бетеп килә, ә Карленның әле нәрсәдән башларга дигән бер ачык уйнияте дә юк. Менә шунда ул бер ялгызың гына, дөресрәге, үзең өчен генә эшләүнең авырлыгын беренче мәртәбә тойды. Әгәр дә ул ялган акча ясаучыны көч-куәтле Америка исеменнән эзләсә, Парижда аңа шундук ярдәмгә килеп, Булон урманы янындагы күркәм йортны да, анда ирле белән яшәүче гүзәлне дә хәзер тәүлек буе күзәтү астына алып, телефоннарын тынлый башлар иделәр. Ә егерме дүрт сәгать, йә, ярый, кырык сигез сәгать эчендә булсын, ди, әгәр дә мсье Робер чынлап та бөек кутюрье Кристиан Лакруада эшли икән, аның турында бөтен мәгълүматны алган булыр иде инде. Әмма юк тек юк—аның каравы уңышын да беркем белән дә бүлешергә туры килмәс. Әгәр дә инде «граверның» эзенә төшсә, аның яшерен үзәгенә барып чыга калса, ике-өч айлык хезмәт хакына тиң премия һәм чинын-дәрәҗәсен күтәрү генә булмас, ә гомеренә җитәрлек зур байлык алыр. Бу соңгы өмет-хыял Карленны дәртләндереп җибәрде, аның өметсезлеккә бирелергә хакы юк, аннары уңыш дигәне дә әлегә аңардан мыскыллы йөзен чөергәне юк ич әле.

Кич җитте. Париждагы беренче кич... Карлен уйларыннан айнып, уянып киткәндәй булды. Сөт сатучы чибәр Колеттның бүген кич буш булмавына ул чын күңелдән үкенеп куйды, ә кичен номерда бер ялгызы утырып үткәрергә егет һич уйламый иде. Парижда аның барып керерлек яки кайда булса да ресторанга дәшеп, кәеф-сафа корырлык дуслары, артык якын кешеләре юк, димәк, кайчандыр, «Франс-суар» газетында стажировка үткәндә, иске сигез катлы йортның түбә астындагы акча түләп торган кысан бүлмәсенә алып кайтып күңел юата торган кызлары кала. Ә андыйлары бар иде.

«Дипломат»ыннан электрон блокнотын алып, Карлен шул кызларның Париждагы элекке телефон номерларын эзли башлады. Изабель... Беатрис... Мануэла... Жанетт...—дип Париждагы элекке мәгъмуналарының исемнәрен укыды ул, алар белән күптәнге очрашуларның нинди дә булса кызыклы-рәхәт мизгелләрен дә исенә төшерергә тырышты. Очрашуларның аерым рәхәт вакытларын тәфсилләп, бутап җибәрергә Ходай язмасын—хатын-кызлар бик тә үпкәләүчән, алар бит үзләрен ирләр хәтерендә бердәнбер һәм кабатланмас булып кала дип уйлый.

Карлен, күзен йомып, тисә-тиенгә, тимәсә—ботакка дигәндәй, бер исемгә төртте: Беатрис килеп чыкты. Кайчандыр Сорбонна университеты студенткасының телефон номерын бер сулыш белән җыеп та өлгерде. Хәзер инде Беатрис укуын тәмамлагандыр яки филфакның соңгы курсын кимереп ятадыр. Бәхеткә, Беатрис өендә иде, кияүгә чыкмаган, беркая китмәгән, кәефе әйбәт һәм хәтта Карленның чылтыратуына шатланган да иде. Күрәсең, егетнең ярлы стажер студент тормышын онытмагандыр, аны үртәп:

—Бәлки, син мине «Максим» ресторанына кичке ашка чакырырсың?—диде.

—Ә нигә чакырмаска, ди?—Карлен җавабы белән кызның бераз һушын алды шикелле.—Мин хәзер Мәскәүдә эшлим, анда да «Максим» рестораны ачтылар, ачу тантанасына мэтр Карден үзе килгән, дип сөйләделәр. Дөрес, минем әле анда булганым юк-югын—эш, төрле мәшәкатьләр... Париждагы «Максим» белән Мәскәү «Максим»ы соңгы

тәлинкәләренә, соңгы бокалларына һәм гардеробтагы элгечләренә хәтле бер-берсенә бер тамчы су кебек охшаш, диләр. Шулаймы-түгелме икәнен, димәк, бүген ачыкларга менә дигән мөмкинлек туа, бәлки, берәр гаугалырак мәкалә дә язып ташлармын. «Максим» икән—«Максим» булсын, мин синең тәкъдимеңне кабул итәм...

—Шаяртмыйсыңмы? Яки көтмәгәндә баеп киттеңме?—дип мыскыллап сорады Беатрис.

—Мин озак очрашмый торганнан соң яңадан очрашуыбызны зиннәтле «Максим»да билгеләп үтәрлек вакыйга дип саныйм. Аннары, минем өчен дә, синең өчен дә Карден гастрономиясе белән беренче танышуыбыз булыр,—дип шаярткан булды егет.—Әйә, сине анда сәгать ничәдә көтим? Бәлки, сине кереп алыргадыр?

—Юк, рәхмәт, мин үз машинамда килермен. Бер яхшылык эшлә, андагы метрдотельне кисәтеп куй, минем «Максим»га даими йөрүчеләргә охшамаган булуым да мөмкин. Анда мин төгәл ике сәгатьтән соң килермен.

## 5

Юл уңаеннан бик матур ак розалар бәйләме алып, Карлен «Максим»га билгеләнгән вакыттан егерме минут алданрак килде. Ул ялгызы гына ресторанның эчке бизәлешен карап йөрергә теләмәде, алдан алып куйган өстәл янына ашыкты—тыныч кына, җентекләп кенә сый-нигъмәт сайларга кирәк, аның элекке чибәркәен малайларча таң калдырасы килә иде. Метрдотельнең ярдәме белән тиз генә менюны хәл иттеләр: табынга «яңа урыслар» яратып эчә торган «Тайттингер» шампан шәрабе, Карлен үзе бары тик Мәскәүдә генә беренче мәртәбә авыз итеп караган устрицалар, французларның диңгез сыен ошатканнарын исәнә төшереп, зур гына лобстер һәм кара уылдык белән затлы семга балыгы китерергә кушты. Табын гел диңгез азыкларыннан гына торачагын чамалагач, төп ризык итеп берәр төрле кош ите өстәргә булды—эченә нарат җиләге белән ак гөмбә тутырып әзерләнгән ак көртлекләргә тукталды. Көртлек белән гөмбәләрне «Максим»га Польшадан китерәләр икән. Кыскасы, табын, Карлен Мәскәүдә күнегеп өлгергәнчә, урысча-кавказча бай булып чыкты.

Беатрис килеп җиткәнче барысы да әзер иде инде: заказ бирелгән, чәчәк һәм бүләкләр өстәлдә.

Кыз белән егет ул кичне «Максим» ресторанында бик матур итеп үткәрде, ресторан икесен дә сокландырды, бераз капкалап алганнан соң, алар икәүләп аның залын әйбәтләбрәк карап чыктылар. Әгәр дә бу ноябрь кичендә Карлен белән Беатрисны читтән карап торучы берәрсе булса, мөгаен, бер дә шикләнмичә: «Нинди бәхетле пар!»—дияр иде.

Елисей кырларындагы отель янында Беатрис белән саубуллашканда, Карлен сүз уңаенда гына әйтеп куйды:

—Миңа иртәгә синең ярдәмең һәм машинаң кирәк булачак. Мескен хәбәрчегә булышырга вакытың һәм теләгең булырмы? Мин бер бик җитди-мөһим мәкалә әзерлим, барып чыкса, ул минем киләчәк үсешем өчен зур эш булачак.

—Соң, эш синең киләчәгеңә бәйле һәм әгәр дә шуннан соң син Парижга ешрак та йөри башласаң, үзем дә, иске калтырчам да синең ихтыярыңда.—Бәхетле кыз һәммәсенә дә риза шикелле иде.—Сәгать ничәдә һәм кайда килим?

—Рәхмәт! Мин сиңа бүгенге матур кичебез өчен дә бурычлы һәм синең янәшәмдә булуың эшемә дә ярдәм итәр дип ышанам. Әгәр каршы булмасаң, иртәнге сәгать тугызга шушында, «Палас-отель» янына кил. Бергәләп капкалап та алырбыз...

Иртән ашап утырганда, Беатрис Карленның үзеннән нинди ярдәм көткәнен белергә теләде. Егет аңа ин элек «Себастьян» кибетендә төшереп алынган фоторәсемле Мәскәү журналын күрсәтте. Әлбәттә,

рәсемнәрне Беатрис сокланып карады: аңа кабриолет та, машинаның хуҗабикәсе дә бик ошады, өем-өем долларларга да тиешле бәясен бирде. Карлен кызның ничек тәэсирләнгәнен рәхәтләнеп карап утырды, аннары чын серен ачмыйча гына, Беатриска бераз мәгълүмат бирүне кирәк тапты.

—Мин «яңа урыслар» турында мәкалә язам. Алар хәзер үзләренең кыланышлары белән гарәп шәехләрен дә уздырып җибәрде. Һәркайда бик күп акча күтәреп йөриләр... Мине менә шушы «мазерати» эчендә утырган яшь хатын кызыксындыра. Аның исеме Натали, ул урыс кызы, Мәскәүдән. Хәзер Парижда—абруйлы-дәрәҗәле районда, Булон урманы янындагы күркәм бер йортта тора. Миңа мәгълүм булганча,—анысын ныклап ачыклап бетерәсе бар әле,—ул ниндидер француз мсье Роберга кияүгә чыккан. Мсье Робер Кристиан Лакруа салонында зур урында утыра... Тиздән, ул бөек кутюрьедән бүленеп чыгып, үз модалар салонын ачарга җыена, аның иң төп моделе үз хатыны, шушы Натали булачак. Әгәр дә бу мәгълүматлар дөрескә чыкса, минем язасы мәкаләм бөтенләй башка төсмер алачак... Сиңа тыңлавы кызыкмы?—дип, аңына килеп сорады Карлен.

—Бик тә кызык. Әмма мин сиңа ничек ярдәм итә алам соң?—Беатрис, аптырашта калыбрак, җилкәләрен сикертеп алды.

—Ашыкма, кофеңны эчеп бетер, китәр вакыт җитте. Барып җиткәч, вакыйгалар агышына карап эш итәрбез.

Машинага кереп утыргач, Карлен ялган долларларны юмарт сибә торган, Парижның әле яңа «пешеп чыккан» бу мадамы яшәгән йортның адресын әйтте.

Булон урманы янындагы әлеге күркәм йорт янына бик тиз барып җиттеләр һәм Карлен кичә үк билгеләп куйган урынга барып туктадылар. Нәкъ шул вакытта консьержлар каравыллап торган ике капкадан ике машина чыгып килә иде: берсе—кара «мерседес», икенчесе шулай ук немец машинасы—«порше», нәкъ шундыйны Карлен кичә «Себастьян» кибетендә күргән иде. Боларның теләсә кайсысында эшкә китеп баручы мсье Робер булырга мөмкин—мөгаен, аларның гаражында бер «мазерати» гына тормыйдыр. Шул хакта уйлана-уйлана, Карлен бакча түрендәге йортны игътибар белән күзәтеп утыручы Беатриска әйтте:

—Без уйлап-нитеп тормастан килдек. Мин очраклылыкка ышанам, «кинәт» дигән сүз минем яраткан сүзем. Нәкъ бер сәгать көтеп торырбыз, әгәр дә безнең бәхеткә таныш «мазерати» килеп чыкмаса, туп-туры Кристиан Лакруа салонына китәрбез һәм, шунда мсье Роберны күрергә тырышып, күрә алсак, аның Мәскәү гүзәле Наталига нинди мөнәсәбәте барлыгын сорашырбыз. Минем хәтта бу җәһәттән кайбер уй-ниятләрем дә бар, ләкин вакыйгаларны ашыктырмыйк, минем эшем уңучан була... Музыканны кабызып җибәр дә, миңа Сорбонна студентлары тормышыннан берәр кызык сөйлә,—дип елмайды ул.

Бер егерме минутлап вакыт үтте, капкалардан бер-бер артлы машиналар чыгып китә торды. Карлен бик вакытлы килгәнлекләрен искәртеп алды: мсье Робер мода салонында гади тегүче генә түгел, аның эшкә дә минутын минутка барасы юктыр.

Вакыт ага, эшнең уңышлы чыгасына өметләр дә эри бара иде. Карлен, бер минутка гына тимер капкалардан карашын алып, уйга калды: нишләргә соң хәзер? Монда Наталины эләктереп булмаса, чукынмыш Робер хезмәт иткән Кристиан Лакруа салонына бармыйча да булмас шул.

Кинәт бакча түрендә «мазерати»ның ерткычларча озын күләгәсе чалынып китте, Беатрис ирексездән күзләрен уып алды: әллә күзенә генә күренәме соң? Ул бит әлеге машинанын чыгуын түземсезлек белән көтә иде. Шунда ул капканың әкрен һәм тавышсыз гына ике якка ачылып киткәнен күрде—машина чыгып килә иде. Дулкынланудан Беатриснын сулышы кысылды, пышылдап кына нәрсәдер әйтергә теләсә

дә, авызыннан сүзе чыкмады, ул уйларына чумган Карленга бары тик йодрыгы белән каты гына төртеп алды. Егет шундук исенә килде һәм шатланып раслады:

—Ул үзе, жанашым. Кабыз моторынны, артыннан элдерәбез, тик күздән генә югалта күрмә. Мин мадам Натали ирен эшкә илтәдер дип уйлыйм, әгәр, әлбәттә, аның янәшәсендәге кеше мсье Робер булса...— «Мазерати»да ике шәүлә: ир һәм хатын-кыз шәүләсе яхшы күренә иде.

Берничә квартал үтүгә, Беатрис шатланып:

—Чынлап та, Кристиан Лакруа йортына баралар, ахрысы,—диде.

—Алайса, Беатрис, тыңла мине яхшылап. Бу очракта безнең бурыч бик гади һәм ачык. Автомобиль мода йорты янында туктагач, мадам Натали белән аның юлдашы машинадан чыгарлар, син алар артыннан барырсың. Мадамның өстендә нинди плащ яки пәлтә икәнен исеңдә калдырырга тырыш. Монысы—алар холлда туктап тормыйча, икәүләп лифтта мсье Робер бүлмәсенә күтәрелгән очракта. Ләкин, алар тукталып, аста берәрсе белән сөйләшеп китәргә дә мөмкин—французлар тел тегермәнен әйләндерергә ярата. Бәлки, кемдер мадам Наталига берәр мактау сүзе әйтер яки мсье Робер белән исәнләшер—кемнең кем икәнлеген аңлар өчен безгә шул житкән. Журналдагы рәсемдәге дама мадам Наталига охшаганмы һәм мсье Робер ниндирәк кыяфәтле кеше,—аның фоторәсеме миндә юк—менә шуларны белү бик кирәк.

—Мин үзем генә барамmы?—дип кабынып китте Беатрис.—Бу мажара аны кызыксындырганнан-кызыксындыра бара иде.—Әгәр дә...

—Мин дә синең арттан барып керермен,—дип тынычландырды аны Карлен.—Әгәр алар холлда, мин уйлаганча, ике-өч минутка гына тоткарлансалар да, мин эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап алырмын. Ләкин монысы безнең өчен иң уңышлы вариант. Әгәр дә инде алар холлда тукталып тормастан, өскә менеп китсәләр, син заказлар кабул итүче хатынга мөрәжәгать итәрсең. Әле генә бер чибәр хатын-кыз белән ир кеше үтеп китте, ул мадамның өстендә бик матур көзге пәлтә, мин дә үземә шундыйны тектермәкче идем, диярсең. Инде, «нинди хатын иде» дип сораштыра башласа, алар әнә теге, тәрәзә буенда торган купшы «мазерати»дан төштеләр, мөгаен, шушында эшлиләрдер, диярсен.

—Миңа Кристиан Лакруада пәлтә яки плащ тектерергә туры килермени? Ул бит коточкыч акча тора...—Беатрисның күзләре гажәпләнүдән шар булды, Карлен кычкырып көлеп жибәрде: хатын-кыз хатын-кыз шул инде.

Ул кызның тезенә кулын куеп, тынычландырып әйтте:

—Борчылма... Әгәр эш шуңа барып терәлсә, заказын да бирербез, түләрбез дә, ул пәлтә синең бүгенге мажараларыңның бер истәлеге булыр. Мин якын-тирәдә генә булырмын, кирәгем чыкса, шундук янына килермен, яме...

Беатрисның иске генә, әмма житез «рено» машинасы алтынсу «мазерати»ның артына ук килеп туктады, «мазерати» эченнән ике пассажир да чыкты, монысына Карлен шатланып куйды, Натали, мсье Роберны гына төшереп калдырып, үз йомышлары белән китеп барырга да мөмкин иде бит—ул чагында хет икегә ярыл: башта кайсысы артыннан барырга? Эш тагын ике-өч көнгә сузылырга мөмкин, яңадан Беатристан ярдәм сорарга кирәк булачак иде.

Теге парлар артыннан Беатрис та машинасыннан тиз генә чыгып китте, Карлен аңа:

—Пәлтәсен исеңдә калдыр, ул дөрестән дә бик матур...—дип пышылдап калды.

Алгы ишектән Натали белән мсье Робер һәм алар артыннан ук Беатрис кереп китүгә, Карлен да машинадан чыкты...

Зиннәтле итеп жиһазланган, хушбуй исләре аңкып торган иркен холлга барып кергәч, берничә минут элек кенә Беатриска күрәзәлек итеп әйткән күренешкә тап булды: ихтимал, мадам Натали иренең эшендә

еш булмыйдыр һәм хәзер мода йортының мсье Роберны каршы алган хезмәткәрләре, шаулашып, аның гүзәл хатынына, кигән киемнәргә соклану белдереп: «Нинди бәхетле парлар!»—диешә иделәр. Алардан ерак та түгел тукталып, Беатрис сатарга элеп куелган үрнәкләрне игътибар белән карарга кереште, Карлен белән күз карашлары очрашкач, бәхетле елмаеп, нәрсәләрдер ымлап аңлатырга тырышты—янәсе, ул бөтенесен дә белеп өлгергән иде. Хәер, биредә әллә ни сер дә юк, бәхетле парларга әйтелгән берничә сүзне ишетеп калуга, Карлен үзе дә кемнең кем икәнен аңлап алды. Әйе, мадам Натали журнал рәсемендәге «мазерати»да утыручының нәкъ үзе, аның ире мсье Робер да коеп куйган француз һәм Мәскәүдәге кияүгә һич тә охшамаган иде.

Иркен холлның аргы башында, коелган көзге яфраклар төсендәге матур келәм җәелгән баскыч янында—баскыч икенче катка менеп китә,—дүрт кешелек урынлы кафе-бар урнашкан, килүчеләр өчен баскыч астына ук өч кечкенә өстәл куелган. Бик уңайлы, Кристиан Лакруа үзе яхшылап уйлап ясаткан урын иде бу. Карлен Беатрисны шунда чакырды. Холлны күзәтеп торырга җайлы бер өстәл янына килеп утыргач, Карлен Беатристан сорады:

—Бу мода йортында бер күлмәкне киеп карау күпме вакытны ала икән, белмисеңме?

—Нинди күлмәктер бит,—дип көлемсерәде Беатрис.—Биредә һәр әйбер кулдан тегелә, димәк, кырык минуттан да ким булмастыр. Син миңа пәлтә урынына күлмәк тектерергә уйладыңмыни?—дип хәйләкәр генә төрттереп куйды кыз.

Карлен, елмаеп, үкенечле кыяфәттә кулларын җәеп җибәрде:

—Күрәсең, Ходай язмагандыр, Беатрис, ә сиңа пәлтәгә заказ бирә ала идек юкса. Ләкин син пошынма,—диде ул, кызның күзләрендәге моңсулыкны күреп,—син бүләккә лаек эш эшләдең, минем өстә калмас. Ә үлчәү-киеп карау мадам Наталиның үзенә кирәк, ул шуның өчен иреннән эш урынына килгән дә, мин моны ишетеп калдым. Безгә ул маржаны шушы рәхәт җылы урында көтеп утырудан да яхшысы булмас. Каршы килмисеңме? Сиңа нинди кофе китертим? Ә бәлки, берәр чәркә шатрез яки бенедиктан кирәктер? Урамда салкын бит...

Алар кафе-барда кырык минуттан артык утырдылар, шуннан соң гына холлда Натали күренде, аның артыннан мсье Робер килә—киеменә караганда, ул хатынын машинага хәтле генә озата иде. Шулай булып чыкты да, алар «мазерати» янында үбешеп саубуллашып торган арада, Карлен белән Беатрис үз машиналарында моторын кабызып утыра иде инде. «Мазерати» кире кайтыр юлга борылмады, юкса Карлен шулай булыр дип уйлаган иде, ә алга таба кузгалды, күрәсең, Натали Елисей кырларындагы кибетләрне бер йөреп чыкмакчы булгандыр, тик ул машинасын куярга урын таба алмыйча озак кына изаланды, аннары, ниһаять, кечкенәрәк бер кунакханәнең түләүле мәйданчыгына кереп туктады. Карлен, аның бераз китеп барганын көтеп торды да, артыннан атлады. Беатрис машинасында утырып калды, хәзер эшкә дөньяви хәбәрләр репортеры үзе керешә.

Наталиның балкып торган витриналарны сокланып күзәтүеннән, юлында очраган һәр кечкенә кибет яки салонга кереп чыгуыннан Карлен шуны аңлап алды: Натали әле Парижны яхшылап белми, ана ияләшмәгән, әмма шәһәр белән менә шулай ялгызы гына капшанып-танышып йөрү аңа рәхәт иде.

Биек үкчәле түфлидән булса да, Натали тиз-тиз, ашкынып атлый, аның атлавында ук ниндидер килешле нәфислек бар һәм ул ир-атларның кызыксынулы карашларын тоеп бара иде. Куеп калдырган «мазерати»еннан шактый ерак китеп өлгерде ул, мадам ерагайган саен Карлен шатлана барды. Иртәме-соңмы «биек үкчәле туфли үзен сиздерәчәк һәм Натали, бераз тын алып, аякларын ял иттерер өчен, Елисей кырларындагы берәр кафе яки ресторанга кереп утырырга мәҗбүр булыр. Менә шунда инде

Карленга жай чыгар: ул аның янына барып кунаклар, арган, хәлсезләнгән мадамга үзенең «көйсез» сорауларын бирер.

Хәзер инде хатынның атлауларында арыганлык сизелә, хәрәкәтләрендәге нәфислек юкка чыкты, биек үкчәле туфли кигәненә үкенүе йөзеннән үк күренеп тора. Карлен алдан уйлаганча, Натали юлында очраган кафе һәм бистроларга караштыргалый башлады. Берәр чынаяк кофе эчеп, ял итеп алырга, хатын-кызлар бүлмәсенә кереп, үзен тәртипкә китереп чыгарга унайлырак урын эзли иде ул. Карлен да арыды, ул да бераз утырып торырга, кофе гына түгел, берәр чәркә әйбәт коньяк та йотып куярга каршы килмәс иде. Көн шатланырлык түгел, ләкин Карленны аучы дәрте куа: Натали менә-менә үзенә әзерләп куелган капкынга килеп кабарга тиеш.

Алда «Гранд-отель»нең мәһабәт борынгы бинасы күренде, унтугызынчы гасыр азагында һәм октябрь революциясенә кадәр урыс байлары шунда яшәргә бик яраткан, отель шуңа күрә дә беренче дулкын урыс мөһаҗир язучыларының күп кенә романнарында сурәтләнгән. Кунакханәнең яңартылып, заманча стильдә гел пыяладан эшләнгән алгы өлеше тротуарга чыгып ук тора диярлек. Карлен: «Ял итеп алырга моннан да әйбәт урынны таба алмассың»,—дип уйларга да өлгермәде, Натальяга әллә үз артыннан бер дә калмый ияреп килгән америкаи шымчысының уй дулкыннары барып иреште шунда, әллә үзе «отель отель булыр инде»,—дип абайлап алды, әллә тагын зур пыяла дивар аша кергәч тә ишектән уң якта, Кристиан Лакруа модалар йортындагы шикелле, шулай ук баскыч астына урнашкан кафе-барны күреп алды,—ул ышанычлы адымнар белән ишеккә таба атлады, купшы униформа кигән горур швейцар аңа тәкәллефле генә итеп ишекне ачып җибәрде һәм елмаеп нәрсәдер әйтеп алды. Кунак мадам да аңа елмаеп җавап кайтарды.

Карлен да ишеккә якынайды, пыяла аша «Гранд-отель»нең иркен холлы яхшы гына күренә иде. Ул Натальяның кафе-барга, дөресрәге, ресторан гардеробына таба атлаганын шәйләде—түрдәрәк ресторан ишеге үзе дә күренеп тора иде. Парижга хас кечкенә өстәлчекләрнең күбесендә парлылар утыра, берсен генә өлкән яшьтәге өч кеше биләгән, иң аргы бер өстәл генә буш иде. Карленның башына әйбәт фикер килде: Натали хатын-кызлар бүлмәсенә кереп, төзәтенеп-ясанып чыккан арада, әлеге буш өстәл янына барып утырырга кирәк. Әгәр Натали кафега керергә уйласа, аңа Карлен янындагы буш урынга барып утырудан башка чара калмый, әгәр дә инде ресторанга юнәлсә, шымчыга да шунда барырга туры киләчәк. Аның каравы, әгәр Карленның чамалавы дөрескә чыкса, Наталины ул искәртмәстән, капылт эләктерәчәк: көтелмәгәндә кинәт һөҗүм итү—уңышның яртысы, дип өйрәтteләр аны разведка мәктәбендә.

## 6

Карлен соратып алган «Наполеон» коньягының бер чәркәсен эчеп бетергәндә, бар дәрте ташып торган, җыйнак-пөхтә, җинел адымлы Натали килеп керде. Көзге белән ихтыяр көче хатын-кызны ничек кенә үзгәртми, диген! Буфетчы янына барып, ул нәрсәдер сораштырганда, Карлен алдан әзерләп куйган «Фигаро» газетына төрелгән булды, үзенә атап әйтелгән сораудан соң гына ул газеттан башын күтәрде.

—Мин бирегә утырсам, каршы килмәссезме?—дип сорады Натали. Аның французчасы ярыйсы гына, әмма урыс акценты барыбер сизелә иде.

—Әйдәгез, рәхим итегез!—дип җавап бирде Карлен һәм канәгать йөзен газет артына яшерергә тырышты. Һәммәсе дә әлегә нәкъ ул дигәнчә бара иде.

Натали иркен сулап, рәхәтләнеп урындыкка утырды, әгәр дә янәшәсендә бу яшь кеше булмаса, хәзер ул аякларын зур ләззәт белән сузып җибәрер иде, аяклары, салкында кылдай тартылган телефон

чыбыклары шикелле, гүләп тора. Елисей кырлары буйлап кибеттән-кибеткә кереп йөргән соңгы минутларында ул кулына беренче очраган үкчәсез, жинел табанлы берәр туфли алып кияргә дә теләгән иде. Әмма хәзер ул үзе белән горурлана—түзде бит! Ни өчендер, мәрхүмә әнисенең яшьлегендәге әйтемен исенә төшерде: калтырансаң—калтыран, әмма фасонынны китереп йөр. Дөрес, бу сүзләрне кырыс урыс кышларында да капрон оек киеп йөрүче кызларга карата әйтәләр иде, әмма асылы барыбер шул булып кала—мода һәрвакыт, һәр заманнарда да корбаннар сорый.

Наталига сораган ашамлык-эчемлекләрен китергән гарсон, Карленнын буш чәркәсе белән кофе чынаягын җыеп алганда, сорап куйды:

—Тагын нәрсә булса да теләмисезме?

Карлен, бер генә мизгелгә газетыннан аерылып:

—Рәхим итеп, шуларны ук кабатлагыз,—диде һәм янадан газетына кадалды.

Натали, үзе теләгәнчә аякларын сузып утыра алмаячагын аңлады, кинәт кенә үзенең тунганлыгын да тойды һәм үзенә дә берәр рюмка эчемлек-фәлән алмаганына үкенде—ул әле Париж хатын-кызлары роленә кереп бетмәгән иде.

Ул кул изәп гарсонны чакырып алды һәм зур бер чынаяк ликерлы кайнар шоколад китерергә кушты, ә кофены соңрак бирүләрен үтенде. Кайнар шоколадның рәхәт җылысы тәненә тарала баруын тоеп, аны эчеп бетергәндә генә, күршесе, газетын бер якка куеп, илтифатлы елмайды һәм бик әйбәт итеп урысча сорап куйды:

—Парижда ничек яшисез соң, Россияне, Мәскәүне сагынмыйсызмы?

Егет елмаеп кына сорады шикелле, аның соравында бернинди күнелсезлек сизелмәсә дә, Наталиның эченә салкын йөгергәндәй булды, хатын-кыз сизгерлеге белән үзенә бәла киләсен бик тиз тоеп алды. Шул чагында гарсон аңа кофе китерде һәм Наталига уйларын тәртипкә китерерлек вакыт калган иде, ләкин башына бер юньле-рәтле фикер дә килмәде; кинәт үзен тораташ калдырган курку хисе ихтыярын гына түгел, бөтен тәненең җегәрен алган иде, ул гарсоннан бер рюмка коньяк китерүен үтенде, шуннан соң гына күршесенә таба борылды һәм җавап урынына елмаеп, үзе сорау бирде:

—Ә сез минем француз кызы түгеллегемне ничек чамаладыгыз? Сез урысча бик әйбәт сөйләшәсез. Россиянмы сез, Мәскәүлеме?

—Юк, мин америкалы, Лос-Анджелес шәһәреннән. Урысчадан тыш, тагын әле француз, инглиз, итальян телләрен дә беләм,—дип мактанып ташлады Карлен.

—Сез минем соравыма җавап бирмәдегез: минем урыс кызы икәнлегемне каян белдегез? Күпләр мине француз кызы дип кабул итә, француз телен яхшы беләм, дип саныйлар...

—Әйе, французча сез шактый әйбәт сөйләшәсез,—дип, аның белән килеште Карлен, үзе Натальяга сынап карап тора иде.—Ләкин мин нәкъ менә урыс акцентыгызны чамаладым. Шулай да мин сезне акцентыгыз буенча танымадым. Минем һөнәрем шундый—күпне белү, мин кеше серләрен аулаучы.—Ул инде Натальяның эчтән сагаеп, киеренке халәткә кергәнен сизеп алган иде. Бу халәт артык сизелерлек тә түгел шикелле, әмма шымчы-шымчы инде ул, ә Наталья тәҗрибәсез бер урыс кызы.—Мин сезне Мәскәүдән үк беләм, минем өчен сез бик кызыклы шәхес һәм сезгә берничә сорау бирмәкче булам,—дип юри тыныч кына дәвам итте Карлен, шуннан соң югалып калу, нишләргә белмәү һәм хәтта курку хисе Натальяның бөтен чибәрлеген күз алдында юды да төшерде. Сорау алып, тикшерү үткәргәндә, «хакыйкать мизгеле» дигән бер мизгел туа, әнә шул мизгелне ычкындырмаска гына кирәк. Һөҗүм никадәр аптырашта калдырырлык булса, уңышка ышаныч та шул кадәр зуррак була. Боларын Карлен яхшы белә иде.

—Кызык, кызык,—дип елмайгандай итте Наталья, каушап калуын

яшерергә теләп кофелы чынаягына үрелгән булды, әмма хәрәкәтләре ышанычсыз, кызганыч иде, ул бөтенләй коелып төште.

Ул «Гранд-отель»гә ник кергәненә үкенә башлады, аннары кинәт сорау алуга күчеп барган бу сөйләшүдән берничек тә котылып калып булмаячагын, бу американның әлеге өстәл янында янәшә туры килүе һич тә очраклы түгеллеген аңлап алды. Ә Карлен, аның кәефен җибәрүне максат итеп куйгандай, ашыкмый гына сүзен дәвам итте:

—Мина сезнең Мәскәүдә, «Пекин» рестораныңда күптән түгел булып узган туегыз бик ошаган иде. Бик бай туй, күп кешеле, ә кунаклары! Кунаклары нинди! Сезнең киявегез дә аерым даирәләрдә танылган кеше. Сүз уңаенда күрсәтим әле, сез икәү бергә бик матур күренәсез.—Ул кесәсеннән әлеге туйда төшерелгән берничә фоторәсем алып, аны Натальяга сузды.—Ә хәзер сезне Парижда очраклы гына очратам да, бередә дә, гаҗәп ки, күптән түгел генә ирегез барлыгын беләм—мсье Робер, ул да билгесез кеше түгел. Шуннан соң ничек инде сораулар тумасын, ди? Шулай түгелме?

Наталья бу фоторәсемнәрне беренче күрә: ул «Пекин» ресторанын янында, туй күлмәгеннән Константин Николаевич белән бергә басып тора. Димәк, бу адәм, чынлап та, аның турында бик күпне белә... Ул инде елап җибәрергә яки, истерикага бирелеп, кычкырына башларга әзер иде, шулай да үзен кулга ала алды һәм, тыныч булырга тырышып, сорады:

—Сез кем? Ни өчен сезне минем шәхси тормышым кызыксындыра?

Карлен, Көнбатышта яшәүче һәр кешегә хас булганча, бу «шәхси тормыш» дигән сүзләр белән хатынның һөҗүмгә күчәргә маташуын аңлады. Шәхси тормыш—ул тыелган зона, анда чит кешеләр кереп тыкшынырга тиеш түгел. Ләкин шымчы югалып калмады, өстенлекне үз кулыннан ычкындырмады.

—Сез хаклы, сезнең Мәскәүдә булсын, Парижда булсын—никахларыгыз, билгеле, шәхси тормышыгыз һәм ул мине һич тә кызыксындырмый, ышаныгыз, мин әдәп-әхлакка өйрәтүче түгел.—Ул, кулындагы кофе чынаягын әйләндергәләп, беразга тынып калды, гүя Натальяның сорау биргәнен көтә иде, ләкин Наталья дәшмәде.—Мине бөтенләй башка нәрсә кызыксындыра. Сез һәркайда күп долларлар белән акчалата түлисез, менә «Себастьян» кибетендә дә шулай эшләгәнсез.—Ул хатынга тиешле битендә ачылган журналны этәрде.

Наталья «Себастьян» кибетеннән «мазерати» сатып алган көнне төшерелгән бу фоторәсемне беренче тапкыр күрә иде ахрысы. Үзен фотога төшерүчене ул берәр очраклы сатып алучы гынадыр, чибәрлегенә һәм бик кыйммәтле машинасына сокланып кына төшергәндер дип уйлаган иде. Ул иртәдә, бигрәк тә кабриолеты янында басып торганда, Наталья үзен Голливуд кинойолдызларыннан да ким хис итмәгән иде! Менә сиңа фоторәсемгә төшүеңнең нәтиҗәсе! Туйда һәм кибеттә төшереп алынган фоторәсемнәр махсус сайланган—алары билгеле. Натальяны уңайсыз хәлдә калдырса да, ул әлеге үҗәт американның нәрсә төпченгәнен аңлап бетермичә, үзе һөҗүмгә күчмәкче булды: һөҗүм—иң яхшы саклану чарасы, диләр бит.

—Ә нигә, сатып алган әйберләренә акчалата түләү ярамыймы әллә? Мин бередә бертөрле дә җинаять күрмим...—диде ул.

—Юк, ярамый дип әйтмим,—дип килеште Карлен.—Әмма сез һәркайда бер үк сериядәге эре акчалар түлисез. Ә ул сериядәге егерме миллионнан артык долларлар, Американың Федераль резерв банкы подвалларыннан алынып, Россиядәге сәүдә максатлары өчен китерелгәч, Шереметьево аэропортында моннан ел ярым элек урланганлыгы сезгә билгелеме?—дип, ышандырырлык итеп алдашты Карлен һәм, хатынның күзләреннән карашын алмыйча, кырыс кына сорады:—Ул акчалар сезгә ничек килеп керде?

Наталья, күрәсең, теләсә нинди сорау көткәндер, ләкин мондый

куркыныч сорауны—ай-һай! Хәер, ул әле Мәскәүдә үк, иренең Кутузов проспектында булган остаханәсендәге яшерен урыннан шул долларларны табып алгач, нәрсәдәндер бик шикләнгән иде. Ләкин акчаларнын урланган булуы һәм аларны эзләүләре аның башына да килмәгән иде, алар бит инде ул доллларлар белән күптәннән һәм теләсә кайда, шул исәптән Парижда да түли тордылар. Әгәр дә Наталья моны сизенгән булса, акча урларга кулы күтәрелмәс тә иде. Бар нәрсәсе житеш булып торган чагында, яшь гомерен ни өчен шундый куркыныч астына куяр иде икән ул?! Һәр әйбер законлы иде бит—хатын иренең гөнаһлары өчен җавап бирми, ул моны гына белә иде. Хәзер инде менә ул үзе карак (икеләтә карак!) булып чыга һәм аны, гаепләп, җаваплылыкка да тарта алалар. Әмма шундый рәхәт иркле тормышны, Парижны югалтып, төрмәгә кереп утырырга аның бер дә теләге юк һәм ул, өметсезлектән гажиз булып, үзен-үзе белештермичә кычкырып җибәрде:

—Минем акчаларым түгел алар...

—Ә кемнеке соң?—«хакыйкать мизгеленең» нәкъ менә хәзер булганын аңлады Карлен, инде аны соңгы тамчысына кадәр кысып чыгарырга гына кирәк. Натальяның бөтенләй мәлҗерәп төшкәнен тоеп, ул тагын да кырысрак итеп кабатлады:—Кемнеке соң, йә?..

Хатын ыңгырашып пышылдады:

—Фешин Константин Николаевичныкы...

—Ул кайда яши, нәрсә белән шөгыльләнә, берәр кушаматы бармы?—Наталья исенә килеп өлгергәнче, Карлен тизрәк иң кирәкле мәгълүматларны алып калырга ашыкты. Сөйләшү-сорашуның рәсмилеген белдерү өчен, ул әңгәмәне язып барган кесә магнитофонын өстәлгә үк чыгарып куйды.

—Мәскәүдә, Кутузов проспектында,—Наталья йорт, квартира һәм телефон номерларын әйтте.—Һөнәре буенча рәссам ул. Дуслары аңа кайчакта Тоглар дип дәшәләр, ләкин мин аның кушаматмы-түгелме икәнен белмим.

Хатынның кинәт үлек төсле агарынып киткәнен күреп, Карлен:

—Әгәр саф һавага чыгып, әңгәмәбезне башка урында дәвам итсәк, каршы килмәссезме?—диде.

Наталья хәлсез-ихтыярсыз гына урыныннан кузгалды, алар бергәләп кафедан чыгып киттеләр. Тротуардан берничә адым атларга да өлгерә алмадылар, Карлен артта үзен искәртеп кычкырткан автомобиль тавышын ишетте, борылып карагач, «Гранд-отель» янына килеп туктаган машинасыннан елмаеп карап торучы Беатрисны күреп алды. «Егет икән!»—дип, күнеленнән генә мактап куйды аны Карлен, ә Натальяга борылып:

—Бирелә шоферы белән минем машинам тора, ул безне сез калдырып киткән «мазерати»ыгызга кадәр илтеп куяр. Каршы килмисезме?—диде.

—Рәхмәт. Мин, мөгаен, җәяү барып җитә алмас идем, аякларым һәм аркам бик сызлый,—дип зарланды Наталья һәм алар ак «рено» машинасына юнәлделәр.

Карлен машина ишеген ачып, алдан аны кертте дә, янәшәсенә үзе утырды.

«Мазерати»ны куйган урынга барып җитеп, машинадан төшкәч, Карлен Натальяны култыклап алды:

—Катлаулы әңгәмәбезне хет сезнең өйдә, хет «Палас-отель»дәге минем номерда дәвам итәргә кирәктер дип уйлыйм. Кунакханә моннан ерак түгел, шул ук Елисей кырларында, бары тик икенче башына таба гына.

—Сездә яхшырак булыр, якын гына да дисез. Шул кадәрле арыдым, бу коточкыч вакыйгадан тизрәк котыласым килә,—дип, мәҗбүри ризалашты Наталья. Аның элекке гүзәллегенең эзе дә калмаган иде инде.

—Тизрәк булмас дип куркам, сез бик күнелсез хәлгә килеп капкансыз. Мондый зур күләмдә урлашу гадәти җинаять кенә түгел, дәүләтнең икътисадына зыян китерү санала—Америкада акчага бөтенләй

башка мөнәсәбәт бит. Әгәр дә без «Палас-отель»гә барырга уйласак, мин машинамны җибәрәм...—диде Карлен.

Ул «рено» янына барып, Беатрис белән саубуллашканда, кич белән шылтыратырга вәгъдә итте. Наталья янына әйләнеп килгәч, аның бөтенләй мәлҗерәп төшүен күреп:

—Рульне үзем тотсам, каршы килмәссезме?—дигән булды.

Наталья, бер сүз дә әйтмичә, ана ачкычларын тоттырды.

## 7

Номерына кайтып кергәч, кунакны чишендерергә булышканда, Карлен аның көч-хәл белән генә басып торганын абайлады. Андый мизгелләрдә кеше, үзен-үзе белештермичә, теләсә нәрсә эшләргә мөмкин. «Алдан әйтеп булмый торган стадия»... Иллинойстагы укытучылар мондый халәтне шулай атыйлар иде бугай. Натальяның киеренкелеген бик тиз йомшартырга кирәк иде, шунлыктан Карлен, ресторанга шылтыратып, бер шешә әйбәт коньяк, урысча шәп саналган кара уылдык, балык, дердериле тел-мазар, яшелчә һәм кофе китерүләрен сорады. Кофены янып торган спиртовкалы кофе савыты белән бирүләрен үтенде—әңгәмә озакка сузылырга мөмкин иде. Наталья аның телефоннан сөйләшүен ваемсыз гына тыңлады, ул хәзер нәрсәне булса да аңларлык хәлдә түгел, үзенең өметсез уйларына кереп баткан иде.

Әңгәмәне дәвам иттерергә кирәклеген һәм хәлнең бик җитдилеген аңлатып, Карлен өстәлгә аның алдына ук диктофонын куйды да кабызып җибәрде. Әмма әлегә кадәр язып алынган күңелсез сорауларга газапланып биргән җавапларны тыңлап бетереп булмады—көндезге ресторанның өлгер гарсоны номерга арбасын тартып килеп тә керде, «ә» дигәнче табынны да корып куйды.

Карлен Натальяны табын янына чакыргач, хатын сискәнеп китте һәм кинәт күңелле генә итеп:

—Әйе шул, мина хәзер шәпләп кенә эчеп кую комачауламас,—диде.

Татлян аның теләсә нәрсә эшләргә әзер икәнлеген сизенеп, ул-бу булмагае, дигәндәй, диктофонның мини-кассетасын алды да аны кесәсенә яшерде: бу маржадан барысын да көтәргә була.

Ул чәркәләргә коньяк салды, көннең начарлыгын әйтеп, кәеф турында да нәрсәдер сөйләнеп, эчеп куярга тәкъдим итте. Наталья кыстатып тормады, көтмәгәндә шешәне кулына алып, коньякны су эчә торган фужерга салды, чәркәдәгесен дә шунда өстәде һәм, берсүзсез-нисез, берничә йотымда су эчкән кебек кенә итеп эчеп тә бетерде—урыс гадәтләренә күнеккәнлеге күренеп тора иде. Табын янында Карлен эш турында бер сүз дә кузгатмады, күбрәк Париж һәм һава хәлләре дигән булып сөйләнеп утырды. Эчкәне башына китә башлагач, Наталья үзе «Гранд-отель»дә кузгатылган күңелсез әңгәмәне яңартырга маташмакчы иде, ләкин Карлен урынлы гына әйтеп куйды:

—Россиядә шундый мәкаль бар бугай: һәрнәрсәнең—үз вакыты.

Бу сүзләр Натальяга икеле-микеле булып тоелды, ахрысы, кинәт кенә ул Карленга күз уйнатырга, болай да сыланып торган оекларын төзәтергә тотынды, әмма, башына киткән булса да, американның битараф күз карашын күреп, үзенең әшәке кыланганын сизенде. Кофега чират җиткәч, Карлен:

—Менә хәзер без әңгәмәбезгә кире кайта да алабыз,—диде.—Һәм аны кул хәрәкәте белән тәбәнәк өстәл янындагы кәнәфигә күчәргә чакырды, кофелы чынаякларны да шул өстәлгә китереп куйды.

Хәер, аның артык мөһим сораулары да калмаган иде инде, ул үзенә кирәклесен алып бетергән иде. Әмма Натальяның сүзләрендә, үз-үзен тотышында ниндидер әйтеп бетерелмәгән серләр кала шикелле—үзен гаепсез сарык бәрәне итеп кенә күрсәтәсе килсә дә, аның алай

беркатлы гына түгеллегенә Карленның иманы камил иде. Көтмәгәндә, аңа тәвәккәл бер уй килде:

—Мин сезне Мәскәүгә алып кайтырга тиешмен. Сезне Фешин әфәнде белән күзгә-күз очраштырырга кирәк, бәлки, сез аңа яла ягасыздыр—кем белә. Акчаны нindидер Тоглар түгел, ә сез унга-сулга сибәсез бит, шулай түгелме?—Килеп туган хәлдә бик урынлы сораулар иде шикелле болар, әмма һич көтелмәгән тәэсирле булдылар.

Наталья, агарынып, чыелдап кычкырып, кофе чынаягын кулыннан төшереп җибәрде, чынаяк тәлинкәгә бәрелеп чыңлап куйды.

—Юк, юк! Үтерсәгез дә, Мәскәүгә кайтмыйм мин! Теләсә нәрсә эшләтегез, ләкин кайтмыйм, ялварып-ялынып сорыйм, зинһар...—һәм ул, Карлен һич көтмәгәндә, кәнәфидән шуып төште дә аның алдына тезләнде.—Иң яхшысы, мин үземне-үзем шушында, Парижда үтерәм, анда кайтсам да, мине бары тик үлем генә көтә.

—Нишләп? Кем сезне анда үтерергә тели?—дип, шәфкатьсез сорау бирде Карлен, ул аны тынычландырырга да тырышмады, чөнки тагын нindидер бик әһәмиятле сергә килеп төртелгәнен сизде.

Мона кадәр шактый озак үзен кулда тотып килгән хатын түзмәде, акырып елап җибәрде, күз кырыеннан агып төшкән сөрмә буяуларын сөрткәләп, әйтергә мәҗбүр булды:

—Мин ул акчаларны Мәскәүдә Фешиннан урладым, әгәр аның дуслары моны белсә, мине өзгәләп кенә ташлаячаклар,—диде.

—Ә-ә-ә, эш менә нәрсәдә икән!—дип чын күңелдән көлеп җибәрде Карлен, әмма шундук җитдиләнде.—Каракныкын бур урлаган булып чыга, ә җавап тотарга теләмисез, Парижда иң бай дамаларның берсе булып яшәргә хыялланасыз: квартира, «мазерати», мода дөньясында танылып килүче ир. Акылың алтын икән! Күпме урладыгыз инде сез?

Наталья, ничек кенә сындырылган-изелгән булмасын, кинәт акылына килеп, чын күңеленнән үкенгәндәй, уйлап та тормыйча:

—Әй, күп, бик күп, тулы дүрт миллион доллар!—диде. Югыйсә әйтелгәннән шактый артык чәлдергән иде.

—Аз түгел. Фешин әфәндегә яшәргә күпмесен калдырдыгыз инде?—дип, мыскыллап ачыклады Карлен.

—Бер дә калдырмадым, соңгы тиененә кадәр алдым...—Наталья гаепле башын игән булып кыланды.

Карлен «әдәп-әхлак» дип, сөйләшеп тормады, ачу белән кистереп:

—Сез мәкерле генә түгел, комсыз да хатын икәнсез. Ничек диләр әле: комсызлык фраерны һәлак иткән, диләрме? Бер нәрсәне генә аңлый алмыйм: нигә сез моны эшләдегез? Сез бит аның хатыны идегез, акчалар болай да законлы нигездә сезнеке иде... Мантыйкка сыймый, мадам Натали. Ман-тыйк-ка...

Хатын көлемсерәп куйды, аның күзләрендә очкыннар кабынды:

—Шулай дип уйлыйсызмы? Әле житмәсә, минем хакта барысын да беләм, дип раслаган буласыз. Ул вакытта сез минем Фешин белән очрашканга кадәр, әллә кайчаннан Робер Платтның сөяркәсе булуымны да белергә тиешсез, ул бары тик финанс мөмкинлекләре булмаганлыктан гына миңа өйләнә алмый йөрүен кат-кат әйтә килде. Менә мин шул четерекле мәсьәләне үземчә хәл итмәкче булган идем...

—Фешин хисабыннанмы? Аның акчалары һәм язмышы хисабыннанмы? Башкаларны бәхетсез итеп үз тормышыңны бәхетле итеп буламы соң? Миңа Тоглар да сезне ярата шикелле тоелган иде. Һәрхәлдә, сезнең туегызда ул бик бәхетле күренгән иде...—Бу сүзләрне Карлен кырыс итеп, гаепләп әйтте.

Наталья дәшмәде, үзенең бу үҗәт шымчы күз алдында нинди түбәнкабахәт кеше булып калганлыгын аңлый иде инде ул. Ләкин комсызлык турында әйтелгән сүзләр аны тәвәккәл бер фикергә китерде: әй, беткән баш—беткән! Бик нык килеп капканын сизгәч,—әле белеп булмый, кемнәр куркынычрак: братвамы, дәүләтме, әллә бу американмы,—ул иДәннән

күтәрелде, юбка итәгендәге юк чүпне каккалаган булды һәм көр тавыш белән, бөтенләй җинаятьчеләрчә кыланып:

—Әйдә, начальник, тыныч кына килешеп аерылыйк. Син мине тапмадың, мин сине күрмәдем. Шулай буламы?—диде.

Аның мондый оятсызлыгыннан көлә-көлә, Карленның эченә кату чыкты, ниһаять, күзендәге яшьләрен сөртеп, мыскыллап сорады:

—Сез моны ничек күз алдыгызга китерәсез инде, мадам?

—Мин сезнең белән долларларымны бүлешәм һәм сез мине онытасыз. Шереметьево-2 аэропортында югалган долларларыгызның җеп очын кулыгызга тоттырдым, рәхәтләнеп Мәскәүдә казыныгыз—флаг хәзер сезнең кулда.

—Ләкин сез онытасыз, мин ришвәткә сатылып теләсә ни эшләргә әзер урыс милиционеры түгел, мин яшерен хезмәт агенты. А-ме-ри-ка-ны-кы...—дип, Натальяга барып җитсен өчен иҗекләп әйтте Карлен.— Хәзер аңладыгызмы инде?—Һәм ул, бераз кәпрәебрәк, аңа үзенең иң соңгы чиктә генә күрсәтелергә тиешле чын таныклыгын күрсәтте. Ләкин хатын ул документка карап та тормады.

—Барлык ментлар да бер төсле, вакыты җиткәнче генә алмый торасыз, ә мин сезгә җитди сумма тәкъдим итәм...—диде ул.

—Җитди дигәнең күпме була инде ул?—дип кызыксынды Карлен һәм кәнәфигә аркасын терәп, хатынның икенче кыяфәткә керә барганын күзәтә башлады.

—Сез мине яңадан да комсызлыкта гаепләмәс өчен, нәкъ яртысын бирәм. Шулай гадел булыр, дип уйлыйм: мин дә бит үз тормышымны куркыныч астына куйган идем.

—Юк, анысында һич шигем юк,—дип көлемсерәде Карлен.

—Тик торганда, бер дә юктан берьюлы ике миллион бакс алу—һәр агентка да эләкми ул, хәтта Американыкы булса да,—дип, үз чиратында Наталья да мыскыллы төрттереп алды, шымчының да карашы алмашынганын сизде, күрәсең.

—Бу тәкъдим турында уйларга, һәрьяклап үлчәп-исәпләп бетерергә кирәк,—диде Карлен, аның тавышы элекке шикелле үк кырыс түгел иде инде һәм хатынны яңадан өстәл янына чакырды—анда ашар-эчәр нәрсәләр калган иде әле.

Бу юлы коньякны чәркәләргә Наталья үзе салды һәм тост тәкъдим итте: шәфкатьлелек өчен. Карлен сүзсез генә эчеп куйды, аннары хатынга сынаулы караш ташлады.

—Акчаны мин хәзер үк, шушында ук кулдан-кулга ала аламмы?— дип сорады ул.

—Әйе, бер кырык минуттан. Безгә барабыз да, мин сезгә туп-туры кулдан-кулга бирәм. Әлбәттә, шундый суммадан аерылуы кызганыч, әмма ирек анлык кына торадыр. Дөрес, минем бер шартым булыр...

—Нинди?—дип ачыклады Карлен. Бу хатынның бөтенләй үзгәреп китүе аны хәйранга калдырган иде. Шайтан алгыры, бу аңа хәтта ошый да башлады.

—Беркайчан да һәм беркайда да сез мине Парижда күргәнегезне телгә алмаска тиеш буласыз,—дип чатнатып әйтеп салды Мәскәү карагы яки әле пешеп җитмәгән Париж мадамы.—Яки—яки...

—Офицер сүзе бирәм,—дип, ихластан һәм җитди ант итте Карлен. Бер сәгатьтән кесәсенә ике миллион доллар керү уе инде хәзер үк аның күңеленә рәхәтлек бирә иде. Алай гынамы сон—аның күңеле җырлый, ул биеп китәргә әзер тора иде: вакыйганың болай хәл ителерен ул хәтта күз алдына да китермәгән иде бит.

—Нишлисең бит, Америка офицерының намуслы сүзенә ышанырга кала инде...—Наталья, үзен тәртипкә китереп, бизәнеп-ясанып алыр өчен кечкенә сумкасына үрелде.

«Бигрәк тә сезнең башка юлыгыз калмаган чагында, мадам»,—дип күңеленнән нәтиҗә ясап куйды журналист.

## 8

Ике сәгатьтән соң Карлен, нәкъ ике миллион доллар салынган пластик пакет тотып, номерына кайтып керде. Ул шундук акчаларны санап чыкты—чибәр Натали бу юлы алдамаган, әйткәнен намус белән үтәгән иде. Карленнын Франциягә килгәненә ике генә көн үткән иде әле—ә ул инде барлык мәсьәләләрен дә хәл итеп бетергән—ул болай ук тиз уңышка ирешермен дип уйламаган да иде. Шатлыгыннан ул Мәскәүгә, үзенең Ольгасына чылтыратты: аның өс һәм аяк киеме үлчәмнәрен ачыклады—хәзер ул акчасын күпме кирәк, шул кадәр исраф итә ала иде. Крис белән Абрекны да онытмады, ләкин аларга чылтыратып тормады, болай да зәвыкларын һәм гадәтләрен белә бит, күнеленнән генә аларга яшел тышлы дипломатик паспорт өчен рәхмәт укыды. Бу паспорт белән Карлен Россия башкаласына тикшерүсезнисез теләсә ни чаклы акча алып кайта ала иде. Мондый байлык белән ул бөтенләй башкача яши башлаячак: туен да шаулатып үткәрәчәк, хатыны исеменә яздырып менә дигән квартира сатып алачак—кыскасы, исенакылларын китәрлек мөмкинлекләр ачыла, ул бит, ниһаять, тегеләймеболаймы, супербанкнотлар ясау белән яки аларны шудырып тору белән шөгыльләнүче Тоглар кушаматлы кешегә килеп чыкты.

Шул ук кичне сөт сатучы Колеттка шылтыратып, аны ресторанга чакырды. Ырымнарга ышанучан Карлен үзенең Париждагы уңышлары шул кыздан башланды дип исәпләде, аннары ошый да иде ул аңа—сүзгә үткен, сөйкемле кыз.

Парижда ул тагын ике көн торды, чөнки көннәр бик матурланды: жылытты, кояш күренде, болытлар эреп бетте һәм җил тынды—әйтерсең лә, Франция башкаласына әбиләр чуагы кайтты. Мондый көннәрдә, аның күнелне кузгата торган урамнарында иркенләп йөрмичә китеп бару—гөнаһ булыр иде. Әле бит Беатриснын да күңелен күрәсе бар иде: ул ана тән жылысы да, жан жылысы да бирде, вагъдә ителгән бүләкләрен дә кызганмады... Карлен хәтеренә Париж серле, ягымлы, уныш вагъдә итә торган шәһәр булып кереп калды...

Күп бүләкләр төяп, ул «Эйр-Франс»ның төнге рейсы белән кайтып китте. Самолет Мәскәүгә таң атканда килеп төшәсе, шуңа күрә Карлен, үзен каршы алуларын үтенеп, дусларын борчып тормаска булды. Ихтимал, кәефе яхшы булгангадыр, самолетта ул черем итеп тә алмады—һаман төрле планнар корып утырды. Хәзер бит ул максатына шактый ук якынлашкан иде, шунадырмы, вакыт-вакыт эченнән генә ялган долларларның серен белгән кешенең кушаматын кабатлады. Башында, һич китмәстән шул бер үк сүз бөтерелә иде: «Тоглар... Тоглар...». Кинәт кенә ана бу исемне үзе кайчандыр ишеткән шикелле булып китте. Сирәк кушамат, буташтырырга һич мөмкин түгел. Ләкин Карлен анын белән бер нәрсәне дә бәйли алмады, әмма башындагы уйдан да котылып булмый иде...

Өенә кайтып кергәч, ул әйберләрен дә сүтеп-бушатып тормыйча, үзенең һәрнәрсәне белүче компьютеры янына ашыкты, анда бит ялган акча ясаучыларнын барысына да мәгълүматлар тупланган. Тоглар кушаматлы кешене бик күп бүлекләрдән эзләп карады, хәтта охшаш исем дә чыкмады, инде өметен өзеп, ул, тисә—тиенгә, дигәндәй генә, үлгән «граверлар» исемлеген ачты. Шунда эше уңды да: исемлекнен иң сонында ул тырышып эзләгәнен тапты—ФБРдагы коллегалары юкка гына ипи ашамый икән шул. Мәгълүматлар мондый иде: «Фешин Константин Николаевич, 1943 елны туган, дәүләт өчен әһәмиятле документларның ялганнарын ясаганы өчен хөкемгә тартылган. 1966 елдан бирле даими Мәскәүдә яши, өйләнмәгән. Җинаятьчел даирәләрдә абруй-дәрәжәле кеше. Бик сирәк һөнәр иясе—теләсә нинди документны чынынннан аермаслык итеп охшатып ясый, димәк, аерым хәлләрдә акчаларны да ясый ала, дигән сүз. Кушаматы—Тоглар. 1990 елнын декабрендә Мәскәү тирәли әйләнмә юлда автокатастрофада һәлак булган, Востряков зиратына жирләнгән, кабер номеры—11632".

Һәлак булган? Янә нинди дер сер. Ә бәлки, хокук органнары яки көндәшләре күзеннән озакка юкка чыгып, ялган супербанкнотлар ясауны юлга салу максатыннан, оста оештырылган ялган үлемдер. Вакыт ягыннан бөтенесе дә туры килә ич. Шунда Карлен «Пекин»дагы туйдан төшереп алынган фоторәсемнәргә Абрек биргән аңлатмаларны исенә төшерде, әле бик иртә булуга карамастан, дүртенче катка чылтыратты. Трубканы Абрек үзе алды. Исәнләшкәч һәм үзенең кайтып төшкәнен әйткәч, Карлен сүзен озын-озакка сузып тормыйча, туп-туры сорады:

—Хәтерлисеңме, без ничектер «Пекин» ресторанында узган бер бик бай туй һәм андагы кияүне кайчандыр Рафик СВО агай бик югары бәяләве турында сөйләшеп утырган идек? Исеңә төшер әле, зинһар, аның кушаматы Тоглар түгел идеме?

—Әйе, нәкъ шулай—Тоглар!—дип шатланып җавап бирде Абрек—ниһаять, искә төште бит. Соң, шундый сәер кушаматны хәтердә калдырып буламыни? Кувалда түгел, Кистән түгел, Балда түгел. Сиңа нигә кирәк булды соң әле ул? Аның турында мәкалә язып бастырырга телисеңме әллә?—дип, йокылы тавышы белән иснәп куйды Абрек.

Ләкин Карлен аның нәрсәләр мыгырданганын ишетмәде дә... Һәммәсе дә тигеләй дә, болай да туры килә: АКШның махсус хезмәт оешмалары җир бетереп эзләгән кешенең кушаматы—Тоглар.

*Ахыры киләсе санда*



## «Казан утлары» елъязмасы

**Моннан 25 ел элек (1977)** «Казан утлары» журналында **Хәсән Туфанның** шигырьләре *(№ 1)*, **Нәҗар Нәҗминең** «Иблис» поэмасы *(№ 7)*, **Хәсән Сарьянның** «Бер ананың биш улы» повесте *(№ 9)*, **Рәдиф Гатауллинның** (Гаташның) «Европада татар шагыйрьләре» циклыннан шигырьләре *(№ 9)*, **Мәгъсум Хуҗин** хикәяләре *(№ 10)* дөнья күргән.

**Моннан 20 ел элек (1982)** «Казан утлары» журналында **Нурихан Фәттахның** «Сызгыра торган уклар» *(№№ 3-5)* романы, **Сибгат Хәкимнең** «Эзлиләр Европа буйлап» *(№ 5)* **Разил Вәлиевнең** «Иске сәгать дөрес йөри» *(№ 6)* повесте, **Мөхәммәт Мәһдиевнең** «Исәнме, Кәшфи абый!» *(№ 8)* повесте һәм **Зөлфәтнең** «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» *(№ 8)* поэмасы, **Мәгъсум Хуҗинның** «Өч каен ышыгы» *(№ 11)* хикәясе, **Әмирхан Еникинең** «Соңгы китап» *(№ 12)* әсәре урын алган.

**Моннан 15 ел элек (1987)** «Казан утлары» журналында **Гариф Ахуновның** «Идел кызы» *(№ 1, 2)* романы, **Мәдинә Маликованың** «Басып сайрар талы бар» *(№№ 3, 4, 5)* романы, **Рәшит Әхмәтҗановның** «Бишташ» *(№ 4)* поэмасы, **Равил Фәйзуллинның** «Таулар» циклыннан *(№ 7)* шигырьләре, **Рашат Низамиевның** «Беренче мунча» *(№ 8)* хикәясе, **Рөстәм Мингалимнең** «Өченче булмәдә эт яши» *(№ 8)* пьесасы, **Әхәт Гаффарның** «Яшиселәр алда иде әле» *(№ 9)* повесте басылган.

**Моннан 10 ел элек (1992)** «Казан утлары» журналында **Әхмәт Рәшитнең** «Колшәриф» поэмасы *(№ 1)*, **Туфан Миңнуллинның** «Илгизәр + Вера» пьесасы *(№ 9)*, **Фоат Садриевның** «Таң җиле» романы *(№№ 10, 11)*, **Тәүфикъ Әйдинең** «Йөртә безне язмышлар» дип исемләнгән сәяхәтнамәсе *(№ 11)* укучыларга барып ирешә.



## Асия Юнысова

**СӨЕНЧЕ**

### Әллә яфрак, әллә...

Кыштыр-кыштыр! Әллә яфрак, әллә...
Балачакны искә төшереп,
Лампа яктысында утырамы
Минем әни дәфтәр тикшереп?

...Көн дә шулай өйгә алып кайта
Кочак-кочак дәфтәр—төн озын.
Иплэп кенә ача дәфтәр битен,
Уятудан куркып ул-кызын.

Көнен—мәктәп, кичен дәфтәрләре
Урладылар бездән әнине.
Арган йөзе, уйчан күз карашы
И әрнетә иде гел мине.

Безнең өчен әни. Башкаларга
Укытучы Апа иде ул.
Апа иде әби-бабайга да,
Укучысы иде бар авыл.

Агитатор иде. Арып кайта.
Иртәгесен кабат яшәрә.
Авыл сәхнәсенә җырлап чыга
Галиябану яки Мәйсәрә.

Өйдә бәйрәм, әни бәйләм алып,
Җылы мичкә арка терәтеп,
Сөйләп китсә безгә «Ак Бүре»не,
Тагын берне шуңа ияртеп.

---

Асия ЮНЫСОВА— *шагыйрә, журналист; балалар өчен «Ускән кыз» , «Кышны яратам», шулай ук «Айлы юл» исемле лирика китабы авторы. Казанда яши.*

Ак нияттә узган гомер юлы
Чәчләренә калган ягылып.
Акъәбие хәзер авылның ул,
Ак яулыгын йөри ябынып.

Кыштыр-кыштыр! Әллә яфрак, әллә
Әни кулындагы орчыгы...
Яфрак-яфрак—хатлар түгелме, дип,
Хәбәр көтә, микән борчылып?

## Сөенче

—Сөенчегә миңа ни бирәсең?
Алып килдем сиңа сөенче!—
Шулай диеп, шатлык тояп килгән
Кем ул булган илдә беренче?

Ерак юлдан кайтып килгән җайдак—
Уң кулында очлы сөңгесе.
Илгә кайткан куанычлы хәбәр,
Сөңге очында кайткан сөенче.

Илче булып йөргән киленчәкләр,
Кендек кискән изге карчыклар
Тиешлесен алган хәбәренә—
Алтын-көмеш чыккан янчыктан.

Йә алкасын салып биргән сылу
Егетеннән алган хат өчен.
Аргамаклар хәтта җәл булмаган,
Ат кадәрле булса сөенчең.

Яланаяк чаба бер малайчык,
Барын узып, тузан туздырып.

И шәп булсын иде сөенчесе,
Шатланырлык, телдән яздырып!

Үзе чаба, үзе оран сала:
«Сөенче!»—ди.—Миңа алдырык!»
«Сөенчегә—сиңа сул колагың!»—
Кемдер үрти, йөрәк яндырып.

Сөенечләр сирәк күргән халкым
Сөенә белгән азга олыдан.
Булганына канәгатьлек холкын
Мирас иткән кызы-улына.

Бер шатлыкны ике итәр өчен,
Яулык биреп күлмәк котлаган.
Шуңа күрә күркәм бу гадәткәй
Тарих буйлап алга атлаган.

Югалтмаска иде бу йоланы!
Яңа гасырларның капкасын
Җитезаяк яңа кыз-малайлар:
«Сөенче!»—дип кат-кат шакысын.

## Малай кайтты өйгә

*Сөмбелгә*

Уңган хатын малай таба, диеп,
Ул тапканны зурлау—электән.
Әй, анысы!
Һәр баланы сандугачтай күреп,
Өй түренә бәллү әленгән.

Мәшәкате-мәхәббәте бергә—
Бала урны гел дә гел түрдән.
Тик шулай да малай анасына—
Олы хөрмәт гомер-гомердән.

Кайнананың йөзе айдай балкый.
Үз алдына йөри сөйләнеп:
«Өйнең көе килен белән икән,
Яхшы иткән улым өйләнеп.

Киленебез чынлап яратылган
Үзем изеп баскан туфрактан.
Гел дә инде менә минем кебек
Баш балага малай апкайткан».

Малай тапкан килен кемнән ким ул—
Ишәйтүче нәсел-ыруны?!
Ул яшь бикәч иде кичә генә,
Бүген зурлый нәсел ананы.
(Киләчәктә насыйп итсен аңа
Сөеп багу онык-турунны...)

Күкрәгенә куеп сөт имезә,
Егәр бирә улы—Антейга:
Җир терәтер егет үсә икән,
Күкрәк сөте хәләл андыйга!

## Дусларга

Иң якын дуслар дигәннәр
Иң җылы сүзләр кирәктә
Калдырды хәтерләрем...
Арагыздан китеп барам—
Яшь килеш хәтерләгез.

Мин генә якын иткәнмен,
Без һаман бергә, дигәнмен.
Күптән ерак икәнбез.
Яшьлеккә бергә кергәннәр
Берәм-берәм китәбез.

Торгызырга егылганны,
Юатырга елаганны
Вакыт та юк, ара да.
Яшьлектәге уртак хыял
Онытылган арбада.

Таралганны җыештырып,
Югалганны табыштырып
Илтер урын бар ла ул,
Калган хәтер, китек күңел—
Бар да шунда бара ул.

## Яшәү кирәк

Кем аңлаган бу дөньяда яшәү серен!
Кичә генә мең кояшлы зәңгәр күгең
Каплап ала иртәгесен кайгы-сөрем.
Шул чагында кемнәрең бар,
Кемгә сыя эчеңдәге соңгы серең?

Таштан түгел, һаман йөри безнең баштан,
«Без күрәсен...» дигәннәр дә хәттин ашкан.
«Өр-яңадан салыйк мәллә юл башларын,»
Дигән чакта яныңдамы
Йөкләреңне күтәрешер юлдашларың?

Кайгы гына үлчәми бит кеше гомерен,
Мәккәләрдә үстермиләр бәхет гөлен.
Күләгәдәй качып йөргән куркак кунак—
Шатлык туташ, күзгә күрен,—
Киңрәк итеп ачыйк сиңа ишек бүген.

Быел тагын шау чәчәктә хыял-сирень,
Сөйгәннәрне сөендереп яшәү кирәк.
Яшәү кирәк сөймәгәнне үкендереп.
Мәңгелеккә килгән кебек
Яшәү кирәк гомеркәйнең бердәнберен.



## Әхмәт Гадел

# ӨРӘК ҺӘМ АУЧЫ

*хикәя*

Ул бүренең эзенә тиз төште. Җанвар ерак булмаска тиеш иде сыман. Әнә теге таучыкны үтеп, аргы елгага житкәч тә, бер ауган агач бар. Шунда булырга тиеш, хәсис!

Бүре исә аның эзеннән бара иде. Аучы кырны кичеп, урманлы тау ешлыгына кереп китү белән, ул кырны бер селтәүдә кичәчәк. Ә аннан соң теге елгадагы ауган агачлар өермәсенә житкәч, аучының сыртына ташланып, бугазына ябышачак.

Былтыр булган хәлнең үчен ул шулай алачак. Аның күз алдында әүмәкләшеп-тәгәрәшеп уйнап яткан ике кеше—ир уртасы һәм яшь кыз... пәйда булгандай тоелды. Җан сыкравына түзә алмыйча, бүре улап җибәрә язды, көчкә тыелып калды, ярамый, иртә! Сабырлык кыл, үз-үзенне явыз аучы кулына вакытсыз тапшырма! Син үч алырга тиеш!

... Аучы шактый юл үткән иде инде. Бүре эзе буйлап хыялланып барды ул. Эзләр шулкадәрле оста буталган, хәтта аларны аңлау да, аларның серенә төшенү дә, эзләренең тылсымлы эчтәлеген чишү дә мөмкин булмас иде, әгәр ул тәҗрибәле аучы булмаса. Урман авызында ул агач төбен күреп алды. Төпкә утырып ял итү яхшы, утырмасаң, тагын да яхшырак, төп сихерле, ди иде аның атасы, мәрхүм. Ул да оста аучы иде. Аның гәүдәсен яз гына таптылар. Ауда үлде, бахыр!... Бүреләрме, төлкеләрме—кем икәнлеген кем белсен инде аның,—мәетне кимереп ашап бетерә язганнар иде. Кулларын, эчке әгъзаларын—йөрәк-бавырларын кимереп юк иткәннәр, тик башы гына читтә тәгәрәп ята, аңа тимәгәннәр. Атасының абыйсы белән, эзли торгач табып, Аучы аны урманнан үзе алып кайтты. Сәер һәм үкенечле үлем иде бу. Тирән елгадан күтәрелеп,

---

Әхмәт ГАДЕЛ *(1942)—шагыйрь, кинодраматург, прозаик; «Чам», «Яшьлек урамы», «Дәрт», «Йолдызлы чат», «Рух бәйрәме» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

төп өстенә ял итәргә утырган, күрәсең, һәм шунда төптән, бахыр, янтаеп төшкән дә, жанын тәслим иткән.

Аның алдыннан бер атна элек мондый хәл булды. Яшь Аучы ике көпшәле уналтылы мылтыгын тотып ауга чыккан иде. Бик озак йөрде ул ни дә булса эләктерәм дип, инде көн авышкач кына, Мәшләк кырыннан түбән Дәүли елгасы дигән бер тирән ермакка житәрәк, кинәт куян күреп алды. Бу урында төлкеләр күп, кырдагы эскертләргә «тычкан мәжлесе»нә киләләр алар. Тычкан белән сыйланырга. Тулы акылга ия булган сәламәт куян монда якын килергә тиеш түгел иде кебек.

«Бу ниткән куян тагын?!»—дигән яшендәй уй йөрәген кисеп үткәндәй булды аның. Әмма мылтык күтәрелгән, куян мөшкәгә алынган, тәтегә басылган да иде инде. Куян гөрселдәп ауды да, кинәт күтәрелеп алга ташланды, ләкин туктап калды да аучыга тулы күзләре белән текәлеп карады да, кешедәй ыңгырашып, нидер ялваргандай сыкрап, алгы аякларын нәкъ кеше сыман күкрәгенә хачлап куеп озак үкседе, ыңгырашты да, карга ауды. Аның ыңгырашуы үзәкне өзгеч иде. Сабый, хатын-кыз, яралы ир ыңгырашуы—бөтенесе бергә ачы зар булып кушылган иде. Аучы куянның чиксез зур күзләре тагын да зурая төшүенә шаһит булды. Мондый хәлне күргән аучы, үзе дә бичара, күзләрен терсәге белән каплады.—Аһ, ни эшләдем, ни кылдым, кемнең гомерен кистем,—дип ыңгырашканын үзе дә тоймастан, бәгырь түреннән чыгарып, чит кеше ыңгырашуын ишеткәндәй булды ул. Куянга якын да килмичә, кагылмыйча, жәһәт борылды да, арган-талганлыгына карамыйча, кире авылына ашыкты Аучы. Башында аның куркыныч уй—гомердә дә кешегә сөйләмәслек төшенү иде. Әлхәмделуллаһ Раббил Галәмин Әлхәмделүллахиләззии... Юл буенча дога укып кайтты ул, кычкырып та укыды, эченнән дә...

Бу хакта ул өч көн, өч төн уйланып йөрде. Бер кем белән дә уртаклашмады. Тик атна ахырында гына атасының ахири дусты, үзенең дә өлкән кинәшчесе, умартачы Мансурга барысын да сөйләп бирде. Кышкы буран улавын тынлый-тынлый төне буе сөйләшеп утырдылар алар умартачы өендә. Тышта салкын, кар, жил котыра, өйдә жылы... Өстәвенә, әле алар мич башында торган әлүмин бидоннан әче бал да состылар.

—Хәрәм эш кылынган,—диде Мансур.—Ичмасам алып та кайтмагансың...—Куян булмаган ул—кеше жаны... якын кешенең жаны...—диде Мансур, тагын да уйчанлана төшеп.—Атаң өйдәме соң әле, авырмыймы?

—Әтине беләсең ич инде, кыш життеме, атналар буе бүре аулый, өйгә дә кайтмый, кая куна, ни ашыйдыр... Ярата ул ауда йөрүне...

—Әйе, исемә төште, ауга чыккач, минем дә яныма кергән иде бит, Тәкәнеш якларына барам, анда әле урманнар калын, бигрәк тә Лубян тирәсендә, диде...

—Аннан ул Нократ тарафына чыгып китә, Сосновка урманнары аша...—Алла сакласын инде үзен, сугышлардан исән-имин котылып кайткан кешенең ар урманында үлеп калганын теләмәс идем...—диде.

—Пилмәне күп иде. Шуны пешереп тәгам итәдер инде...

—Әйе, ауга чыкса, ул йә пилмәнен ашап яши, йә кош-корт ата... Дүрт-биш бүре тиресе алып кайтырлык булмаса, ул бер-ике атна йөри инде...

—Аллаһ сакласын, Хозыр Ильяс юлдаш булсын!—диде нидәндер курка төшеп, Мансур.

Аннары умартачы янә көрсенеп куйды:

—Авыр хәл!.. Әле ул шушы тирәләрдә йөрсә кирәк, ерак китә алмагандыр, эзли чыгарга кирәк. Яшь түгел бит инде... Син, таң ату белән өенә кайт. Авыл егетләренә шом сал. Мине алып чыгарсың, эзләргә кирәк! Бүреләр ишәйделәр, араларында бик усалы да бар... Төсе-кыяфәте белән дә башкалардан бик нык аерылып тора, өрәк түгелме икән, шомлы уем да бар. Өрәк шулай йөри, үч ала кешедән... Жәзаланып

үтерелгән кешенең кан үчен алмасаң, шулай... Кешене ул жыртып кына ташлый... Атаңа зарар кыла күрмәсен.

Егетнең сәер куян атканы турында белгән әнисе үксеп-үксеп елый башлады. «Атаңа бер чегән хатыны әйткән, жан варисыннан саклан!— дигән... Ул атаңның рухы гына булмаса ярар иде. Бәлки ул сиңа ышыкланырга дип килгән булгандыр.»

—Әллә нинди тузга язмаган сүзләр сөйлисең син, әни!

—Тузга язмаган түгел, ата-бабалардан күңел дәфтәренә алынган йола шартлары ул... Аллам, үзең сакла! Аллам, үзең сакла!...

—Әни, куян ул куян инде, ә әти—әти! Куянга атып атага кемнең тидергәне булган икән?! Борчылма!

—Юк, балам! Хәтерлисеңме, Әбдедәге Домолазовны?! Бар иде анда шундыйлар, үзләре Ташлы ярныкылар... Сугыштан бер кул белән кайткан иде, герой!..

—Әни, теге энесе атып үтергәне булса, анысының ике кулы да юк иде бит аның. Мылтыгын терсәк кәүсәсенә куеп тәтедән килгән бауны теше белән тартып ата иде. Снайпер булган сугышта. Ай, төз ата да белә иде, мәрхүм! Шулар энесе белән Әбде урманына бүре ауларга баралар. Ул елларны, сугыштан соң, бүре бик күп иде. Урман аланының икесе ике почмагына басалар. Этләре бүреләрне аланга куып чыгара башлый, аларның бер көтү ау этләре бар иде. Менә этләр һау-һаулап урманны яңгыраталар. Тегеләр бүрене атарга әзер торалар. Жан тартылган. Киеренкелек. Көтәләр. Шул вакытта аланга ниндидер куян атылып чыга. Ауда мондый хәл булуы бик мөмкин. Энесенең эчтән ниндидер бер кычыту күтәрелә, сабырлыгы югала, куянга атып жибәрергә тели һәм... атып та жибәрә, ә аланга теге сугыштан исән кайткан ике кулсыз абые чыккан була... Бер атуда газиз абыйсын һәм куянны... Кайгы-хәсрәткә баткан егет, абыйсының үле гәүдәсен чаңгыларына салып, тартып авылына алып кайта. Куян турында оныта. Әмма куянны һәм бу хәлне исенә төшергәндә, абыйсы янында берниндидә дә куян булганын хәтерләми ул. Соңрак барып тикшергәндә дә, үлгән куян эзләре калмый аланда.

Аллаһтан ингән тәкъдир дигән нәрсә бар дөньяда. «Баш очында һәрвакыт Гали хәзрәт кылычы эленеп торыр!»—диләр...

* * *

Аучы әкрен генә күзләрен кырдан йөртеп чыкты. Кар өстендә искиткеч зур куян шәүләсе ялт иткәндәй булды. «Бүре!»—диде Аучы. «Урман эченә кереп тормыйча, кире кайтып китәргә, өйгә кайтырга!»—дигән шомлы да, моңлы да уй үтте аның йөрәген кискәндәй итеп. Ул үзенең чарасыз кала баруын сизенде. Ләкин эченә шайтан кереп утырган иде инде. «Курыкма! Чытырман эчендә бүре өне! Хәзер эш язга таба бара, былтыргы көчекләре зурайган булса кирәк, быелгылары да инде булырга тиеш. Йөр, сине алда уңыш көтә!»—дигән сыман иде ул аңа.

Бу эчке аваз аны һаман котыртты, һаман алга әтәрде.

Көн сүрәнлеге энгер белән кочаклашкан иде инде.

Өрәк кудымы икән аны, эчке шом әйдәдеме икән? Кем белә бит... Адәм баласыннан Аллаһы Тәгаләнең бик күп серләре яшерен булып кала.

Әмма ул калын урман эченә чаңгысын тагын да тизләтә төшеп, шуды да шуды...

Бүре алга ыргылды. Бу—йөзенче кан үче! Моның канын эчмичә, жир шарын калдыру—ахмаклык! Үзе төшәчәк ул тәмуг утына! Тегеләрнең рухы утта янырга тиеш бит! Ул бит заманында гөнаһсыз күңел парәсе иде, кемнеңдер өмете, кемнеңдер мәхәббәт йолдызы...

—Бирешергә әле иртәрәк!..—диде ул, дымлы ботын тотып. Адәми

зат-гүзәл кыз чагында да шулай булды. Алдан менә шундый дымлылык кан... Аннан ары аның ярым үле гәүдәсен аучы көчләде. Көчләде дә, салкын кырда, салкын сукмактан бераз читтәрәк урман буенда ташлап та калдырды. Кыз әле исән иде. Аны үлемнән сакларга була иде әле, ул кышкы зәмһәрирдә катып үлде. Әкрен генә, ашыкмыйча гына боз керде дә сылуның тәненә, рухны кысрыклап чыгарды. Рух калыпсыз калды. Әмма вакытыннан алда ул Аллаһка да кирәк түгел иде.

—Мин Рух! Ә Рух исә ул үлемне белми. Рух ятим-тәнсез—калыпсыз калса да, Кеше затын да, җен-пәри затын да җинә. Ул үзе кеше дә, җен дә була ала. Рухны Илаһи көч кенә җинә, җыештырып алала. Әмма моның өчен кемдер көчле догалар укып, Аллаһка ялынырга тиеш. Илаһи көч җинә аны, әмма гомерен кисә алмый—төрле гөнаһлардан тазарта гына ала. Ләкин үлемгә дучар итми.

—Мин Аллаһ алмаган Рух. Өрәк диләр миңа кешеләр. Ятим тәненнән мәхрүм калган рух исә фәрештәләр тарафыннан хөрмәтләнеп күккә—Аллаһы Тәгалә хозурына алып кителми. Ул адаша. Тәнен-калыбын эзли.

Бүре—шул гаҗәеп сылу кыз иде. Авыр сугыш елларында бу гүзәл җан иясен Анасы саклап, дошманнар басып алган илдән бире алып килде, назлап үстерде. Авызыннан өзеп хәләл ризыгын аңа бирде. Аны ач үлемнән саклады. Газиз аталары ил сагында иде.

Кырык ике, кырык өч, кырык дүртенче еллар... Һәр хатында Ата нәни кызы—йөрәк парәсен сагынып, аңа сәламнәр юллый иде. Хатында ана дигән җылы сүзләр тулып ятыр иде. Алар телеграф чыбыгына тезелгән карлыгачлар сыман матур иделәр. Кызын да Ата «минем кара карлыгачым», дип атый иде. Ата шулай кызы аша, аның әнкәсенә булган сөю хисләрен житкерә иде.

Ана исә ул хатларны кычкырып-кычкырып кызына укыр, сөенә-сөенә, кабат-кабат сәламнәрен кабатлар иде. Инша Алла, Ата да сугыштан җинеп кайтты. Кыз да үсеп житте. Илленче елларның азагында кыз күрше авыл мәктәбендә балалар укыта башлады. Атна буе шул авылда торган кыз, ялга әнкә-әткәсе янына кайта, кунак була, булыша... Ләкин, кыш көннәренең берсендә, кыз кайтмады—югалды. Каян гына эзләмәде аны ике авыл халкы. Таба алмадылар. Яз көннәре житкәч, аның мәетен нәкъ шушы урында, урман эшчеләре тапты. Вакытсыз, һәм Аллаһтан ризалык алмыйча үтерелгән кызның рухы исә, нәкъ шушы урынга елына бер тапкыр тәнен-калыбын эзләп килә, аны таба алмыйча, үзенең тормышын кискән адәм баласыннан үч ала. Аны үзен мәсхәрәләгән сыман тилмертеп җәзалый, канын суырып эчеп, интектереп үтерә. Ә аның башына житүче Карт аучы иде... Шуңа да ул аучыларны җәзалый, аларны сагалап, хөкемгә тарта. Үзе көчләп үтергән җан ияләренең кыяфәтенә дә керә ала иде Кыз.

Әйе, менә хәзер ул бүре калыбын сала да, үзенең җирдәге гомерен кискән аучы кыяфәтен ала. Ә инде тагы йә бүре, йә бөркет кыяфәтенә кереп, корбанына ташлана. Шаша-шаша әвәли ул аны, аннан ары күкрәген җыртып канын эчә, кана-кана—туйганчы!

...Урман эчендә аучы утырган урыннан бик үк ерак булмаган бер таманда тимер юл үтә. Сугыштан соң бередә бик зур тимер юл казасы булды. Каза-катастрофада меңләгән кеше һәлак булды. Һәм тимер юлның ул борылышлы текә жиреннән рельсны кем алганы һич табылмый калды. Меңләгән рух үзенә тынычлык таба алмый дөнья буйлап тән калыбын эзләп иза чигәргә калды. Ә бәланең башында шул ук карт аучы иде. Ул нинди юлга басканын абайламыйча, рельстан гайкаларны борып алган иде. Бүре ядрәсе ясаганда ул аларны форма итеп файдалана иде. Тик менә һәлакәт турында уйламады ул.

Күз алдына да китерүе кыен: пассажир составы шушы кискен текә ярдан түбән очкан...

Елга төбеннән, яр буеннан малайлар әле дә төрле-төрле кыйммәтле әйберләр таба, ләкин әти-әнкәләре аларны өйгә якын китерергә рөхсәт

итмиләр, аларга жиһан тамгасы төшкән имеш. Ә инде тынламыйча өйләренә ул әйберләрне керткән кешеләрнең башы бәла-казадан чыкмый икән. Кайчандыр яшь сылу кызга да таныш егете, шуннан алып кайткан алтын йөзек бүләк иткән иде. Әмма ул ана бу турыда әйтмәде. Бәхетсезлегенә, кыз бер ни дә уйламыйча, ул йөзекне алып киде.

Яшь сылу укытучының үләр алдыннан нинди жәзалар күрүен шәйләү һәм күз алдына китерү авыр булмастыр. Яз көне табылган мәетнең кулларына да хәтта имән чөй кагылган иде. Вәхшиләрчә, көчләнеп үтерелгән иде ул.

Үтерүче-көчләүчене күпме эзләсәләр дә, таба алмадылар. Әмма нәкъ шул урында, кызның еллыгы дигән көннәрдә, аучы юкка чыкты.

Аучыны бик озак эзләделәр, әмма таба алмадылар. Тик бер ел үткәч кенә, аучының улы белән энесе аның ерткычлар тарафыннан өзгәләнеп беткән кулсыз-аяксыз жәсәден таптылар. Нинди дер бер усал ерткыч аның башын тәненнән өзеп, читкә алып киткән иде. Ләкин тимәгән—кимермәгән. Кешеләр бу жинаятьнең дә башка жинаятькә якын торганын бик яхшы чамалый иделәр. Жәзалау ысулы бер төсле иде...

...Өрәк дәһшәтле болытка әверелде. Андагы ачу, нәфрәт энергиясе бик тә көчле иде. Ул болытны кыса төшеп, куәтен тагын да ныграк туплады, аннан ары аучыга таба ыргылды. Әмма кинәт туктап калды. Ана йөзек бүләк иткән һәм үзе дә сизмәстән, бәла китергән егет иде бу кеше.

Аучы исә алдында зур ак кибән күрде. Ак кибән башта хәрәкәтсез торды, аннан ары аның очлы башында ике күз пәйда булды, ул эскерт кебек тагын да  үсте, аның куллары да күренә башлагандай итте. Көтмәгәндә мондый сәер зат пәйда булгач, аучы куркып калды. Өрәкләр турында аның инде ишеткәне бар иде.

Аучы алдан бисмилласын әйтте, аннан ары «Колһуалла»ны укыды. Аучының теше-тешкә тими, ул бик хәтәр курыккан иде. Ул нигәдер әтисен исенә төшерде. Әтисенең дә мәетен нәкъ шушы урыннан тапканнар иде бит. Аучы утырган төп янына ауган иде ул, янтаеп төшкән иде. Кара, монарчы агач агачка авып, чытырманлык ясалып беткән куркыныч Дәүли елгасына төшкәнемне ничек абайламаганмын мин, дип уйлады ул. Кышкы салкын үзен тагын да сиздерә төште. Кызарып ай күтәрелгән сыман тоелды. Әмма нинди дер кара болыт аны бик тиз каплады—йотты. Нәкъ шушы вакытта, әбисе сөйләвенчә, жен-пәриләр котырына да инде...

Заманында коммунистик гаилә кысаларында тәрбияләнгән бу егет дөньяда икенче, өченче һәм тагы да әллә ничәнче үлчәмнәр булуы турында мәгълүматсыз иде. Әмма әби тәрбиясенең бер чеметеме аны барыбер андый серле бер дөнья булуы хакында уйландыра иде. Ул хорафат дигәннәргә бик нык ышана, алардан курка да иде. Аннары, егет заманында хәрби хезмәттә Алманиядә булды. Немец халкының төрле хорафатларга ышанып, төрле чикләүләр куя белүеннән ул хәбәрдар. Аурупаның тап үзәгенә утырган алманнар төнлә су янына килергә, урман-тауларга чыгарга курка, тыела. Ә үзенең якташлары, бигрәк тә урыслар, космоска чыгуларын күреп куана, үзен дә шул куркусызлар сафына куймакчы була. Белми иде егет заманында бу эшләрнең иблис кыланмышлары икәнлеген. Ул вакытта солдат егет кешенең ни өчен гази булырга, үзенә тиеш булмаган өлкәгә бәреп керергә теләгәнен белми иде әле. Үзе ясаган ракетага утырып һәр кешенең жирдән жинел генә аерылып китә алмаячагын да ул күз алдына да китерми иде әле. Илаһ исә кешенең бу көчәнешенә көлеп кенә карады.

—Әйдә, шайтан суына бирелгәнче, уйла, көчән, тырыш—шөгыль булсын, адәми зат!—ди иде сыман Гали зат. Шушы вакытта жир жисеменнән ерак булган башка үлчәм жан ияләре иректә төшеп, менеп йөриләр иде. Алар өчен бу кешенең урамга чыгуы, өйгә керүе кебек кенә иде.

Аучы кибәннең кинәт миллионлаган очкын булып чәчелгәнен күрде. Юк, алар күккә атылган ракета яисә фейерверк кебек түгел иде. Ул жир

өстеннән гайре табигый чәчелде. Дәһшәтле дә, куркыныч та иде табигатьнең бу кыланышы. Аучының битенә кайнар сулыш дулкыны бәргәндәй булды. Ул мылтык көпшәсенә, бисмилласын әйтеп, ике патронын тыгып куйган иде. Дошманын каршыларга әзер, рухы нык, иманы камил иде аның. Дәһшәтле кар буранын күтәреп, туздырып, шаулап алган Рух бераздан инде үзенең бүрелегеән дә, шәүләлегеән дә, очкынлыгын да, «кибәнлеген» дә онытып, йокы таратучы томан булып, Аучы тарафына агыла башлаган иде. Кызыл офык кинәт юкка чыкты. Табигать ойый башлап шашты, урманда яман көчләрнең җилле фөрьяды купты. Ләкин нindидер Зур, Гали Аң Аучыга утырган урыныннан күтәрелеп китәргә куша иде. «Бер ун-егерме аршын булса да, читкәрәк кит, сулга кит!—ди аңа Аң. Бар көчен җыеп, Аучы читкәрәк, карт имән артына барып посты. Менә шунда Аучы үзенең нинди хәлдә каласын күрде дә инде. Ул утырган урын кинәт купкан дәһшәтнең гайрәт үзәгендә иде! Шул урынга ут эчендә янган башлар оча башлады. Куркыныч та, тетрәнгеч иде бу күренеш. Башлар очып төп янына төшәләр дә, мескенләнеп, керфекләрен кага-кага эреп бетәләр, алардан исә, яңа көч—кылыч булып, елан калкып чыга, күтәрелә һәм төпне чага. «Менә миңа нәрсә буласы булган икән»!—диде үз-үзенә Аучы һәм Илаһи Гали көчкә рәхмәт укып, дога кыла башлады.

Бу манзарага карап ни эшләргә белмәгән Аучы, кинәт аңына килеп тагын да читкә, кайтыр юлына китәргә булды. Әмма чаңгылары бозга каткан сыман иде. Ә нindидер Югары Гали Аң аңа урыныннан кымшанмаска кушты. Менә шунда инде ул үз атасының акайган күзле башын күрде. Ул баш та очып, әйләнеп-тулганып йөргәннән соң, төпкә бәрелеп, очкыннар чәчеп таралды—юкка чыкты. Шул вакытта күктә гүзәл кыз пәйда булды. «Бәй, бу бит таныш сылу!»—диде шаккаткан аучы егет. Кызның кулын күреп алды ул кинәт. Аның сул кул бармагында ул бүләк иткән йөзек иде. Йөзек тә, кыз да нур сибәләр. Кинәт йөзектән егетнең атасы чыкты. Атасының кызга атылып ни кылганына шаһит булды егет, барысы да аңлашылды аңа. Менә нәрсә булган икән аның сөеклесе белән! Кыз әкрен генә яңадан зурайды, атасы кечерәеп, йөзеккә кереп югалды. Кыз олы керфекләрен әкренләп күтәрде, аның карашы куркыныч иде. Ул үзе дә зурайганнан зурайды, күк буйлап озайды да, кинәйде. Һәм бервакыт куллары белән капшап егетне—аучыны эзли башлады. Аның күзләреннән, ирennәреннән, кулларыннан кан саркып-саркып тама. Кыз кинәт ук чәчкән күзләрен ачты, очлы хәнҗәрләрне хәтерләткән керфекләре ялтырый, утта кызаргандай булалар. Кыз аларны берәм-берәм күзләреннән суырып ала да аучыга ата.

—Салкын! Салкын! Салкын!—ди кыз.—Синең җылы кочагыңны телим, егет! Аучы кочагын телим!!! Коч мине! Сар мине! Җылыт мине! Йөз ел, мең ел коч мине—җылыт, Гали көчнең хөкеме шул! Һәм ул тирә-якны, урман-кырларны капшый, аны эзли, таба алмый иза чигә. Төн уртасы да житеп авыша башлады. Кыз елый, жирне капшый. Тик егет бисмилла һәм догалар укып утырган имән янын гына читләтеп уза. Елый. «Кил, вакыт кичә!»—ди. Ул—рух, аңа киләчәктә яшәү өчен кан, башка рух белән кушылу кирәк...

Кинәт дөнья яктыргандай булды. «Кая ул алан?!—диде сылу усалланып.—Кая ул кеше?! Алып килегез аны минем каршыма! Мин аның канын тояргa гажизмен!»

Бөтен дөнья тагын кар-буранга чолганды. Агачлар ава—буй сузыла, Дәүли елгасының төбенә ята. Кыз кинәт Бүрегә әверелеп, алан буйлап чапкалый, иснәнә, эзли, аның тирәли өрәкләр чабыша, аларның көмеш сыман сыннары аучыга якынлашканда гына куркып кире чигәләр. «Йә, ни булды, нәрсә бу?»- дип уйлады аучы егет. Ул барысын да яхшы аңлады. Үз өстендә атасы калдырган зур гөнаһы барлыгын да, үзе дә белмичә кылган ялгышын да аңлады. Кинәт ул тагын үз атасының авыр хәлдә икәнлеген күрде. Аны Бүре жырта, күккә чөя, уйный... Ул оланына

нидер әйтмәкче, коткаруын сорап ялвармакчы, ләкин иреннәре эреп аланга агып төшә дә, алар урынына яна иреннәр кызарып, үсеп чыгалар. Күзләрендә исә—иләмсез ут ташкыны...

—Гасырлар буе бөтен киләчәк буын нәселегез шушылай тилмерәчәк!—ди кинәт бүредән кыз булган зат.—Син, хатын кочагы күрмәгән гөнаһсыз сабый, сине телим! Атаң мине теләгәндәй, сине телим!!! Бирегез миңа аны табып!!!»—диде кыз, күк күкрәгәндәй тавышын бөтен җиһанга җәеп-җәйрәтеп. Һәм аның тирәсендәге башка рухлар-өрәкләр төрлесе-төрле почмакка ташланды, аучыны эзли башладылар: «Кая ул гөнаһсыз сабый! Вакыт уза. Китерегез аны бире!»

Ләкин имән янына килеп җитү белән алар туктап кала да, кире әйләнеп китә иделәр. Бисмиллаһир рахманир рәхим. Иза җаә насрулла вәх-фәтх...

Яшь аучы Аллаһтан өрәк-рухны үзенә алуын, аның хәлен жиңеләйтүен ялварды. Кызга Ясин чыкты. Шуның белән ул Рух-өрәкнең яманлыгын тойды.

Ошбу дога ярдәм итте дә инде егетне тискәре көчләрдән саклап калырга! Аучы үзе дә, боларның барысын да кино экранында гына түгел, үз тирәсендә, үз тормышында күргәннән соң, исән калса, изгелектән, игелекле эшләрдән башка эш кылмаска ант итте. Аллаһтан мәрхәмәтлелек, миһербанлылык иңдерүен ялварды. Кинәт бар дәһшәт тынып калгандай булды. Салкын күктә болытлар таралды, туфан, җил-давыл тынды. Таң мәле сизелде...

Егет туңган булуын да, карыны ачканны да сизми иде бугай. Ул бик озак сәерсенеп, таң калып, дөньяга карап торды. Селкенерлек хәле булганмы, юкмы дисәгез, дөресен әйтергә кирәк, ул үзендә ярты урманны аударып чыгарлык көч-кодрәт тоя иде. Гайрәтләнеп, егет чаңгыларын карга ышкып алды. Кар коры, шома иде. Ул тиз-тиз Дәүли елгасы дигән урыннан чыгып, кыр кочагына элгәп, Мәшләк басуы аша туган авылына элдерү ягын карады...

Эченнән гайрәтле һәм тынгысыз чит рух чыгып киткән ана бүре башын алгы аякларына куеп, өне алдында ята иде. Аның күзләреннән тамчы-тамчы яшь тама. Ул да бушанып калган. Ничәмә ел ул үз эчендә чит рух йөртте. Әлбәттә, ул рух аның җанына комачау итә иде. Тән ара, аяклар сызлый, баш чатный... Ул торып өне яныннан китте, читләште. Гадәтенчә, ул дәһшәтнең икенче көнендә, рух аны калдырып киткәннән соң, аланга бара, киселгән нарат төбенә килә, анда рух үтереп, рухын үзенә алган тән-калып-мәет ята торган була иде. Бүре шуннан тукланырга, көчекләренә өлеш чыгарырга ияләнгән иде. Әмма бу юлы ул көткән «күчтәнәч» аланда юк иде. Бүре тамагы ач икәнлеген тойды һәм башын күккә күтәреп, күзләрен күктәге ерак бер ноктага төбәп улый башлады. Аның Рухка ялварып мөрәҗәгать итүе иде. Ничек инде аны ашсыз калдырып, биеккә менеп киткән Рух?! Болай гадел түгел ич аның эшхәрәкәте, фигыль-гамәле...

Кешеләр нинди дә булса эшкә тотыныр алдыннан уйланып тотынсыннар иде... Беренче адымыңны ясаганда, һәрчак уйлап яса, аягыңны кая куясың, ышанып буламы баскан җиреңә, упкын ясә ут, ясә сусызлык түгелме алда... Яманлык кыласыңмы син, игелекме?!—боларның барысы турында да уйлап, барысын да үлчәп эш кылу мәслихәт адәм баласына. «Алдын-артың карап эш ит!»—ди халык борын-борыннан. Яманлык игелек булып кайтмый. Менә ул бүгенге төндә булган дәһшәтләрне күреп төшенде.

Рух исә биектән, йолдызлар яныннан бар дөньяны, җирне күзәтеп торды. Ул да елады. Аллаһка да, җан ияләренә дә ул кирәк түгел иде, чөнки Аллаһ вакытыннан алда килгән рухларны кабул итми, алар салкын фәләктә иза чигәргә мәҗбүр, һәммә җан иясе дә үз рухы белән туа, башка калыпларга ятим рух вакытлыча гына, кадер кичәсе, ясә үзедәй җан иясе тарафыннан, тән-калыбына һөҗүм ясалып, аннан куылып

чыгарылганнан соң гына кайта ала. Аллаһ аларны җәзаларга мәҗбүр. Аллаһ хөкеменә күчә алмаган рух яшәвен шулай дәвам иттерә...

Аучы ару-талуны белмичә алга барды. Ул янадан, өр-яңадан туган сыман иде! Кар чаңгылар астында бераз шыгырдап та куя, әмма баруы җинел, күнел рәхәтлек сизә. Төнлә кичергәннәргә ышанырлык та, аларны сөйләрлек тә түгел. Ул күргән-кичергәннәр аның күңелендә бер риваять—әкият булып кына калыр күрәсең, тора-бара, бәлки, онытылыр да...

Юк-юк, онытыла торган күренеш тә, бирелгән сабак та түгел бу!

Ул туктап кала. Алга карый. Тәңрегә ялварып, тагын догасын укый. Җиңеллек тоя, сулышы киңәя сыман аның. Тагын авылына таба, өенә таба чаба ул чаңгыларын җиңел шыгырдатып. Аннан ары тагын туктап кала да, Аллаһтан әби-бабалары, атасының рухын кичерүне ялварып, тагын дога кыла.

Ләкин... Кызарып Кояш чыга, бераздан ул биеккә күтәрелә, елмаеп җиргә карый.

«Әй, Кояш җәнаплары, рәхәт сина, син бер кайгы-хәсрәт белмичә яшисең, сина кеше хәле нәрсә?»—дип уйлый аучы. Ә үзе һаман алга атлый.

Киң кырда, киң дөньяда, әйтерсең лә, ул гел берүзе, япа-ялгызы калган. Дөньяда сихри тынлык һәм яктылык хакимлек итә. Шулар уртасында үткән буын кылган гөнаһлардан арынган кеше—адәм улы берүзе тора...

Бар җиһан үзәгендә Кояш та, ул... Бөек Тәңре тарафыннан алар икесе дә саклана һәм аларны рәнҗетер бернинди дә көч юк!

Биектән-биектән аны күргән рух-өрәк күз яшьләрен агыза, шатлыклы яшьләрен түгә. Димәк, егетнең ялварып укыган догалары Аллаһка барып җиткән. Алар чиксез күктә йолдызлар булып балкыйлар, җем-җем итәләр. Өметләрен югалткан юлчыларга өмет бирәләр, явызларны һәм аларның нәселеннән булганнарны җәзалыйлар...

Менә авыл да күренә. Кеше, бүреген салып, битен сөртә.

Йә, Аллам, кичә генә кап-кара булган чәчле башы аның бүген кышкы көрт сыман ап-ак. Ә урам тулы—кеше. Алар ни эшли икән урамда?!

«Әллә мине эзли чыктылармы? Таба алмый кайттылармы? Кайгырышалармы?—дип уйлады ул, һәм аларга табан ашыга-ашыга шуып, китеп тә барды.

*1975—2001*

*Казан—Биектау—Иске Казан.*

## «Татарның тулы йортыннан...»



*Сафуан Мулла Гали—Оренбур ягы татары. Андагы Абдуллин районы Чаганлы авылыннан ул: шунда туып үскән, егет булган... Аннан язмыш юллары аны еракка—Үзбәкстан якларына алып китә... Яшьтән иҗат белән җенләнгән егет анда да шагыйрь булып танылыр иде, бәлки: «үзбәкчә яз, журналларда бастырабыз...»—диләр аңа, әмма ул татар улы татар булып кала, горур бер үҗәтлек белән, язганнарын Казанга, Сибгат Хәким, Илдар Юзеевларга җибәрә, киңәш хатларын укый... аннары инде төп илгә, «татарның тулы йорты»на, мәркәзебез Казанга күченеп кайта. Иллене тутыргач, горбәтлекнең прозасын нык татыгач кына шигърияткә килә ул: туган тел, туган халык, моң төшенчәсе «телен ача» аның! Казанда Сафуан аганың бер-бер артлы китаплары басылып чыкты («Сәлам бирәм», «Күзге балкыш», «Мәңгелек йөрәк» кебек лирика китаплары, «Биздерсәләр туган җиреңнән» исемле шигъри повесть һ. б.). Иҗатына хәерхаһлык белән Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Мөдәррис Әгъләм, Зиннур Мансур, Мансур Вәлиевләр җылы сүзләрен әйттеләр, ярдәм кулын суздылар—шагыйрь бу турыда аларга багышлау шигырьләрендә дә рәхмәтле хисләрен әйтә килә. Садә җан ул!*

*Язучылар берлегенә дә кабул ителде ул, берничә матур җыр авторы буларак та танылды («Кояшым бул, ярым» һ. б.). Кыскасы, үз максатына, иҗат бәхетенә иреште Сафуан ага: «Ыктан агып кергән бер тал мин» дип язган шагыйрь инде уңдырышлы Идел ярларыннан урын алып, милли нигезенә кучереп утыртылды; хәзер бу тал—олы гомер агачына әверелгән. 75 яшьлек өянке ул, бәлки?!*

*Ләкин безнең өчен кадерлесе—шагыйрьнең изге «сөттән»—татарлыгыннан аерылмыйча, кайда яшәсә дә милли рухын саклап кала алуында. Читләргә сибелгән төрле язмышка юлыккан милләттәшләребез өчен үрнәк тә, гыйбрәт тә бу гомер. Әйе, без—татар, бөек халык баласы, зур, катлаулы, тарихи язмыш варисы, аннан соң гына—шагыйрь. Ә бу—бик табигый ич!*

Рәдиф ГАТАШ

# Сафуан Мулла Гали

### Үлемсез булыйк

**Куй башыңны күкрәгемә,
Тыңла йөрәкне.
Соңгы айларда бу йөрәк
Бирде кирәкне.**

Тимер чүкегән шикелле,
Гел чүки җанны,
Чүкелгән җан ут эчендә
Төннәрен янды.

Нәкъ ут янган төндә инде
Назланып кына
Син киләсең—гүя былбыл
Йөрәккә куна.

Кил әле, утыр яныма,
Тын калып уйлыйк:
Мәхәббәт—үлемсез бәхет...—
Үлемсез булыйк...

~

Җырлый-җырлый үтеп бара
Кыз бала.
Күңелләрдә яткан бозлар
Кузгала.

Ыкны иңләп бозлар ага—
Эри боз.
Үзәкләрне өзеп-өзеп
Җырлый кыз:
«Эзләмәгез, сандугачлар,
Монда м-и-и-н...
Моң да моң Ыкның буйлары,
Моңда м-и-и-н...»

~

Бәгыремдә сызлый җир ярасы,
Кайгысын да аның үз итәм.
...Яфракларың белән яп өстемне,
Ташлап китмә, талым, өзелсәм...

Җир-әнкәмнең кайнар йөрәгеннән
Мәкерләрнең кара кендеген
Тамырлары, таш-таулары белән
Өзеп ала торган көн бүген.

Сызла, җир ярасы, бәгыремдә,
Ил ярасы, сызла йөрәктә.
Сызлагыз сез, газиз яраларым,
Җирем өчен бүген кирәксә.

~

Йөрәгемә минем җырлар тама,
Җан тетрәткән моңнар ишетәм.
Кичерегез, дөнья кешеләре,
Җыр илткәндә сезгә кичексәм...

Кичерегез, вакыт төшенчәсе
Мин санаган кебек чыкмаса.

Кичерегез, илтеп җиткерәсе
Җырым барда
Йөрәк туктаса...

## Өмет бетсә

Өмет белән килдем дөньяга,
Өмет белән бастым юлларга.
Өмет белән акты уйларым,
Өмет кушты миңа җырларга.
Өмет тартып алды үлемнән,
Өмет мине күккә күтәрде...—
Өметемне җуйсам, бүгеннән
Шыр ялангач дөнья калачак,
Моңсызларның берсе—утын, дип,
Учагына мине салачак.
Салачак...

## Синең өчен

Хөкемдарың булмадым мин,
Булдым тугры хезмәтчең.
Халкыма хезмәт итүне,
Хурлык диеп кем әйтсен?

...Сиңа йөгерәм мин, халкым,
Синеке мин, синеке.

Иң изге син, иң бөек син—
Әнием күк сөекле...

Чәчәкләр күтәреп әйтәм,
Бу—иң соңгы нәзерем:
Гарасатка күкрәк куеп,
Таш булырга әзер мин.

~

Үткәнеңә борылып карыйсың да
Моңлы-зарлы гомер арасын—
Тукай белән үткән гомереңә
Мең шөкерләр итә аласың.

~

Җир үзәге—ил үзәге,—
Алмаз кендек—сынмый торган.
Шул алмаз кендеккә басып,
Тарихыма йөзне борам.

Биләр, Болгар... шәмдәленнән
Күзгә төшә зәңгәр яктьы.
Бик еракта булса да ут,
Җылысы бар, җанга якын.

Якын, якты—ялкынлана,
Төшкә керә—кинәндерә...
Бәһасез алтын бөртек күк
Хәтерләргә иңә менә.

Тамырлана, бөреләнә,
Яфрак яра...
Шулай һәр көн
Халкымның бөек тарихы,
Киләчәккә нурын бөркеп,
Балкыр һәр көн!



## Айдар Хәлим

# «ЯҢА САГЫШ КИТАБЫ»

*Күпме алтын калды саф алтында?*
*Күпме атом бар соң атомда?*
*Күпме дус бар дуслар арасында?*
*Күпме халкың калды халкыңда?*

### Кереш сүз урынына

КАЙЧАНДЫР гасыр башында бөек Тукай үзенең «Китмибез!» дигән атаклы шигырендә «Кара көчләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр» дип язган иде. Беренче карашка бик тә гади бу сүзләрнең мәгънәсен татар-башкорт мөнәсәбәтләренә күчергән хәлдә, аларның канатлы әйтемгә әйләнәчәкләрен ул күз алдына да китермәгән булгандыр. «Тәклиф итү»—гарәпчәдән «мәҗбүр итү, көчләү» дигән сүз.

Әйе, бөтенрәсәй, хәтта ки бөтендөнья масштабында кабатланмас күренешкә әйләнгән башкорт шовинизмы тугандаш татар милләтенә, димәк, аның аша барлык төрки милләтләргә тарихта күрелмәгән тәклифлек, көчләү алып килде.

Бүгенге татар-башкорт мөнәсәбәтләре турында язу—ул йөрәгеңне кулыңа йомарлап, күзләреңне йомып сыктау, йөрәкләргә төшеп чеңләү. Татар-башкорт туганлыгын югалту—туган Илне, хәтта туган милләтне югалтуга тиң югалту ул.

Шулай итеп, без бүген, башкорт хакимияте тудырган чынбарлыктан чыгып, элек үзебезнең кальбебездә тышаулап, арканлап килгән үй-фикерләребезне иреккә җибәрергә, әйтми килгән шик-шөбһәләребезне чәчрәтеп әйтергә мәҗбүр ителдек. Мондый әйтми калып килүнең безне нинди тупикка куып кертүен татар милләтенә татар зыялылары аңлатырга тиеш. Моны, беренче чиратта, әле һаман да татар-башкорт мөнәсәбәтләренең алсу хыяллар томанында йөзгән, бу мәсьәләләрдә әле һаман да

Айдар ХӘЛИМ *(1942)—шагыйрь, прозаик, публицист; татар, башкорт, рус телләрендә күпсанлы китаплар («Беренчеләр», «Гомеремнең ун көне», «Биктырыш», «Минем түгәрәк Иманем» һ.б.) авторы. Чаллыда яши.*

иҗтимагый йокыдан уянмаган татар җәмәгатьчелеге һәм ялган пропаганда белән алданган гади башкорт мәнфәгатьләрендә эшләргә бурычлы без.

Минемчә, татар җәмәгатьчелеген генә түгел, бу төбәктәге барлык милләтләр җәмәгатьчелеген моңардан да ныграк кызыксындырган мәсьәлә булмаска тиеш кебек. Безнең милләтебезнең киләчәктә булу-булмавы нәкъ менә бүген без кабул итәргә тиеш булган дөрес карарларга бәйле.

Бәла узган елның җәй башында килде. Дөресрәге, Башкортстанда татарларның милләтен үзгәртүнең, мәктәпләрдә татар теле дәресе урынына башкорт теле кертүнең яңа кампаниясе турында май-июнь айларында мәгълүм булды. Яңавыл районындагы татар авылларына Мәскәү һәм Уфа антропологлары килеп, халыкны клубка җыеп, шунда килгән адәми затларның баш сөякләрен, күз-колак тишекләрен үлчәп, анализга кан алуның кагыйдә буенча бары тик медпунктларда, шифаханәләрдә генә оештырылырга тиешлегенә карамастан, шунда ук кан алып, кул-бармак эзләрен тикшереп мәш килгәннәр. Тән төзелешен тикшерү генә җитмәгәч, авыл кешеләренең күңел һәм зиһен төпкелләренә дә кагылып караганнар. Тау, дала, урман, елга рәсемнәрен күрсәтеп: «Сезгә нинди табигать күренешләре якынрак?»—дип сорашканнар. Авыл кешеләренең сары чәчлеләрнеме, әллә кап-кара чәч үстерүчеләрнеме үз итүләре бигрәк тә кызыксындырган. Антропологиядә мондый тикшерүләр була, диләр. Әмма авыл кешеләре фәндә әллә ни алга киткән халык түгел, шунлыктан кайберәүләр: ...«Бу адәмнәр безгә СПИД йоктырырга килмәдеме икән?»—дип шикләнгән. Нинди максат белән һәм нинди тикшерү алып барганнар соң Яңавылда? Ни өчен Россия Фәннәр Академиясенең Н. Н. Миклухо-Маклай исемендәге этнология һәм антропология институты һәм Башкорт дәүләт университеты, педагогия институты галимнәре Башкортстанның көньягындагы Хәйбулла яки Бөрьян районына түгел, ә нәкъ менә Яңавыл-Тәтешле якларына килгәннәр? Татар халкының күренекле әдипләре Нил һәм Илдар Юзеевлар, Нурихан Фәттах, Хәсән Сарьян, Риза Ишморат, Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов, Әнгам Атнабаев, танылган җырчылар Салават, Хәния Фәрхи һәм башка бик күп күренекле татарлар туган авылларның этник тарихын, раса үзенчәлеген өйрәнү нинди нәтиҗә биргән соң? Хәзергә бу хакта галимнәр берниндн мәгълүмат таратмады. Күрәсең, бу якларда чыннан да татарлар яшәве раслангандыр. Башкача булса, әллә кайчан кычкырып әйтерләр иде. Галимнәр килгән дә киткән, аларны Башкортстан хөкүмәтенең һәм Фәннәр Академиясенең заказын үтәгән өчен гаепләп булмый. Әмма кеше канын һәм тәнен, җанын тикшерүчеләр киткәч озак та тормый, Уфадан мәгариф вәкилләре килгән. Яңа уку елында мәктәпләрдә беренче сыйныфтан ук башкорт теле кертелергә тиешлеген аңлатканнар. Район түрәләре, мәктәп директорлары, укытучылар күрсәтмәнең каян килгәнен һәм ничек үтәлергә тиешлеген яхшы беләләр.

Ни өчен бәла дип атадым мин бу гамәлләрне? Көнбатыш Башкортстандагы татарларны башкорт телен өйрәтү белән куркыта алмыйсың. Кирәк икән, бу яктагы татарлар башкортча гәзитен, журналын, китабын укып, тиешле урында, башкортның үзеннән һич калмыйча, бу телдә сөйләшә алалар. Туган теленнән биш-алты процентка гына аерылган телне белү зур бәла да, җәза да түгел. Бәла башкада: кардәш халыкның телен,—ә бәлки, диалектныдыр?—туган тел итеп кабул итәргә мәҗбүр итүдә. Мин татар икән, димәк бу минем язмыш һәм Аллаһы Тәгалә карары. Мин француз да, урыс та, швед та, бурят та булырга теләмим. Минем бердәнбер гомеремдә үзем булып яшәргә, дөньяны үзем аңлаганча кабул итәргә хакым бар. Кешегә берниндн дини яки милли ярлык тагу мөмкин түгел. Шуңа күрә дәүләт һәр ватандашка намус ирекe гарантияли. Нинди Аллага табыну, нәрсәгә өзелеп ярату—бу аның үз эше. Шуңа күрә үзаң дигән бөек төшенчә белән саңлашалар. Үз аңың, үз аңлавың, кайда, ничек, кем белән яшәвеңне үзең хәл итү—ул синең ирекең дигән сүз. Син үзеңә-үзең хуҗа, үзең теләгәнчә сулыш аласың, булдыра алган кадәр хәрәкәт итәсең, җаның кушкан һәм язмыш мөмкинлек биргән кадәр дөньяны, кешеләрне күреп йөрисең, туган ягың әүнкеләрен, яшел күбек кебек тауларын

карыйсың, җәйге яңгыр тамчыларының күктән җиргә акканын карап сокланасың, буран, җил тавышын тыңлыйсың, янган яфрак тӧтенен иснәп, мең ел элек шушы җирдә синең ата-бабаң нилер эшләп йӧргәнен күзаллыйсың. Бәхетең дә үзеңнеке, кайгың да. Әти-әниең дә, балаң да, хатының да, ирең дә үзеңнеке. Алар ничек, шулай кабул итәсең,. Алар сине үз итә, кичерә, син дә аларны гафу итәсең. Шуннан башка кешенең иң беренче һәм иң соңгы ирегә буламы? Бу бит аның тормышы. Аңа беркем дә нинди дер сәяси-милли күсәк белән кагылырга тиеш түгел.

Әгәр дә Миякәдә, Туймазыда, Чакмагышта, Илештә, Дүртӧйледә яшәгән татарларга: «Синең тарихың башкача, милләтең башка, үзең ялгыш юлга баскансың, сине татарлаштырганнар, туган телеңнән аерганнар»,— дип бертуктаусыз тукый башласалар, бу инде иректе тормыш түгел. Татар кешесе: «Бәлки шулайдыр»,—диярге мӧмкин. Ул кесәсендә «башкорт» дип язылган паспорт йӧртергә, анкетасының бишенче графасына шуны яздырып, бирәр җиргә укырга, эшкә керергә мӧмкин. Ләкин ул үзенең кем икәнлеген белә, туган телен һәм милли тәрбиясен үз вакытында алган булса, ул бервакытта да үзлеген онытмый.

Шулай итеп, 2001 елның кӧзендә мәктәп директорларын РОНОга җыеп, башкорт телен ӧйрәнүнең нормаларын аңлатып, зур кӧчләү кампаниясе башлап җибәргәннәр. Башкорт телен дәүләт теле буларак кына ӧйрәнсәләр, бер хәл. Бу дәүләт телен урыслар, чувашлар, мордвалар да шул ук дәрәҗәдә белергә тиештер бит. Димәк, татарның җаны тыныч булырга тиеш. Ул болай да «дәүләт теле» имтиханын җиңел үтәчәк. Ләкин юк шул, башка милләтләргә түгел, бары тик татарларга гына бәйләнәләр. Һәм башкорт теле дәүләт теле буларак кына түгел, ә нәкъ менә туган тел буларак беренче класстан ук ӧйрәнелергә тиеш, имеш.

Шул рәвешле, «кӧнбатыш Башкортстанда тарихны тӧзәтергә» дигән булып, татарларның үзаңына тәэсир итү, аларны башкорт халкын татарлаштыруда гаепләү кӧн аралаш яңгырый башлады. Имештер, хәтта Татарстанның Актаныш, Минзәлә, Мӧслим районнарында да кешеләрнең милләтләре дӧрес түгел. Аларны кӧчләп татарлаштырганнар, имеш. Бусы инде территориаль дәгъва белдерүгә охшап тора. Бәла дими, ничек атыйсың бу хәлне? Мондый уеннар Брежнев заманнарында булган иде. Яңа түгел алар. Әмма хәзер бернинди чамасыз, ачыктан-ачык дау күтәрелә.

Кызганыч, татар галимнәре бу мәсьәләләргә «сәяси» итеп карап, күрәсең, бәхәскә керүдән тартына. Болар бит әрләш-талаш объекты түгел, ә фәнни аңлашу зарурияты. Болар бит, беренче чиратта, бу телләрнең хуҗалары булган милләт вәкилләренә кирәк.

Әйе, үземә килгәндә, мин үземне татар-типтәр итеп тойсам һәм тәрбияләнгән булсам да, әти ягыннан ерак әбием башкорт булган. Димәк, миндә башкорт каны да ага. Тагын шунысын да әйтим, үземнең башкортлыкка катнашым булу сәбәбеннән, күрәсең, мин үземне һәрвакытта да, татар белән беррәттән, башкорт милләтенең дә бәхете һәм сәгадәте ӧчен кӧрәшчесе итеп тойдым. Тойдым гына түгел, җитәрлек ӧлеш тә керттем.

Шушы татар-башкорт бердәмлеген табу тойгысы мине җитмешенче еллар башында Уфага кайтарды, гомеремдә башкорт теленнән бер генә дӧрес алмасам да, республиканың үзәк башкорт газетасы «Совет Башкорстаны»на урнаштырды, шул тойгы мине шул елларда ук башкортның танылган публицистларыннан берсе итте. Мин Уфада татар телендә язып, татар шагыйре дә була алган булыр идем. Әмма андый мӧмкинлекләрдән мәхрүм ителгән кеше буларак, мин татарча уйлап, татарча язсам да, беренче китапларымны рәсми рәвештә башкорт телендә чыгарырга мәҗбүр булдым һәм СССР Язучылар Союзына башкорт шагыйре буларак кабул ителдем. Бу шул заманнарда рәсми идеологиянең миңа таккан мәҗбүрияте иде. Минем язмыш бер миңа гына хас язмыш түгел иде. Милләте татар булган йӧзләгән «башкорт» шагыйренең язмышы иде бу. Әмма бу халәт безнең беребезне дә татар яки башкорт милләте алдында гаепле хәлгә куймады. Без беребез дә, шул исәптән мин дә,

беркемне дә, бернәрсәне дә сатмадык. Без бары тик, үзебезгә тагылган шартлардан чыгып, гомумән алганда «бер әдәбият» булган уртак (төрки) «татар-башкорт» әдәбиятына хезмәт итәргә тырыштык.

Үткән гасырның сиксәненче еллары уртасында мин, җитмешенче еллар азагында башланган «башкортлаштыру» процессының ике милләткә никадәр зыян салачагын алдан күреп, беренче чиратта, башкорт милләтенең бәхетле киләчәген—аның мәктәбен, газета-журналларын, телевидение, киностудияләрен яклап, урыс телендә «Книга печали» дигән китабымны яздым. Аның «Язык мой—друг мой...» дип исемләнгән өзекләре «Дружба народов» дигән бөтенсоюз журналында чыкканнан соң, башкортның иң кара көчләре тарафыннан кыйналдым һәм бүген дә кыйналуымны дәвам итәм.

Мин анда «персона нон грата». Менә ун ел инде Башкортстанда бер әсәрем дә басылганы юк. Исемемнең күренгәне юк. Бер генә дә иҗади кичәм, укучыларым белән очрашуларым оештырылганы юк. Мин анда «тыелган» шәхес.

Узган ел Татарстан Дәүләт Советының милли комиссиясе рәисе шагыйрь Разил Вәлиев, Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчесе Индус Таһиров Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимовка хат яздылар. Шулай-шулай, Мортаза агай, татар һәм башкорт әдәбиятларына хезмәт иткән якташыбыз Айдар Хәлимнең алтмыш еллык юбилеен туган районында һәм Уфаның берәр мәдәният йортында үткәрергә ярдәм итә алмассызмы? Җавапны премьер-министр урынбасары Хәлиф Ишморатов бирде. Айдар Хәлим Башкортстан Язучылар союзыннан учеттан әллә кайчан төшкән, ул Татарстанда яши, гомумән, бездә 50 яшьлек, 75 яшьлек һәм 100 еллык юбилейлар гына үткәрелә. Шуңа күрә...

Җырдан алып җырга салганда да
Җырдан туймас халык—башкорт бар—

дип язган идем заманында. Ул халык белән уртак тел табып була. Чиновниклар белән аңлашу гына кыенрак. «Алар әллә үз халыкларының башын катыру, тормышын катлауландыру өчен генә яши микән?»—дип уйларга туры килә.

## Милләтебез икеме—әллә телебез берме?

«КӨЧЛӘП башкорт телен укыту» дибез. «Башкортлаштыру» дибез. Бик сәер, нормаль кешегә аңлашылмаган күренеш бу. Чөнки татар телен белгән кеше башкортча аңлый, укый, кирәк булса, сөйләшә. Һәм киресенчә—башкортлар татарны аңлый. Ягъни, татарлар җыелган җирдә башкортларга туган телдән башка телгә күчәргә кирәкми. Без бит әле, егерме татар яки башкорт янына бер-ике рус кешесе килсә, аны рәнҗетмәс өчен, барыбыз да аның теленә күчәбез. Бигрәк тә элек бу шулай булды. Башкортстанда әле дә бу күренеш табигый. Татар белән бергә яшәү башкортның дәрәҗәсен төшерми, аның мохитен һич тарайтмый. Син башкорт икән, сөйләш матур итеп үз телеңдә. Минем җавабымны тылмачсыз аңлап, үз фикереңне әйт. Якташым Айдар Галимовның концертларында гадәттә бер алып баручы татарча, икенчесе башкортча сөйли. Һәр ике телнең үзенчәлеген, аермасын һәм охшашлыгын тыңлавы кызык. Мин башкорт авылларына татар муллалары килеп, җирле халыкның телен үзгәрткән, аны татарлаштырган дигән әкияткә ышанмыйм. Дим буйларында бер-берсеннән дүрт-биш чакрымда татар авыллары белән башкорт авыллары аралашып утыра. Гасырлар буе бергә яшәп, хәтта бер колхозга берләшеп тә, кыз биреп, килен алып та, бу авылларның теле үзгәрми. Татар авылы татар булып кала, башкорт авылында башкортлар яши. Ә еш кына һәр авылда да ике телне яхшы беләләр. Шунда ук чуваш авылы булса, анда да тугандаш татар-башкорт телен беләләр. Безнекеләр дә чувашча ару гына сукалый. Гасырлар буе килгән табигый күптеллелек тәҗрибәсен өйрәнергә галимнәр табылмый шул. Татар һәм

башкорт телләрен берьюлы белү, куллану методикасын шул ук Башкорт дәүләт университеты, педагогия институты профессорлары булдыра алмас идемени? Юк шул, хәзер алар антропология һәм сәясәт белән мавыгалар.

Башкорт телендә татар аңламаган, белмәгән сүзләр юк диярлек. Әйе, башкорт теле, әгәр ул бар икән, шул ук татар теле ул. Әйе, без бер үк вакытта татар телен дә башкорт теле дип атый алабыз. Бер тел булгач! Шулай бит инде! Әгәр башкорт галимнәре безнең халык авыз иҗатыбыз, барлык борынгы мирасыбыз бер, уртак дип баралар икән, нишләп соң әле безнең телебез икәү булырга тиеш?! Монда алогизм килеп чыга түгелме?

Җәмәгатьчелеккә шундый сорау бирер көннәр җитте: башкорт теле менә мең ел инде халыкара аңлашу, Рәсәй империясенең, аннан СССРның рәсми булмаган дәүләт телләре ролен үтәгән, Берләшкән Милләтләр Оешмасы тарафыннан дөньядагы ундүрт халыкара телнең берсе итеп танылган татар теленең аерым бер тел статусына күтәрелгән диалекталь бер сөйләме, тармагы түгелме? Әйдә, барлык Җир шары алдында башкорт галимнәре расласыннар: бәлки татар теле үзе башкорт теленең бер диалектыдыр? Чынлап та, ә?.. Әмма нигездә болгар-татар теле яткан мең еллык дәүләтчелеге, составына башкорт кабиләләре дә кергән Болгар, Казан, Алтын Урда дигән дәүләт-империяләре, Алтайлардагы балбалларга Күлтәгин биләр яздырган Таш Хатлар, «Кыйссаи Йосыф»лар, «Нуры содур»лар иҗат ителгән бөек татар теле булган бит әле!

... Бүген бер башкорт мең татар яшәгән авылны, ун мең татар яшәгән район үзәген, йөз мең татар яшәгән шәһәрне көчләп башкортча укытып маташа. Татарны болай итеп башкортча укыту татарны татарча укытуга тиң булырмы? Болай итеп куркытып укыту баланың аңын гариплэтмәсме, иманын качырмасмы? Болай итеп укыту татар баласына үз телендә бирелгән интеллектуаль байлыкны—аңны, зирәклекне бирә алырмы?

Әгәр тарихи җирлектә татар теле булмаган булса, милләтләре белән татар булган, бары тик татарча сөйләшкән һәм язган Зәки Вәлиди, Шәехзадә Бабичлар, алар гына да түгел, хәтта милләтләр атасы Сталин, егерменче еллар уртасында ашык-пошык рәвештә «башкорт әдәби теле»н барлыкка китергәндә, аны кайдан һәм нинди җирлектән алган булырлар иде икән? Төрек, әзәри, үзбәк һәм башка телләрдәнме? Алар да «уртак төрки тел» бит югыйсә? Нигә алардан алмаганнар башкорт телен? Нигә татардан алганнар? Нигә шул ук елларда дәүләт статусы алган ул төрки телләр дә үз телләрен мең еллык тарихи, дәүләти кануны булган төрки татар теленнән алганнар? Әмма ләкин бу сораулар арасында иң кызыгы шул: ничек итеп ул безнең телләребез, башкорт галимнәре раславынча, шулкадәр аерым, шулкадәр төрле булгач, мең еллык мирасыбыз нишләп уртак була икән? Ул ничек итеп йөз-ике йөз ел буе татар шагыйрьләре, татар галимнәре булып йөргән Риза Фәхретдин, Мифтахетдин Акмулла, Гали Чокрый, Шәехзадә Бабич, Мәҗит Гафурилар кинәттән генә башкортка әверелләләр һәм башкорт шигърияте антологиясен бизәп торалар икән?

Әйе, башкорт «әдәби теле»нең аваз-хәрефләрен, ягъни әлифбасын, югарыдагы хакимият фәрман төшергәч, шул ук татар Сәгыйть Рәмиләр корыштырып биргән.

Моннан нинди хакыйкать килеп чыга. Татар теле—башкорт телен бар итүче түгел. Ул аның нигезе. Башкорт теле,—әгәр ул бар икән,—татар теленнән башка туа алмый иде. Татар теле «прото-тел», ягъни, тудыручы ата-ана теле буларак, башкорт теленнән башка мөстәкыйль яши алса да, башкорт теле исә әле бүген дә татар теленнән башка яши алмый.

Әле егерменче еллар азагында гына яралуга «дучар ителеп» маташкан башкорт милли-әдәби телен татардан мөмкин кадәр аеру өчен, Мәскәү телчеләре башкорт орфографиясен «ничек ишетелсә, шулай язу» принцибына күчерә алдылар. Беренчедән, хәзерге имляда каты «г»-сы да, нечкә «г»-сы да бер төрле булган татар баласы, көчәнә-көчәнә, хаталар ясый-ясый, дистә еллар буе «мәнфәгать, табигать» дип язарга мәҗбүр булса, каты һәм нечкә «г»лары аерым булган башкорт баласы һич тә көчәнмичә «мәнфәгәт, тәбигәт» дип кенә язып килде. Бу башкорт әдәби

телен үзләштерүне бик җиңелләштерде. Икенчедән, татарның барлык архаик, диалекталь, кулланудан төшеп калган җирле сөйләм сүзләре башкорт сүзләре дип игълан ителде һәм тавышсыз-тынсыз гына куллануга кертелде. Өченчедән, татар телендә сирәк кулланылган сүзләр башкортта «башкорт сүзләре» буларак тормышка җигелде. Артык «татарча» була дип, «сугышчы»ны «һугышсы», «бүләк»не «бүләк», «кибет»не «кибет» дип алырга тартынгач, бу сүзләрне «воин», «награда», «магазин» дип язып килделәр. Никадәр «башкортча», әйеме! Ә менә гарәптән саф төркигә әйләнгән «мөстәкыйльлек» дигән сүзне, «татарча» булганы өчен исеннән үк яратмыйча һәм алырга теләмичә, бер-ике ел элек кенә аны «үзаллылык» белән алыштырдылар.

Шулай итеп, барлык дөнья интеграциягә—берләшүгә тартылганда, башкорт зиһене генә татар белән интеграциягә-берләшүгә керергә тырышмады. Киресенчә, Мәскәүнең даими котыртып торуы нәтиҗәсендә, сепарация, аерылу, бүленү, ничек кенә булса да татарга охшарга тырышмау, хәтта урлашып үзләштерү максаты белән яшәде. Мәскәү мондый карашны үтереп мактады һәм ярдәм күрсәтте. Мондый ярдәм белән рухланган «башкортчылар» барлык «гомумтөрки» генә түгел, барлык гомумтатар Колгали, Мөхәммәдьяр, Акмулла, Чокрый, Гафури, Тукай һәм Ризаэтдин Фәхретдиннәрне җиңел генә «башкорт» дип игълан итте һәм итә килә. Мин инде Сәйфи Кудаш, Мостай Кәрим, Нәҗар Нәҗмиләр турында сөйләп тә тормыйм. Бу хакта заманында мәрхүм галимебез Альберт Фәтхи, язучыбыз Нурихан Фәттах тетрәткеч мәкаләләр язганнар иде...

Башкортстан Тел, әдәбият институтының «бармаем-кайтмаем» формасының бары тик башкортныкы гына булуы турында чүбек чәйнәгән «акыл ияләренә» шуны әйтәсе килә. Татар арасында ата татар булган, аның яңа мәгърифәтенә, яңа әдәби теленә нигез салган, әле дә тиешле бәясен алмаган, Казанда һәйкәл куелырга лаеклы бөек мәгърифәтчебез, галимебез, тел остабыз мәшһүр Каюм Насыйрине укысыннар иде алар.

Хәзер Яшел Үзән районына кергән Шырдан авылы татары Каюм баба әсәрләренең телендә башкортлар үзләренеке генә санаган «белмәем», «мөргән», «алыс», «уксадак» сүзләре актив кулланылган. Алар барысы да борынгы төрки-татар сүзлеге байлыгы. Хәзер Актаныш, Мөслим, Минзәлә якларында һәм Башкортстанның кайбер районнарында татарлар «үдебеднең кыдыл бодау», «бармаем-кайтмаем», «бер алманы бишкә бүләек» дип сөйли икән, бу аларның башкорт булуын күрсәтми, киресенчә, татар теленең борынгы һәм диалект формаларына бай булуын гына раслый. «Йыл», «йәшлек», «кайтайык» дип «е», «я»,«ю» хәрефләрен ишетелгәнчә язганда, татарча да дөресрәк яңгырар иде. Бу башкорт орфографиясенең түгел, ә хакыйкатьнең җиңүе булыр иде. Һәрхәлдә телнең шушы элементлары татар белән башкортны аера алмый.

Менә бер өр-яңа мисал.

Былтыр октябрь аенда Уфада Бөтендөнья башкортлары корылтаеның Башкарма комитеты утырышы булып үтте. Анда чыгыш ясап, Башкарма комитетның рәисе тарихчы-археолог Нияз Мәҗитов менә болай дип белдерде (Комитетның органы «Ватандаш» журналының 2002 елның гыйнвар санында урыс телендә басылган бу чыгыштан өзекләрне без шулай ук урысча китерергә тиеш таптык. Бер уңайдан шунысын да әйтеп китик: Бөтендөнья башкортлары корылтае бары тик башкорт милли горурлыгын күтәрүгә багышланган «Ватандаш» дигән гадәттән тыш экспрессив вә агрессив журнал чыгарып ятканда, безнең Бөтендөнья татарлары Конгрессының исә бу хакта уйлап та караганы юк бугай): «Перед нами стоит ответственная задача содержательно провести подготовительную работу к предстоящей переписи. При формировании ответа о своей национальности на сознание человека будут влиять следующие факторы: кто лидеры этого народа, престижна ли его малая и большая Родина... Наш народ подарил миру таких талантливых и выдающихся людей, как Батыршин, Салават Юлаев, Гали Сокорой, Ахметзаки Валиди, Шайхзада Бабич, Назар Наджми, Мустай Карим и многих других».

Күрәсез, «Чокрый»ны «Сокорой» дип күпме кирәк, шул кадәр бозып язсаң, ул «башкортча» була инде. Урыста, теләсә нинди башка милләттә, бер үк сүз төрлечә кулланылган, төрлечә әйтелгән кавемнәр, ырулар, кабиләләр азмыни? Урыс бер дә аларны «кривич теле» дими бит. «Урыс теле», ди. Ә менә монда татар теле «башкорт теле», «мишәр теле», «типтәр теле», «көнбатыш башкортлар теле», «себер татарлары теле», «Әстерхан татарлары теле», хәтта ки «керәшен татарлары тел»ене дә әйләнә икән бит әле. Татарны ничек кенә булса да таркатырга, аңардан мөмкин кадәр күбрәк милләт ясарга кирәк икән...

Мәҗитов исемлегендә... бер генә этник башкорт та юк диярлек. Әгәр Салават Юлаевны исәпкә алмасак. Хәер, Салават Юлаев турында романының сугышка кадәр чыккан беренче басмасында Степан Злобин аның да әнисе ягыннан типтәр-татар булуын язган булган дип сөйлиләр сөйләвен...

## Корыч арканга әйләнгән ефәк җепләр

ӘЙЕ, мин чиста күңелле, тырыш, җырлы-моңлы, теле шаян мәзәкләр генә ыргытып торган гади башкорт халкын, аның күңелен бозып, гафу итегез, «кортлатып торган» башкорт шовинистларыннан аера беләм. Алар күп түгел, әмма соңгы вакытта күбәяләр. Кызганыч, никадәр кызганыч, егерменче гасыр башында «татар-башкорт туганлыгы җырчысы» Шәһит Ходайбирдиннәр кулында булган татар-башкорт бертуганлыгы әләме безнең көннәрдә «татар-башкорт дошманлыгы җырчылары»—язучы, галим исемен йөрткән, Башкорт энциклопедиясенең баш мөхәррире Рәшит Шәкүр, Газыйм Шафиков, Җиһат Солтан, Нияз Мәҗитов, Гайса Хөсәенов, Марат Колшәрипов, Дамир Вәлиев, Айтуган һәм Ирек Акмановлар, Рим Янгузин, Роза Буканова, Әнвәр Әсфәндияров кебек кешеләр кулына күчте. Кызганыч, шуларның «үгет-нәсихәте» нәтиҗәсендә милләт кадәр милләтнең табигате дә үзгәрә, хәтта кире якка—гаделсезлеккә таба тәгәри икән. Без моңа кадәр һәрвакыт милләткә бер мәңгелек гаделлек чыганагы, безне бар итү чишмәсе итеп карап өйрәнгән идек. Милләтне шәхесне бозу, черетү, юк итү чыганагы итеп карауны без күз алдына да китерә алмый идек. Әмма заманалар үзгәрә, заманалар белән иң бөек, иң изге төшенчәләр дә үзгәрә икән. Нәкъ җырдагыча: «Замананы авыр диләр, кем күтәреп караган?»

Безгә бер җитди нәтиҗә ясарга вакыт: радио-телевидение, үгет-нәсихәтнең гамәли чаралары барлыкка килгән чорда адәм баласын милләт түгел, күбрәк адәм баласы үзе милләтне тәрбияли икән.

Әйе, милләт кадәр милләтнең рухи сыйфатлары да йә яхшыра, йә начарая икән.

Шунысы факт: башкорт милләте кичәге башкорт милләте түгел. Аның бертуганы булган татарга карашы кискен үзгәрде. Дөресрәге, үзгәрттерделәр. Шунысы факт, күп туганнарыбыз туган булудан туктадылар. Башкорт туганнар дигән туганнарыбыз арасында туганнарыбыз калдымы әле? Бармы әле алар? Нәкъ моннан утыз ел элек язылган шигырьдәгечә:

Күпме алтын калды саф алтында?
Күпме атом бар соң атомда?
Күпме дус бар дуслар арасында?
Күпме халкың калды халкыңда?

Бардыр әле алар, туганнар арасында, сирәк булса да, туганнар калган булырга тиеш. Шайтан гына өметсез, диләр бит. Алар турында ике тугандаш милләтебезгә туктаусыз сөйләргә, аңлатырга кирәк. Мәсьәләне татар белән башкорт арасына күчергән хәлдә, беренче чиратта шунысын әйтү мөһим: безгә—галимнәргә, язучыларга, сәнгать кешеләренә һәм башка барлык зыялыларга ике милләтнең исән калган туганлыгын күз карасы кебек сакларга кирәк.

Миңа бу язмаларны язуы җиңел түгел. Бу язмалар шунысы белән үзенчәлекле: алар башкорт милләтчелеге турында гына түгел, ә безнең

кебек «вак» милләтләргә яңа күренеш булган башкорт шовинизмы турында. «Вак» милләтнең үзе кебек, үзеннән дә нык изелгән милләттәшенә булган агрессиясе турында. Татар әле мондый кыргый шовинизмны күз алдына да китерә алмый, аның җанында мондый зәм юк, ул моның өчен «үсеп җитмәгән». Әйе, башкорт милләтчелеге күптән инде нибары «туган тел, мәктәп» өчен генә көрәшкән гади милләтчелек булудан туктады. Ул милләтчелекнең иң агрессив, иң югары ноктасы булган этник шовинизм формасына күчте. Туган тел, туган телдәге мәктәпләр хакына башланган, «ефәк җепле» милләтчелек башкортчылык идеологиясе нигезендә корыч арканлы шовинизмга әверелде. Милләтчелекне без элегрәк шовинизмлы зур милләтләр агрессиясе белән генә бәйләргә өйрәнгән идек. Имештер ки, милләтчелек булса да, ул «вак» милләтләрдә генә була, ә менә шовинизм дигәне бары тик зур, барлык башка милләтләрне «йотарга теләгән» супермилләтләргә—әйтик, урысларга гына хас. Әмма кайбер «вак» милләтләр дә шовинизм белән чирли һәм үзеннән күпкә зур булган милләтләрне йотарга хыяллана, хәтта ки, бугазы аша үтә алса, бугазына тормаса, йотарга да керешә икән. Әйе, бу күренеш милләтнең санына бәйле түгел икән. Башкорт-татар мөнәсәбәтләрендә соңгы елларда нәкъ менә шундый вәзгыять барлыкка килде: башкортның шовинистик монстры (гыйфрите) сан ягыннан үзеннән ун мәртәбәләр зур булган татар милләтен йоту өчен җирлек әзерләде һәм Мәскәү биргән шартлар нигезендә шуны тормышка ашырырга тотынды.

Татарда шовинизм юк. Һәм ул безгә кирәкми дә. Башкортстан халкының ун гына процент чамасын алып торган этник башкорт телен дәүләт теле итеп игълан итү, ә республика халкының яртысын дип әйтерлек тәшкил иткән татарның телен рәсми исемлектән сызып ташлау нәрсә соң ул? Шовинизм! Җиде миллион татар моны «күрмичә-нитмичә» йотып җибәрде.

Үзгәртеп кору башланганда татар җәмәгатьчелеге, бик зур шау-шу куптарып, элеке Кушнаренко татар педагогия училищесын аякка бастырган иде. Бүген исә бер генә этник башкорт та булмаган бу төбәктәге ошбу уку йорты башкорт педагогия училищесына әйләндерелде. Безнең күз алдында. Без аны күрмибез дә, ишетмибез дә. Йөз елга якын тарихы булган атаклы татар Бәләбәй педагогия училищесы инде күптән татар мәгърифәте үзәге булудан туктады. Кайчандыр Фатих Кәрим, Гази Кашшаф, Таһир Таһировларны, шул исәптән, минем әти кебек меңәрләгән татар укытучыларын әзерләгән бу атаклы татар педагогия учагын искә төшереп елыйсы гына калды хәзер. Кайчандыр анда алты-җиде, хәтта унар татар группасы эшләп килгән булса, бүген анда нибары бер-ике татар группасы «бүген үләм-иртәгә үләм» дип тын алып маташа. Ә менә кабатлап әйтсәк, бер генә этник башкорт та яшәмәгән, булганы да «импортный» булган төбәк шартларында, бирегә бернич «башкорт һәм чуваш группалар»ы эшли башлаган. Юк, эшләсеннәр, без аңа куанабыз гына. Тик нигә татарны кысрыклау исәбенә? Үзгәртеп кору башлангач, татар җәмәгатьчелеге көч-хәл белән киртәләрне җимерә-җимерә, Бәләбәйдә татар гимназиясе оештыра алды. Анда бүген нибары ике йөзләп бала белем ала. Хәерче хәлендә яши. Утка, суга, коммуналь хезмәткә акча бүленми, анда бер электр шәмен сатып алу өчен дә ата-аналардан акча җыярга кирәк. Китаплар, дәфтәрләр, барлык уку-укыту әсбаплары һәм башка кирәк-яракларга тиешле акча бүленми, барысы да ата-аналар җилкәсендә. Этник башкортлар бөтенләй яшәмәгән шул ук Бәләбәй төбәгендә моннан бернчә ел элек күз явын алырлык, ялт итеп торган бинада башкорт гимназиясе ачылды. Анда, мисал өчен әйтик, ун башкорт, җиде йөз татар баласы белем ала. Тегә татар гимназиясендә ярлылык хөкем сөрсә, бирегә байлык вә барлык хөкем сөрә. Егерме татар укытучысына бер башкорт укытучысы. Әмма укыту башкортча һәм башкорт рухиятендә алып барыла. «Китаплар Өфедән китереп бушатылган. Финанс мәсьәләләре хәл ителгән. Акса бар. Ут бар. Һыу бар».

Күптән түгел мин Уфадагы бердәнбер татар гимназиясендә булдым. Гимназия директоры Рәшидә ханым Харитонова, үз эшенә мөкиббән китеп бирелгән кеше, мәктәптәге тәрбия эшен татар әхлагына якынайту өчен

барысын да эшләргә тырыша. Әмма, әмма... Анда дүрт йөз меңләп Уфа татарының нибары ике йөзләп баласы... урысча укый! Татар теле предмет буларак кына кирә. Татар китаплары җитми. Казанның бер тиенлек ярдәме юк. «Без Казанга ышанмыйбыз да, аңа ярдәм сорап бармыйбыз да»,—диләр укытучылар бертавыштан. Башкортстан хөкүмәте башкортлар яшәгән төбәкләрне бушка уку-укыту әсбаплары, әдәби китаплар белән күмгән чакта (бу юнәлештә елына 100 миллион сумга якын акча тотыла), Казанның Татарстан мәктәпләрен дә тәэмин итә алмавы сәер булса да, гадәти хәлгә әйләнгән. Әлбәттә, Уфадагы бу мәктәп әлегә күбрәк исем өчен генә «татар мәктәбе» дип атала. Уфада яңа татар мәктәбенең ачылу мөмкинлеге бөтенләй күз уңында тотылмый. Уфаның Киров районы хезмәтчәннәре менә ничә дистә еллар инде татар мәктәбе ачтыру өчен көрәшә. Әмма—юк. Күптән түгел район хакиме Марс Рәхмәтулла угылы Кәлметов, «үз татарымыз»,—татар милли хәрәкәте активистлары белән очрашканда: «Татар мәктәбе турында авызыгызны да ачмагыз, иначе моя встреча с вами өзелгән будет»,—дип белдергән.

Мин Уфаның Рәми Гарипов исемен йөрткән, махсус төзелгән асаба-элиталы башкорт гимназиясендә булдым. Анда, ярымхәрби тәртип нигезендә, меңгә якын бала башкортча белем ала. Ул бүген башкортның урыслардагы элекке Царское Село лицее вазифасын үти. Ул—алтын-көмеш белән йөгертелгән милли белем сарае. Казанда андый бинасы булган татар гимназиясе юк. Анда һәр квадрат сантиметр башкорт милли горурлыгына эшли. Мин Татарстан укытучыларын бирегә алып килеп, бер генә тапкыр булса да күрсәтер һәм лекция укытыр идем...

Мин шулай ук Уфаның «Дан» бульварында урнашкан башкорт икътисади көллиятендә булдым. Мондый көллиятләр Уфада берничә. Башкортстанда исә алар шәһәр саен. Ятим балалар урам буйлап тырай типми биредә. Башкорт милләтенә хезмәт итә. Мондый лицей-интернатлар ир һәм кыз балалар өчен аерым оештырылган. Биредә ашау, яшәү һәм кием-салым бушка бирелә. Яшәү тәртибе—устав буенча, ярымхәрби. Аларга ел саен районнардан меңгә якын укучы кабул ителә. Берничә елдан Башкортстан икътисады белән җитәкчелек итү алар кулына күчәчәк.

Башкортстан хөкүмәте шушы ысул белән соңгы ун елда башкорт теле һәм әдәбияты буенча меңнәрчә укытучы әзерләп өлгерде.

Бүген Башкортстанда кырыкка якын башкорт гимназиясе һәм лицее бар. Мәктәпләрдә йөз меңгә якын татар баласы үз теле, әдәбияты урынына башкорт телен һәм әдәбиятын өйрәнә һәм, әйтергә кирәк, өйрәнгән булып надан кала.

Бүген Бәләбәй мәктәпләрендә укучы меңләгән татар баласыннан бары тик җитмешләп бала гына туган телен өйрәнә. Калганнары башкорт теленә җәлеп ителгән. Куаныргамы моңа, әллә үкенергәме? Әллә, гафу итегез, мәнкортлар кебек, «чукынып китмәсләрме шунда» дип игътибар да итмәскәме?

Хәзер бу «рухият»ның Татарстан чигенә килеп җитүе хыял түгел, ә чынбарлык. Көнбатыш Башкортстанның Дүртөйле, Кушнаренко, Илеш, Краснокам, Яңавыл кебек утызлап районында һәм Нефтекамск, Бөре шәһәрләрендә, Бәләбәйдәге кебек үк, башкорт гимназияләре ачылырга әзерләнә. Анда унбиш этник башкорт белән бергә меңләгән татар баласы «башкортса укыясак».

Ә менә башкорт шовинизмы этник башкортны татарга «бирүне» (татарча укытуны) күз алдына да китерә алмый. Ул аны урысча укытса укыта, әмма татарча укытмый.

Әйе, бу юлларны укыганда мәсьәләнең никадәр тирәнгә китүен белмәгән беркатлы татар укучысы сискәнеп куярга мөмкин. Ничек кенә шомартырга тырышсак та, факт: милләтчелекнең башкортчыл төре яшәешен бары тик икенче милләт исәбенә яшәү белән генә аклый торган шовинизмга әйләнде. Бу Рәсәйнең «вак» халыклары тарихында әлегәчә күрелмәгән күренеш. «Шовинизм» сәяси сүзлектә «милләтчелекнең гадәттән тыш агрессив формасы» дигәнне аңлата. Башкорт шовинизмы өчен ул гына аз. Аңа милләтчелекнең геноцид сыйфатлары хас. Шуңа күрә, бу язмалар башкорт шовинизмының әлегәчә яктыртылмаган ягы—аның эчке

анатомиясен сурәтлүгә дә багышлана. Бәлки, бу хакта миңа да язмаскадыр? Нигә үземнең һәм башкаларның йөрәген өзгәләргә? Җитәкчеләребезгә ямьсез күренергә? Әнә, Уфада китап чыгарган дистәләгән авторларыбыз бу хакта язмыйлар һәм язмаячаклар, шулай бит?

Сез карагыз әле, Өченче мең ел башында... әле моннан сиксән ел элек кенә... татар Уфасыннан оештырылып бирелгән Башкортстан хөкүмәте кушуы буенча, аның матбугаты (хәер, ул күптәннән килә инде!) Татарстанның Азнакай, Актаныш, Мөслим, гомумән алганда, элеккеге Минзәлә өязе территориясенә дәгъва белдерә. Татарстанга гынамы?! Башкорт корылтае рәисе Нияз Мәҗитовның югарыда китерелгән чыгышында шушы хакта ачык әйтелә һәм бу җирләрне кайтарып алу бурычы Башкарма комитет резолюциясенә кертелә. *«За пределами Башкортстана самая большая группа башкир живет в Челябинской области—около 250 тысяч, в Оренбургской области—около 70 тыс., в Свердловской области—более 60 тыс., в Пермской области—более 60 тыс., в Курганской—около 20 тыс., в Республике Татарстан—около 30 тыс., в Самарской области—около 10 тысяч.—ди ул.—Как историк, особо хочу подчеркнуть, что вся названная агромная территория есть территория исторического Башкортстана, где башкиры, как коренное население, живут примерно с IX–X вв. н. э. В состав исторического Башкортстана до начала XX века входила территория восточного Татарстана, всем известный Мензелинский уезд, где проживало около 200 тысяч башкир (по итогам переписи 1897 года). В 1920 году Мензелинский край передали Татарстану. Мензелинские башкиры затем подверглись сильнейшей татарской ассимиляции, но башкирское самосознание еще живо у многих мензелинцев».* Шушы «мәгълүматны» ул «Агыйдел» журналының быелгы 4 нче санындагы «Тарихи язмышыбыз хәл ителә» дигән язмасында да китерә. *«Башкортстандан читтә башкорттар күпләп йәшәгән иң зур төбәк—Силәбе өлкәһе, унда 250 мең самаһы башкорт бар. Ырымбур өлкәһендә—70 мең самаһы, Свердлов өлкәсендә—60 меңдән ашыу, Пермь өлкәһендә—60 меңдән ашыу, Курган өлкәһендә—20 мең самаһы, Татарстан Республикаһында—30 мең, һамар өлкәһендә 10 мең башкорт көн күрә. Атап кителгән гәйәт зур территория Тарихи Башкортстан тип атала.*

*Башкорттар, төп халык буларак, был ерзәрзә якынса безнең эраның IX-X быуаттарыннан бирле йәшәй. XX быуат баштарына тиклем Көнсыгыш Татарстан да Тарихи Башкортостан составына ингән. 1897 елгы халык исәбен алыу йомгактары буйынса Минзәлә өйәзендә, мәсәлән, 200 мең самаһы башкорт йәшәй. 1920 елда Минзәлә тирәһен Башкортостандан тартып алып, Татарстанга бирү асылда унда яшәгән башкорттарга хыянәт итеү булды. Артабан Минзәлә башкорттары үтә көслө татар ассимиляцияһына дусар ителде, ләкин Минзәлә халкының байтагы әле булһа башкорт үзаңын югалтмаган»,*—дип яза ул. Йә, «Минзәлә халкы», сез үзегез бу хакта нәрсә диярсез икән?!

Алтын Урда кебек бөек дәүләтләр тоткан татар милләте бу җирләрдән кая гына китеп югалды икән соң? Ничек килеп чыга икән бу? Урыс тарихы башкорт кавеме гомере буе Болгар, Казан ханлыклары, Алтын Урда дәүләте составында вассал булып яшәгәннәр дип раслап килде. Бу хакта Рәсәйгә ярамсакланган башкорт галимнәре аеруча яратып язды. «Изеүсе татарзарзы» ничек кенә сүкмәделәр. Казан Иван Грозный камалышында кансырап ятканда, башкортларның Казан кальгәсен калдырып чыгулары белән ничек кенә горурланмадылар! Башкортны урыс алдында мескен күрсәтергә, аны татар белән чөкештереп, Мәскәүдән зуррак бюджет алуга ирешкәндә татар «изүче милләт» булып сурәтләнеп килсә, бүген, татарны башкортлаштыру өчен, алар уйлавынча, барлык алшартлар тудырылгач, Башкортстанда татар «кичә генә килеп басып алган оккупант, килмешәк» элемент икән! Кая монда логика?

Бәй, татарлар «Башкортстанда» бөтенләй булмаган икән! Татарлар Агыйдел-Урал буйларында бөтенләй бер дә күренмәгән-беленмәгән кавем икән! Алар «Башкортостанды кисә генә килеп басып алгандар» икән!

«Тарихчы» Мәҗитов 1922 елда Сталин тарафыннан «Бәләкәй Башкортстан»га куып кертелгән, нәтиҗәдә бу гаделсезлеккә каршы баш

күтәрергә мәҗбүр булган Бөре, Бәләбәй, Уфа өязләре—бүген шул территориядәге утызлап районда яшәгән ике миллионга якын татар халкы турында да ләм-мим. «Миндәлә башкорттары»ның никадәр башкорт булулары турында аларның үзләреннән сорау кирәклеге турында да эндәшми ул.

Анычча, мишәрләр һәм типтәрләр татар милләтенә катнашы булмаган «аерым милләт» кенә түгел, җитмәсә алар башкорт милләтенең аерылгысыз өлешләре дә икән. *«Мишари—самостоятельный тюркский народ... С момента прихода на территорию Башкортстана мишари входят в активный контакт с местным башкирским населением, часто образуя единые деревни. Вместе с башкирами они составляли сословие служилых людей... Уже в середине XIX в. мишари, равно как и тептяре и бобыли, в этнокультурном плане вместе с башкирами представляли однородную, т.е. близкую, родственную массу...»*—дип яза ул. Һәм, бу мәсьәләдә артык тирәнгә керми, әлеге телгә алган журналда *«... мишәрзәрзең төп өлеше үзен үзаллы халык тип исәпләй»* дип кенә узып китә. Нияз Мәҗитовның калган «ачышларына» кереп тормыйбыз. Һәр аңлы татар вә башкорт кешесе үзе аңлар, дип уйлыйк.

Кызык килеп чыга бит: мишәрләр дә башкорт, типтәрләр дә башкорт булгач, татар халкы кайда булып чыга икән соң?

## Башкортстанда «Тарихи Башкортстан» бармы?

ӘҮВӘЛ ТАТАР-БАШКОРТ республикасы турында берничә генә сүз. Милли Мәҗлеснең «Идел-Урал штаты» проектына альтернатив рәвештә татар большевиклары һәм социалистлары тәкъдим иткән, Ленин һәм Сталин тарафыннан яклау табып, бу хактагы документка Владимир Ленин һәм Мулланур Вахитов кул куйган «Татар-Башкорт республикасы», кызганыч ки, тормышка ашырылмый калган. Бу хата, күрәбез, менә йөз елга якын инде, татар-башкорт халыкларының бәхетсезлек чыганагы булып тора. Бүгенге башкортчылык котыруы да шуның нәтиҗәсендә килеп чыккан чираттагы бәла. Татар-Башкорт республикасының тормышка ашырылмавында аңа каты каршылык күрсәткән өч шәхесне атап китәргә кирәк: алар билгеле башкорт милли хәрәкәте җитәкчеләре Зәки Вәлиди белән Шәриф Манатов һәм Милләтләр Эшләре буенча халык комиссары Иосиф Сталин. 1918 елның март уртасында Татар-Башкорт республикасы буенча РКП(б) Үзәк Комитеты белән берлектә Милләтләр Эшләре буенча Комиссариат үткәргән өч көнлек киңәшмәдә чыгышлар ясап, Зәки Вәлидинең ул чактагы урынбасары, башкорт социалисты Шәриф Манатов Сталинның Татар-Башкорт республикасына карата мөнәсәбәтен кире якка үзгәртүгә ирешә. Сталин РСФСР уртасында «татар экспансиясенең территориаль көчәюенә» каршы чыгарга кирәк дигән карарга килә. Аның милли мәсьәләдә атаклы татар большевигы Мирсәет Солтангалиевкә көнләшеп каравы, аңа каршы егерме еллык көрәше менә шул көннәрдән чыганак ала...



Менә укучы игътибарына Ленин һәм Вахитов кул куйган Татар-башкорт республикасы проекты буенча тәкъдим ителгән территориаль харитә (карта).

Аны соңгы дистә елларда татар-башкорт милләтенең күргәне дә юк инде. Харитә белән танышканнан соң, күңелне горур-

лык хисләре белән ала. Их, борынгы бабаларыбыз яшәгән җирләрнең уннан берен генә биләгән булса да, нинди зур, бай буласы булган икән безнең уртак республикабыз! Беткән, татар арасында «эрегән» булыр идеме башкорт халкы, әгәр бу дәүләт аякка бастырылган булса? Юк, әлбәттә! Башкортның милли холкын-табигатен, аңын, сәнгатен, фәнен кадерләп, ватмый-җимерми үстергән булыр иде дә бит татар халкы! Мең ел мөселман булган татарның тугандаш төркиләргә генә түгел, чит, башка милләтләргә карата булган бер генә вәхшилеген тарихтан табып карагыз! Юк, табып булмый... Әмма нишләтәсең, Татар-Башкорт җөмһүрияте юлына киртәләр салына. Һәм аны башкорт милләтчесе булып йөргән ике татар типтәре—Зәки Вәлиди белән Шәриф Манатов сала. Их!—дип үкенергә генә һәм, уфырып, борынгы бабаларымызның «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар»,—дигән тарихи гыйбарәләрен кабатлыйсы гына кала.

Төзелә алмый кала бу ирекле җөмһүрият.

Инде килеп...

«IX гасырда Башкортостанда...» Башкорт тарихчысы бүген шулай яза. Димәк, аларча шулай килеп чыга: IX гасырда ук Башкортстан дигән дәүләт булган икән. Фәннән ерак кешегә, гади гавамга шушы фикер сеңдерелә.

«IX гасырда Башкортстанда...» Татарстан тарихчысы да шулай яза. Кызганыч ки, бу аңлашылмый. Ул чорда Башкортстан, башкорт дәүләте булганмы соң? Юк, булмаган андый дәүләт. Була да алмаган ул. Башкорт тарихчысы бу төшенчәгә сәяси, геосәяси мәгънә бирсә, татар тарихчысы аңа бары тик географик, төбәк-территория мәгънәсен генә бирә. Әмма шунысы кызык: шул ук татар тарихчысы, гәрчә ул заманда татар-болгар дәүләтчелеге булса да, нишләптер «IX гасырда Татарстанда...» дип язмый. Үзебез теләп эшлибезме без бу хатаны, әллә бездән кемдер эшләтәме? Әллә татар башына урыс кидергән кыршау ирек бирмиме? Татар тарихчысы татар дәүләте турында язарга курыкканда, башкорт тарихчысы авыз тутырып булмаган «Башкортостан дәүләте» турында кычкыра. Менә сезгә татар белән башкорт арасындагы фикерләү аермасы! Казанда университетның «Казанский» дип, Уфадагы университетның «башкирский» дип, Казандагы авыл хуҗалыгы институтының «Казанский» дип, Уфадагыныкы «Башкирский» дип аталуының һәм һәрнәрсәнең шулай тамгалануының арасында татар башына Мәскәүдән киертелгән кыршау һәм бернинди кыршаусыз башкорт башы ята.

Сүз дә юк, башкорт автономиясе, башкорт иреге тарихы—канлы тарих.

Әмма бу шарт куелырга тиешле сораудан азат итми. Рәсәйнең кайсы изелгән милләтенең тарихы канга манчылмаган? Бүгенге Башкортстанда тарихи башкорт җирләре, «тарихи Башкортстан» бармы?

Сүз дә юк—бар. Һәм ул башкортның тарихи җирләре саналган «Урал арты», шуннан алып Тубыл, Иртешләргә кадәр сузылган җәйләүләре саналган җирләр. Башкорт кабиләләренең борын-борынгыдан Болгар патшалыгы, Казан ханлыгы, Алтын Урда берләшмәсе кул астында гомер кичерүе, урыс агрессиясе вакытында Казан камавы эчендә оборона тотуы һәм бу фактның дөнья тарихына кереп калуы күптән билгеле нәрсә. Әлбәттә, башкорт кабиләләре көнбатыш тарафларга да җәйләүгә чыкканнар. Ләкин кеше тыгыз утырган, урыс басып ала килгән көнбатышка мал белән сәяхәт итү инде ул заманнарда ук куркыныч шөгыль булган. Шуңа күрә башкортлар үз көтүлекләрен урыс көнбатышына караганда татар көнчыгышы—Себергә таба киңәйткәннәр. Бу аңлашыла да. Бүген башкортларның Курган өлкәсендә сакланып калулары, әмма шуннан ары китә алмаулары фәнгә мәгълүм нәрсә. Эзләнергә кирәк! Бәлки киткәннәрдер дә. Бәлки әле Тын океан ярларына, Курил, Шикотан утрауларына кадәр барып җиткәннәрдер. Тумышы белән Дүртөйле татары булган Башкортстан халык шагыйре Нәҗар Нәҗми бу тарафларда озак еллар «башкорт бугазын» эзләп, табалмагач, Сахалинга кадәр барып җитеп, үзенең атаклы «Татар бугазы» дигән шигъри китабын да язган иде бит...

Ленин һәм Сталин тарафыннан Башкортстан оештырылганнан соң,

калдык-постык кисәкләрдән корыштырылган бүгенге Татарстан территориясенә кергән чиктәш Азнакай, Актаныш—ягъни элеккеге Минзәлә өязенең археологик-мәдәни катламнарында башкорт катламнарын табу бик шикле шөгыльдер.

Әйе, ул тарихи Башкортстан бар һәм ул мотлакан «Бөлекәй Башкортстан». Менә аның—Зәки Вәлиди үзе шәхсән кул куеп төзегән, оештырган һәм соңыннан кәчләп РСФСР составына кертелгән беренче башкорт дәүләтенең харитәсе. Харитә башкортның атаклы тарихчысы, әйтергә кирәк, чын тарихчысы, тарих фәннәре докторы Билал Юлдашбаев редакциясендә әле ерак 1959 елда чыккан «Образование Башкирской советской социалистической республики» дигән бер мең битлек документлар җыентыгыннан алынды.



Ленин һәм Вәлиди җитәкләгән Башревком белән 1919 ел 20 март килешүе нигезендә барлыкка килгән, өстәргә кирәк, урыс империясе, аның колониаль милләтләре тарихында беренче булып төзелгән бу беренче милли дәүләтчелек өч ел да өч ай—1922 елның 14 июнендә РКП(б) Үзәк Комитеты һәм ВЦИК карары белән Уфа губернасы исәбенә киңәйтелгәнәнә кадәр яши. Башкаласы башкортның тарихи Ватаны—Урал артындагы Баймак калачыгыннан ерак булмаган вулыс үзәге Тәмәс авылы. Бу территориядә тимер юл да, су юлы да, телефон-телеграф та, хәтта бер генә шәһәр дә булмый. Әүвәлдә «Бөлекәй Башкортстанга» Уфа да, Стәрлетамак та керми.

Ленин белән Сталинның яңа гына оешкан «Бөлекәй Башкортстан» дәүләтен курчак урынына уйнатып, РСФСРга куып кертүе һәм башка бик күп «федераль» гаделсезлекләр белән килешмәгән Зәки Вәлиди РСФСР белән килешү нигезендә төзелгән башкорт гаскәрләрен (якынча саны 15 мең—ике дивизия штык һәм атлы гаскәр, штаб начальнигы һәм асылында командующие—күренекле татар милләтчесе И. Алкин) Колчак ягына алып чыга. Әмма, составына башкорт гаскәрләре кергән генерал Дутовның да башкортка мөстәкыйль дәүләт бирергә теләмәүләрен күргәч, киресенчә, башкорт гаскәрләрен коралсызландыра башлагач, Колчакка протест рәвешендә, З. Вәлиди 1919 елның май-август айларында гаскәрләрен совет ягына алып чыга.

Менә 1922 елның 14 июнь килешүе нигезендә, ягъни «Бөлекәй Башкортстан»га кушылачак һәм, ниһаять, кушылган Уфа губернасын да кертеп төзелгән харитә.

Ленин һәм Сталин белән берничә тапкыр күзгә-күз очрашканнан соң, аларның милли сәясәтенең нинди икенлеген һәм нинди булачаклыгын аңлаган, җитмәсә, берничә тапкыр кулга да алынган Зәки Вәлиди үзенә хас гасабилык белән мондый уеннан чыга һәм бер төркем фикердәшләре белән таҗиклар иле аша Персиягә, аннан Төркиягә юл ала—кача.

Ленин—урын өстендә. Булачак диктатор Сталин РСФСРда «беренче булып» оешкан «юлсыз-телефонсыз» Башкортстан автономиясен урыска лояль рәвештә саклап калырга тырыша. Моның бердәнбер юлы—1920 елда тегеннән-моннан корыштырылган, үз тарихи җирләренең биш процентын да алмаган Татар һәм үз тарихи җирләрендә оешкан Башкорт республикалары арасында «хуҗасыз яткан» Уфа губернасын «Бөлекәй Башкортстан»га кушу. Һәм ул шулай килеп тә чыга.

Иң элек «Бәләкәй Башкортстан»ны «телефонлы һәм су юллы» итәбез дип, аңа 1919 елның сентябрендә Стәрлетамакны кушалар һәм ул Башревкомның яңа үзәге дип игълан ителә. 1920 елның 12 августында ВЦИК Стәрлетамак шәһәрен һәм өязен «Бәләкәй Башкортстанга кушу турында» декрет чыгара. (399—409 документлар).

Юк, бирегә беркем дә тоташ татар яшәгән Бөре, Бәләбәй, Уфа өязләрен Башкортстанга кушу турында сүз алып тормый. Чөнки Уфа губернасының бар киләчәген бары тик татар язмышы, яңа оешкан Татарстан белән генә бәйләгән миллион ярым татар крестьяны һәм ике миллионга якын урыс халкы аларны уптым-илаһым «башкортка бирүләрен» күз алдына да китерә алмый.

Менә шуннан соң башлана да инде Сталин җитәкчелегендә шыпырт кына Уфа губернасын «Бәләкәй Башкортстан» кесәсенә салу эпопеясы. *«Образование Большой Башкирии в корне изменяет административные и экономические условия Башреспублики, которая получит свыше миллиона башкир, в настоящее время оторванных от нее, крупный культурно-административный центр—Уфу, большую железнодорожную и водную базу, довольно цельную в промышленно-экономическом отношении территорию (запад—сельскохозяйственный, восток—промышленно-лесной), позволяющую планомерно развивать органическую работу Башреспублики и скоро изжить экономическую разруху...»*—диелә БашЦИК-ның 1921 елның март уртасында ВЦИК-ка суккан телеграммасында.

Күрәсез, телеграмманың теле Мәскәүнеке. Анда этник татарлар «сословный башкорт» буларак күрсәтелә, Дзержинскийлар рухы сизелеп тора.

«Олы Башкортстан» оешу авыр сәяси һәм икътисади шартларда дәвам иткән. Юлдашбаев хезмәтендәге 410-420, 421-460 санлы документлар күрсәтүенчә, эш бик шома гына бармаган. Нинди документны карама, анда «Нет мнения Уфимского губкома». (416 документ) «Нет мнения...» «Нет мнения...» Ә югарыдан күрсәтмә: «завершить до распутицы...» (414 документ). Документларда, бигрәк тә халык күңелендә шул уңайдан булып үткән канлы сәнәк чуалышлары турында риваятьләр сакланган. Менә бу документ нинди вакыйгалар турында сөйли икән? *«Нужно отметить, что некоторая часть населения вновь отходящей территории не понимает этого шага Советской власти, а обывательщина даже склонна рассматривать его как новый шаг оступления...»* (418 документ).

Бүгенге башкорт шовинистлары, татарны нәкъ менә шул милләтнең хәлсезлегеннән, бөлгенлегеннән, яклаучысыз калганлыгыннан файдаланып, башкортлаштырырга тырышкан кебек, ул чактагы сталинчылар да татарга каршы көрәштә, татар автономиясен җирсез һәм милләтсез калдырганда, халыкның авыр хәленнән шулай оста файдаланганнар. Илдә әле генә гражданнар сугышы беткән. Кая карама, ачлык. Бөлгенлек. Җимереклек. Проект буенча «Олы Башкортстан»га Златоуст тау районы, Ырымбур губернасы, Минзәлә өязе кушылырга тиеш була. Менә империя тек, империя!.. Әмма, урындагы хакимиятләр каршы булганлыктан, бу проект төшеп кала.

Үзәк хакимият белән килешү буенча, «Бәләкәй Башкорстан»га кушылу, гадәттәгечә, бөтенхалык референдумына чыгарылырга тиеш була. Әмма ул референдум булмый кала. Халык чуалышлары ГПУ тарафыннан тиз генә бастырыла. Шулай итеп, «башкорт-татар туганлыгы» нигезендә «Олы Башкортстан» төзелә.

Кыскасы, бүгенге Башкортстан һич кенә дә «Башкортстан республикасы» дип атала алмый. Ул татар, урыс һәм башка милләтләрнең җан әзерлеге, рухи рөхсәтеннән башка, мондый чакларда үткәрелергә тиешле халыкара хокукый референдум—халык фикерен исәпкә алмыйча, ихтыярый юл белән төзелгән җирле идарә генә. Татар милләте моның белән беркайчан да килешмәдә һәм килешмәячәк.

Әйе, бүген Башкортстан, татар милләте мәсьәләсеннән чыгып караганда, ике референдум алдында тора. Беренчесе—территориаль мәсләк. «Сез 1922 елда миллион ярым татарның, киңәшсез-нисез, «Зур Башкортстанга» куып кертелүе белән килешәсезме? Сез, «телсез татар» булып, бүгенге

Башкортстан республикасындамы, әллә, «телле татар» булып, иске Уфа губернасында яшәр идегезме?»

Икенче—тел мәсьәләсе. Билгеле булганча, моннан ике ел элек Башкортстан Дәүләт Корылтаеның йөзгә якын депутаты, милләтнең үзе белән киңәшеп тә тормыйча, рәсми расланганынча гына да республика халкының өчтән бер өлешен алып торган татар телен дәүләт теле хокукыннан мәхрүм иткән иде. Бу—сәяси яктан дөрес булмаган адым буларак бәяләнде. Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясы резолюцияләре, халыкара хокук оешмалары кабул иткән документлар дәүләт теле мәсьәләсен бары тик бөтенхалык референдумының гына хәл итә алуын раслый. Димәк, бүгеннән башлап Башкортстан җәмәгатьчелеге республика Дәүләт корылтае кабул иткән «тел турындагы закон»га бойкот игълан итәргә һәм татар теленә дәүләт теле статусы бирү буенча референдумга әзерлек башларга тиеш.

Татар милләте бу көрәшкә Идел-Урал төбәгенең барлык милләттәшләрен, барлык зыялы көчләрен җәлеп итәргә бурычлы. Безнең көрәш телләр турындагы бу дискриминацион законны юкка чыгармыйча, татар теленә тигез хокук яуламыйча туктамаска тиеш.

Республиканың сәяси статусы, исеме—«Татар-Башкорт республикасы» итеп үзгәртелүен тормышка ашыру буенча референдум һәм татар теленең статусы буенча референдумнар икесе бер юлы үткәрелә ала.

Башкорт ягы безне шундый көрәшкә китереп бәйләде. Без егерменче гасыр башында җибәргән ялгышларыбызны төзәтү юлында тарих үзе биргән форсаттан файдаланып калырга тиешбез.

## Без ничәү, йәгъни кисекбаш Сәлимхан закуннары

БЕР КАРАГАНДА, «татар-башкорт мөнәсәбәтләре» дигән тәгъбир бик сәер яңгырый, чөнки бу мәсьәләдән, конкрет хакыйкатьтән ерак торган беркатлы гавамга, мондый «мөнәсәбәтләрнең булуы мөмкин түгел, татар белән башкорт «ике игезәк кавем булганлыктан», бирредә аерымлык, дошманлык өчен бернинди «җирлек юк».

Әмма, әмма...

Хәзерге яшьләр һәм бу мәсьәләдән ерак торуны акыллылык санаган өлкән яшьтәге татар объективистлары да, үткән гасырның соңгы утыз елында Башкортстанда булып үткән фаҗигале вакыйгалар турында белмиләр дә, әлбәттә. Андыйларның исләренә төшереп китү һич тә зыянга булмас кебек. Моңа керешер алдыннан Башкортстандагы этник халәтне әйтеп китү дә урынлы булыр.

1979 елдагы халык санын алу татарны башкортлаштыру кәсафатының котырган чорында һәм басым астында үткәрелгән иде. Көнбатыш Башкортстанның йөзләгән татар авыллары башкорт булып язылган, бер гаиләдә, бер ата-анадан туган балаларның, яшәгән җирләренә карап, берсе татар, берсе башкорт булып теркәлгән очраклары халыкта мәзәк итеп сөйләнелә иде. 1989 елдагы халык санын алу, Горбачев башлаган үзгәртеп кору елларына туры килгәнлектән, Башкортстанда микроимператор Мидхәт Шакиров хакимияте хөкем сөрсә дә, шактый заманча барды. Нәтиҗәдә үткән халык санын алуда җибәрелгән хаталарның күпмедер өлеше төзәтелде, татар милләте ясалма тагылган башкортлыктан кире үз милләтенә кайта алды. Шунысы ачыкланды: республикадагы халыкның 39 проценты (1 млн. 548 мең) урыслар, 28,4 проценты (1 млн, 207 мең) татарлар, 21,9 проценты (863,8 мең) башкортлар. Мин моны якынча гына объектив, әмма анык булмаган күрсәткечләр дип саныйм. Минем уемча, Башкортстанда урыслар 1 миллионнан артмый, артса да, бер миллионга плюс 100-200 меңнән артмый. Минем кебек башкорт итеп язылган кешеләр башкортның кимендә өчтән берен алып торуын исәпләсәк, Башкортстанда иң күп халык—татарлар. Аларның саны ике миллионнан да ким түгелдер. Этник (асаба) башкортларның саны, минемчә, Башкортстанда 300-400 меңнән дә артмыйдыр кебек.

Башкортстанда бүген, соңгы ун елда читтән кайтучыларны да

исәпкә алып, 4 миллион 101,7 мең кеше яши икән. Статистик мәгълүматлар идарәсе хәбәр иткәнчә, соңгы ун елда Башкортстанга 160 мең кеше кайта һәм шул чама китә дә. Кайтучыларның яртысы диярлек этник һәм кайчандыр башкорт язылган татарлар.

Башкортстанда халык санын алу гел генә дә сәяси уенга әйләндерелгәнлектән, анда татарларның һәм башкортларның фәнни-объектив санын ачыклау мөмкин түгел. Бер караганда, халыкның санын алу белән объектив статист-хисапчылар гына шөгыльләнергә тиеш. Башкортстанда халык санын алу ул һәрвакытта да халык санын арттыру шигаре астында бара һәм,—көлсәң-көл, еласаң-ела,—мондый «арттыру»ны башкортчы «тарихчы-галим»нәр алып бара. Бүген халык санын алу уңаеннан Башкортстан матбугатында башланып киткән язмалар ташкынын укыганда, ихтыярсыздан елмаеп куясың. Петр патша заманнарыннан ук башкортны үзләренә күпме кирәк шулай язалар һәм, бу саннарга тәмам ышанып, үзләренә үзләре кул чаба башлыйлар.

Монда юл уңаенда әйтеп китәсе тагын бер фикер бар. Кешелек тарихында милләтләр чәчәк атсын өчен идеаль чорлар булган кебек, милләтнең тарих аренасыннан юкка чыгуы өчен дә идеаль чорлар була. XX гасырның башы (Октябрь түнкәрелешенә кадәр), мәсәлән, татарның чәчәк атуы өчен идеаль ЗАМАН, АЛТЫН ЗАМАН булды. XXI гасыр башын мин, киресенчә, татарга уңай килгән чор дип атамас идем. Барлык факторлар әлегә татарга каршы эшли. Идеаль кире шартлар. Әмма бу милләт бетә дигән сүз түгел. Кем белә, бәлки бу экстремаль шартлар моңа кадәр көлҗемә кебек таркалып барган татар кавемен берләштерер, яңа пьедесталга бастырыр? Амин, шулай була күрсен иде. Ничек кенә булмасын, татар милләте без кергән XXI гасырның беренче чирегендә үзенә карата бик сак, таләпчән булырга тиеш. Әгәр гасырның беренче егерме биш елын хәвефсез үткәреп җибәрсә, алдагы тарихы чагыштырмача куркыныч булмас кебек.

Соңгы ун елда Башкортстанга кайткан (исәпкә алынган һәм алынмаган) ике йөз меңләп кешенең өчтән икесе татар, йә башкорт булып яздырылган татар булганлыктан, андагы татар милләтенең бүгенге саны шактый артты, ул һич кенә дә ике миллионнан ким түгел һәм ул республиканың этник харитәсенең яртысын алып тора, дип ышаныч белән әйтергә мөмкинлек бар. Шуннан чыгып, Мәскәүнең кайбер даирәләренә татарны башкортлаштыру исәбенә башкортның санын арттыру, аңа үзәктән киткән малны, җан башына карап, мулрак бүлү, бертуган татар белән башкортны чәкештерү, дошманлаштыру, шулай итеп, «бүлгәләп хакимлек итү», башкортны көчәйткән булып, татарны көчсезләндерү, аны катнаш никахлар аша башкорттан да, урыстан да талату, аларны ишәйтү сәясәтенең никадәр мөһим икәнлеге, 2002 елда үткәреләчәк халык санын алу кампаниясенең Үзәк тарафыннан гаделсез чарага әйләндереләчәге көн кебек ачык.

Хәзер Башкортстанның илле дүрт районыннан тулаем татар районы дип әйтергә мөмкин булган утызлап районында,—алар арасында башкортчылык афәтенең иң авыр өянәген кабул итәчәк Туймазы, Кушнарен, Бүздәк, Илеш, Дүртөйле, Чакмагыш, Чишмә, Бакалы, Борай, Благовар, Бөре, Тәтешле, Учалы, Шаран, Яңавыл, Бәләбәй, Миякә, Федоровка, Стәрлебаш, Ярмәкәй, Әлшәй, Авыргазы, Краснокама районнарын күрсәтеп үтик,—татарларны ничек башкорт итеп яздыруга әзерлек бара. Уфадан һәр районга, һәр авылга андагы халыкның «башкорт булуын раслау» өчен упалнамучтылмачлар, «галимдар» билгеләнгән. Бүген бу якларның һәр урамы, һәр почмагында халык санын алу буенча инструкторлар эшли. Башкортстанның татар районнары җитәкчеләренә (бригадирга кадәр!) телефоннан шалтыратып булмый. «Барысы да перепись» буенча киңәшмәдә. Мин, менә ничә көн инде, Кушнарен районындагы бер колхоз рәисенә шалтыратам. Хатыны, мескен: «Ул бер атналык азык алып китеп, унбиш чакрымдагы Кушнаренда куна ятып, мишәрләрне ничек итеп «башкорт мишәре» итеп язарга өйрәнә»,—ди. Өйрәнмәсә—капут. Астыннан рәислек урындыгы китәчәк. Балаларына да юл ябылачак.

Мин әлегрәк Кушнарен районындагы юллар буйлап үткән идем.

Анда, район үзәгенә кергәндә, Тукайның «Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем» дигән сүзләре таштактадан яктырып, бар дөньяга күренә иде. Хәзер юк ул. Бетон хәрефләрне ватып, таштакtаны кыргычлап юганнар. Кушнарен районының һәр юл почмагындагыча, анда «Йөшә, Кушнаренко, һинең һәркайза дустарың күп!» кебегрәк мәгънәсез шигарь уеп язылган. Аны саклап, янында алтатарлы милиционер тора. Гомумән, туксан процент мишәр яшәгән Кушнаренның һәр адымы «Йәшәһен Башкортстан» диеп кычкыра. Шунысын белергә иде: юл чатларындагы шундый язуларны бүген Башкортстан милициясенең ничә оперы саклый икән?

Шунысы да игътибарга лаек: башкорт «зиһене» республиканы Мәскәү йөрәгенә бал булып яткан шигарьләр белән ялмап алган. Кая карама, чакырулар: *«Мы за демократический Башкортстан в составе великой России!»*

Бүгенге Башкортстанның никадәр «демократик» икәнлеген сүрәтләү өчен безнең сәләт кенә җитәрлек түгел.

Һәр районда, Баймак, Зилаер якларыннан башкортлар китертеп, «Шәҗәрә» бәйрәмнәре, «Озынкөй» конкурслары, «Башкортлыгыңды беләһеңме?» дигән викториналар үткәрәләр. Районнар арасында татарларны башкорт итеп кем күпме яза алу буенча ярыш ачылган. Ярыш ялкыны көчәйгәннән-көчәя. Җитәкчеләр, әле эшләнгән постларын саклап калу, нәселләре өчен асаба башкортлык льготалары алу максатында, үзләрен, гаиләләрен, нәселләрен башкорт итеп яздырып та куйганнар инде. Татарларны башкорт итеп язу буенча район җитәкчеләре арасында күләме миллион сумнан да ким булмаган махсус премияләр булдырылган. Шул ук вакытта, «Башкортстан» газеты язуынча, башкорт авылларында эчкечелек һәм наркомания чәчәк ата, анда җирләрнең илле процентган артыгы бөтенләй чәчелми кала. Кышка керсәләр, ачка үлмәс өчен, игенне һаман да шул «яман» татар районнарыннан ташыйлар.

Мәскәү татарга каршы булырга дигәндә проблеманы һәм уенга кертерлек «кадрларын» табып кына тора! Рәхимов «эсеп яткан» башкорт вилаятләренә игенне татар районнарыннан ташыса, Мәскәү Кремле хакимияте татарга каршы татарларны барлык ил буйлап Кремльгә ташый. Хәтерегездәме, имлябызны күчерү мәсьәләсендә ул татарча сөйләшә дә белмәгән, моңа кадәр күз күрмәгән, колак ишетмәгән ниндидер Эмма Володарскаяларны эзләп тапты? Хәтерегездәме, Уфа татары Роберт Нигъмәтуллин кебек атаклы популист—Дума депутаты булган татар мөнкортларын ничегрәк татарга каршы өстерде, ә?! Сасы аракы сатып, шуның хакына ике тапкыр Дәүләт Думасы депутаты катыргысын сатып алган һәм Татарстаннан икенче бер депутат Шашурин, ата коммунист Салий белән бергә кичәге колхоз председателе Сәлимхан Әхмәтханов Татарстан суверенитетына, татар теленә, аның язмышы булган имлясына ничегрәк өрде, ә?! Татар милләте боларга исәп алып барырга тиеш! Бервакыт миңа аларны бергә күрергә насыйп булды. Мин ул чакта татардан шундый Дума депутаты булганы өчен түгел, ә Сәлимхан белән бер милләттән булганым өчен үкендем. Хәер, ул бәлки татар түгелдер? Самогонны чөгендердән куа башлап, саф бодайдан кууга кадәр килеп җиткән эволюция юлында татар булып калып булмыйдыр ул?

Ярый, Сәлимхан—сәяси яктан надан булсын, ди. Мин аның хакында исем-фамилиясен бераз гына үзгәртеп, «Депутат Тычканов» дигән хикәя дә язып маташам әле. Роберт Нигъмәтуллин бит самогонщик Сәлимхан түгел, академик, атаклы галим, атаклы популист, кием калыбы кебек матур адәм, шулай да аның да үз милләтенә Дума исеменнән нинди имляда язарга боерык бирергә хокукы юк, шулай да, татарын сатып, барыбер үзеннән дә матур күренә алмас кебек.

Мин бу документлар белән танышканнан соң Сәлимханга хат яздым. Ул җавап бирмәде.

Рәсәй Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты Сәлимхан Әхмәтхановка 2001 елның 5 ноябрендә язылган хатымнан:

*«Мин бу хатымны сезнең, аракы сатып баеган надан бер татар баеның, ничек итеп, нинди очраклы, нинди юллар белән депутат булуыгыз һәм үзегезне, халык сөйләвенчә, Чаллыга кайтканда-киткәндә исерек оргиялар*

*оештыруыгызны, ничек итеп әдәпсез тотуыгызны күрсәтү һәм киләчәктә сезнең бу әшәкелекләрегез бәясез калмаячак дип кисәтү өчен генә язам. Сез онытмагыз: гомер буе депутат булып утыра алмассыз. Сез дә бер килеп безнең туган тарафларыбызга кайтырсыз. Сезгә дә бәлки безнең җылы сүз, ярдәм кирәк булыр. Без бит татар балалары. Сез онытмагыз: кичә генә отставкага киткән һәм бары тик сезнең акчагыз өчен генә сезне уратып алган ФСБ генераллары, марҗа, яһүдә кочагында йоклап генерал һәм адмирал булган «коры җир дингезчеләре»нә ул чакта сез кирәк булмассыз, алар сезне коткара да алмас. Сез өстегездә Ходай Тәгалә һәм Коръән барлыгын онытмасагыз иде...»*

## Милләт каравлары, яки мишәр дә башкорт икән...

БИЛГЕЛЕ БУЛГАНЧА, җитмешенче еллар азагында КПССның Башкортстан өлкә комитеты, халыкның үзе белән киңәшеп-нитеп тормыйча, кайчандыр билгеле бер сәяси шартларда башкорт булып яздырылган этник татар районнарындагы һәм авылларындагы меңгә якын (аларның анык санын беркем белми) мәктәпне, берниндн өзерлексез-нисез, башкорт теленә укытуга күчерткән иде. Чынлыкта ул болайрак килеп чыкты: татар авылларына Уфа педагогик уку йортларыннан берән-сәрән башкорт телен белгән укытучылар җибәргәләштерелде, укытучыларның җитмәгән күпчелеге авылларда кичә генә татар теле һәм әдәбияты укыткан «иске» укытучыларга йөкләнде. Укытучыларның август киңәшмәләре алдыннан курслар оештырылды, кичә генә укучылары белән «исәнмесез!» дип исәнләшкән Габдулла абзыйга иртәгә инде туган татар авылындагы туган мәктәбендә «һаумыһыгыд!» дип исәнләшергә, ә укучы балаларга анасы белән «әсәй» дип сөйләшергә кушылды.

Башкортстанның яртыдан артык байлыгын бар иткән, үз нефте өстендә утырган, иң югары иген уңышы алган, иң югары савым сауган, эшчән, тырыш, әмма рухи түбәнсенү кичергән татар ата-анасы үз баласының йөзенә, күзенә карарга оялды. Ун ел тукмалды безнең халык. Ун ел буе надан калдырылды. Ата-аналар, үзләре дә сизмәстән: «Татары да кирәкми, башкорты да кирәкми, баламны бары тик урысча гына укытам!»—дип, үз теленнән дүндерелгән отышлы юлга бастылар. Башкорт хакимиятенең татар баласын башкортча укытып маташуы бары тик провокация һәм бары тик Мәскәү кушкан заказ гына икәнлеге яхшы аңлашыладыр.

Бу хакта миңа күптән түгел бер хат килде. Ул Чаллыда яшәүче якташым Наил Гомәровтан иде. Баксаң, кайчандыр барлык Башкортстанга билгеле зур татар урта мәктәбе булган Балтай мәктәбен дә башкортча укытуга күчереп азапланганнар икән. Мин моны белми идем әле. Хәзер ул мәктәп юк икән инде. Аны, минем туган Миякә район урта мәктәбе кебек үк, төбе-тамыры белән йолыкканнар.

Наил Гомәров хатыннан берничә юл: «Ана телемә булган мәхәббәтне үзем укыган сигезьеллык мәктәптә дәресләрдән бөек Габдулла Тукай, Һади Такташ, Мәҗит Гафури, Фатих Кәрим, Муса Җәлил һәм башка язучылар әсәрләрен өйрәнгәндә күңелемә салдым. Кешене ана теленнән аерудан да зур җинаять буламы соң, бу бит яңа туган баланы ана сөтеннән аерып, ясалма сөт белән тукландыруга тиң!..»

Сабый башкортча укырга, ата-анасы һәм укытучысы башкортча укытырга теләмәде, татарча укытырга ярамады, татарча укытырга теләгән өчен йөзләрчә, хәтта меңнәрчә ата-аналар, педагоглар, җитәкчеләр эшеннән очырылды, иң мөһиме—балаларын бөтенләй надан калдырмас, аларны һәм үзләрен чиргә сабыштырмас өчен, аптыраган үрдәк кебек, «сиңа да булмасын, миңа да булмасын» дип, балаларын бары тик урысча укытуга күчерү белән килеште. Нәтиҗәдә, гасырлар буе урыслашудан саклана алган татар мәктәбе, «тугандаш башкорт» хакимияте ярдәме белән урыслаштырылды да куелды.

Мәскәү нәкъ менә шуны теләгән иде.

Мәскәү әле дә шуны тели һәм эшли.

Биредә урыс империясе белән башкорт микроимпериясенең максатлары уртак. Татар никадәр аз, кыска гомер яшәсә, тегеләр үзләрен шулкадәр озак яшәячәк дип уйлыйлар. Әмма ялгышалар. Империяләр, бер килеп, барыбер җимерелә.

Кызганыч һәм шунысы фаҗига: Татарстан җәмәгатьчелеге Уфа татарын яклый алмады. Сиксәненче еллар азагы, туксанынчы еллар башында булып алган болганышта Уфа татарларына карата булган телəктәшлектә Казан галим-голамәсе бик соңлап уянды. Аларның беренчеләре Казаннан—тарихчы, әдәбиятчы галимнәр Марат Мөлеков, Дамир Исхаков, Марсель Әхмәтҗанов, Һәнүз Мәхмүтов, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Чаллыдан язучы Вахит Имамов булды. Уфа татары аларның хезмәтләрен мәңге онытмас дип уйлыйм.

Әгеренки Казан һәм Уфа татарларының бердәм фронты оештырылган булса, без элек тә һәм әле дә мондый кыен хәлләргә тарымаган булыр идек. Татар бу юнәлештә хәзер өлгереп җитте, ягъни пешеп өлгерде. Шуңа күрә, яңа, хәзер башланган икенче глобаль башкортлаштыру барышында татарларның бердәм фронт булып хәрәкәт итәчәкләре кирәктер.

Бүген Уфа-Агыйдел буйлары татарларын тәмам башкортлаштыру мөмкинлеге теге заманнарга караганда күпкә киңрәк. Соңгы ун елда моның өчен барлык алшартлар тудырылды. Башкортстан хакимиятенә җитәкчелеккә идеологиясе башка милләтләрне күрә алмаучылык рухы, милли-этник асаба башкортчылыкка нигезләнгән этнократия килде. Гади башкорт малайлары һәм кызлары бүген, кыска вакыт эчендә, башкортчыл милли шовинистик элитага әйләнеп, дәүләт бюджеты, татар түләгән салымныр исәбенә төзелгән коттеджларга күченде, аттан, черек үрәчәле арбадан джипларга менеп атланды. Башкортстанның бар байлыгы, финанс ресурсы шушы аз санлы «яңа башкорттар» кулына әлекте һәм бу байлыклар башка милләтләрне, беренче чиратта, татарны йотуга хезмәткә куелды. Юк, без байлыкларның хезмәт кешесе, хезмәтчел милләт кулына төшкәненә үкенмибез, тар күңеллек күрсәтмибез. Киресенчә, куанабыз гына. Әмма сорау куябыз: нигә моңа татар исәбенә ирешелә? һәм мондый процесс озакка барырмы? Башкортстанда хәзер югары һәм урта урындагы җитәкчеләрне башкортлаштыру процессы төмамланды. Хәзер иң түбән алыштыру бара.

2002 елда халык санын алу буенча Башкортстан хөкүмәте берничә карар кабул итте. Бу мәсьәлә, ягъни татар исәбенә башкортны үрчетү буенча башкорт матбугатында, радио-телевидениесендә көне-төне туктамый торган пропагандистик өмә башланды. Татарлар күпләп яшәгән районнарда Бөтендөнья башкортлары корылтаеның җирле башкарма комитетлары төзелде. Этник (асаба) башкортлар аз булганлыктан, аларның күбесе аумакай сатлык татарлардан оештырылды. Үзләре яшәгән район халыкларының «татар түгел, башкорт» булганлыкларын раслап мәкаләләр чыгару, чыгышлар ясау, күренеп алу өчен җитәкчеләр башкорт газеталарына, радио-телевидениесенә чиратка басты. Башкортстандагы башкортчыл пресс астында татарча чыгып килгән «Кызыл таң», «Өмет» газеталарының, «Тулпар» журналының авызларына су каптырылды. Татарны йоту, татар исәбенә башкортны арттыру кампаниясенең башында тарихчы-археолог, тарих фәннәре докторы Нияз Мәҗитов тора. Бүгенге башкорт матбугаты аның чыгышлары, интервьюлары, мәкаләләре белән тулган.

Башкорт милли корылтае Башкарма комитетының утырышында тоткан нотыгында ул татарны башкортлаштыруның иң нечкә, иң үтемле рецептларын биргән. Аныңча, әйткән идек, мишәрләр, типтәрләр—татар түгел. Алар башкортлар. Көнбатыш Башкортстан татарлары—алар башкортлар. «Шәҗәрәләр шуны раслый», имеш. *«Наукой доказано, что тептяре—особая группа башкирского народа»* дип кенә еффәрә ул. *«Язык северо-западных башкир (татарлар дип аңларга кирәк—А. Х.) башкирскими и татарскими лингвистами рассматривается как особый диалект башкирского языка»,— дип тә кочәнә. «Мы не боимся открытого обсуждения результатов всех переписей, в том числе переписи 1989 г., так как опираемся на тысячи документов, свидетельствующих, что подавляющее большинство населения*

*северных и северо-западных районов Башкортстана являются башкирами...»*— ди ул. Ә «меңләгән документларын» нигәдер күрсәтми. Чөнки юк алар!

Мишәрне татардан аерырга тырышу ак тукымада кара җеп булып ярылып ята. Шул ук «Ватандаш» журналының быелгы февраль санында үзенең хезмәттәше Назыйр Кулбахтин белән берлектә язылган «История башкирских населенных пунктов» дигән мәкаләсендә менә нинди ачышлар ясый ул.

*«... Есть один бесспорный момент: В XIV—XIX веках, даже в первой половине XX века мишари, как самостоятельный народ, жили в Среднем Поволжье, Западнее территории Татарстана».*

Ул бер милләт булган «мишәр» белән «татар»ны ничек кенә булса да чәкештерү өчен барлык көчен куя, әмма бу омтылышлар провокация булудан ары уза алмыйлар: *«Мишари и тептяри Башкортстана уже более двух веков(???) стали неделимой частью башкирского народа»,*—дип тә яза ул.

Әле ул гына җитми: *«Нам ученым Башкортстана пора осознать, что широкие массы мишарей, тептярей Пермской, Свердловской, Челябинской, Курганской, Оренбургской областей и современного Башкортстана давно стали себя считать башкирами и непризнание этого очевидного факта есть искажение объективной истории».*

Сорау туа: мең еллап Касыйм, Мәскәү тирәсе, Ука, Идел буйларында яшәгән мишәр белән шулай ук мең еллап көньяк Уралда яшәгән башкорт ничек ике-өч мең чакрым аша бер халык була алганнар һәм, әгәр булган хәлдә, нигә ике генә гасыр бер милләт булып исәпләнәләр икән? Аңарчы мишәр аерым милләт булган да, ике гасыр элек кенә башкорт белән кушылганмы? Мондый коткы гына җитмәгәч, татарга булган дошманлык күкрәкләренә сыеша алмагач, алар, үзләре дә сизмичә, янәсе, «үзләренең милләттәшләре» булган барлык мишәр кавемен татарга каршы көрәштә мактаган булып, гамәлдә исә мишәр кавемен хыянәтче булуда гаепли, аның тарихи дәрәҗә-абруен төшерә. *«Обращает на себя внимание то, что мишари не входили в состав Казанского ханства, и они одними из первых приняли русское подданство и активно участвовали в наступлении русских против Казанского ханства и взятии Казани в 1552 году. С этого момента мишари становятся опорой Российского государства при проведении восточной политики...»*—дип язалар.

Мәҗитов ишеләр үзенең мең еллык тарихында бөтендөнья сәнгатенә бөек җәүһәрләр биргән, биш гасырга якын империаль коллыкта яшәсә дә, үзеннән дә якын күргән башкорт туганнарына дин, әхлак, әлифба, әдәбият, сәнгать биргән татар туганнарын «изүчеләр» итеп хурларга, таптарга тотына. Сез игътибар гына итегез, Мәҗитовлар менә нәрсә яза: «Башкиры, кипчаки, булгары, финно-угорские народы Урало-Поволжья испытывали на себя общий гнет Золотой Орды, Казанского ханства, Ногайской Орды...» Бәй, шул ук «башкортлар, кыпчаклар, болгарлар» шул ук Алтын Урда халкы—әле күпмилләтле милләт булып яралып килгән төрки тамырлар—уртак генезис булмадылармы икәнни? *«Народы Башкортстана в течение веков вместе боролись против... панисламизма и пантюркизма...» «В течение многих веков народы Башкортстана испытывали на себе политику натравливания друг на друга со стороны золотоордынских и казанских ханов, ногайских мурз...»*—дип тә өстиләр әле.

Үзләренә кирәктә башкортны Казанга буйсынган, татарны үзләренә изүче итеп, кирәкмәгәндә исә, шул ук башкортны Казанга буйсынмаган, татарга бөтенләй катнашы булмаган гына түгел, ә бәлки аңа каршы көрәшкән, татарларны Башкортстанга бары тик урыс чукындыра башлагач кына килгән килмешәкләр итеп күрсәткән башкорт галимнәре, публицистлары нәрсә уйлый икән? Бер генә мисал. Салават Хәмидуллин дигән галимнәре күптән түгел генә менә нәрсә язып чыкты: *«Башкорт ырузарының Рәсәй составына инеү процессы акрынлап барган. Беззең карашка, батша власын тәүгеләрзән булып Кама йылгаһының Казан өлешендә йәшәүсе башкорттар танырга мәжбүр булган. Могайын, Казан воеводаһы П. Шуйскийзың 1557 йылда язып калдырган мәгълүмәте уларга кагылгандыр: «Башкорттар килде.. ясак түләне». 1552 йылда Казан*

*аугандан һуң, Волга буйында 5 йыл буйы «Казан һугышы» дәрләй: Казан ханлыгы гәскәрзәренең исән калган өлөшө урыстарга каршы һугыша. 1557 йылда һугыш тәмамлана һәм Казан өйәзендә йәшәүсе башкорттар батша властен таный. Шуга күрә ошо йыл Башкортстандың Рәсәйгә «ирекле рәвештә» кушылуының рәсми датаһы һанала башлый».* (С. Хәмидуллин. Башкорттар Мәскәүгә кушылганмы?—«Азна».—Өфә.—7 апрель 2002 ел).

«Татарстан яшьләре» газетасында Рәиф Усмановның Нияз Мәҗитов белән әңгәмәсе басылды. Шуннан кечкенә өзек китерик әле. «—1892 елда Минзәлә өязендә генә дә 200.000 башкорт булган. 1921 елда алар Татарстанга кушылган, ә 1926 елда үзләрен 100 процент татар дип күрсәткән,—ди Мәҗитов.

—Аларны да башкортчага өйрәтәчәксезме?

—Башкорт теленә өйрәтергә уебыз юк, ләкин башкорт итәргә уебыз бар. Тел бит ул мөһим түгел, иң мөһиме—рухың белән башкорт булу.

—Кыен булачак бит бу.

—Кыен булачак. Ләкин безнең тукталырга исәп юк. Без аларга объектив мәгълүмат, архив документлары бирергә телибез. Фәлән авыл, фәлән ел, сезнең әби-бабаларыгыз башкорт булган...»

Үзенең көчәнүләрендә ул хәтта көлке хәлгә дә төшеп куйгалый.

Менә ул, мәсәлән, Башкортстан хөкүмәте чыгарган һәм түләүсез таратылган пропагандистик әдәбиятның никадәр «үтемле» булуын романтик буяуларда расларга тырыша. *«Согласно историческим документам, основным населением южных районов Свердловской области являются башкиры, но под влиянием агитации татар значительная их часть в ходе переписи 1989 года записалась татарами. Мы им подарили несколько книг профессора Анвара Асфандиярова «История башкирских населенных пунктов Пермской и Свердловской областей», где излагаются архивные материалы XVIII—XX веков. Активисты Свердловского областного курултая рассказали нам, что люди, прочитав книгу и узнав, кем же они на самом деле являются, плакали от радости».*

Безнең бөтенләй диярлек татарча да, башкортча да укый вә яза белмәгән, төмам урыслашкан, Казаннан һәм Уфадан бер газет-журнал алмаган, еш кына эчкечелектән арына алмаган кешеләр, Әнвәр Әсфәндияр китабын укый да, үзенең татар түгел, башкорт икәнлеген белеп, шатлыктан елый башлый, янәсе.

Күрәләтә ялган, аз да түгел, күп тә түгел, миллэт кадәр миллэтләрне урлау, үзләштерү максатларына нигезләнеп, СССР, Рәсәй тарихында булмаган, ә бәлки дөнья тарихында да сирәк очраган мондый авантюрага барган адымнарның артында нәрсә ята соң? Беренчедән, Мәҗитовлар белә: зур урыс неоимпериализмы шартларында «урысның мәңгелек» дошманы итеп каралган татарның хокуксыз, яклаучысыз калуын аңлагач, моның өчен тарихта иң кулай көннәр килүен сизенеп, туган татарын талый. Әмма алар ялгыша. Татар милләте бүген Брежнев заманындагы татар түгел. Ул да демократиянең түмен белде һәм милләтен алай гына сатмаячак. Шул ук «Ватандаш» журналының 2002 ел гыйнвар санында сәяси фәннәр докторы (башкортта хәзер гел доктор да, гел академик!) Илдус Илишев *«Предстоящая перепись населения: политический аспект»* дигән язмасында менә нәрсәләр бәян итә: *«С морально-психологической точки зрения, уменьшение численности башкирского народа или даже его сохранение на прежнем уровне (Отсутствие прогресса равносильно в данных условиях регрессу) может окончательно деморализовать коренное, автохтонное население (!!!), объективно заинтересованное в укреплении государственности Башкортостана, и в итоге лишит руководство республики надежной социально-политической опоры».*

Күрәсезме, аларга бары «артырга» гына кирәк! Дөньяның бер генә милләте дә «артуның», гафу итегез, көн-төн йокламыйча бала үстерүдән башка юлын белми. Әмма башкортлар курай уйнап, кымыз эчеп яткан арада, милләтне кисәгә салып та арттыралар икән! Күрәсез, милләт аларга хатын-кыз һәм ир-ат арасындагы уртак мәхәббәт нигезендә табигый, Аллаһы Тәгалә рәхмәте нәтиҗәсендә арту түгел, ә башка милләтләр исәбенә—аларны телефон күрсәтмәсе, келәмгә бастырып сугу,

рухи кыйнау-камчылау, кимсетү, куркыту юлы белән арттыру объекты икән!

Хәзер Башкортстанда татарларның «татар түгел, башкорт булулары» турында дистә меңләгән тиражлар белән китаплар, калын-калын монографияләр (мәсәлән, «Законы Российской империи о башкирах», «Атайсал», «Западные башкиры», «История сел и деревень Башкортостана» һәм башкалар) чыга, алар бушка таратыла. Радио-телевидение, ике миллион татарга ярты сәгать вакыт бирмәсә дә, аның татарлыгын инкярь итеп кимсетүгә көненә 18 сәгать вакыт бүлә. Башкорт газета-журналлары берсеннән берсе уздырып, татарга «Һәд башкорт! Һәд башкорт!» дип төкрекләрен чәчә. Алар белән җитәкчелек итү өчен республикада фактик яктан яп-яңа министрлык—милләтара мөнәсәбәтләр һәм мәдәният (?) министрлыгы төзелде.

«Халык исәбен алыуза... өсөнсө—сәйәси бурыс...—дип яза Миңзифа Илтенбаева дигән автор «Башкортостан» газетының 2002 елгы 15 март санында чыккан мәкаләсендә.—... республикабыззың, бигрәк тә көнбатыш төбәктең үзенсәлегенә бәйле, шуга күрә уга айырыуса нескә караш таләп итәлә. Был... тарихи газеллекте тергезеү мәсьәләләрен дә үз эсенә ала... Фундаменталь эш башланды инде...»

«Мин—Илеш башкорто!» дип кычкыра шул ук газет битеннән җирендә бер генә дә этник башкорт булмаган Илеш районының Этәй авылыннан татар кызы Зөлфия Габидуллина. Аңа, бер этник башкорты булмаган Нефтекама шәһәрендә ачылган башкорт педагогия училищесы укучысына, укып чыккач, башкорт хакимиятеннән мәктәп директоры посты кирәк булган («Башкортостан», 7. 02. 2002). «Мин—Сакмагош башкорто!» дип кычкыра газет битеннән бер этник башкорты булмаган Чакмагыш татары—милиция майоры Мозаһит Диләвәров. Ул Башкортстан Эчке Эшләр Министрлыгының Баш тикшерү идарәсендә эшли. Тизрәк полковник буласы килә. Әле шигырьләр дә язып азаплана икән. Әмма чыгара алмый, ди. Башкортстан язучылар берлегенә әгъза булып керәсе килә. «Мин—башкорт!» дип кычкыргач, аңа редакция урынны да мул биргән! («Башкортостан», 29 март, 2002 ел).

«Мин—Яңауыл башкорто!» дип кычкыра газет битеннән татар миллионеры, Яңавыл хакиме Зыязов «туган» («Башкортостан», 29 март 2002 ел). Ул районда, йөз процент этник татар яшәгән төбәктә татар мәктәпләре, татар радиосы-телевидениесе булмаса да, менә, шөкер, башкорт газеты, башкорт телевидениесе эшли башлаган. Мәктәпләрне алдагы ике елда башкорт телендә укуга күчүне тәмамларга дип йөкләмә дә алганнар.

Мондый мисаллар һәр татар районында җитәрлек. Менә тагын берсе.

Татарның бөек Батыршасы чыккан мишәр төбәге Балтач районыннан яңа хәбәр бар. Район хакиме Мәгъзүмов Айрат Муллый угылы күптән түгел район җитәкчеләренең семинарын үткәргән. Мәгъзүмов кардәшемез барлык районга яңгыратырга мәҗбүр иткән: «Безнең Балтачта сиксән процент башкорт! Безнең Балтачта сиксән процент башкорт!»

Хәзер Балтач районы газеты-радиосы шуны гына тәкърарлый ди.

Бер үк вакытта башкорт эмиссарлары авылдан-авылга, районнан-районга халыкны куркытып, куып йөри. Җыялар районнарда ата-аналар конгрессын. «Карагыз аны,—диләр.—Әгәр башкорт дип язылмасагыз, бүген мәктәптә укып йөргән балаларыгыз Башкортстан вузларына керә алмаячак! Менә безнең кулда Уфа вузларында укучы сезнең район студентлары исемлеге. Сезнең балаларыгыз. Карагыз аны, әгәр башкорт дип язылмасагыз, алар вузлардан куылачак!».

Бер гаепсез ата-ана зар җылый. Авылдан кая качарга белми...

*«Это, безусловно, результат мудрой национальной политики, которую проводит руководство суверенной республики в последние 10 лет»*,—дип яза мондый адымнар турында шул ук телгә алынган Нияз Мәҗитов белән Нәзир Кулбахтин. («История башкирских населенных пунктов», «Ватандаш», 1, 2002).

«Ватандаш» журналы быелның беренче санында Бөтендөнья Башкорт корылтае Башкарма комитеты утырышының резолюциясен бастырып чыгарды.

Сез андагы «геополитик глобальлеккә» игътибар итегез:

*«... Разработать комплексный план подготовки к предстоящей в 2002 году переписи населения РФ и добиться его претворения в жизнь, предусмотрев:*

*широкую пропаганду среди населения об общественно-политическом значении этой кампании;*

*необходимость массовой разъяснительной работы итогов состоявщихся в XVIII—XX веках переписей населения, отражающих этнокультурную историю Башкирского народа, а также методов и критериев определения национальной принадлежности;*

*рекомендации в этих целях: повсеместно провести районные, городские, областные курултаи, конференции, вечера, праздники «Шеҗере» и другие мероприятия;*

*публикацию в районных и городских газетах, а также в виде брошюр, материалов об итогах переписей населения XVIII—XX вв. по башкирским деревням;*

*сбор и публикацию материалов по этнической истории башкир Мензелинского края, Пермской, Свердловской, Челябинской, Курганской, Оренбургской, Самарской, Саратовской областей...»*

*Һәм шунда ук: ... приостановить бесконтрольную миграцию в РБ жителей из стран ближнего зарубежья...»*

Монысы инде якындагы еллардән кайтучы татарларны, әгәр алар башкорт булып язылмыйлар икән, андый «манкортларны» кертмәскә дигән сүз...

Башкортстанның ярты халкын алып торган, төп табигый байлыкларының, бу җирләрнең—Днепр ярларыннан Алтайларга кадәр—Һун бабайлар заманнарыннан, Болгар, Казан патшалыклары, Алтын Урда чорларыннан алып чын тарих хуҗасы булган һәм республиканың 100 процент нефтен чыгарган, 80 процент игенен, маен, итен җитештергән, Уфа, Стәрлетамак, Салават, Ишембай, Нефтекам, Октябрьский, Дүртөйле һ. б. калаларның төп халкын тәшкил иткән, андагы барлык милли байлыкларны бар иткән, әмма хәзер телсез, мәктәпсез, сәнгатьсез калдырылган татарлар бүген бары тик ишек шикелле эшләргә һәм эшләргә генә тиешме икән?!

Үзәккә куелган темаларны тикшергәндә тагын бер ачыклап китәсе нәрсә бар. Ул да булса, ике арадагы «мөнәсәбәтләр». Бар идеме татар белән башкорт арасында мондый «мөнәсәбәтләр?»

Юк иде. Чөнки аның өчен татар халкы башкорт халкына бернинди җирлек тә бирмәде. Киресенчә, башкортны үзенә иң якын кавем санап, ул аны үз бишегендә тирбәтеп үстерде һәм укытты. Татар бер генә кавемгә дә башкортка ярдәм иткән кебек ярдәм итмәде. Ул аны дәүләтле, әлифбалы итте, сәхнәгә күтәрде, кулына каләм белән китап тоттырды. Бүгенге башкорт яңарышының, тормыш ихтыяҗының кайсы гына тармакларын алсаң да, анда уңышларның хәлиткеч өлеше татар илтифаты белән барлыкка китерелүен тану авыр түгел. Бүген башкорт халкы, әгәр ул тарихи дөреслеккә тугры икән, үзен аякка бастыручы татарга һәр шәһәрендә һәйкәл куярга тиеш.

Башкортларның Болгар, Казан ханлыклары заманнарыннан татар биләмәләре эчендә протекторат рәвешендә яшәгән чорлардан ук башкорт халык телендә дә, татар халык телендә дә, авыз иҗатында да татар-башкорт дошманлыгы турында бер генә кәлимә сүз дә сакланмаган.

Сорау туа: әгәр башкорт кабиләләре татар ханлыклары кул астында яшәмәгән булса, алар Болгар, Казаннарны яклап сугышкан булырлар идеме? Әгәр Казан татарлары Агыйдел-Урал буйларында бары тик XVII-XVIII гасырларда, ягъни чукындыру чәчәк аткан чорларда гына күренә башлаган булсалар, башкортлар 1552 елгы һәлакәттә Казанны якларга килгән булыр иде микән?

Бүген исә, Мәҗитов кебек тарихчылар Мәскәүдән күбрәк ирек яулау хисабына татарны хурлый, 1552 елда башкортларның Казан кремлен татарлар белән бергә саклаудан баш тартып, аны калдырып чыгып китүләре белән горурлана... Кан эчендә яткан бертуганнарыңа, үзеңә әлифба һәм Коръән биргән кардәшеңә хыянәт итү белән

горурлану һәм барлык милләтне—яшь буынны шул рухта тәрбияләү... Нәрсә соң бу?!

Кабатлап әйтәм, булмаган мондый дошманлык мөнәсәбәтләре. Татарның башкорт өстеннән протектораты да формаль төстә генә булган. Җаек белән Иртеш арасында җәйләгән-кышлаган, «үз боеручысы» татарга караганда, казакъны һәм калмыкны күбрәк белгән, күбрәк алар белән мәш килгән башкортка караганда, Казан татары Мәскәү урысларын күбрәк белгән һәм шуны мөһимрәк санаган. Идел төркие—болгар-татарның X-XX гасырлар арасында барлык төрки мөселман дөньясы алдында зур казанышы бар: гәрчә бүген кайбер башкорт галимнәре моны «татар гаепләре» исемлегенә кертсә дә, ул—мәҗүси башкортларны мөселман диненә күндерү.

Алда әйткәнебезчә, Башкортстан дигән дәүләт бары тик 1919 елда гына барлыкка килә. XX гасырда 1919 елдан «Бәләкәй Башкортстан республикасы», 1922 елдан Сталин аңа Уфа губернасын да кушканнан соң, «Олы Башкортстан республикасы» дип атала башлаган бу Урал алды-Агыйдел буе төбәкләрендәге башкорт милләтчелеге өч чор үтә: беренче чор—1917—1930; икенче чор—1953—1988; өченче чор исә бүгенге көнгә кадәр елларны тәшкил итә.

Әлеге Башкортстан составына кертелгән, гомер-гомердән Уфа губернасында яшәгән саны ике миллионга җиткән татар милләтен соңгы утыз елда инде икенче тапкыр башкортлаштырырга омтылу ифрат дәрәҗәдә фаҗигале хәл.

Беренче башкортлаштыру чорында җибәрелгән хаталарны һич кенә дә кабатларга теләмәгән яңа башкорт түрәлеге, хакимияткә килгәч, мондый кара эшкә керешер алдыннан тирә-ягына каранды. Әйе, теге чорлардан аермалы буларак, бүген байтак хәлиткеч алшартлар бар иде.

Хәзер шул алшартларга тәфсилләбрәк тукталып китик.

Игълан ителгән Конституция һәм суверенитет нигезендә, барлык җир асты һәм җир өсте байлыклары урындагы хакимият, «халык кулында», ягъни, титуллы башкорт кулында дип игълан ителде.

Башкортстан суверенитеты үзенең беренче көннәреннән үк этнократик хакимият төзүгә юнәлеш алды. Башкорт милли хәрәкәте белән башкортның хакими элитасы бербөтен симбиоз булып укмашты. Аның нигезенә төп идеологик өскормә булып иҗтимагый паразитаризм идеясе ятты.

Башкорт милли хәрәкәте, «татарның урыска гел гамәли каршылыкта булуы, шуңа күрә урысның Казанны җимерүе, ә менә башкортның урыска үз теләге белән кушылуы» дигән сүзләрне оста файдаланып, Ельциннан Башкортстан-Рәсәй Килешүенә өстәмә рәвештә «Башкортстанның төп байлыгы—башкорт халкы, Башкортстанда яшәгән барча милләтләрнең бурычы—арыган, таушалган башкорт милләтен аякка бастырырга ярдәм итү» дип язылган документларга кул куйдыра алды. Туксанынчы еллар башында Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимовның, Федератив Килешүгә кул куймыйча тарткалашып йөргәннән соң, бу тантаналы процедурага нибары җиде минут калгач, Ельцин кабинетыннан елмаеп чыгып, башка автономия җитәкчеләре белән бергә Килешүгә кул куюының төп сере менә шунда иде.

Уфада узган гасырның туксанынчы елларында ук башланган яңа башкортлаштыруга Казан җәмәгатьчелеге, татар интеллигенциясе күз йомды. Авызына су капты.

Казан татарларын йоклатыр өчен, Уфа хакимияте Башкортстан белән Татарстан арасында мәдәният, мәгърифәт мәсьәләләре буенча 1996 елда Яңавылда кул куелган республикаара Килешүдә тагын бер җиңүгә иреште. Анда ике якның да матбугатында милли мәсьәләләрне яктыртуга рәсми булмаган тыю салынды. Имеш. Әмма ул Уфа өчен генә «имеш» иде. Казан өчен мотлак, ягъни «обязательный» булып чыкты. Әйтик, Уфада синең милләтеңне изәләр, әмма Казан түзә, син, җаның әрнеп, мәкаләләр язган буласың, әмма «интернациональлеккә тугры» Казан аны бастырмый, чөнки Килешү буенча ярамый. Уфа исә, Тукайның таз малае кебек, берничә карамый үзенекен итә—радиодан, телевидениедән,

газет-журналлардан көне буе сеңдерәләр: «Һин башкорт, башкорт, башкорт... Татар тегеләй, татар былай...»

Татарлар исәбенә баю, ныгу, чәчәк ату һ. б. теләкләргә нигезләнгән этнократик Башкорт дәүләтен төзү алшартларының берсе—фәнни галимнәр армиясен булдыру иде. Бу профессиональ алдакчылар милләт кадәр милләтне татарга каршы котыртып, татарның милләт буларак «юклыгын, беткәнлеген» раслап, барлык төрки-татар мирасын башкортныкы дип игълан итеп кенә калмады, Башкорт милли горурлыгын дәүләт дәрәҗәсендәге ихтыяҗга күтәреп, шумер, грек, юнан мәдәниятләрен дә үзләре нигезләгән мирас итеп игълан кылдылар. Кыскасы—Атилла (Ат иле)—Башкорт булган! Башкортлар—һуннар алар! Көлмәгез, Башкорт Академия театры «Атилла» дигән спектакль дә куячак икән!

Милләт кадәр милләтне яңадан башкортлаштыруга керешү өчен иң элек үзәктәге һәм урыннардагы хакимиятне башкортлаштырырга кирәк иде.

Димәк, алда «кадрлар» мәсьәләсен хәл итү бурычы тора иде... Бездә, беләсез, «Кадрлар барысын да хәл итә».

Сталин бабайның диктаторларга калдырган иң бөек васыятьләреннән берсе бу.

Совет властенең СССР таркалганчы сиксән өч елы эчендә Башкортстанда партия, дәүләт һәм хөкүмәт башында, алтмышынчы-җитмешенче елларда Министрлар Советы рәисе булып эшләгән Акназаровны исәпләмәгәндә, бер генә тапкыр да саф башкорт кешесе утыра алмады. Бу хәл, әлбәттә, башкорт зыялыларын бик тә борчыды һәм бу борчылу бер яктан караганда аңлашыла да иде. Ниһаять, Башкортстан тарихында беренче тапкыр аның җитәкчелегенә милләте ягыннан саф, этник башкорт килде һәм ул шулай ук тарихта беренче тапкыр республикадагы югары, урта, түбән урындагы хакимиятне, ул төбәкләрдә нинди милләт яшәвенә карамастан, башкортның туган-тумачалык этнократиясе—«агайлык» принцибына күчерүне бурыч итеп куйды. 1919 елдан башлап, башкортлар Башкортстандагы гомум халык санының биштән берен дә алып тормавы һәм, халыкның социаль-мәдәни өзерлеге түбән булганга күрә, җитәкчелектә башкортлар азчылыкны тәшкил итеп килде.

Башкортстанда әлеге этнократик җитәкчелек, хакимияткә килү белән, урындагы җитәкчелекне милләтчел рухта башкортлаштыра башлады.

Әйе, Башкортстанда кадрларны милли принциптан торып чистарту һәм башкортлаштыру—алда торган иң зур һәм иң беренче проблема иде. Әгәр сиксәненче елларда эре җитәкче кадрлар арасында өч татар, бер-ике урыс аша бер башкорт булса, туксанынчы елларда ул биш башкорт, бер урыс аша бер татар, хәзер инде, урынына карап, ун башкорт, ике урыс аша бер татар нисбәтендә тора.

Кадрларны татарлар һәм башка милләтләр исәбенә башкортлаштыру, яисә аларны башкортчылык идеясенә тугры булырга ант эчкән татар һәм урыслар белән алыштыру ун елга исәпләнгән булса да, бу бурыч өченче мең еллык башына тәмамланып өлгермәде. «Процесс» әле дәвам итә. Хәзер башкортлаштыруның башка рычаглары да хәрәкәткә китерелеп, моның өчен иң уңай шартлар барлыкка килде. Туксанынчы еллар башында бу нәрсә җәмәгатьчелекне бик тә борчый иде. Хәзер инде җәмәгатьчелек «арыды». Урта баскычтагы татар җитәкчелеге башкортлаштыру белән «килеште»: һәркемгә эш урыны, гаиләсенең, балаларының киләчәге кадерле.

Татар милләтен икенче тапкыр глобаль башкортлаштырырга омтылып караучылар беренче омтылыштагы ялгышларын кабатламаска тырышалар. Әгәр алар беренче омтылышларында татар мәктәпләрен башкорт телендә укытуга үз укытучыларын әзерләмәгән килеш тотынган һәм «ашыгып, ашка пешкән» булсалар, бу юлы алар 1991 елдан башлап, университетның һәм педагогия университетының филология факультетларын киңәйтеп, шуларга өстәп, берничә яңа педагогия университеты һәм училищесы ачып, татар авылларына якындагы елларда «десант» төшерү өчен меңләгән башкорт теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләп өлгерделәр.

Татар авылларындагы, шәһәр, район үзәкләре, поселок, бистә

мәктәпләрендә әле исем өчен генә татар телен, әдәбиятын өйрәнеп маташкан сыйныфларны тулы циклдагы башкорт сыйныфлары, мәктәпләре, йә булмаса башкорт теле һәм әдәбиятын өйрәнүче сыйныфлар, мәктәпләр итеп үзгәртеп җибәрү бүген Уфа номенклатурасы өчен берни дә тормый.

Моның өчен аларга барлык шартлар да бар. Башкортстан җитәкчелеге бүген Казанны йоклату өчен зур саннар куллана. Имеш, Башкортстанда бүген мең чамасы татар мәктәбе бар икән. Алданмыйк. Бүген Башкортстанда укыту беренче сыйныфтан унынчыга кадәр түгел, хәтта беренчедән бишенче сыйныфларга кадәр дә туган телендә алып барылган бер генә татар милли мәктәбе дә юк. Әйтик, татар авылындагы мәктәпнең өч сыйныфы иң җылы бүлмәләрдә, «кызык өчен генә» башкорт теле өйрәнә. Калган сыйныфлар салкын, түшәменнән су үткән бүлмәләрдә татар теле өйрәнә. Башкортстан Мәгариф министрлыгындагы исемлектә мондый мәктәпләр «татар мәктәбе» дип аталса да, алар барысы да диярлек Гогольнең «үле җаннарын» хәтерләтә. Татарстан Мәгариф министрлыгы, татар халкының киләчәге белән бераз гына булса да кызыксынса, Рәсәй Федерациясе Мәгариф министрлыгы белән берлектә Башкортстандагы «татар мәктәпләренең» милли мәктәпләр статусына туры килүен ачыкларга тиеш.

«Демократия»нең ун елында башкорт этнократиясе башкорт балалары өчен йөзгә якын сигезьеллык һәм урта мәктәп, гимназия ачса, республика халкының яртысын алып торган татарга бер генә яңа мәктәп тә ачмады һәм яңа бина да төземәде. Уфа мәсьәләләреннән бераз гына хәбәрдар кеше, бәлки, татар гимназиясе Уфаның Черниковка өлешендә һәм Бәләбәйдә бар бит, дияр. Шәһәр читендә, тиешле шартлары, әсбаплары булмаган, татар теле уен өчен бары тик «компонент» булып кына кергән, нибары ике йөз чамасы бала укып азапланган, асылында исә урыс мәктәбе булып калуын дәвам иткән мәктәпне без татар мәктәбе дип әйтә алмыйбыз. Бәләбәйгә килсәк, анда Башкортстан мәгариф министрлыгының беркайчан да татар гимназиясе ачканы булмады. Татар милләте, татар милли хәрәкәте мәгърифәтчесе Н. Хөсәенов җитәкчелегендәге бер төркем педагогларның ничә ел көрәшеп куйган тырышлыклары, Бәләбәй шәһәр советы кургән кайгырту нәтиҗәсендә ачылган мәктәпне Башкортстан Мәгариф министрлыгы бары тик фактик күзәтү астына гына алды һәм беренче көненнән үк аны яптыру өчен хезмәт күрсәтә башлады. Инде ун елга якын уңышлы эшләп килүенә карамастан, аңа министрлык иҗади ирек бирми, туктаусыз тикшерүләр, төрле жалулар оештыртып, мәктәп директорын хөкем юлыннан кайтармый.

Моннан ун ел чамасы элек яңадан ачылган Кушнарен татар педагогия училищесы белән дә шулай булган иде. Ябу белән куркытып, жалу арты жалу өлгертеп, бер этник башкорт та булмаган Көнбатыш Башкортстан районнары өчен укытучылар әзерләгән Кушнарен педагогия училищесында, көчәнә-көчәнә булса да, башкорт бүлекләре ачтырдылар. Соңгы елларда, мин бер-ике тапкыр кереп чыкканнан соң, бер дә тавыштыны юк, әллә яптырдылар инде?

Укучы дөрес аңласын, башкорт бүлекләренә без һич кенә дә каршы түгел, алар хәт Америкада ачылсын, без аңа куанабыз гына—сүз бирердә килешеп, сыешып тыныч яшисе урында милләтара психоз куптару, шом белән куркытып яшәтү турында гына бара.

Бәлки, безгә татар баласын башкортча укытканга борчылмаска, куанырга гына кирәктер? Ни өчен дигәндә, шактый факторлар уңай кебек: беренчедән, Казанның башка республика, өлкә, губерналардагы татар балаларын туган телендә укытуны юлга салу өчен башкорттагы кебек теләге дә, ярдәм күрсәтерлек финансы да юк, кадрлары да җитешми; икенчедән, башкорт теле шул ук төрки тел, татар баласын төрки телдән бөтенләй мәхрүм калдырганчы, аларны Башкортстан биргән финанс, кадрлар, мәктәп биналары һ. б. матди байлыкларын файдаланып, башкорт телендә укыту яхшырактыр; өченчедән, бәлки, башкортча укыган бу балаларны өйдә без—ата-аналар татар телендә, татар әдәбияты, мәдәнияте рухында тәрбияләп, әхлаксызлык сазлыгыннан коткарып калырга кирәктер?

Әмма сорау туа: күпме татар ата-анасы моңа әзер? Бик азлар гына әзер.

Егерменче гасырда «туксан җиде» процентын татар Шәехзадә Бабич, Мәҗит Гафури, Сәйфи Кудаш, Гариф Гомәр, Имай Насыйри, Мостай Кәрим, Динис Исламов, Нәҗар Нәҗми, Әнгам Атнабаев һәм башкалар тудырган башкорт әдәбияты хәзер кабатланмас биеклекләр булып калды.

Әмма балаларыбыз, башкорт телендә укыган хәлдә, бозылып, гарипләнеп булса да, ата-анасы белән туган телендә китап укый, хат яза, сәнгатьне аңлый алачак.

## Галимҗанга бер тиен дә, Килдеголга биш тиен

КАДРЛАРНЫ башкортлаштыру үзеннән-үзе финанс агымының үзгәрүе белән янәшә алып барылды.

Татар районннары белән башкорт районнарын капма-каршы чәкештереп, булмаганны бар итеп, коткы тарату, халыкның иҗтимагый аңына агу салу һәм шуның нәтиҗәсендә икътисади потенциалны бүлешүдә бер генә якка чалышаю өчен нигез сиксәненче еллар уртасында ук салынган иде.

Ягъни мәсәлән, үзгәреш җилләре исә башлагач та, сиксәненче еллар уртасында башкорт газетлары, имештер ки, «җитәкчелектә татарлар гына утырганлыктан, татар районнарына акча күп бүленде, шуның нәтиҗәсендә алар алга китте, башкорт районнары исә артка калды» дигән коткыны очырып җибәрде. Аннан бу коткыны радио-телевидение күтәреп алды, аннан аны рәсми җитәкчеләр халык теленә күчерделәр.

Туксанынчы еллар башыннан, башкорт районнарын социаль тернәкләндерү турында махсус карарлар кабул ителеп, финанс агымы башкорт районнарына бермә-бер арттырылып, татар районнарына бермә-бер киметелде, йәки иске дәрәҗәдә калды. Бер караганда, монда бернинди үкенерлек нәрсә юк кебек. Башкорт туганнарыбызның яхшы яшәвенә кем куанмый?! Тик ул башкалар исәбенә, башканың тиене, бәхетсезлеге исәбенә генә булмасын.

Башкортстанның башкортлар яшәгән тау районнарындагы уңай үзгәрешләрне күреп, күңел куана. Башкортстанның татар районнарындагы ташланганлыкны, аларның башкалар белән тигез яшәмәвен, рәнҗетелүен күреп, күңел әрни.

Ике төп милләтнең болай капма-каршы куелуы яхшыга китерми һәм китермәячәк.

Финанс агымын милләтенә карап бүлүдәге тигезсезлек дәвам итә. Моны тикшереп, хөкемгә тапшырыр егетләребез, кызларыбыз бар микән, булмаса, кайчан туарлар икән, әгәр татар мәктәпләре булдырмасак, алар, гомумән, бер килеп туар микән?

## Без—Мумулар күпме?

БАШКОРТСТАН парламенты тарафыннан кабул ителгән «Дәүләт телләре турындагы Закон»га да тукталып узыйк әле.

Башкортстандагы өч иң зур халыкның—сан ягыннан караганда иң күбе булган татар, урыс, башкортларның бары тик икесе—башкорт һәм урыс теле генә дәүләт теле итеп кабул ителде.

Ул «закон» законлы, ягъни легитим түгел. Сез, бәлки, ни өчен законсыз диеп әйтерсез? Ә менә ни өчен. Халыкара хокуклар нигезендә тел мәсьәләсе, бигрәк тә Башкортстанда күпчелекне, халыкның утыз процентын, чынында исә аңардан да артыгын алып торган татар халкының тел статусын бары тик халык референдумы гына хәл итә ала. Сез карагыз: ике миллион халык!

Менә шул «закон» нигезендә ике миллион татарны Муму ясадылар. Хәтерлисезме, урыслашкан татар Тургеневның «Муму» повестен? Мескен

Герасимны? Ике миллион Башкортстан татары нәкъ менә шул Муму—Герасим булып телсез калды.

Демократия этнократия белән алыштырылган, коллектив җитәкчелек дигән нәрсә бер кеше диктатурасына әйләнгән, һәркем үз тәне, эш урыны өчен калтыранып торган бу шартларда миллət беркемдә дә ышаныч күрми. Безгә аның канатын сындырмаска иде. Миллət—барлык байлыкның иҗатчысы. Милләтнең авызына гына карап торырга кирәк—ул бервакытта да гаделсезне якламый. Әмма гаделлекне яклау бу заманда бик авыр.

Кадрларны башкортлаштырып, милли-социаль климатны яклаучысыз итү, мәктәпләрне башкортча укытуга күчерү, радио-телевидениене бары тик башкорт телендә һәм башкорт бөеклеге турында гына сөйләтү, башкорт телен дәүләт теле итеп кабул итү, татар телен икенче сортлы тел итеп, кулланудан чыгарып ыргыту һәм башкалар—болар барысы да татар кешесенең миллилек канатын сындыралар. Татар коралсызландырыла. Ул төшенкелеккә бирелә. Төшенкелек җәмгыятьне, әгәр ул үзен тотып торучы ислам диненә кире кайтып өлгермәгән, үзен яклау нормативын тудырып өлгермәгән булса, эчкечелек, наркомания һәм башка төрле чирләргә китерә.

Димәк, Башкортстан татарының телен саклау, ул аның үз телендә сөйләшү-аңлашу, сәнгать аша аралашу һ. б. хокукы гына түгел, ә бәлки милләтнең физиологик тазалыгын, биологик фактурасын саклау хокукы да.

Бүген Башкортстандагы татар халкына карата бәяләп бетергесез дәрәҗәдә мораль, психологик яра салына, физиологик, матди һәм икътисади зыян китерелә.

Берләшкән Милләтләр Оешмасының халыкара топонимия һәм картография нормаларын бозуны алдан кисәтү һәм моның өчен җавапка тарттыру турындагы резолюциясе нигезендә кайсыдыр милләтнең җирле тарихи топонимиясен беркем дә, берничек тә үзгәртә алмый. Моны бары тик халыкара оешмалар гына эшли ала. Рөхсәтсез эшләгән хәлдә, бу канунны бозган көчләр миллион долларлар күләмендә штраф түләргә тиеш. Әйтик, әгәр дә син ниндидер һәм кем өчендер «әйтүе уңайсыз булган» Мбабетанаририве исемен «Зәңгәр кыя»га үзгәртәсең килә икән, башта БМО ның халыкара картография комитетына мөрәҗәгать ит, миллион долларлар түлә, әгәр рөхсәт булса—үзгәрт. Ә безнең папуаслар беркемнән берни дә рөхсәт сорап тормыйлар, птамушты—«позади Москва».

Менә сез Татарстан ягыннан Башкортстанга кереп киләсез. Кайсы яктан гына керсәгез дә, монда сез барлык Башкортстан буенча үтсәгез дә, мең татар авылы аша үтеп, бер башкорт авылын очратмаячаксыз. Чөнки ул юк. Әмма Башкортстан ягына каратып, орденнар да төшереп, яңа буяуларга буятып, унар метрлы баганаларга язып куелган: «Башкортостан республикаһы».

Мин быел да Башкортстанда булып килдем. Андагы үзгәрешләргә таңнар калдым. Әле күптән түгел генә Кушнарен, Дүртөйле, Чакмагыш якларында, берән-сәрән булса да, исән-сау торган татарча язулар, күрсәткечләр, чакыруларның берсе дә юк. Барысы да башкортча.

Актаныш ягыннан керәсеңме, Бакалы ягыннанмы, әллә Яңавыл, Октябрьский тарафыннанмы, һәркайда—татар, татар тормышы, татар теле, татар авыллары... Әмма ул кинәттән генә Башкортстанда ниндидер «итальян»га әйләнә дә куя. Безнең Президентыбыз Минтимер Шәймиев, күрше Актаныш егете, безнең Парламентыбыз рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, күрше Әлмәт егете, алар бу тамашаларны карап туймадылар микәнни?

Менә без Актаныш ягыннан «Башкортстан» дип аталган сөер республиканың халкы йөз процент татар булган Илеш районына килеп керәбез. Андагы башкортча һәм урысча язылган шигарьләр шаккатыра: «һаумы, Илешем, тыуган якка кайтып килешем!» «Да здравствует Россия—великая держава!» Менә тагын бер шигарь: «Яшәһен үзаллы Башкортостан республикаһы!» «Үзаллы» дигән төгъбирне укып, мин елмаеп куям. Юк башкортта андый сүз. «Үзаллы» дигән ясалма сүз Уфада чагымда минем күз алдымда ясалды. «Мөстәкыйльлек» татарча була дип, урысның «самостоятельный» сүзеннән үлек калька итеп тәрҗемә иттеләр аны.

Илешкә без беренче татар авылы Җәйләү аша керәбез. Нинди гүзәл, нинди сөйкемле авыл ул Җәйләү! Исеме генә дә җырлап тора. Җәйләү кешесе үзен татар итеп саклап калу өчен ни эшли ала икән? Сез үзегезне аның урынына куярга тырышыгыз әле. Тирә-якта татар табигате. Татар нефтен суырган урыс һәм башкорт мәтәлчекләре. Татар авылы. Татар кешеләре. Татар балалары. Алар өйдә «әти-әни» ди, мәктәптә кем өчендер «атай-әсәй» ди. Юл аша гына татарның үзеге—Татарстан...

Юл буе атамалары башкортлаштырылганнан соң мин инде Башкортстанны ничә тапкыр аркылы-буйга гизеп чыктым икән. Башкортстанны кичеп, Свердлауга кадәр дә үттем. Мондагы әкәмәтләрне сөйләп аңлатырлык кына түгел. Шундый фикер туа: бередә юл топонимиясен үзгәртү комиссиясенә кергән башкорт телчеләренең «Теләсә нәрсә язарга ярый, тик татарса гына булмаһын» дип эшләгәнлекләре көн кебек ачык. Атаклы «Атсөяр» бередә «Атһуар—Атхуяр»га әйләнгән.

Мондый көлке һәм фаҗигале мисалларны йөзләрчә китерергә мөмкин.

1912 елның җәендә бөек шагыйребез Габдулла Тукай Уфага килә. Үзенең көндәлекләрендә язуынча, ул Уфада бер чын башкортны күрә алмавына үкенә, башкорт җыруларының аһәңе киләчәктә олугъ милли сәнгатькә алып килсен иде диген ышаныч белдерә. Ул Мәҗит Гафури белән очрашуны көтеп, «Сабах» китап кибетенең складында бераз «черем итеп» тә ала.

1996 ел. Уфа. Башкортстанның, Уфаның татар җәмәгатьчелеге Тукайның тууына 110 еллык уңаеннан (моның өчен дистә еллар көрәшкәннән соң), ниһаять, «Сабах» китап кибете бинасының диварына Тукайның 1912 елда Уфада булуы хөрмәтенә истәлекле таштакта куйдыруга иреште. Уфада ул чакта хакимияттә «үз татарларымыз» иде. Күпме генә тырышсак та, барыбер безгә таштактага текстны татарча язарга рөхсәт итмәделәр... Сез күз алдыгызга гына китерегез, әгәр китерә алсагыз... 400 мең татар яшәгән Уфада... ике миллион татар яшәгән «республиканың» башкаласында... хакимияттә «үз татарларымыз» утырган заманнарда...

Юк, бу вакыйга шулай тавышсыз-тынсыз гына үтеп китте. Әйе, подумаешь, Уфада Тукай таштактасына татарча язарга рөхсәт итмиләр, Казан өчен вакыйгамыни бу?! Имеш, анда «Башкортостан» бит!

Их, ул чактагы әрнүләр! Уфада бу турыда сүз кузгатсаң: «Ярар инде, куан, хет таштакта куйдылар»,—диләр, Казанда бу турыда сүз катсаң: «Без Башкортстанның эчке эшенә кысылмыйбыз!»—диләр.

Ә быел исә... Тукай туган көнгә—26 апрельгә атна-ун көн генә калгач, бу истәлекле таштакта төбе-тамыры белән суырылып алынган һәм каядыр олактырылган. Мондый вөхшилек турында белеп алганнан соң, Уфаның бер төркем татар зыялылары борынгы китап кибете бинасының таштактасы алып ташланган дивары каршында пикет та оештырганнар. Транспарантта «Тукай, гафу ит! Татарны телсез иттеләр! Сиңа куелган тактаны да юк иттеләр!»—дип язылган иде...

Башкортстанда башкорттан кала нинди дә булса милләтнең туган телен өйрәнгән мәктәпләрдә яхшы укучы балаларны башкортча укытуга, башкорт телен өйрәнүгә күчерү бара. Мин үзем Башкортстанның Авыргазы, Миякә районнарындагы (ул тулысы белән диярлек татар районы) берничә урыс мәктәбендә булдым. Анда моңа кадәр татар телен өйрәнгән татар балалары (алар анда туксан процент) «яхшы укучылар» буларак, кинәт кенә, башкорт телен өйрәнүгә күчерелгәннәр. Минем: «Ни өчен алай иттегез?»—дип соравыма алтынчы сыйныф балалары, ике дә уйламыйча: «Без бит яхшы укыйбыз, яхшы укучылар башкорт телен өйрәнергә тиеш. Башкорт теле, татар теленә караганда, өйрәнү өчен җиңелрәк»,—дип җавап бирделәр.

Менә халык санын алуның яңа кампаниясе килеп җитте. Башкортстан хөкүмәте моның буенча махсус комиссия төзеп, берничә карарлар кабул иткән. Хәзер Уфа эмиссарлары, районнан районга чабып, татар халкын эшкәртәләр. Имеш, алар, татарлар, татар түгел, ә башкортлар икән, алар тарих алдында үзләренең гаепләрен танып, киләсе «переписьтә» башкорт

булып язылырга тиешләр икән. Башкорт радиосы һәм телевидениесе хәтта тән йокламый шушы хакта башны болгата. Газет-журналлар шушы хакта гына яза. Татар районнарындагы җитәкчеләрнең үз постларында утырып калуы-калмавы «шушы әзерлекнең» барышына бәйләнгән.

Кайчандыр Николай Чернышевский куйган үлемсез сорау бар: нәрсә эшләргә?

Әгәр татар милләте халык санын алу буенча бу кампаниядә оттырса, тарихи хата ясаячак.

Быел көз үтәчәк халык санын алу бөтенләй яңа шартларда барачак. Тарихта беренче тапкыр Федераль үзәк статистика органнары алдында татарны ваклау, аны Рәсәйдә сан ягыннан икенче милләт булудан артка тәгәрәтү бурычын куйды. Татарга каршы беренче санлы уенчы булып башкорт факторы кертелә. Моны Рәсәй үзе кертә. Бюджет исәбенә.. Әстерхан, Себер татарлары, инде килеп керәшеннәрне «үз теле, мәдәнияте булган аерым милләт итеп» танырга тырышу, алар белән уйнау шуны күрсәтә. Әгәр теләсәләр, типтәрләр белән мишәрләр дә үзләрен «аерым халык» итеп күрсәтә ала. Башкортстандагы массакүләм пропаганда чаралары менә ничә ел инде «мишәрләр татар түгел, алар башкорт!» дип кычкыра. Татарның халык санын алуда өч зур куркыныч бар әле. Алар белән ничек көрәшергә? Тагын да шул сорау: нәрсә эшләргә?

Татарның беренче дошманы—татар үзе! Халык санын алуда татар үзен бердәм этнос итеп күрсәтү өчен аңардан тирән милли аң сорала. Бу исә иң кирәкле сыйфатларның берсе. Җир йөзендә татар кебек талана торган тагын да берәр милләт бар микән? Ул үзен-үзе талый. Бу бер. Аны урыс талый. Бу ике. Урыс талау белән ул инде килешкән, ул аңа игътибар да итми. Хәзер инде башкорт талый... Алар барысы да татарның төп дошманы—татарның үзендәге ихтыяр көченең җитешмәве белән бәйләнгән.

Мин моны ни өчен сөйлим? Татар милләте киләчәктәге халык санын алуда үзен бердәм милләт итеп күрсәтергә тиеш. Моның өчен массакүләм пропаганда чаралары, радио-телевидение даими рәвештә аңлату эшләре алып барырга тиеш. Бу бик катлаулы эш. Әңгәмәләр бик эчтәлекле, фәлсәфи яктан тирән, ышандыру көченә ия булырга тиеш. Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел әдәбият һәм сәнгать институты, Тарих институты, башка уку йортлары галимнәре, язучылар, политологлар, журналистлар бүгеннән башлап татар яшәгән төбәкләргә сәфәрдән кайтып кермәскә тиешләр.

Башкортстанга игътибар беренче урында булырга тиеш.

Моның өчен Татарстан Фәннәр Академиясенең Тарих институтында башкорт экстремизмы буенча аерым галимнәр төркеме булдырылырга тиеш. Алар Рәсәй неоимпериализмы карынында яралган «вак милләтләр», бу җәһәттән, башкорт экстремизмы турындагы яңа фәнни эзләнүләре белән Европа Советы, Милләтләрнең Европа Ассамблеясы һәм Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясын һәм аның региональ структураларын таныштырып барырга, алар белән бергә фәнни-гамәли конференцияләр, симпозиумнар үткәрергә бурычлы. Татарстан Фәннәр Академиясенең Тарих институты Идел буе республикалары һәм регионнарының фәнни җәмәгатьчелекләре белән бергә якын киләчәктә «Башкортчыл экстремизм һәм Идел-Урал регионында милләтара тотрыклылык» дигән темага халыкара симпозиум үткәрергә тиеш.

Безнең Казан даирәләренә соңгы вакытта тәвәккәллек җитми. Казан Уфа белән эш иткәндә оялчан кызны хәтерләтә. Уфа исә үзе белән шактый тупас, шактый дорфа һәм көч күрсәтеп сөйләшкәнне ярата. Шуңа күрә, Казан, әгәр Уфада аның белән исәпләшсеннәр дисә, иркен хәрәкәт итәргә тиеш.

Әйтегез әле, сез берәр Казан татар галиме, академикның, үткәреләчәк халык санын алу уңаеннан башкорт этносын төрле ыруларга бүлеп, әйтик, гәйнә башкортларын башкорт дип түгел, ә «гәйнә ыруы» дип, мең башкортларын «мең ыруы» дип язарга чакырып, газеталарда мәкаләләр бастыруын күз алдына китерә аласызмы? Юк, китерә алмыйсыз, шулай

бит? Татарның башына килүе мөмкин булмаган нәрсә бу. Ә менә Рәсәйнең социаль фәннәр академиясе академигы, тарих фәннәре докторы, Башкорт дәүләт университеты профессоры Рим Янгузин «Башкортостан» газетының 2001 ел, 11 май санында мишәрләрнең, типтәрләрнең, керәшеннәрнең һәм башка бик күп татар кавемнәренең татар булмавын расларга тырышып, аларны халык санын алганда аерым халык булып теркәлергә чакыра.

Татар белән башкортны чәкештереп, башкортка бөеклек ялап булмаячак. Аны бетереп кенә булачак.

Башкортчыл экстремистлар менә утыз ел инде мишәрне татардан аеру өчен тырышалар. Татарны башкорт итә алмагач, алар татарны эчтән таркату эшенә керештеләр. Ни өчен? Бер караганда, барыбыз да бер төрки тамыр бит! Юк икән шул. Мондый хезмәт өчен Мәскәү яхшы түли. Күптән түгел Башкортстан Татар иҗтимагый Үзәгенең Бәләбәй бүлекчәсе (җитәкчесе М. Кәримов) бу хакта Белдерү кабул итте. Анда болай диелә: *«Башкорт милләтчеләренең татар милләтен бүлгәләп таркатырга тырышуы бер бүгенге яңалык түгел. Бу юнәлештә эшне алар планлы рәвештә һәм күптән алып баралар. Алар, мәсәлән, Башкортстанның көнбатыш районнарындагы һәм Татарстанның Минзәлә районына кадәр урнашкан районнардагы татарларның башкорт булуын расларга тырышып, «җирле башкорт телендә» китаплар чыгарырга җыеналар. Без барлык татар халкын бу провокацияләргә бирелмәскә һәм алдагы халык санын алу кампаниясендә бердәм рәвештә татар булып язылырга чакырабыз...»*

Менә без шуларны эшләргә тиеш.

Шовинизм бер милләтнең икенче милләттән өстен булуын раслый торган ялган тәгълимат. Ул тупас көчкә нигезләнгән. Шовинизм ялган тарихка нигезләнә. Башкорт шовинизмының фәлсәфәсе черек, аның фәнни нигезе юк. Аның барлык фәне төшенчәләрне, фактларны алыштыру, ягъни, урысча әйткәндә, «подтасовка фактов» була.

Башкорт милләтчелегенең феноменаль сурәте менә шулар белән гәүдәләнә.

Башкортның бүгенге шовинистик төре милләтнең үзеннән түгел, ә бер төркем профессура милләтчеләреннән үсеп чыкты. Милләтчелек алар тарафыннан студентлар арасына сеңдерелде. (Бу күренешне, бәлки, бүгенге Әфганстандагы «талибаннар» (шәкерт-студентлар) хәрәкәте белән тәңгәл китереп булыр иде.) Аннан аны халыкка сеңдереп, бүгенге шовинизм «дәрәҗәсенә» күтәрделәр.

Башкортның бүгенге шовинизмы үткән гасырның илленче-алтмышынчы елларында, беренче чиратта, Башкорт дәүләт университетының тарих-филология факультеты, Башкорт дәүләт медицина институты, Уфа сәнгать институты факультетларында һәм кафедраларында яралды. Мин, мәсәлән, университетта укырга керү имтиханнары вакытында, фән-гыйлем сорашыр урында: «Йәле, кустым, татарлар турында мәзәк беләһеңме?»—дип анекдот сөйләтеп, университетка укырга кабул иткән һәм әле булса исән-сау шулай имтихан алып утырган «профисырларны» беләм.

Кабатлап әйтәм, башкорт милләте түгел, аның бер төркем адәмчекләре безне, ике милләтне упкынга алып бармасын өчен без кулдан килгән чараларны күрергә тиешбез.

Беренче итеп, Татарстан җитәкчелеге Башкортстан җитәкчелеге белән хөкүмәтара сөйләшүләрне башларга тиеш. Делегация составына иҗтимагый хәрәкәт вәкилләре, белгечләр, тарихчылар да кертелергә тиеш. Моннан тыш, халык дипломатиясен, халыкның җан табиблыгын тулы куәткә эшкә җигәргә кирәктер. Гади башкорт халкы эчкерсез, кунакчыл, киң күңелле, татарны борынгыдан бертуганы итеп караган халык. Әмма соңгы елларда башкорт халкы, әйткәнемчә, татар милләтеннән читләштерелде. Башкортның шовинист даирәләре тарафыннан татар белән очраштырудан ерак тотылган, татар турында төрле уйдырмалар белән туендырылган башкорт җәмәгатьчелеге белән якыннан очрашырга, ике милләтнең туганлыгыннан бары тик һәр ике якның да отачагыбызны тирәннән аңлатырга, дошманлык юлыннан киткән хәлдә икебезнең дә юкка чыгачагыбызны тарихи, икътисади һ. б. дәлилләр белән расларга кирәк.

Бу юнәлештән чыгып караганда, Татарстан белән Башкортстан районнарының, шәһәрләренең, уку йортларының, предприятиеләренең, хәтта авылларының дуслык күперләрен төзү, җөмһүриятләребез арасында мәдәният, мәгърифәт һәм әдәбият көннәрен даими үткәрү бик тә отышлы булыр иде. Башкортстандагы татар мәктәпләре өчен китапларны Уфаның үзендә татар түләгән салымнар исәбенә бастырып чыгару яхшы нәтиҗәләргә китерер иде. Менә без шуларны эшләргә тиеш.

Ике бертуган милләт арасына аерым «каһарманнар» өйгән чүпне читкә чыгару яхшы түгел. Морадыбызга ирешү өчен без иң элек үзебезнең эчке мөмкинлекләрне файдаланырга тиешбез. Без, беренче чиратта, милләтләребезне элекке якынлыкка кайтару өчен татар һәм башкорт гаиләсенең мөмкинлекләрен киң файдаланырга бурычлыбыз. Биредә гаилә, фән, милли күрәш көннәре һ. б. ш. чаралар үткәрү бик тә урынлы булыр иде.

Башкорт этнократиясенең, кызганыч ки, җинаятьчел адымнарыннан туктарга нияте юк. Иртәме-соңмы, аларның исемнәрен атап, дөнья җәмәгатьчелегенә фаш итәргә кирәк булачак. Моның өчен Кеше хокукларының халыкара Хельсинки оешмасына, Европа Советына, Балтыйк илләре берләшмәсенә, Берләшкән Милләтләр Оешмасының дөньядагы барлык структураларына, халыкара матбугат чараларына пресс-релизлар, аналитик материаллар таратырга кирәк. Татар милли хәрәкәте бу юнәлештә Рәсәйнең Дәүләт Думасы, Федерация Советы, урыс-америка матбугат үзәге белән хезмәттәшлек итсә һәм аларны Рәсәй масштабындагы национал-шовинизмның башкортчыл формасы белән даими таныштырып бара алса, яхшы булыр иде. Болар барысы да киләчәктә милли-прогрессив демократиянең тупас милли шовинизм белән бәрелешендәге көрәшен яктыртуда фәнни-гамәли әһәмияткә ия булачак.

Татар матбугаты, милли матбугат булып каласы килә икән, ул үз милләтеннән читләшмәскә, киресенчә, халыкара масштабта милләт быргысы бурычын үти башларга тиеш.

Бүген Башкортстанда татар милләтенә карата геноцид үткәрелә дип әйтергә безнең тулы хокукыбыз бар. Берләшкән Милләтләр Оешмасының 1948 елның декабрендә кабул ителгән «Геноцид җинаятен алдан кисәтү һәм аның өчен җәзалар тәгаенләү турындагы Конвенция» резолюциясенең II маддәсендә болай язылган:

«а) бер кавем балаларын икенче кавемгә көчләп яздыру;

б) аларны икенче телдә көчләп укытып, надан калдыру;

в) шуның нәтиҗәсендә ата-ананы, сабый балаларны психологик шаукымга, чирләргә дучар итү;

г) шундый юллар белән аларның кавем буларак артуын, үрчемен чикләү һәм башкалар барысы да геноцид дип аталган җинаятьне тәшкил итә.»

Белсеннәр, күрсеннәр дип, без ул документтан урысча да өзек бастырабыз:

## Конвенция о предупреждении преступления геноцида и наказания за него

Принята и предложена для подписания, ратификации или присоединения резолюцией 260 A (III) Генеральной Ассамблеи от 9 декабря 1948 года

Вступление в силу: 12 января 1961 года в соответствии со статьей XIII.

Договаривающиеся стороны,

принимая во внимание, что Генеральная Ассамблея Организации Объединенных Наций в своей резолюции 96 (I) от 11 декабря 1946 года объявила, что геноцид является преступлением, нарушающим нормы международного права и противоречащим духу и целям

Организации Объединенных Наций, и что цивилизованный мир осуждает его, признавая, что на протяжении всей истории геноцид приносил большие потери человечеству, и будучи убежденными, что для избавления человечества от этого отвратительного бедствия необходимо международное сотрудничество, соглашаются, как это предусмотрено ниже:

**Статья I**

Договаривающиеся стороны подтверждают, что геноцид независимо от того, совершается ли он в мирное или военное время, является преступлением, которое нарушает нормы международного права и против которого они обязуются принимать меры предупреждения и карать за его совершение.

**Статья II**

В настоящей Конвенции под геноцидом понимаются следующие действия, совершаемые с намерением уничтожить, полностью или частично, какую-либо национальную, этническую, расовую или религиозную группу как таковую:

а) убийство членов такой группы;

в) причинение серьезных телесных повреждений или умственного расстройства членам такой группы;

с) предумышленное создание для какой-либо группы таких жизненных условий, которые рассчитаны на полное или частичное физическое уничтожение ее;

д) меры, рассчитанные на предотвращение деторождения в среде такой группы;

е) насильственная передача детей из одной человеческой группы в другую.

Башкортстан җөмһүриятендә соңгы елларда башкортчылык басымыннан рухи, мәдәни, икътисади, шәхсәни һәм башка зыян күргән һәр кеше, милләтенә, дини инаниятенә карамастан, Башкортстан хакимиятенең кайбер шовинистик җитәкчеләрен Халыкара хөкемгә тапшыра ала дигән сүз бу.

Димәк, әгәр без үзебезне үзебез ихтирам иттертәсебез килә икән, киләчәктә бер генә Мәҗит Гафури, бер генә Габдрахман Кадыйров, бер генә Фәйзи Гаскәров, бер генә Габдрахман Хәбибуллин, бер генә Фәридә Кудашева, бер генә Бәхти Гайсиныбызны да башкаларга бирергә тиеш түгелбез. Кем әйтмешли, алар бит урамда аунап ятмый. Аларны бит әле шул ук «булмаган» татар үстерә.

Башкортлар, телне белсә дә, татар белән татарча сөйләшергә яратмый. Урысча гына сөйләшә. Минем дә Уфадагы «дусларыбызга», Мәскәү теле белән әйткәндә, «давайте жить дружно, ребята» дип әйтәсем килә.

*Март—май 2002 ел.*

*Татарстан язучыларының XIV корылтае*

## Факил Сафин

# ГЫЙБРӘТ АЛЫЙМ ДИСӘҢ...

Язучы өчен шушы чорда туып, иҗат итү бәхет үк булмаса да, бәхетсезлек тә түгелдер. Вакытлар үткәч, бездән көнләшеп тә куярлар: бер гомер эчендә ике система җимешен татып карадык, яңа гасыр, яңа меңьеллыкның башлануына шаһит булдык. Меңьеллыкны көтеп, бер ел бусага төбендә таптанып тордык, ул арада иске проблемалар яңа дәвергә үтеп, шактый ерак китеп өлгергәннәр булып чыкты. Шулай да сөеник: теләсә кемгә тәтеми безнең чорга килгән үзгәреш, буталыш, болганышлар! Бигрәк тә моннан язучы халкы язарына ни дә булса эләктерми калмас.

Ике съезд арасында укучыга барып ирешкән проза әсәрләре белән танышып чыккач, әлеге фикер миндә тагын да ныгыды. Күпме генә зарланмыйк—язучыларның биш-ун ел китап чыгара алмый җәфаланучылары да, ел саен өч-дүрт китап әмәлләп торучылары да яздылар, язалар, әле дә язып ятмышталар. Әдәбият җәмгыятьнең рухи халәтенә, иҗтимагый фикер үсешенә йогынты ясый, иҗтимагый фикер исә, формаль яктан караганда абстракт тоелса да, чынлыкта, социаль мохиткә, икътисад үсешенә тәэсир итүче факторларның берсе, димәк, җитлеккән әдәбият тормышны көйләргә ярдәм итә.

Проза осталарының зур күпчелеге шушы миссияне аңлап иҗат итәләр. Бәхеткә, язганнарны бастырып чыгарырга әзер торучы газета-журналларыбыз бар, менә алар булмаса, һәм язучы, һәм укучы өчен чын кара көннәр башланыр иде! Уку культурасы халыкта бераз саклана икән, беренче чиратта вакытлы матбугатка бурычлы без. Үткән өч ел эчендә «Казан утлары»нда 12 роман, 14 повесть, 30 дан артык хикәя дөнья күргән. «Идел» журналы ел саен нигездә заманга адекват, үткен мәсьәләләр күтәргән 1-2 роман, 7-8 повесть, унлап хикәя бастырып чыгара. Нәбирә Гыйматдинова, Эсфир Яһудин, Нурислам Хәсәнов, Вахит Имамов, Фоат Садриев, Рафаэль Сибат, Вахит Юныс, Фәнис Яруллин, Солтан Шәмси, Сәмига Сәүбанова, Хәбир Ибраһим кебек язучылар белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итә. Шунысын да әйтергә кирәк, «Идел»—авторларга таләпчән, үз йөзен һәрдаим сакларга омтыла. Прозага «Мирас» журналы да битараф түгел. Барлас Камаловның «Дулкынлана хәят» повесте, Вакыйф Нуруллинның «Хыянәтчеләр» әсәре, Мәсгыйт Хәбибуллинның «Атилла» романы, Фәүзия Бәйрәмованың «Соңгы намаз» романы, Фирдәвес Зариф, Хәләф Гарданов, Әхмәт Гадел, Әсгат Сәләх, Хәнәфи Бадигый әсәрләре һәм классик язучыларыбызның әдәби хәзинәсе белән шушы журнал аша таныштык. Журналда басылып чыккан әсәрләрнең әдәби эшләнешләре төрлечә, еш кына әсәрләрне бастырып чыгарганда талымсызлык та күрсәтелә дигән фикер туа. Оештыручылары Чаллы шәһәр хакимияте һәм Татарстан Язучылар берлеге булган «Мәйдан» журналы шушы вакыт эчендә унлап повесть, дистәгә якын хикәя бастырып чыгарды. Алдагы саннарда Вахит

Имамовның «Тозлы яра» романы, Газиз Кашаповның «Дисбат» повесте, Фаяз Дунайның «Алданган пәйгамбәр» әсәрләре һәм аерым санда «Чаллы хикәяләре антологиясе» дөнья күрәчәк. Укучылар Рәшит Бәшәр повестьларын, яшь авторлардан Амур Фәләхнең «Таш бәгырь» повестен, Айгөл Әхмәтгалиева хикәяләрен яратып кабул иттеләр.

Чорыбыз катлаулы, каршылыклы, аңлаешсыз да. Менә шул ягы белән дә язучы өчен кызыклыдыр ул. Язучы заман, вакыт колы була алмый дисәләр дә, эпоха, социаль мохит һәр шәхескә йогынты ясый. Без үзгәрешләрнең тормышны җайга сала торган уңай һәм аңлаешлы булганнарын көтәбез, әмма кеше өчен яшәеш кануннары һәрвакыт кырыс, иң кулай дип фаразлаган системаның да Шәхескә тулы ирек, бәхет, сәгадәт бирүе шикле. Барысы да кешенең үзеннән, аның иҗтиһат итүеннән, омтылышының реаль нигезгә корылган булуыннан тора. Без укучыны үткән, мәрхүм «бәхетле чор» иллюзиясеннән арынырга ярдәм итәргә бурычлы. Әдәбият—кеше рухын дәвалаучы ашыгыч ярдәм чарасы ул! Язучы нәкъ вакытында һәм кеше җанын дәваларлык итеп әйтә белергә тиеш үз сүзен. Бүген безнең халыкта үткән чорны сагыну, илаһи романтизм дәрәҗәсенә күтәрү тенденциясе көчәя. Язучыга да җиңел түгел. Кайберәүләр, аңлы рәвештә, язучының башын әйләндерергә азапланалар. Бүгенге чорны язса—укучыга хәзергене язып күрсәтүнең хаҗәте юк, тарихны язарга кирәк дип ысылдыйлар; тарихны язганына—ник кирәк ул тарих, хәзерге чорны яз син, укучы шуны көтә, бүгенгене мунча ташы кебек әйләндереп, салып күрсәт, диләр. Теге темага әсәрләр язылмаган, язучылар тарафыннан бу төп тема күтәрелмәгән диючеләр дә бар, яисә кайсыбер язучы нииндидер бер китап укып чыга да башка язучылар моны укымаган, шуңа күрә алар язучы түгел дип сөрән салып йөрүчеләр дә бар. Кыскасы, безнең каләм әһелләре бер-берсенең башын әйләндерергә әллә нәрсәләр табалар. Әгәр дә барлык темаларга да әсәрләр язылып бетсә язучы булып йөрүнең кирәге дә калмас иде. Без яшәгән көннәрдән бераз артка чигенеп, үткән тоталитар, коммунистик режим чорын, искиткеч кысым шартлары аша үткән язмышларны күрсәтеп, гыйбрәт-сабак алырга чакырган әсәрләр кайберәүләрнең бигрәк тә ачуын китерә. Югыйсә, үткәнне барлау—бүгенгенең социаль-иҗтимагый яшәеш призмасы аша киләчәккә карау икәнлеген һәркем белә. Мондый язучыларга җай чыккан саен типкәләп киту түгел, рәхмәт әйтергә кирәк, чөнки үткән совет режимы кеше шәхесен изүдә тиңдәше булмаган машина иде, аны истән чыгару ахмаклык.

Бүгенгене идеаллаштыру, һәрьяктан камил җәмгыять дип расларга тырышу да дөрес булмас иде. Кешелек дөньясы абына-сөртенә үзенең билгесез киләчәгенә баруын дәвам итә, искедән сабак алуны уйламый да. Әмма безнең чор кешегә иҗтиһад итү мөмкинлеген арттырды, язучыны тасвирда хәзер Вакыт һәм Пронстранство чикләре тотып тормый, әсәрләрдә геройның хәрәкәт диапазоны киңәйде. Яңа шартларда милли әхлак тәрбияләүгә нигез салынды, яңа милли кадрлар үсеп килә, милли кыйбла ачыклана, татарның бердәм халык булып яшәвенә комачау тудырылган сәбәпләр күрсәтелә.

Яңа гасырның беренче елларында да, социаль-лингвистик шартлар, лингвистик-психологик мохит зур үзгәреш кичермәде, татар теленең чынлыкта дәүләт теленә әверелмәве аның кулланыш сферасын янә чикли башлады. Инде халык санын алу вакытында Рәсәй империясе татарга соңгы һәм, аларның нияте барып чыкса, яңадан һуш җыя алмаслык удар ясап маташа—моңарчы бер рухи, тел пространствосында яшәгән халыкны этник төркемнәр җирлегендә аерым милләтләр итеп бүлгәләү турында карар кабул ителде. Шуны гына көтеп торган кебек «бүлгәләнергә» теләүче азгыннар да табылды. Алар арасында үзләрен язучы дип санаучылар да юк түгел.

Менә шундый шартларда проза нинди үсеш, үзгәреш кичергән, нинди табыш, югалтулар бар?... Югалту дигәннән, үткән чорда татар әдәбияты иң саллы жанрда—проза өлкәсендә эшләүче бөек язучыларыбызны бер-бер артлы югалтты. Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Тәүфикъ Әйди кебек проза осталарының мәңгелек йортка күчүен бик авыр кичердек. Алар ышыгында артык хафаланмыйча гына иҗат иткән яшьрәк буын прозаикларына якты дөньяга чыгарга, эш күрсәтергә вакыт җитте. Безгә язучы батырлыгы үрнәгең Гомәр ага Бәширов күрсәтте, йөзьяшәр әдип

гомереңең ахырына кадәр язу өстәленнән аерылмады, «Гыйбрәт» дигән роман язды. Язучылыкны миссия дәрәҗәсендә иңсәсенә алган әдипләргә сокланырлык, гыйбрәт алырлык үрнәк бу. Милләт белән, әдәбият белән, укучы, ахыр чиктә, җәмгыять белән бергә-бер калу авыр да, шактый куркыныч та икән. Җаваплылык тойгысы инде чынлап торып проза язучыларны әзәрлекли, эш күрсәтергә өнди.

Корылтайда сөйләрлек, фикер алышырлык нигез бар прозада. Нәшриятлар чыгарган китаплар, газета-журналларда басылган чәчмә әсәрләр белән танышып чыккач, хәйран калып тордым. Болар хакында тәфсилләп сөйләү өчен бер корылтай түгел, ике съезд вакыты да җитмәс. Язучылар яза тора, укучылар карап тора дип, шаяртып әйтсәк тә, укучылар йотлыгып укый торган әсәрләр дә аз язылмаган икән. Татарстан китап нәшрияты ике корылтай арасында 45 ләп проза китабы бастырып чыгарган. Әлеге китапларның байтагы классик язучыларыбызның күптомлыклары, кайбер авторларның кабат бастырып чыгарган әсәрләре икәнен исәпкә алганда да, алар арасында Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Аллаһы бүләге», Фоат Садриевның «Бәхетсезләр бәхете», Камил Кәримовның «Ком сәгате», Адлер Тимергалинның «Кабул булсын теләгең», Алмаз Гыймадиевның «Хуш, Тамчыгөл», Нәбирә Гыйматдинованың «Сәвилә», Нурия Измайлованың «Язылмаган хатлар», Таһир Нәбиуллинның «Качкын», Вакыйф Нуруллинның «Җавап бир, кеше», Вахит Имамовның «Утлы дала», Флүс Латыйфиның «Ишелеп төшкән бәхет», Туфан Миңнуллинның «Утырып уйлар уйладым», Рафаэль Сибатның «Ялгызак», Айдар Хәлимнең «Татар моңы», Ркаил Зәйдулланың «Ил», Нурислам Хәсәновның «Җан авазы» кебек укучылар күңелен җәлеп итәрлек яңа әсәрләрдән тупланган китаплар бар.

Күренгәнчә, авторлар төрле, аларның язу рәвеше, дөньяны тою, сурәтләп бирү үзенчәлеге төрле, холыклары төрле. Шушы ук нәшриятта «Татар хикәяләре антологиясе» дөнья күрүе бөтен әдәбиятыбыз өчен куанычлы вакыйга булды. Антология татар хикәя жанрының үсеш юлын күзалларга ярдәм итә, перспективасын күрсәтә. Төзүче Мәгъсүм Хуҗин гаять кирәкле һәм зур эшне югары кимәлдә башкарып чыга алган. Егерменче гасыр хикәясе авторларга бай, төсмерләргә мул, киң сулышлы һәм татар прозасының төп үсеш тенденциясен фактта раслый. Тик бу эшне дәвам итәргә кирәклеге күз алдында: әле прозада озак еллар ат уйнатып та, антологиягә керми калучы язучылар, аларның шәп хикәяләре бар. Моны хикәя жанрын үстерүгә бар иҗат гомерен биргән Мәгъсүм ага үзе дә яхшы беләдер кебек. «Мәгариф» нәшрияты нигездә инде сыналган, укучылар тарафыннан яратып кабул ителгән һәм теге яки бу дәрәҗәдә мәктәп, ВУЗ программаларына кертеп, өйрәнелә торган әсәрләрне югары полиграфик сыйфатта кабат бастырып чыгарып, бик тә игелекле эш башкара. Чаллыда «КамАЗ» китап нәшрияты, «Раннур» нәшрияты, «Матбугат Йорты» нәшрияты, «Рухият» нәшриятлары да проза китаплары чыгара киләләр. Әмма ике съезд арасындагы прозадагы үсеш-үзгәреш хакында, жанрга хас төп тенденцияләр турында сөйләгәндә без хаклы рәвештә инде сиксән еллык тарихы булган мәртәбәле «Казан утлары» журналына мөрәҗәгать итәбез. Журналның төп уңышын яхшы проза әсәрләре билгеләве беркемгә дә сер түгел, шуңа күрә чәчмә әсәрләрнең төп казаны да шушы редакциядә.

Инде алда әйткәнчә, үткән өч елда «Казан утлары» журналында байтак роман, повесть, хикәя һәм истәлекләр, хатирәләр, көндәлекләр тибындагы чәчмә әсәрләр, эсселәр урын алган. Байлык бу, җәмәгать, халкыбызның акыл хәзинәсенә язучыларның керткән өлеше. Журнал әсәрләрне сайлап алуга зур әһәмият бирә, әдәби зәвык дибез икән, ул бүген укучыда «Казан утлары» аша тәрбияләнә. Редакциядә Флүс Латыйфи, Камил Кәримов, Марат Закир кебек прозаикларның эшләве дә моңа тәэсир итми калмыйдыр.

Ирек мәгънәсен проза язучылар жанр кысаларын ватуда, әлеге критерийның асылын аңлаешсыз дәрәҗәгә җиткереп әсәр язуда күрделәр дисәк тә хата булмас. Укучы, әсәр кызыклы икән, ни язсаң, шуны кабул итә, жанр турында уйлап баш ватмый. Әлеге проблема галимнәрне утка салды. Язучы халкы үҗәт, үсүзле, хәтта үчлекле халык, алар «роман» дип мөһер сукканны повесть дисәң, күрмәгәнеңне күрсәтерләр! Гомумән, авторлар тарафыннан тәнкыйтькә басым ясау күренеше бар. Шуңа күрә Рифат Сверигин

әйткәнчә, «дәшми калып тәнкыйтьләү» формасына күнегеп киләбез.

Чыгыш кысасында әсәрләрдәге тематик уртаклыкларны күрсәтеп, мәсләк-фикер якынлыгы җирлегендә язучыларны төркемнәргә бүлеп, прозадагы вәзгыятькә гомумкүзәтү генә ясап «котыла» алган булыр идем. Шулай эшләгәндә күбрәк исем атала, чыгышны әзерләү дә уңайлы булыр иде. Башкачарак юлны сайлап, прозада бүген җиң сызганып эшләгән язучыларга аерым тукталып китәргә булдым. Алдагы дистә елларда прозабыз дилбегәсе мин телгә алачак авторлар кулында булачак бит. Әдәби барышка нинди йогынты ясый алар, аларны нинди проблемалар борчый, Тукайчалап әйтсәк, мондый авторлар белән «без әле кая барабыз?»—шуларга җавап табу төп максат иде.

Соңгы елларда прозада ныклы урын алган язучы, Мөдәррис Әгъләм әйтмешли, Мөслим «Шолоховы»—Фоат Садриев. Аның «Бәхетсезләр бәхете» романы соңгы елларның зур казанышы буларак кабул ителде. Өч китаптан торачак зур романның беренче китабын Рифат Сверигин «үткәнне каһәрләү» үрнәге итеп күрсәтте. Бүген җитмеш яшьлек Рифат ага Сверигин заманында социалистик реализм кысаларында хәләл көче белән әдәбият фәне үрләрен яулаганда, үткән ел гына алтмыш яшен тутырган Фоат Садриевка район масштабында әлеге реализмның бөтен хикмәтләрен үз башыннан кичерергә туры килә. Автор, мондый гаепләүләрне алдан күргән сыман: «Халык тормышының теләсә кайсы чоры олы сабак алырлык. Һәр чорның үз хакыйкате әйтелергә тиеш. Шул дәвер тегермәнендә тартылган кеше буларак, мин әйтмәсәм, аны кем әйтер?..»—дип, иҗат принцибының асылын ачып бирүне кирәк тапкан. Әсәр буена хәрәкәт итүче герой—Ирек Сабитов, башта шактый үзсүзле күренгән булдыклы егет, партия әһелләре куйган тозакка килеп капкач, үзе өчен көрәшкә талпынып ала. Әмма мәхәббәт, тормыш сынауларыннан районнан китеп тә котыла алмый ул. Партиянең җәтмәсенә бер эләксәң, аннан исән-имин котылуың шикле иде шул. Фоат Садриев үз геройларын Мәскәү күрсәтеп кайтарырга һәвәс. «Таң җиле»ндә Нуриәсма да йөрде Мәскәүдә, Ирек тә белем алу теләге белән Мәскәүгә юл тота. Әмма Ирекнең Мәскәү чоры әсәргә ышанычны киметте. Стильдә һәм тасвирда ниндидер алышыну барлыкка килә.

Быел Флүс Латыйфи ике романы: «Хыянәт», «Ишелеп төшкән бәхет» әсәрләре өчен Тукай премиясенә тәкъдим ителде. Зур прозаны иярләгән остаңың хакыйкән танылу алуы билгесе дип карарга кирәк моны. «Хыянәт» хакында шактый күп сөйләнде, ул «Мәгариф» нәшриятында искиткеч матур итеп кабат басылды һәм тагын тиз арада таралып та бетте, бүген мин «Бәйсез этләрне атарга» әсәре белән «Ишелеп төшкән бәхет» романына тукталам. Беренчесен автор роман-нәсер дип тамгалап, күпләрнең һушын алды. Һичшиксез, әсәр җыйнак повесть кимәлендә язылган. Флүс Латыйфиның теле җырлап тора, шактый катлаулы нәрсәләр хакында язып та, теле аһәңлекне, сыгылмалыкны югалтмый, төсмер-табышларга бай. «Бәйсез этләрне атарга» әсәрендә ачык буяулар белән совет режимы чорында яшь гражданнарны тәрбияләүнең типик алымнары күрсәтелә. Һәр гамәлдә курку, гаиләдә пышылдап кына сөйләшү, дөнья көтүгә җайлашуның примитив ысуллары, хокук органнарының кылган гамәлләре—барысы да ышандыргыч һәм гыйбрәт алырлык итеп сурәтләнгән. Шул ук вакытта әсәр сәнгатьле эшләнеше ягыннан да ота. Үсмер Харис белән Лилия арасында кабынган якты вә саф мәхәббәткә тартым хисләр әсәрне кызыклы, персонажларның язмышын өметле итә. «Ишелеп төшкән бәхет» романы—совет армиясендә үткәрелгән экспериментлар корбаннарына—яшьли һәлак булган милләттәшләргә реквием ул! Автор татар милләтенә карата алып барылган астыртын геноцид сәясәтен ачып салды, аның ысулларын, башкаручыларын күрсәтте... Романны Флүс Латыйфиның гражданлык батырлыгы дип бәяләсәк тә урынлы булыр. Сирин Сабиров үз илендә геноцид процедураларын башыннан кичерә, Акчуриннар исә чит илгә качып та, коммунистлар эзәрлекләвеннән котыла алмыйлар. Өлкән Акчурин гомер буе туган җиренә кайтырга, һич тә булмаса туганнарына исәнлек хаты җибәрергә хыялланып йөргәндә, Сирин бу илдән китеп кенә Шәхесен саклап калырга мөмкин дигән карарга килә... Саф мәхәббәткә тару, университетка укырга керү, якты киләчәккә ныклы ышаныч

авыл малаеның өстенә ишелгән бәхет булса; кысымнар, ракета гаскәрләренә эләгеп сәламәтлекне югалту, əзəрлекләүләр, туган илдән аерылу—шушы бәхетнең авып, ишелеп төшүе. Роман авторның зур уңышы, әдәбиятыбызның казанышы.

Әдәби мәйданда инде шактый еллар бил бирмәгән язучыларның берсе—Вахит Имамов. КамАЗ нәшриятында «Могикан» исемле китабына шул исемдәге повесть һәм «Кәнәфи» исемле әсәре, Татарстан китап нәшриятында исә «Утлы дала» романы, берничә китаптан торачак эпопеяның беренче кисәге дөнья күрде. Повестьлар һәм роман язылышы белән актуаль, әмма эшләнешләре төрлечәрәк. «Кәнәфи» повесте провинциядәге партократиянең кылган гамәлләре, аларның хакимлектәге соңгы көннәре, үзара яклашу, хыянәт итү, форсат чыкканда типтереп калулары, ахыр чиктә төп персонаж Кадриянең дусларсыз, сөйгән ярсыз ялгыз калуы белән төгәлләнә. Кадриянең кылган гамәлләре, кичерешләре, дөньяга, димәк кәнәфигә чытырдап ябышуы җете буяулар белән тасвирлана. «Могикан» повестенда тыныч кына яшәп яткан татар җиренә, шунда гасырлар буена үз җае белән яшәгән татар халкына КамАЗ дигән монстрның нинди афәтләр алып килүе, язмышларны җимерүе сурәтләнә. Әсәрне КамАЗ турында белеп язылган беренче саллы әсәр дисәк тә ялгышмабыз. «Могикан» повесте хакында сүз күп булды, җитмәгән якларын да әйтеп бирделәр, уңышлары да күрсәтелде, әсәрнең каршы кую алымы белән язылуы аеруча хупланды, кыскасы, кимчелекләре булуга карамастан, повесть укучыларны битараф калдырмады. «Утлы дала» романы исә—гомумтатар әдәбиятының уңышы. Уникенче-унөченче гасырда магул далаларыннан алып кыпчак, урыс җирләре, Идел буйлары, Болгар дәүләтендәге хәл-әхвәлне чагылдырган әсәр тарихи чынбарлыкка нигезләнгән. Әгәр галимнәр тарихи әсәр нинди дә булса концепцияне тудырырга, шуны тормышка ашыру юлларын күрсәтергә, ягъни фәнни югарылыкта булырга тиеш дип саный икән, мондый әсәр нәкъ менә «Утлы дала» романы инде. Төп герой тарих, төп проблемалар—татарның дәүләтчелеген булдыру һәм саклап калу юллары, күршеләр белән мөнәсәбәт, татар тарихының шул чордагы тарихи процесслар белән тыгыз бәйләнеше; үзсүзле хакимнәрнең кылган гамәлләре, акыл иясе булган кавемдәшләреннән төрлечә үч алулары, халык, ил язмышына бәла-казалар китергән хыянәт мисаллары да үтә дә гыйбрәтле. Бүген дә нәкъ менә үзен күрсәтү өчен генә яшәүче, башкаларны исәпкә алмый, үзенекен генә сүз итәргә тырышучы, үз мәнфәгате өчен теләсә нинди явызлыкка, хыянәткә бара торган бәндәләр юкмы? Вахит Имамов шушы көннәрдә яңа роман төгәлләде, насыйп булса, ул «Мәйдан» журналының алтынчы санында роман-газета шәкелендә басылып чыгар дип өмет итәбез.

Чаллы авторлары турында сүзгә керешкәч, Айдар Хәлимнең соңгы елларда проза өлкәсендә уңышлы эшләвен билгеләп китәргә кирәк. Язучының бер карасаң стиле үзенчәлекле: вакыйганы умырып-умырып алып мөшкә авызына ыргыта, сюжет буенча кисәк-дуамал ыргымнар белән алып бара укучыны. Шул ук вакытта Айдар Хәлимне һәм тел җәһәтеннән булсын, әсәрнең төзелеше, аңа салынган эчке накал, сюжет кору осталыгы, образлы сурәтлелек, фикер ягыннан булсын, укучыны җәлеп итәрлек дәрәҗәдә кызыклы, гыйбрәтле. Аның геройлары үз чоры кармавыкларына эләгеп, изелеп басынкыланган, йончыган татар кешеләре. Автор, үзе әйткәнчә, шушы хәяткә тереклек суы бөрки, персонажларны башларын күтәреп як-якка карарга мәҗбүр итә, татарны татарлыгы өчен кыздыра-кыздыра, аларны тормышка, яшәешкә өстери. Айдар Хәлимнең «Татар моңы» дигән китабы соңгы елларда татар әдәбиятында күренмәгән биеклек. Анда укучылар яратып кабул иткән һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан уңай бәяләнгән «Өч аяклы ат», «Татар вакыты» әсәрләре һәм бай палитралы новеллалары тәкъдим ителгән. Аларда тормыш кырыслыгы, халыкның ачы язмышы, җавапсыз йөрәк ашкынуы, иманга кайтуның авыр юлларын, рухи геноцидка китергән шартлар һәм империянең тоткасына әверелгән күрә карауч үз татарларымыз... «Кыйбла», «Эңгер», «Авылдаш», «Берлинга хат», «Казыктагы итальян» новеллалары, алардагы төп персонажлар Гарифулла карт, Җәүдәт, Сөендек, Кадерҗан, Бәгырь образлары татар әдәбиятын яңа тип геройлар белән баеттылар. «Мәйдан» журналында басылган «Җырлар вакыт» әсәре татар

моңына гимн дип бәяләнде, «Казан утлары»нда дөнья күргән «Бөркетле баганалар» новелласы татар әдәбиятының географик чикләрен киңәйтеп җибәрде. Автор Сәет образы аша татарның кайда да татар булып калуын, күпме маңгай тирен түксәң дә татарга тиешле әҗер башка милләтләргә караганда күпкә ким билгеләнгәнен оста тасвирлап бирә алган. Системаның шәхесне сындыру юллары бер төрле, ул милләткә карап тормый, ләкин татарга карата ул аеруча мәкерле һәм аяусыз кылана. Айдар Хәлим традицион җирлектә иҗат итеп тә, әдәбиятта яңа катламнар ачарга мөмкин икәнлеген күрсәтте. Әгәр бездә кинога төшерү индустриясе булса, Айдар Хәлим әсәрләре әллә кайчан экраннан төшмәс иде.

Тагын бер кызыклы прозаикны телгә аласы килә—ул Киров өлкәсендә яшәп, Казанда бер-бер артлы әсәрләр бастырып чыгаручы Рафаэль Сибат. Авторның прозасы үзенчәлекле, ул роман, повестьлар, эссе жанрында нәтиҗәле эшли. «Ялгызак» романындагы Заһидулла образын гасыр герое дип атарга омтылучылар да булды. Мин романның уңышлы һәм кызыклы, жанр таләпләре җирлегендә киң колачлы булуы белән килешәм, шулай ук Рафаэль Сибатның күп авторларыбыздан аермалы буларак, көчле герой тудыру юлында эзләнүләрен хуплыйм. Шулай да татар әдәбиятын үзгәрешләр чоры башыннан бирле борчып килгән «көчле кеше» концепциясе, заман каһарманы миссиясен Заһидулла үти алмый, чөнки аның милли йөзе зәгыйфь. Әсәрнең соңында, картаеп беткәч тә, намаз-нияз турында уйлыйсы урынга Заһидулланың Франциягә, яшьлектәге мәгъшукасы марҗа Тамара янына барырга хыялланы тормыш белән җан-фәрман тартышып ятучы карт зимагурга сагышлы ихтирам хисләре уята уятуын, ләкин аны милләткә үрнәк герой буларак тәкъдим итеп булмый. Шунысы куанычлы: Рафаэль Сибат туктаусыз иҗатта, димәк, туктаусыз эзләнүдә, туктаусыз януда. Автор мавыктыргыч сюжетлар табып, аны тиз арада укучыга җиткерергә ашыга. Әсәрләрендәге кайбер мантыйкка ярашып бетмәгән якларның сәбәбе нәкъ менә шунда да бугай—Сибат бер язганына яңадан әйләнеп кайтмый. Мөхәммәт Мәһдиев шаяртып, әмма белеп әйткән «әсәр өстендә эшләү»нең җитмәве әдәбиятның бәласенә әйләнеп бара. Сүз уңаенда, прозаик язганда гына түгел, булачак әсәре хакында язганчы да, әсәр язылганнан соң да җитди уйларга тиеш дип әйтәсе килә.

Камил Кәримов соңгы еллар прозасының ачышы булды дисәң дә хата булмас. «Ком сәгате» әсәре тел җәһәтеннән дә, әсәрне оештыру, геройларның эш-гамәлләре мантыйкка сыешлы булу ягыннан да, җыйнак булуы белән дә күңелгә ятышлы. Фазыл конкрет эш кешесе булса да, әсәрдәге башка байтак вакыйга, күренешләр, образлар, детальләр кебек үк кинаягә ия персонаж. Гомере буе су эзләп, халыкны кинәндереп яшәгән кеше, ахыр чиктә Казанда су-сазлык уртасында, бакалар арасында җан асрарга мәҗбүр. Һәрнәрсәне Вакыт үз урынына куя дип, кысыр өмет белән яшәүчеләргә, Язмыш иркенә гомерен салганнарга сабак бу—Вакыт өнсез, Вакыт битараф. Ә бит әсәрнең һәр бүлеге бер кыз исеме белән аталган. Тыштан караганда тормышның матурлыгына ишарә бу. Яшьлек хыяллары, яшәүгә омтылыш, билгесез тирәнлекләрдән илаһи тормыш чыганагы эзләү ымсындыра, иләсләндерә адәм баласын. Вакыт, Су, Язмыш—әсәрне фәлсәфи яссылыкка күчерүче ачкычлар әнә шулар. Автор әсәрнең икенче кисәген тәмамлады. Күренгәнчә, хәзер татар әдәбияты җыйнак романнарга йөз тота дип, моны тенденция буларак расларга маташу урынсыз. Фоат Садриев, Вахит Имамов, Факил Сафин, Камил Кәримов шактый перспективалы темаларны алып, икешәр, өчәр кисәкле романнар яздылар. Кыска җиңле романнар күренеш буларак кына бәяләнергә хаклы, тенденция дип түгел.

Прозада сирәк табыш—Галимҗан Гыйльмановның «Албастылар» романы. Әсәрне бер тында укып чыктылар. Матбугатта аны хуплап рецензия язган филология фәннәре докторы Дания Заһидуллинадан да әсәр турында тулырак итеп әйтеп булмас. Галимҗан Гыйльманов татар мифларын туплап, дөньяга чыгарып та милләткә зур хезмәт күрсәткән галим. Әдәби тәнкыйтьтә яңа эз, яңа юнәлеш салган шәхес, инде саллы прозада да уңышлы эшләрлек тормыш тәҗрибәсе булган, яшәеш агышында әхлакый-психологик моментларны дөрес тота һәм җиренә җиткереп тасвирлый алырлык автор

итеп күрсәтте, образлы фикер остасы итеп танытты. «Албастылар»ны укыгач: гасыр башында Г. Рәхим, М. Хәнәфи тарафыннан нигез салынган модернизм үрнәгенә якын әсәр язуга ныклы омтылыш ясалды дип әйтә алабыз.

Татар халкының күңел байлыгын өйрәнеп, матур әсәрләр иҗат итүче Фәрит Яхинны да күрсәтеп китү зарур. Ул киң катлам укучыга популяр формада дини белем бирүне башлап җибәрүче беренче галимнәрдән булды, борынгы әдәбиятны кайтаруда нәтиҗәле эшләве белән дә ихтирамга лаек.

Зиннур Хөсниярның «Терсәк сугышы» романы тормышның кырыс кануннары белән очраштыра. Кеше һәм аның эчке дөньясы, табигать һәм кеше мөнәсәбәтләрендә безнең буын язмышы, рухи халәте ачык буяулар белән тасвирлана. «Терсәк сугышы» әсәрендә кайбер кеше ышанмастай нәрсәләрне дә үткәреп җибәрергә кирәктер, башка әдәбиятта әллә ниләр язалар бит әле, бездә нигә булмаска тиеш ди моның ише хикмәтләр! Урманы булгач, бүресе бардыр, бүресе булгач, риваятьләрдәге хәлләр дә кабатланмый калмастыр дигәндәй...

«Язучының бурычы,—ди Туфан Миңнуллин,—кешене шәхес итеп, татарны милләт итеп, дөньяны камил итеп саклап калу. «Нәбирә Гыйматдинова әсәрләре кешене шәхес итеп, дөньяны камил итеп саклап калуга хезмәт итә дип әйтә алабыз. Лирик-психологик сурәтләү остасы булган язучы геройларның эчке дөньясын, күңел омтылышын, җан сурәтен ачу юлында традицион булмаган алымнарга мөрәҗәгать итә һәм сизелерлек осталыкка ирешә ки, әгәр әсәрендә медитатив алымнар, күз буяулар, күрәзәлек кылулар, урман-чытырманлыклар, сәер холыклы персонажлар килеп кермәсә, аны Нәбирә ханым язган дип тә әйтәсе килми. Нәбирә Гыйматдинова—кеше табигать белән, үз-үзе белән, янәшәдәге башка кешеләр, җан ияләре белән килешеп яшәргә тиеш дигән илаһи принципка тугры калып иҗат итә. Геройлары нык холыклы, баш бирмәс, сыктап утыручылар түгел. Нигәдер ир-ат язучылар шундый образлар иҗат итмиләр. Нәбирә Гыйматдинованың «Аргы очта, бирге очта» повестен укыгач, күңелгә икенче бер автор Гөлчәчәк Галиеваның «Тулгак» повестен искә алмый булмый. Гөлчәчәк Галиева исеме хәзер укучыларга яхшы таныш, «Тулгак» әсәре чыннан да күпләрне тормыш, яшәешнең асылы хакында уйланырга мәҗбүр итте. Телгә алынган ике әсәр охшаш ситуациягә корылган кебек. Әмма тышкы охшашлык шуның белән бетә, Нәбирә Гыйматдинова әсәрне лирик-драматик яссылыкта, эмоциональ нигездә хәл итсә, Гөлчәчәк Галиева, тәҗрибәле педагог буларак, тормышчанлыгы белән алдыра, ике гаилә арасында килеп туган катлаулы ситуацияне социаль-психологик контекстта чишә.

Хатын-кызларыбыз проза өлкәсендә нык куллы булуларын көннән-көн ныграк сиздерәләр. Фәүзия Бәйрәмова «Соңгы намаз» әсәрендә иман, дин юлына баскан шәхеснең үзгәлүнәләрен, уй-кичерешләрен җан тетрәтерлек итеп сурәтләде. Чәчән сугышы әле безне озак бимазалар. Әлеге әсәрнең уңай сыйфатлары хакында Рифат Сверигин үтемле итеп әйтеп бирә алды. Галим белән килешмәү гөнаһ булыр. Мәдинә Маликованың «Алтын ятьмә», Халисә Мөдәррисованың «Бәйге хакы» повесте да җылы тәэсир калдырды, заман проблемаларын хатын-кызлар тойганча оста итеп тотып алулары һәм сәнгатьле итеп чишә алулары белән истә калдылар.

Прозада армый-талмый эшләүче әдип—Фәнис Яруллинны яратып укымаган кеше юктыр. Аның геройлары тормыштан алынганнар, ясалмалык юк, автор вакыйгаларны ихлас тасвирлый, безнең белән янәшәдә гомер итүче олы җанлы, матур уйлы, игелекле гамәлләр кылырга сәләтле кешеләрне сурәтләп, җаннарны сафландырып җибәрде. Америкага киткән ятимнәр өчен җан атучы Миңлегөл апа әдәби әсәр кысаларыннан чыгып, татар хатыны эталонына әверелде. Авторның әлеге «Язмыш яралары» китабы берьюлы өч телдә басылып, дөньяга таралды, һәм, шикләнмичә әйтергә була, әсәр татар әдәбиятының казанышы, йөз аклыгы.

Тарих өлкәсендә Солтан Шәмсинең эзләнүләре нәтиҗәле. «Идел» журналында басылган «Корбанбикә» повесте кирәкле әсәр иде. Сөембикә ханбикәне әхлакый йомшак табигатьле итеп күрсәтеп, гамәлләренә бәя биреп бетерә алмаган, шул сәбәпле Казан ханлыгына килгән афәтне туктата алмауда гаепләүчеләрне ишеткән бар. Болай дип сөйләнүчеләр аерым максатны күздә

тоталар, билгеле. Солтан Шәмси әсәре әнә шундый яла ягуларны кире кагарлык, матур әсәр булды. Аның «Низаглы йортта» дип аталган эссесы бинниһая хезмәт җимеше. Үткәнне язып, Солтан Шәмси бүгенгә сабак бирә, дәүләт белән идарә итүдә ялгышларның, аерым шәхесләрнең кирәк чакта килешүгә бара белмәүләре, кирәк чакта принципларыннан бер адым да чигенмәскә тиешлеген искә алмаулары аркасында дәүләт җимерелә, халык һәлакәткә дучар була. Тарихи әсәрләр язу остасы Мөсәгыйт Хәбибуллин, Нурихан Фәттах, Рабит Батулла кебек өлкәннәр янына Ркаил Зәйдулла, Нурулла Гариф кебек яшьрәк буын язучылар өстәлә тора. Бу жанр безнең милли күтәрелеш чорында алгы планга чыккан иде, киләчәктә дә ул үз позициясен бирмәсен—чөнки тарихи әсәрләр җирлегендә тәрбияләнгән яңа буын үсеп килә, аларның халкыбыз язмышы хакында тирәнрәк белергә булган омтылышын сүндермәскә иде.

Тагын бер язучыны телгә аласы килә, ул—Рәшит Бәшәр. Балалар һәм үсмерләр өчен дистәләгән повестьлар язган һәм ышанып әйтәм, бу жанрда нәтиҗәле эшләүче берданбер прозаик, актуаль, күңелне җәлеп итәрлек темалар күтәрүе белән игътибарга лаек. Аның теле җырлап тора, образлы.

Ике съезд арасында Адлер Тимергалинның «Игезәкләр» повесте, Миргазиян Юнысның тирән эчтәлекле, фәлсәфәгә һәм хискә бай эсселары, Нур Әхмәдиевның «Амбирак яки Кара каен кыйссасы», Марат Әмирханның «Тәкъдир» романы, Якуб Зәнкиевнең «Өтелгән мәхәббәт» романы, Факил Сафинның «Саташып аткан таң» романы, Мансур Вәлинең истә калырлык новеллалар циклы, Сафа Сабировның «Алтын балдаклы абыстай» документаль повесте, Әхсән Баян әсәрләре, Зәки Зәйнуллинның «Гарасатлы юллар» повесте, Әхәт Гаффар, Рафис Гыйззәтуллин, Сәйдә Зыялы, Кояш Тимбикова, Марат Закир, Рифә Рахман хикәяләре, Ләлә Гыймадиева, Дания Гайнетдинова әсәрләре дөнья күрде. Күренгәнчә, исемнәр байтак. Шулай да прозабыз язмышын үз җилкәсенә алырлык көч, теләк-дәрман да бармы әдипләребездә? Бүгенге көндә зур прозада үз сүзен әйтерлек язучыларны яшь ягыннан барлаганда, барлыгы ундүрт язучыны: 50-60 яшьлекләр арасында Флүс Латыйфи, Рафаэль Сибат, Солтан Шәмси, Марсель Гали, Нур Әхмәдиев, Камил Кәримов, Әхәт Гаффар; 40-50 яшьлекләр арасында Вахит Имамов, Факил Сафин, Нәбирә Гыйматдинова, Зиннур Хөснияр, Галимҗан Гыйльман; 30-40 яшьлекләр арасында Марат Закир, Алмаз Гыймадиев иҗатларына гына ныклы өмет белән карарга нигез бар. Боларның да зур күпчелеге хезмәт вазыйфаларына кереп чумган кешеләр. Алар җилкәсендә дөнья, гаилә мәшәкатьләре, җан саклау кайгысы. Бу мәсьәләгә ныклап игътибар итәргә кирәк—эш арасында гына татар әдәбиятын яңа биеклекләргә күтәргән әсәрләр язып булыр микән? Бүгенге прозаикларның уңышлы әсәрләре, ни сәбәптәндер, мәктәп, ВУЗ программаларына кертелми, ныклап өйрәнелми, монысы да җитди проблема. Әйткәнемчә, проза язмышы хакында җыелыш, корылтай вакытларында гына уйланып калмаска, берлек кысаларыннан чыгып, дәүләт югарылыгында уйлану да зыян итмәс иде. Быел прозага игътибар булды анысы, Якуб Зәнкиевкә «Иртеш таңнары» дигән этнографик романы өчен Тукай премиясе бирелде, өлкән язучыбыз Хисам Камалов «Халык язучысы» исеменә ия булды. Әмма ни Язучылар берлеге тәкъдим иткән Мөсәгыйт Хәбибуллин, ни «Казан утлары» кандидаты Флүс Латыйфи комитетта кирәк кадәр тавыш җыя алмадылар. Бу нәрсә дигән сүз? Язучылар берлеге абруеның какшавын аңлатмыймы?.. Иҗат барышын үз кулларында тоткан мәртәбәле оешмаларның фикерен санга сукмау, соңгы елларда премия мәсьәләсендә Марсель Гали исеменә бәйле ыгы-зыгылар белән бер дә килешәсе килми.

Проза әсәрләре языла тора. Сөендергәне шул: авторлар телгә игътибарлы була башладылар. Бәлки редакцияләр әлеге мөһим өлкәгә таләпчәнлекне арттырганнардыр. Әмма иркенәергә иртә әле, телсез әсәр корыштыручылар һаман да бар. Кайбер басмалардагы корректура эшенең сыйфаты белән дә риза түгел без.

Соңгы елларда игътибарны җәлеп иткән автор Уфадан Марат Кәбиров булды. «Казан утлары»нда басылган «Сары йортлар сере» повесте сурәтләү манерасы, хикәяләү ысулы белән бөтенләй яңача, без латин Америкасы әдәбиятында күргән сюрреалистик алымга тартым. Әсәр күңелне тетрәтә,

укый башлагач тиз генә ачкычын табып та булмас кебек. Әсәрне укып чыккач, авторның үтә дә гыйбрәтле әсәр язганын аңлыйсың. Кешелексез, игелекнең кадерен белмәгән, җан асрауны яшәү дип уйлаудан ерак китмәгән буынның тирән фаҗигасе тасвирлана монда.

Истәлек-хатирәләргә, документаль нигезгә корылган әсәрләр дә күп дөнья күрде үткән чорда. Аларның иң күренеклесе, әлбәттә, Әдип ага Маликовның «Гомер мизгелләре» дип аталган китабыдыр. Әдип ага ихлас рәвештә замандашлары, әдәби мохит хакында яза. Сәҗидә Сөләйманова турындагы истәлекләре аеруча кадерле безгә. Рахмай Хисмәтуллинның Нур Баян хакында «Оныкларым, сез бәхетлеме», Әнәс Галиевнең «Чигенгәндә», Кави Латыйпның «Үр арты үр», Гариф Ахуновның «Күз нурым», Аяз Гыйләҗевның «Күңел серләре», Суфиян Поварисовның Галимҗан Ибраһимовның тормышына һәм ачы язмышына багышланган трилогиясе, Равил Мирхәйдәровның «Иртәләгән сагыш» романы (Марс Шабаев тәрҗемәсе), Октябрьск каласында яшәүче Гали Гыйззәтнең «Киттем галәм киңлегеннән...» китабындагы хикәяләр дә гыйбрәтле, укучыны уйга сала.

Зур әдәбият, тынгысыз әдәби барыш хакында сүз йөрткәндә жанр эчендәге бүленешләргә дә игътибар итәргә туры килә. Әдәбият тулы канлы булсын өчен барысы да кирәк. Детектив прозаның уңышлы үсеше өчен шартлар үтә дә уңай. Җәмгыять үсешендәге безнең чор гариплекләре киләчәк буыннар язмышына туры килмәсен иде инде. Туксанынчы еллар әдәбияты казанышы дип хаклы кабул ителгән Тәлгать Галиуллинның «Тәүбә», «Элмәк» романнарының уртак герое Сәет Сакманов кебек типларны алга табан үстергән, шушы юнәлештә иҗади тикшеренүләргә керешергә башка авторларның көче җитмәде. Югыйсә Тәлгать аңа яңа чор тудырган яңа типны (тискәре сыйфатта, әлбәттә) эзләү, табу өчен әйбәт оетка салып куйган иде. Детектив әдәбият та тәрбия көченә ия. Нияз Акмал, Госман Гомәр, Әхәт Сафиуллин, Илдус Хуҗин детектив, маҗаралы әсәрләр жанрын бераз тотып тора алдылар, әмма, алга табан эшләр хәрти сыман тоела, бу юлда актив эшләүче язучылар юк диярлек.

Фантастик әсәрләр язу остасы Радик Фәизов бик шәп «Гаделлек иясе» әсәре белән сөендерде безне. «Рәхим итегез, сәр» хикәясе дә кызыклы. Бу өлкәгә Эсфир Яһүдин, Адлер Тимергалин, Заһид Мәхмүди, Флүс Латыйфи, Ринат Якуштан башка килгән кешеләр күренми.

Сатира-юмор—прозаның потенциаль мөмкинлекләре зур булган өлкә. Безнең бер дигән юмор-сатира осталары бар. Бу өлкәдә армый-талмый эшләүче Фәнзаман Баттал. Шунысын әйтеп китү урынлы булыр, Фәнзаман Баттал каләмдәшләре белән булышуга күп көч сарыф итә торган аерым категорияне тәшкил иткән язучыларыбызның берсе. Туфан Миңнуллин, Фоат Садриев, Камил Кәримов, Илфак Шиһапов, Әхәт Сафиуллин кешелекле юмор-сатирада уңышлы эшләүләрен дәвам итәләр. Тәлгать Нәҗмиев Сабаны мәзәкләштереп, мәзәкне сабалаштырып бетерде бугай инде. Ни дисәң дә, Язучылар берлеге әгъзасы Тәлгат Нәҗмиевнең үҗәтлек белән шушы юнәлешне алып баруын хупларга гына кирәк. Юмор-сатира урыста индустрия төсен алганда, бездә бу тармак халыкчанлык дәрәҗәсендә үсеш алып китә алмый әле. Тормыш булгач, укучыга юмор-сатира да кирәк. Юкса, безнең әдәбият тоташ фаталь язмышлы геройлар әдәбиятына әйләнеп бара. Кайбер әсәрләр «фильм ужасов»ны хәтерләтә, янәсе автор тормыш кырыслыгы хакында язып, укучының йөрәгенә шом салып, аны милли, дини тәрбия алырга этәрә. Тик шуны онытмаска иде: куркыту—ул басым ясау, ә басым ясауны, фикерне көчләп тагарга маташуны бер китап та мактамый. Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләре сагындыра, күңел—җан бөеклегенә әйдәүче, яшәүгә оптимизм тәрбияләүче әсәрләргә ныграк тартыла.

Бүгенге прозада әдәби барышны чикли торган тенденцияләрне искә алсак, беренче чиратта, тирән аналитик куәгә ия булган әсәрләр аз. Интеллектуаль әсәрләр язарга сәләтле берничә исем генә әдәбиятның зурлыгын күрсәтә алмый. Нинди дә булса вакыйганы сөйләп бирүгә генә корылган роман-повестьлар белән бүгенге шактый хәзерлекле укучыны әдәби хәяттә тотып тору кыен булачак. Мондый әсәрләрнең эчке энергиясе юк. Милли идеягә дә хезмәт итми алар, актуальлеге дә чамалы. Геройлар сыек буынлы, күңел халәте, эш-гамәле, әсәр буена үсеш-эволюциясе сизелми, бармактан суырып чыгарылган ситуацияләргә корылган схематик әсәр укучыны тиз

ялыктыра. Әсәрләрдә мотивлаштыру, мантыйк искә алынмый, сюжет-борылышлары зәгыйфь, ягъни күп авторлар әсәрне сәнгатьле иткән төп принципларны да санга сукмыйлар. Кайбер исемнәре танылган язучылар, җиңел кулдан әсәр язып ташлап, һәм шуны мактатып язылган рецензияләргә төреп, аның шәп әсәр икәнлегенә үзләрен дә, укучыны да ышандырып, әдәби зәвыкка зур зыян салалар...

Тагын һәрчак борчып торган сорау—прозага яшьләр киләме? Аяз Гыйләҗев бу сорауга: «Проза бит ул шундый нәрсә, көтмәгәндә берәү килеп чыга...» дип җавап биргән иде. Зур проза өчен өлгереп җитүнең «яшь ценз»ы бар—ул 35 яшьләр тирәсе. Дөнья күргән, күңел тарихы, яшәешне аңлауда азмы-күпме тәҗрибәсе булган, тормышка фәлсәфи караш тәрбияләнгән, башкалар күңелен яулап алырлык әсәрләр язарга сәләтле Рахман Шафигуллин, Илдус Хуҗиннар ышаныч уята. Бүген без Алмаз Гыймадиев, Равил Сабыр, Айгөл Әхмәтгалиева, Амур Фәләх, Нурзилә, Рәмзия Габделхакова кебек авторларга өмет баглыйбыз. Алар әле эзләнәләр, иманнарын ныгыталар. Талантларны барлау, табылганнарын югалтмау—берлекнең мөһим бурычы. Бүген берлеккә яшьләр шактый кабул ителде, тик алар арасында прозаиклар юк диярлек. Алынганнары да әдәбиятка, милләткә риясыз хезмәт итәрләрме, юкмы? Бәлки, иҗаты белән ышаныч тудырганнарны беренче нәүбәттә берлек әгъзалыгына кандидатлыкка алу яхшырак һәм мәгънәлерәк булыр? Бу хакта Рифат Сверигин: «Әдәби әсәр иҗат итү инде формалашкан шәхеснең таланты, гражданлык һәм кешелек дәрәҗәсе белән бәйле була» дип күрсәтә. Уйланырга урын бар. Хәзер карап торасың да, әллә берлектә бер детсад бүлеге һәм дә яңа кабул ителгән өлкән яшьтәгеләр өчен ветераннар клубы оештырасы микән дип куясың. Талантларны үстерү, башка төбәкләрдән эзләп табу, зур иҗатка әзерләү максатыннан Казанда бер югары уку йортында бүлек рәвешендә Югары әдәби курслар ачуны кичекмәстән хәл итәргә кирәк. Мәскәүгә җибәреп укыту проблема хәзер, Милли университет юк, әдәбият институты мәңге ачылмаячак, димәк, бер юл—хөкүмәт белән килешеп, быел ук югары белемле талантлы җиде-сигез яшь кешене укыту эшенә, махсус семинарларда тәрбияләү эшенә керешергә кирәк. Семинарларны җитәкләрлек хәзерлекле Туфан Миңнуллин, Марсель Галиев, Мансур Вәли, Флүс Латыйфи, Солтан Шәмси, Галимҗан Гыйльман, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Зиннур Мансуров, Камил Кәримов кебек әдипләребез бар. Шундый остазлар җитәкчелегендә ике-өч прозаик, ике-өч шагыйрь, бер-ике драматург, әдәби тәнкыйтьче быел ук белем эстәүгә керешергә тиеш дип уйлыйм. Әдәбиятның киләчәк язмышы өчен борчылу чынмы, әллә юри генә уфтанып йөрүме—Югары әдәби курслар эшен башлап җибәрү проблемасын хәл итүдә үк күренәчәк. Болай эшли алсак, «башка төбәкләрдән талантлар килми, кан яңармый» дип сыктап йөрүгә дә нокта куелыр иде бәлки.

Миңа проза хакында чыгыш ясарга тәкъдим булгач, бер идарә әгъзасы яныма килеп: «Син аларны мактыйсың гына инде, әйеме?» дип сорады. Ягъни, аның уенча, мин корылтайда проза язучыларны туздырып, тетеп ташларга тиешмен икән. «Нигә аларны хурларга тиешле әле мин?»—дип сорауга каршы сорау бирдем. Шигырь язгалап гомер уздырган кеше роман-повестьлар язуны аңлый алмас шул. Проза жанры язучыдан талант кына түгел, акыл һәм физик энергиясен, тормыш әзерлеге, белем, рухи һәм тән сәламәтлеге таләп итә. Шөкер, бүгенге прозаның уңышы саналган әсәрләрнең фикер структурасы таза, культура катламы тирән. Романнар дистә еллар дәвамында языла, алар—акылның системалы эшчәнлеге продукты. Проза «кәтер» эше, җәза, ә шул хезмәткә әҗер, гонорар юк дәрәҗәсендә! Шундый шартларда прозага тугры калган авторларга рәхмәт кенә әйтергә кирәк. Кыскасы, бүгенге прозага, гомумән әдәбиятка уйламыйча, хаксыз тел-теш тидергән каләм әһелләренә Гомәр Бәшировның «Гыйбрәт» романындагы Садыйк хәлфә сүзләре белән җавап бирәсе дә килә: «Йа Алла, Йа Раббым! Ниләр ишетәсебез бар икән! Ничек син, бичара бәндә, китапка кизәндең?! Ничек син, әлифне таяк дип белмәгән башың белән, китап хәтле китапка тел озайттың? Нәрсәгә кул суздың? Бабайларның акыл хәзинәсенә, гыйлем чишмәсенә!»

Ышанып әйтәм: бүгенге әдипләребез язганнарның зур күпчелеге халкыбызның акыл хәзинәсен арттыруга хезмәт итәр, гыйлем чишмәсенең саф суына кушылып куәтле агымга әверелер!

# Татарстан язучыларының XIV корылтае резолюциясе

Ике корылтай арасында идарә татар әдәбиятын һәм Татарстан язучылары ижатын пропагандалауда, аларның рухи һәм матди мәнфәгатен, милләтара татулыкны кайгыртуда күп кенә эшләр башкарды;

татар әдәбияты хәзинәсендә булган һәм бүгенге әдәби процесста киң танылып өлгергән иң яхшы әсәрләрне нәшер итүдә, аларны бастырып чыгаруда, пропагандалауда әдипләргә ярдәм күрсәтте, дәүләт нәшриятлары белән тыгыз элемтә урнаштырды;

әдипләрнең юбилейларын, ижат кичәләрен, хәтер кичәләрен үткәрүдә актив эш башкарды; Берлек житәкчелеге, идарә бу эшне әдипләрнең туган төбәкләре белән бергә алып барды;

ике корылтай арасында яшь, өметле каләм ияләре тагын бер мәртәбә барлап чыгылды, Берлек янында «Ак каурый» берләшмәсе оешты, «Сабантуй» газетасы белән берлектә «Каурый каләм» конкурсы оештырылды, башкалабызда яшь ижатчыларның семинар-конференциясе узды;

Россиянең татарлар яшәгән төбәкләрендә, Татарстан районнарында татар әдәбияты көннәре уздыру матур традициягә әверелде;

күрше республикалардагы язучылар оешмалары белән тыгыз элемтәләр урнаштырылды;

остаханәләрнең эше жанланды, балалар әдәбияты, әдәби тәнкыйть һәм тәржемә остаханәләренең эше кабат жайга салынды;

Г. Тукай, М. Жәлил, А. Пушкинга багышланган традицион әдәбият-сәнгать көннәре, шигырь бәйрәмнәре даими уздырылып килә;

әдипләрнең матди хәлен кайгырту, тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту — берлек житәкчелегенең, идарәнең төп эшенә әверелде; яна фатирлар алынды, лаеклы ялда булган әдипләргә өстәмә пенсия булдырылды, Татарстан Президенты каршындагы Мәдәнияткә ярдәм күрсәтү фонды белән тыгыз элемтә урнаштырылды;

Язучылар берлеге аппаратында Матур әдәбиятны пропагандалау бүлеге мөдире штаты булдырылды; бу бүлек идарә раслаган план нигезендә актив эш башлап жибәрде;

берлек житәкчелеге, идарә районнар һәм төбәкләр белән тыгыз элемтәләр урнаштырды, килешүләр төзеде, бу килешүләр нигезендә шул төбәкләрдән чыккан әдипләргә матди ярдәмнәр оештырылды;

Мәдәният министрлыгы белән элемтәләр ныгыды, мәдәни чаралар уртак планнарга һәм чыгымнарга нигезләнеп үткәрелә башлады;

мәрхүм әдипләрнең гаиләләрен кайгырту, аларның каберләрен карау, музейларын булдыру — матур гадәтләрнең берсенә әверелде.

Югарыда санап үтелгән унай эшләрне хуплап, корылтай карар бирә:

идарә эшчәнлеген канәгатьләндерерлек дип бәяләргә;

ревизия комиссиясе хисабын расларга.

Шул ук вакытта түбәндәге теләк-тәкъдимнәрне басым ясап әйтергә кирәк:

Язучылар берлеге эшчәнлегенә күбрәк әдипләрнең тартылуын тәэмин итәргә;

яшь ижатчылар белән эшне тагын да ныграк жанландырырга; яшь алмаш белән эшләү буенча рәис урынбасары штатын булдыруны максат итәргә;

халык белән очрашуларны активлаштырырга, бу эшне мәктәп-гимназияләргә һәм авылларга юнәлтергә; очрашуларда күбрәк әдипләрнең катнашуына ирешергә;

остаханәләрнең, кабул итү коллегиясенең эшчәнлегенә таләпне арттырырга, төп игътибарны өметле яшь буын үстерүгә бирергә;

идарәнең киңәйтелгән утырышларын уздыру практикасын дәвам иттерергә; бу утырышларда Берлек, идарә эшенә һәм көндәлек иҗади процесска караган актуаль мәсьәләләрне даими тикшереп барырга;

драматургия һәм публицистика остаханәләрен гамәлгә куюны максатка ярашлы дип санарга;

«Мәйдан» журналын дәүләт бюджеты аша тәэмин итүгә ирешүне максат итәргә, аны республикакүләм әдәби журнал дәрәҗәсенә күтәрергә;

Татарстан Язучылар берлеге каршында әдәби архив бүлеге булдырырга, бу юнәлештә республиканың Дәүләт архивы белән килешеп эшләргә;

нәшриятлар белән элемтәне тагын да ныгытырга, темплан формалаштыру, гонорарларны арттыру мәсьәләләрен бергә хәл итәргә һәм бу мәсьәләләрне даими игътибар үзәгендә тотарга;

әдипләрнең тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту, фатир алу эшчәнлеген тагын да активлаштырырга;

файдалануга тапшырылу алдында торган «Иҗат йорты»ның эшен җайга салырга, аның штатын булдырырга һәм, кагыйдә-шартларын төзеп, идарә тарафыннан расларга;

«Татар әдәбияты музее»н ачу мәсьәләсен хәл итүне хөкүмәт органнары алдына куярга;

Г. Тукай клубы эшчәнлеген җанландырырга, анда әдәбиятны пропагандалау буенча махсус циклларга берләшкән чаралар уздырырга;

«Әдәби фонд»ны Язучылар берлегенә якынайтырга, бу юнәлештә ике оешманың да идарәләре раслаган килешүләр төзергә;

Татарстан Язучылар берлегенең шигърият буенча Һ. Такташ исемендәге еллык бүләген булдыруны иҗат җанландыруда һәм сәнгатьлелекне арттыруда мөһим фактор булыр иде дип исәпләргә;

балалар китабы нәшриятын оештыруны мөһим бурычларның берсе дип санарга;

Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез белән элемтәләрне ныгытуны иҗат берлеге эшенең мөһим бурычы дип санарга, бу төбәкләрдән яшь талантларны эзләүне һәм тәрбияләүне активлаштырырга;

Татарстан язучыларының әсәрләрен рус һәм башка телләргә, чит ил телләренә тәрҗемә итү буенча актив эш алып барырга;

театр эшлеклеләре берлеге белән драматургия өлкәсендә әдәби бүләк булдыру мәсьәләсен хәл итәргә.

Корылтай ышана: яңа сайланган рәис һәм идарә бу һәм башка өлгергән мәсьәләләрне хәл итүдә зирәклек, эзлеклелек һәм оперативлык күрсәтерләр, берлектә чын иҗади мохит тудыруда нәтиҗәле эшләрләр.

Корылтай аларга уңышлар тели!

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫ ТАРИХЫННАН



**Яңа заман татар әдәбияты елъязмасын Язучылар Берлеге (Союзы) тарихыннан башка күз алдына китерү кыен. Татар совет әдәбияты дип йөртелә торган чор турыдан-туры Язучылар оешмасы эшчәнлегенә бәйле; ул—XX гасырның байтак дистә елларында язучыларның иҗади хезмәтен оештыруда үзгә бер идеологик үзәк ролен үтәп килде. Берлек, шулай ук, каләм ияләренең мәнфәгатен кайгыртуда, әдипләрнең иҗаты өчен шартлар тудыруда, көнкүреш хәл-әхвәлләрен яхшыртуда да күп игелекле эшләр башкарды. Тагын ике елдан, ягъни 2004 елда Татарстан Язучылар Берлеге (Союзы) оешуга 70 ел тула. Оешманың иң югары органы—ул съезд (корылтай). Ике съезд арасында житәкчелек функциясен съездда сайланган Идарә башкара. Бу ретроспектив бөлешмәдә моңа кадәр үткәрелгән съездлар һәм аларда сайланган идарә составы турында укучыларыбызга тәфсиллерәк мәгълүмат биреп узабыз.**

## Татарстан язучыларының беренче съезды (1934)

Язучыларның бу беренче жыены рәсми рәвештә совет язучыларының беренче бөтен Татарстан съезды дип аталган. Съезд Татар Дәүләт академия театрында 25 июлендә ачыла, һәм Мәгариф эшчеләре йортында дүрт көн дәвам иткәннән соң, 29 июльдә ябыла. Беренче оештыру съезды шул заманнарга хас булганча үтә тантаналы һәм патетик рухта үтә. Почетлы президиум, плакатлар, котлаулар, көчле кул чабулар... Съездны кыскача кереш сүз белән язучы **Кави Нәҗми** ача. Язучылар Союзын оештыру комитеты председателе **Г. Ризванов**ның өч сәгатьтән артыкка сузылган докладь тыңлана. Съездда иҗат мәсьәләләре буенча Гомәр Гали, Галимжан Нигъмәти, Кәрим Тинчурин, Риза Ишморат, Фатих Кәрим докладлары тыңлана. Чыгыш ясауларда Гази Кашшаф, Хәбра Рахман, Гомәр Толымбайский, Фәтхи Бурнаш, Әхмәт Фәйзи, Мирсәй Әмир, Шамил Усманов, Ибраһим Салахов, Хәсән Туфан, Муса Җәлил һ. б. катнаша. Съездның оештыру эшләре мондый нәтиҗә белән тәмамлана: идарәгә 9 кеше сайлана, янә 3 язучы идарә әгъзалыгына кандидат итеп кертелә, Бөтенсоюз съездына 12 делегат җибәрергә карар кылына. Татарстан Язучылар Союзының беренче идарә составы:

**Кави Нәҗми** *(председатель)*
**Кәрим Тинчурин**
**Гомәр Гали**
**Гомәр Толымбайский**
**Хәсән Туфан**
**Ләбиб Гыйльми**
**Г. Ризванов**
**В. Красный**
**Кәшшаф Тәхфәтуллин** *(секретарь)*

## Икенче съезд (1950)

Татар язучыларының II съезды, беренче оештыру съездыннан соң, озакка сузылган өзеклек белән, фәкать 16 елдан соң гына жыела. Тарих өчен сәбәпләр аңык: шәхес культы чоры, Ватан сугышы еллары... Татар язучыларының күпләп кырылган, юк ителгән дәвере.

II съезд 1950 елның 13-15 июнь көннәрендә Казанда үтә. Съездда язучылардан тыш, республика житәкчеләре, СССР Язучылар союзы һәм үзәк нәшрият вәкилләре, фән эшлекләре, журналистлар, укытучылар, әдәби

ижат белән шөгыльләнүче студент яшьләр катнаша. Татарстан совет язучылары союзы идарәсенең эше турында хисап докладын **Гази Кашшаф** ясый. Ревизия комиссиясе отчеты белән Гариф Гобәй чыга. Фикер алышуларда 29 кеше катнаша. Алар арасында—Г. Әпсәләмов, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, Г. Гулиа (Мәскәү), С. Баттал, Ш. Мөдәррис, С. Кирьянов (Мәскәү), З. Мансур, М. Хөсәен, М. Максуд, И. Нуруллин, Ә. Давыдов, М. Елизарова, Х. Рәхмәтуллин (ВКП(б) өлкә комитеты секретаре), Г. Насрый, А. Гомәр һ. б.

Съезд Татарстан совет язучыларының эшен канәгатьләнерлек дип тапмый һәм киләчәктә эшне яхшыртуга юнәлтелгән карарлар кабул итә. Съездда яшерен тавыш бирү тәртибендә Татарстан Язучылары союзы идарәсенә түбәндәге язучылар сайлана:

**Гариф Гобәй** *(председатель)*
**Кави Нәҗми**
**Гомәр Бәширов**
**Мирсәй Әмир**
**Гали Халит**
**Риза Ишморат**
**Константин Лебедев**
**Әхмәт Исхак**
**Нәкый Исәнбәт**
**Ибраһим Гази**
**Салих Вәлиди** *(җаваплы секретарь).*

«Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы итеп **Гази Кашшаф** раслана.

## Өченче съезд (1954)

Съезд 24-26 июнь көннәрендә Казанда үтә. Съездда төп ике доклад тыңлана. «Татар совет әдәбиятының торышы һәм бурычлары» **(Гомәр Бәширов)**, «Татар совет әдәби тәнкыйте һәм бурычлары» **(Гали Халит)**. Көн тәртибенең калган мәсьәләләре нигездә хисап һәм оештыру эшләренә бәйле: ревизия комиссиясе эшен тыңлау, идарә һәм II Бөтенсоюз съездына делегатлар сайлау (Шунысы игътибарга лаек: моннан 50 еллар элек тә әдәби тәнкыйть мәсьәләсе актуаль һәм әдәби җәмәгатьчелекнең күз уңында булган. Ирексездән Тукайның «тәнкыйть кирәкле шәйдер» дигән сүзләре хәтергә килә). Докладлар буенча фикер алышуда С. Хәким, М. Дудин (Ленинград) Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Ю. Лебединский (Мәскәү), Ф. Хөсни, К. Нәҗми, И. Гази, Г. Мөсрепов (Казахстан), М. Максуд, Х. Хәйри, Ә. Давыдов һ. б. (барлыгы 28 кеше) катнаша. Яшерен тавыш бирү тәртибендә Татарстан Язучылар союзы идарәсенә түбәндәге язучылар сайлана:

**Гомәр Бәширов** *(председатель)*
**Сибгат Хәким**
**Гази Кашшаф**
**Хәсән Хәйри**
**Фатих Хөсни**
**Тажи Гыйззәт**
**Әнвәр Давыдов** *(җаваплы секретарь)*
**Габдрахман Әпсәләмов**
**Бруно Зернит**

## Дүртенче съезд (1958)



Татарстан язучыларының IV съезды 16 июнь көнне Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында ачыла һәм дүрт көн дәвам итеп, 19 июньдә тәмамлана. Съездны **Нәкый Исәнбәт** (стенографик язмада ул күренекле карт язучыбыз дип теркәлгән. Ана ул вакытта 59 яшь) ача. Съездда Татарстан Язучылар Союзы идарәсенең эше турында **Гомәр Бәширов**, татар поэзиясенең торышы турында Сибгат Хәким, проза әсәрләре турында Хәсән Хәйри, драматургия турында Гази Кашшаф, Татарстанда яшәүче рус язучылары турында Геннадий Паушкин докладлар белән чыгалар. Татар язучыларының съездын котлап килгән кунаклар В. Кожевников (Мәскәү), Б. Кербабаев (Төрекмәнстан), С. Смирнов (Мәскәү), С. Кудаш (Башкортстан), Ә. Мохтар (Үзбәкстан), Ж. Муллагалиев (Казакъстан) һ. б. чыгыш ясый. Докладлар буенча фикер

алышуларда Ф. Хәсни, Н. Дәүли, Х. Госман, И. Пехтелев, С. Баттал, Ә. Ерикәй, Н. Фәттах, М. Максуд, Г. Ахунов, Х. Якупов, Ж. Фәйзи, Ш. Хөсәенов һ. б. катнаша. 19 июньдә Татарстан язучыларының IV съезды яңа идарә, ревизия комиссиясе һәм РСФСР язучылар съездына делегатлар сайлый. Идарә составына түбәндәге язучылар кергән:

**Афзал Шамов** *(председатель)*
**Мирсәй Әмир**
**Сибгат Хәким**
**Гомәр Бәширов**
**Фатих Хәсни**
**Ләбибә Ихсанова**
**Зәки Нури** *(җаваплы секретарь)*
**Гази Кашшаф**
**Геннадий Паушкин**
**Гариф Ахунов**
**Абдулла Гомәр**

Шул ук көнне яңа сайланган идарәнең беренче утырышы була, «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы итеп **Абдулла Гомәр** раслана.

## Бишенче съезд (1963)

Съезд 7 февральдә М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында ачыла. Татарстан язучылары белән бергә, кунак сыйфатында союздаш һәм автономияле республика вәкилләре, республиканың партия-совет җәмәгатьчелеге, сәнгать һәм фән эшлеклеләре катнашкан бу җыен 8-9 февральләрдә үз эшен КПСС Өлкә Комитетының конференц залында дәвам итә. Съездда «Татарстан Язучылары Союзының идарәсе эше» **(Мирсәй Әмир)**, «Бүгенге татар поэзиясе» (Нил Юзиев), «Татар балалар әдәбияты» (Җәвад Тәрҗеманов), «Әдәби тәнкыйтебезнең торышы» (Гали Халит), «Татарстандагы рус язучылары иҗаты» (Геннадий Паушкин) турында докладлар тыңлана. Чыгыш ясауларда Г. Бәширов, С. Баруздин (Мәскәү), Г. Әпсәләмов, М. Кәрим (Уфа), С. Хәким, Г. Ахунов, Ә. Давыдов, А. Шамов, Я. Ухсай (Чабаксар), Р. Мостафин, Ф. Хәсни, Р. Төхфәтуллин һ. б. катнаша. Съездның 10 февральдә язучылар Тукай клубында (Бауман, 19) үткән соңгы утырышында 17 кешедән торган яңа идарә составы сайлана. Алар:

**Мирсәй Әмир** *(председатель)*
**Габдрахман Әпсәләмов**
**Гомәр Бәширов**
**Хәсән Туфан**
**Фатих Хәсни**
**Зәки Нури**
**Газиз Мөхәммәтшин**
**Рафаэль Мостафин** *(җаваплы секретарь)*
**Ләбибә Ихсанова**
**Гариф Ахунов**
**Илдар Юзеев**
**Хәй Вахит**
**Хатип Госман**
**Александр Булгаков**
**Шәүкәт Галиев**
**Гали Халит**
**Геннадий Паушкин**

## Алтынчы съезд (1965)

Татарстан язучыларының чираттан тыш җыелган бу съезды 1965 елның 14-15 январь көннәрендә үтә. Съездда Союз идарәсе председателе **Мирсәй Әмир** татар әдәбиятының торышы һәм бурычлары турында доклад ясый. Доклад буенча фикер алышуларда Г. Әпсәләмов, И. Нуруллин, Б. Гыйззәт, Ж. Тәрҗеманов, И. Гази, А. Булгаков, Г. Ахунов, З. Мәҗитов, съездга кунак булып килгән Мәскәү язучылары Л. Соболев, С. Михалков, Б. Дубровин, чуваш язучысы Н. Ильбеков һ. б. катнаша. Съездда, шулай ук, КПСС өлкә комитеты секретаре З. Тутаев чыгыш ясый. Аннары съезд РСФСР Язучыларының II съездына делегатлар сайлый. Алар—М. Әмир, Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, Р. Ишморат, Л. Соболев, Ф. Хәсни, С. Хәким, Ә. Исхак, Г. Ахунов, З. Нури, Г. Минский, С. Радзиевская һәм А. Расих.

Язучыларның VI съездында, саналган кунаклардан тыш, күренекле

язучылардан А. Алексин, Л. Андреевская, М. Львов, Р. Моран һәм Мостай Кәрим катнаша.

РСФСР язучыларының II съезды алдыннан чираттан тыш үткәрелгән жыенда яңа идарә сайланмый, үткән V съездда сайланган идарә үз эшчәнлеген дәвам иттерә.

## Җиденче съезд (1968)



Бу съезд Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында 25-26 мартларда уза. Залда күренекле шагыйрьләр, прозаиклар, драматурглар, тәнкыйтьчеләр, СССРның һәм республиканың төрле почмакларыннан килгән яшь һәм башлап язучылар, партия-совет оешмалары вәкилләре, мәдәният әһелләре, тугандаш республикалардан килгән кунаклар, матур әдәбият сөючеләр... Съездны аксакал язучы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты **Гомәр Бәширов** ача. Идарәнең ике съезд арасындагы (1965-1968) эшчәнлеге турында хисап докладны, идарә рәисе буларак, Мирсәй Әмир ясый. Ул язучылар ирешкән уңышлар һәм алда торган бурычлар турында сөйләп, язучылар оешмасының 25 кешегә артуын әйтә, СССР язучылар әгъзасы булган язучыларның саны 111 кешегә житкәнен билгеләп. Доклад буенча фикер алышуларда Г. Ахунов, Л. Татьяничева (Мәскәү), Л. Ихсанова, Ф. Хөсни, Г. Камалиев (нәшрият директоры), Р. Мостафин, Х. Гыйлажев (Уфа), Р. Харисов, В. Ганиев (Мәскәү), Ш. Рәкыйпов, Ә. Давыдов, А. Калган (Чувашстан), А. Расих, М. Сәлимжанов (режиссер), Сәхип Җамал (гарәп язучысы), Җ. Тәржеманов һ. б. катнаша. КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев зур речь белән чыгыш ясый. (Шулай ук, бер төркем яшь язучылар яшьләр өчен әдәби журнал таләп итеп балконнан өндәмәләр дә очырдылар бу съездда...) 26 мартта яңа идарә сайлана. Аның составына түбәндәге язучылар керә:

**Ибраһим Гази** *(председатель)*
**Мирсәй Әмир**
**Гариф Ахунов**
**Гомәр Бәширов**
**Зәки Нури** *(җаваплы секретарь)*
**Равил Фәйзуллин**
**Хәсән Туфан**
**Фатих Хөсни**
**Сибгат Хәким**
**Афзал Шамов**
**Риза Ишморат**
**Хатип Госман**
**Гази Кашшаф**
**Илдар Юзеев**
**Владимир Синев**
**Ләбибә Ихсанова**
**Рафаэль Мостафин**

## Сигезенче съезд (1974)

Съезд 24-25 май көннәрендә Казанның Политик-мәгариф йортында уза. Татарстан язучылар союзы идарәсенең 1968-1974 еллардагы оештыру-иҗат эшчәнлеге турында отчет-хисап докладын **Зәки Нури** ясый. Моннан тыш, проза турында Гариф Ахунов, поэзия турында Илдар Юзеев, драматургия буенча Туфан Миңнуллин, тәнкыйть турында Рафаэль Мостафин, балалар әдәбияты буенча Ләбибә Ихсанова, рус язучыларының иҗаты турында Тихон Журавлев докладлары тыңлана. Ревизия комиссиясенең отчетын комиссия председателе Гариф Гобәй ясый. 25 май көнне докладлар буенча фикер алышуларда Р. Ишморат, Ә. Баян, Ү. Саттаров, С. Хәким, Р. Фәйзуллин, Н. Жиһанов (композитор), Ф. Миннуллин, Ш. Хамматов, Х. Госман, А. Әхмәдуллин, Ә. Маликов, Р. Җиһаншина (артистка), Ә. Тумашев (рәссам) һ. б. катнаша. Съездга килгән кунаклардан С. Михалков (Мәскәү), О. Савицкий (Минск), Ф. Гарин (Киев), Б. Байкабулов (Ташкент), А. Алиев (Ашхабад), А. Аетбаева (Фрунзе), И. Араз (Баку), Н. Дедушкин (Чабаксар), И. Пеняев (Саранск), С. Вишневский (Йошкар-Ола), Г. Сабитов (Ижевск) котлау-

чыгышлары ясыйлар. Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев речь белән чыга. Съезд тикшерелгән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә, союзның җитәкче органнарын сайлый. Идарә составына түбәндәге язучылар сайлана:

**Гариф Ахунов** *(председатель)*
**Равил Фәйзуллин** *(җаваплы секретарь)*
**Мирсәй Әмир**
**Азат Әхмәдуллин**
**Гомәр Бәширов**
**Әхсән Баянов**
**Марсель Зарипов**
**Мәдинә Маликова**
**Әдип Маликов**
**Туфан Миңнуллин**
**Зәки Нури**
**Вакыйф Нуруллин**
**Геннадий Паушкин**
**Атилла Расих**
**Шамил Рәкыйпов**
**Гәрәй Рәхим**
**Хәсән Туфан**
**Мөсәгыйт Хәбибуллин** *(оештыру эшләре буенча секретарь)*
**Сибгат Хәким**
**Марс Шабаев**
**Илдар Юзеев**

Ревизия комиссиясе председателе итеп Рәис Даутов сайлана.

## Тугызынчы съезд (1979)

Татар язучыларының IX съезды 23-24 май көннәрендә үтә. Анда СССР Язучылар членнарыннан һәм башлап язучылардан өч йөзгә якын кеше, Мәскәүдән союздаш һәм автономияле республикалардан килгән кунаклар, Татарстанның партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары вәкилләре, сәнгать эшлеклеләре, промышленность, авыл хуҗалыгы һәм культура хезмәткәрләре катнаша. Съездны шагыйрь **Сибгат Хәким** ача. Республика язучыларының иҗаты һәм идарә эшчәнлеге турында хисап докладын **Гариф Ахунов** ясый. Ревизия комиссиясенең биш еллык эше белән Рәис Даутов таныштыра. Өстәмә докладлар—Атилла Расих (проза), Нил Юзиев (поэзия), Азат Әхмәдуллин (драматургия), Мөхәммәт Мәһдиев (тәнкыйть), Шәүкәт Галиев (балалар әдәбияты), Марсель Зарипов (очерк һәм публицистика), Геннадий Паушкин (рус язучылары иҗаты), Илдар Юзеев (яшь язучылар белән эшләү), Әдип Маликов (Әлмәт оешмасы эшчәнлеге) тыңлана. Фикер алышуларда З. Нури, Р. Мостафин, Ә. Гаффар, Ф. Мусин, К. Тимбикова, Ә. Тумашев (Рәссамнәр союзы), В. Нуруллин, Ш. Хамматов (Журналистлар союзы), Ф. Газизуллин (Комсомолның өлкә комитеты секретаре. Хәзерге көндә Дәүләт милке буенча Россия министры—ред.), Ф. Әхмәтов (Композиторлар союзы) һ. б. катнаша.

Съезд кунаклары С. Михалков (Мәскәү), Ә. Мирзаһитов (Башкортстан), А. Мороз (Украина), Ш. Муртазаев (Казакъстан), Л. Прокша (Белоруссия), А. Емельянов (Чувашстан), О. Абдрахманов (Каракалпакстан), Н. Нефедов (Мәскәү) татар әдәбиятын олылап, коллегаларына тәбрик һәм кинәш сүзләрен җиткерәләр. Съездда, шулай ук КПСС өлкә комитетының идеология буенча секретаре М. Вәлиев чыгыш ясый.

Съезд Татарстан Язучылар союзы идарәсен түбәндәге составта сайлый:

**Гариф Ахунов** *(председатель)*
**Азат Әхмәдуллин**
**Әхсән Баянов**
**Шәүкәт Галиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Әдип Маликов**
**Мәдинә Маликова**
**Туфан Миңнуллин**
**Роберт Миңнуллин**
**Фәрваз Миңнуллин** *(җаваплы секретарь)*
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Зәки Нури**
**Вакыйф Нуруллин**
**Геннадий Паушкин**
**Атилла Расих**
**Хәсән Туфан**
**Равил Фәйзуллин**
**Сибгат Хәким**
**Ренат Харис**
**Илдар Юзеев**

Республика Язучылар союзының ревизия комиссиясе председателе итеп яңадан Рәис Даутов, Әдәби Фонд председателе итеп **Азат Әхмәдуллин** сайлана.

## Унынчы съезд (1984)



21-22 май көннәрендә Казанның Политик-мәгариф йортында Татарстан язучыларының X съезды үтә. Съездны РСФСРның М. Горький исемендәге, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, шагыйрь **Сибгат Хәким** ача. Республика язучыларының иҗади эшчәнлеге һәм идарәнең ике съезд арасындагы биш еллык эше турындагы отчет-хисап докладын идарә председателе **Гариф Ахунов** ясый. Съездның беренче көнендә өстәмә докладлар да тыңлана: поэзия (Илдар Юзеев), проза (Мөхәммәт Мәһдиев), драматургия (Туфан Миңнуллин), тәнкыйть (Тәлгат Галиуллин), балалар әдәбияты (Шәүкәт Галиев), очерк һәм публицистика (Марсель Зарипов), рус язучыларының иҗаты (Нонна Орешина), тәрҗемәчеләр эшчәнлеге (Кыям Миңлебаев).

22 майда съезд эшен дәвам иттерә, докладлар буенча фикер алышулар була. Чыгыш ясаучылар С. Михалков (Мәскәү), Разил Вәлиев, Р. Мөхәммәдиев, Р. Мингалим, Р. Миңнуллин, Н. Доризо (Мәскәү), Р. Харис, Г. Шәрәфетдинов (Татарстан китап нәшрияты директоры), Б. Мөлеков (композитор) һ. б.

Татарстан язучылары форумын Ә. Мирзаһитов (Башкортстан) А. Емельянов (Чувашстан), Г. Имамвердиев (Азәрбайҗан), В. Карамазов (Белоруссия), К. Укаев (Кыргызстан), Т. Тула (Үзбәкстан), Н. Бәйрәмов (Төрекмәнстан), Т. Җумаморатов (Каракалпакстан), Н. Рыбаков (Мари-Эль), С. Самсанов (Удмуртия) тәбрикли. Съездда, шулай ук, КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев чыгыш ясый.

Съезд Татарстан Язучылар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составларын сайлый. Съездда сайланган идарә әгъзалары:

**Туфан Миңнуллин** *(председатель)*
**Азат Әхмәдуллин**
**Гариф Ахунов**
**Николай Алешков**
**Әхсән Баянов**
**Разил Вәлиев** *(председатель урынбасары)*
**Шәүкәт Галиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Әхәт Гаффар**
**Аяз Гыйләҗев**
**Зөлфәт Маликов**
**Әмирхан Еники**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Мәдинә Маликова**
**Роберт Миңнуллин**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Флүн Мусин**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Вакыйф Нуруллин**
**Нонна Орешина**
**Равил Фәйзуллин**
**Мөсәгыйт Хәбибуллин** *(җаваплы секретарь)*
**Сибгат Хәким**
**Ренат Харис**
**Илдар Юзеев**

Ревизия комиссиясе председателе итеп яңадан Рәис Даутов сайлана. «Казан утлары» журналының баш редакторы итеп **Ренат Харис** раслана.

## Унберенче съезд (1989)



Съезд 17 майда Казанда, В. И. Ленин Үзәк музееның Казан филиалында ачыла, икенче көнне Язучылар союзының Г. Тукай исемендәге клубында (Комлев 14) дәвам итә. Съездны кереш сүз белән Татарстанның халык язучысы **Әмирхан Еники** ача. Республика язучыларының иҗаты турындагы отчет-хисап докладын идарә председателе **Туфан Миңнуллин** ясый. Аннары, жанрлар буенча өстәмә докладлар—проза (Фәрваз Миннуллин), поэзия (Тәлгат Галиуллин), драматургия (Азат Әхмәдуллин), рус язучылары иҗаты (Михаил Скороходов), балалар әдәбияты (Роберт Миннуллин), очерк һәм публицистика (Газиз Кашапов), «Казан утлары» журналы эшчәнлеге (Ренат Харис), тәрҗемә (Солтан Шәмси)—тыңлана.

Фикер алышуларда Р. Мөхәммәдиев, Н. Әхмәдиев, Разил Вәлиев, Р. Кутуй, С. Наметбаев (Кыргызстан), Р. Фәйзуллин, Ә. Рәшитов, Ә. Мәхмүдов, Ф. Мусин, И. Салахов, Ә. Гаффар, Р. Хәмид, Р. Мингалим, Ш. Янбаев (Башкортстан), Мансур Вәлиев, И. Нуруллин һ. б. катнаша.

Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре Р. Идиатуллин, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе С. Михалков чыгыш ясый.

Съезд яшерен тавыш бирү юлы белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе итеп Ринат Мөхәммәдиевне, «Казан утлары» журналының баш редакторы итеп **Ренат Харисны** сайлый. XI съездда сайланган 23 кешелек идарә составы:

**Ринат Мөхәммәдиев** *(председатель)*
**Роберт Батулла**
**Әхсән Баянов**
**Мансур Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Аяз Гыйләҗев**
**Әмирхан Еники**
**Фәиз Зөлкарнәев**
**Ркаил Зәйдуллин**
**Газиз Кашапов**
**Владимир Корчагин**
**Рифкат Кәрами**
**Мәдинә Маликова** *(председатель урынбасары)*
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Роберт Миңнуллин**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Ибраһим Нуруллин**
**Гәрәй Рәхим**
**Равил Фәйзуллин**
**Ренат Харис**
**Нур Әхмәдиев**

## Уникенче съезд (корылтай) 1994

3 июньдә Казанның Актерлар йортында Татарстан язучыларының XII корылтае уза. Аны, кыскача кереш сүз белән Татарстанның халык язучысы **Гомәр Бәширов** ача.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең 1989-94 еллардагы эшчәнлеге турында идарә рәисе **Ринат Мөхәммәдиев** хисап тота.

Язучылар корылтаенда Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев чыгыш ясый. Иң элек ул Татарстандагы бүгенге сәяси һәм икътисадый хәлләр турында сөйли. Аннары Президент Татарстан белән Россия арасында төзелгән Шартнамәгә һәм Б. Н. Ельцинның Татарстанга визиты йомгакларына кагылышлы фикерләре белән уртаклаша, татар телен дәүләт теле буларак тормышка ашыру, татар мәктәпләре һәм балалар учреждениеләре санын арттыру, газета-журналлар нәшер итү, китап бастыру, язучыларның матди хәлләрен җиңеләйтү, аларга иҗат мөмкинлекләре тудыру мәсьәләләренә дә киң тукта.

Аннары ревизия комиссиясе отчеты (Р. Даутов), төрле жанрлар буенча докладлар—поэзия (Г. Морат), драматургия (Р. Мингалим), балалар әдәбияты (Р. Миңнуллин), әдәби тәнкыйть (Ф. Зөлкарнәй), тәрҗемә (К. Миңлебаев), рус әдәбияты (В. Корчагин) тыңлана. Проза (Ә. Гаффар) һәм публицистика (М. Зарипов) буенча докладлар тыңлаучылар таләбе буенча тулысынча яңгырамый. Фикер алышуларда Р. Фәйзуллин, С. Михалков (Мәскәү), Ә. Баян, Ә. Еники, Ф. Баттал, Г. Ахунов, С. Баттал, Т. Галиуллин, Р. Хисмәтуллин, М. Нәзиров (Уфа), Р. Вәлиуллин, З. Зәйнуллин, М. Маликова, Т. Пулатов (Мәскәү), Х. Әшрафҗанов катнаша.

Корылтайда Татарстан Язучылар берлегенең төзелешен үзгәртеп кору хакындагы декларация кабул ителгәч, ачык тавыш бирү юлы белән яңа идарә әгъзаларын сайлау була. Алар:

**Ринат Мөхәммәдиев** *(идарә рәисе)*
**Гариф Ахунов**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Әхсән Баян**
**Фәүзия Бәйрәмова**
**Разим Вәлиуллин**
**Әхмәт Гадел**
**Шәүкәт Галиев**
**Фоат Галимуллин**

**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Вахит Имамов**
**Владимир Корчагин**
**Рәфкат Кәрами**
**Мәдинә Маликова**
**Зиннур Мансуров** *(рәис урынбасары)*
**Рөстәм Мингалим**
**Роберт Миңнуллин**
**Рашат Низамиев**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Мансур Шиһапов** *(рәис урынбасары)*
**Илдар Юзеев**
**Азат Әхмәдуллин**
**Харрас Әюпов**

## Унөченче корылтай 1999

28 майда башкалабызның Актерлар йортында Татарстан язучыларының XIII корылтае ачыла. Иң башта корылтай делегатлары соңгы 5 елда арабыздан киткән каләмдәшләребезне (алар—40 кеше), аягүрә басып, бер минутлык тынлык белән искә ала.

Корылтайны татар әдәбияты аксакалы—90 яшьлек әдип **Әмирхан Еники** ача. Ике корылтай арасында идарә тарафыннан башкарылган эшләр турында хисап докладын Татарстан Язучылар берлеге рәисе **Ринат Мөхәммәдиев** ясый.

Корылтай эшендә катнашкан Татарстан Республикасы Президенты **Минтимер Шәймиев**, җыенны котлап, җәмгыятебезне үзгәртеп коруга, әдәбиятыбызны баетуга керткән өлешләре өчен, язучыларга рәхмәт белдерә һәм әдипләр алдында торган бурычлар турында сөйли. Аннары ул «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь **Равил Фәйзуллин**га «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелүен игълан итә һәм диплом тапшыра.

Корылтайда катнашучылар әдәбиятыбызның бүгенге прозасы, очерк һәм публицистикасы, шигърияте, драматургиясе, балалар әдәбияты һәм рус әдәбияты турында Фоат Галимуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Фәрит Яхин, Юныс Сафиуллин, Галимҗан Гыйльманов, Владимир Корчагин докладларын тыңлыйлар. Фикер алышуларда Ә. Баян, Ш. Галиев, Т. Миңнуллин, Г. Ахунов, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, А. Хәлим, Р. Батулла, Л. Ихсанова, Л. Шагыйрьҗан, З. Зәйнуллин, К. Булатова, Р. Җамал (Корбанов), М. Маликова, А. Хәсәнов, Ә. Гадел, Д. Салихов һ. б. чыгыш ясый.

Гадәттәгедән үзгә буларак, бу корылтай планлаштырылган көнендә үз эшен тәмамлый алмый. Яңа идарә һәм аның җитәкчесе ике ай чамасы вакыт үткәннән соң, июль ахырында (27 июль) гына сайлана. Корылтайда Татарстан Язучылар берлеге рәисе итеп **Фоат Галимуллин** сайлана. Яңа идарә составына түбәндәге язучылар керә:

**Харрас Әюпов**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Мансур Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Разим Вәлиуллин**
**Әхмәт Гадел**
**Марсель Галиев**
**Фоат Галимуллин** *(рәис)*
**Галимҗан Гыйльманов** *(рәис урынбасары)*
**Җәүдәт Дәрзаманов**
**Вахит Имамов**
**Рәфкат Кәрамиев**
**Владимир Корчагин**
**Ләбиб Лерон**
**Зиннур Мансуров**
**Газинур Моратов**
**Шаһинур Мостафин** *(рәис урынбасары)*
**Рашат Низамиев**
**Гәрәй Рәхим**
**Равил Рахмани**
**Данил Салихов**
**Нәҗибә Сафина**
**Равил Фәйзуллин**
**Мөсәгыйт Хәбибуллин**
**Айдар Хәлим**
**Солтан Шәмси**
**Фәрит Яхин**

Контроль-ревизия комиссиясе рәисе итеп язучы Лерон Хәмидуллин сайлана.

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире вазифасына **Равил Фәйзуллин** раслана. Аңа, шулай ук, Кабул итү Коллегиясен җитәкләү эше дә йөкләнә.

Иҗат остаханәләре җитәкчеләре итеп Солтан Шәмси (проза), Зиннур Мансуров (шигърият), Равил Рахмани, соңыннан Җәүдәт Дәрзаманов (балалар әдәбияты), Мансур Вәлиев (әдәби тәнкыйть), Кыям Миңлебаев (әдәби тәрҗемә), Владимир Корчагин (рус әдәбияты), яшь каләм ияләре белән эшләү бүлеге җитәкчесе итеп Фирдәүс Әһлия билгеләнә.

Идарәдә Әлмәт язучылар оешмасына Разим Вәлиуллин, Чаллы Язучылар оешмасына Вахит Имамов җитәкчеләр итеп сайлана.

## Унdүртенче корылтай (2002)

Шушы елның 31 маенда К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында Татарстан язучыларының XIV корылтае булды. (Журналыбызның алдагы саннарында бу хакта материаллар урнаштырган идек инде.) Аны кереш сүз белән яшь агыннан иң өлкән язучы **Сафа Сабиров** ачты.

Корылтайда катнашучыларны Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев котлады. «Язучыларның зур жыелышы—Татарстан өчен гаять әһәмиятле вакыйга»,—диде ул үзенең чыгышында.

Язучылар берлеге идарәсенең ике корылтай арасындагы эшчәнлеге турындагы хисап доклады белән идарә рәисе **Фоат Галимуллин** чыкты. Ревизия комиссиясе хисабын Лирон Хәмидуллин ясады. Әдәби жанрлар буенча Резеда Әхтәмова (шигърият), Факил Сафин (проза һәм публицистика), Рафис Корбан (балалар әдәбияты), Дания Гыймранова (драматургия), Мансур Вәлиев (әдәби тәнкыйть), Флера Сафиуллина (әдәби тел мәсьәләләре), Лилия Газизова (рус язучылары иҗаты) өстәмә докладлар ясадылар.

Докладлар буенча фикер алышуда Г. Зәйнашева, Г. Рәхим, В. Имамов, Р. Вәлиуллин, З. Мансуров, М. Маликова, Р. Батулла, Ф. Бәйрәмова, Ж. Дәрзаман, Л. Шагыйрьҗан, З. Зәйнуллин, А. Хәлим, В. Лавришко, И. Хөснетдинов һ. б. чыгыш ясады.

Корылтайда альтернатив нигездә күпчелек тавыш белән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп Фоат Галимуллин сайланды. Берлек идарәсенә түбәндәге язучылар керде:

**Харрас Әюпов**
**Фәүзия Бәйрәмова**
**Мансур Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Разим Вәлиуллин**
**Лилия Газизова**
**Фоат Галимуллин** *(рәис)*
**Галимҗан Гыйльман** *(рәис урынбасары)*
**Җәүдәт Дәрзаман**
**Вахит Имамов**
**Рәфкать Кәрами**
**Зиннур Мансуров**
**Хатип Миңнегулов**
**Газинур Морат**
**Шаһинур Мостафин** *(рәис урынбасары)*
**Рашат Низами**
**Гәрәй Рәхим**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Мөсәгыйт Хәбибуллин**
**Зиннур Хөснияр**
**Солтан Шәмси**

Язучылар корылтаенда Ф. Зыятдинов җитәкчелегендә ревизия комиссиясе сайланды.

Корылтайда резолюция һәм халык санын алу уңаеннан язучыларның татар халкына мөрәҗәгате кабул ителде.

Корылтай эшендә Татарстан Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева катнашты һәм чыгыш ясады.

*Белешмә материалны журнал өчен* **Р. ГАБДРАХМАНОВ** *әзерләде.*

Тагix
Тарих

**Булат Хәмидуллин**

# 1552 ЕЛ ФАҖИГАСЕ ТАРИХ БИТЛӘРЕНДӘ

*Казанга һичбер җирдән ярдәм һәм таяныч ирешмәс,*
*Бары тик Тәңре якын һәм фәрешталәр ярдәмче.*

Шәриф Хажитархан
«Казан вилаятенең җинүс» дигән әсәрдән.

1445 елда, Җучи Олысы киңлекләрендә оешкан, шул ук вакытта Идел Болгарстанының да этнополитик варисы булып торган Казан ханлыгының яңа ханы итеп Олуг Мөхәммәд углы Мәхмүт күтәрелә. Никон елъязмасында бу хакта болай дип язылган: «Царь Мамутяк пришед из Курмыша Казань взял, а казанского князя Азыя убил, а сам на Казани воцарился, и оттоле нача царство быти казанское». Воскресенск елъязмасын төзүче шушы вакыйга хакында башкачарак язып калдырган: «Тое же осени [1445 года] царь Мамотяк, Улу-Магметов сын, взял город Казань, вотчича казанского князя Либея убил, а сам в Казани сел царствовати». Билгесез бер Казан елъязмачысы исә, «Казан тарихы»ның авторы (XVI гасырның урталары) Олуг Мөхәммәдне Казанның беренче ханы дип атап, биредә Олуг Мөхәммәднең даирәсе көчәеп китүне күреп, бик үзенчәлекле нәтиҗә ясап куя: «И рады ему бысть изо оставшихся от плена худые болгары. И молиша его казанцы быти ему заступника бедам их, и помощника от насилия, воевания русского, и быти царьству строителя»...

Билгеле булганча, Казан ханлыгы ул чагында таралырга өлгергән Алтын Урда империясенең төньяк биләмәләренең күпчелек өлешен хасил иткән. Көнбатышта аның чикләре Сура елгасы буйлап узган, төньякта Урта Нократ һәм Кама чикләренә җәелгән, көнчыгыштан Урал тау тезмәләренә килеп терәлгән, көньяктан нугай татарлары биләмәләре белән чикләшкән. Ханлыкның биләмәләре башка күрше дәүләтләрнекеннән үзенең мул сулы елга-инешләре, уңдырышлы басу-кырлары, тугай-болыннары, агачка бай урманнары белән аерылып торган һәм Нугай Урдасына табан мал асрау өчен уңайлы иксез-чиксез, мул үләнле дала киңлекләре җәелеп киткән; кыскасы, табигать байлыклары гаҗәеп бай булып, Казан татарларына, мариларга, мордваларга, удмуртларга һәм чуашларга—ягъни анда яшәүче барлык полиэтник кабиләләргә гаҗәеп уңайлы шартлар тудырылган булган. Казан елъязмачысының язуына караганда, Казан ханлыгы: «... место пренарочито и красно велми, и скотопажитно, и пчелисто, и всяцеми земными семяны родимо, и овощи преизобилно, и зверисто, и рыбно, и всякого угодья много, яко не мощно обрести другаго такова места во всей Русской нашей земли нигдеже таковому подобно месту красотою и крепостию и угодием человеческим», дип бәяләнә; ә кенәз Андрей Курбский фикеренчә: «...понеже в земле той поля великие и зело преизобильныя и гобзующия на всякие плоды; такоже и дворы княжат и вельможей зело прекрасны и воистину удивления достойны, и села часты; хлебов же всяких такое там множество, воистину вере ко исповеданию неподобно: аки бы на подобие множества звезд небесных;

тако же и скотов различных стад безчисленное множество, и корыстей драгоценных, наипаче от различных зверей, в той земле бывающих: бо тамо родятся куны дорогие, и белки и прочия зверия ко одеждам и ко ядению потребные; и мало за тем далей соболей множество, такожде и мехов: не вем, где бы под солнцем больше была».

Инде әйтеп үткәнебезчә, этник составы ягыннан Казан ханлыгының халкы шактый чуар булган. Шул ук Андрей Курбский язганча, татарлардан тыш анда тагын биш телдә—мордвача, чуашча, марича, вотякларча, або арча [удмуртча] һәм башкортча сөйләшкәннәр. Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, XIV-XVI гасырларга караган бер генә чыганакта да бер генә татар булмаган халыкны Казан ханлыгы составына көчләп куып керту күрсәтелми. Бу дәүләт, мөгаен, төрки һәм фин-угор халыкларының үз теләкләре белән төзелгән берлеге булгандыр. Шулай ук Казан ханлыгы чорындагы бер генә чыганакта да үзәктән читтә яшәүче халыкларның Казан татарларына каршы милли-азатлык хәрәкәте алып баруы хакында билгеләп үтелми. Бу уңайдан XX гасыр башында яшәгән татар тарихчысы Гайнетдин Әхмәров сүзләре аеруча ышандырырлык яңгырый: «...Болгариягә алмашка Казан ханлыгы килгәч, ар, чуаш, чирмеш, башкорт кабиләләре үз теләкләре белән аның хакимлеген кабул иткәннәр һәм яңа дәүләт составына кергәннәр. Бу кабиләләр бер генә тапкыр да Казанга каршы баш күтәрмәгәннәр, киресенчә, казанлылар белән бергә уртак дошманга каршы яу йөргәннәр, бергәләп Казанны саклаганнар, җиңелә калсалар, рус кул астында калмас өчен барысын да эшләгәннәр, каршы яуга күтәрелгәннәр, ә җиңелә калсалар, дошман тарафыннан тапталган туган җирләреннән иркенлек хөкем сөргән башкорт далаларына качып китүне артыграк санаганнар. Мондый барлык хәрәкәтләр мәҗүси кабиләләрнең Казан төркиләре белән, ә тагын да алдарак Болгар төркиләре белән һәм этник яктан, һәм рухи берлек ягыннан якын торганлыгын, шулай ук Болгарда да, Казан державасында да халыклар тигез хокуклы һәм ирекле булганнар дип фараз кылырга мөмкинлек бирә. Нәсел-нәсәбәле рус дворянины Михаил Дмитриевич Каратеев та (1904-1978) «Русь и Орда» дигән трилогия авторы, бер хезмәтендә шушыңа охшаш фикер әйтә: «Кул астындагы халыкларны—чирмешләрне, башкортларны, чуашларны һәм башкаларны—татарлар җәберләмәгәннәр һәм шуңа аларга каршы буталышлар, баш күтәрүләр булмаган. Киресенчә, бу халыклар Казан патшалары урнаштырган тәртипләр белән, күрәсең, канәгать булганнардыр һәм шуңа күрә тышкы дошманнардан сакланырга булышканнар» *(Каратеев М. Д. Казанское царство // «Арабески» истории.—М., 1994.—Вып. 1.—54 б.).* Бу чорда җирле полиэтник халык үзенең тулы бер сәяси бөтенлеккә буйсынганлыгын аңлаган булса кирәк (бу хакта XVI гасыр уртасында Урта Идел халыкларының коллыктан котылу өчен сугыш алып барулары да бәхәскә урын калдырмаслык итеп раслый), һәм ул шушы бөтенлекне үзенең уртак ватаны итеп кабул итә!



*Тимер бөҗралардан «чигелгән» көбә күлмәк. XIX-XV гасырлар*

Казан ханлыгы хуҗалыгының иң алга киткән тармаклары булып, әлбәттә, җир эшкәртү, терлек үрчетү, урманчылык, балыкчылык, умартачылык, һөнәрчелекнең төрле тармаклары—тире эшкәртү, ювелирлык, тимерчелек, чүлмәкчелек саналган; эчке һәм тышкы сәүдә (халыкара сәүдә) киң җәелә—XV гасырның Венеция сәүдәгәре Иосафат Барбаро болай дип язып калдыра: «Казан—сәүдә шәһәре; аннан Мәскәүгә, Польшага, Пруссиягә, Фландриягә күпләп тире-мех чыгаралар. Мехны төньяктан һәм төньяк-көнбатыштан дзагатайлардан [бортаслардан?] һәм Мордовиядән китертәләр». Ә менә Казан ярминкәсен шул ук «Казан тарихы»ның авторы ничек сурәтли: «На той же день [24. 06. 1505] съезжахуся в Казань [на Гостиный остров на Волге] изо всея Руския земля богатии купцы и многие иноземцы далныя и торговаху с Русью великими драгими товары».

Шәһәр төзелеше һәм архитектура шактый югары баскычка күтәрелгән булган. Архитектура үсешен сурәтләгәндә, Казан елъязмачысының Иван IV нең җимерелгән Казанга килеп керүен сурәтләгән шигырен хәзерге эшкәртелүдә бирәбез:

«...И когда город очистили,
В нее сам самодержец наш выехал...
Он приехал на площадь великую,
У царева двора с коны доброго
Соскочил, удивляясь бывшему...
Не напрасно казанцы противились
И сражались со славою до смерти,
Ибо царство сие стоит этого!
И вошел он во двор, в сени царские,
И пошел в златоверхие теремы,
И палаты, любуясь, осматривал,
Хоть была красота их разрушена
От стрельбы непрестанной от пушечной...»


*Иван Грозный гаскәрләренең Казанны камау күренеше. Урта гасыр миниатюрасы.*

Казан ханлыгы чорында җирле халыкның рухи-мәдәни культурасы югары биеклеккә күтәрелә. Дәүләт биләмәсендә күпсанлы башлангыч һәм урта мәктәпләр эшләп килә, Казанда югары уку йорты һәм китапханә эшли, Хан сараенда исә бай китапханә сакланган. Шәрекътә кабул ителгәнчә, шигърият киң үсеш ала: Мөхәммәд Әмин ханның, Мөхәммәдъярның, сәед (ягъни пәйгамбәрнең турыдан-туры токымы) Кол Шәрифнең һәм башка бик күп шагыйрьләрнең иҗаты моның ачык мисалы булып тора. Мөхәммәдъяр юкка гына:

«Бер гаҗиб бу кем, шәһәр эче тулугъ—
Шагыйрь улмыш барча кечек һәм олугъ»,

—дип язмагандыр...

Билгеле, Казан ханлыгында Ислам дине халыкларның рухи тормышында үзәк-төп урынны алып торган, чөнки ул дәүләтне оештыручы халкының, ватанның сәяси элитасы-зыялыларының рәсми дине булган. Ләкин шунысын ассызыклап әйтү зарур, Казан ханлыгында Ислам дине өстенлек иткән хәлдә дә башка диннәрне чикләү, кысу булмый. Бу күпмедер күләмдә Хәзәрия, Идел Болгарстаны һәм Алтын Урда традицияләре сакланып килү белән аңлатыладыр. Казанның үзендә христиан храмы—әрмән чиркәве эшләп килгән, ә күпчелек фин-угор кабиләләре һәм бертөркем төрки кабиләләре элгәрләреннән күчеп килгән мәҗүсилек динен тотканнар. Ислам дине көчләүсез, күпчелек очракта этник һәм мәдәни аралашу-берләшүгә китерүче чара буларак, ирекле рәвештә таралган.

Казан ханлыгы 1445 елдан соң бераз үзгәрәк төс алып үсә башлый. Ханлыкта, әйтик, «Олуг Мөхәммәд урда»сы вәкилләренә нигезләнгән җирбиләүчеләрнең яңа бер катламы үсеп чыга. Бу хакта Казанда Урдадан ук килгән Ширин, Барын, Аргын, Кыпчак, Мангыт һәм башка ыруларның яшәп килүе шул хакта сөйли. Алар, күрәсең, дәүләтнең кайбер өлкәләре белән дә идарә иткәннәрдер (административ яктан ханлык даругаларга—Алат

даругасына, Арча даругасына, Атыз даругасына, Галич / Гареч даругасына, Нугай даругасына, Окреч даругасына, Чуаш даругасына һәм башкаларга бүленгән; Никон елъязмасы дәүләт составына «Камск», «Сыплинск», «Костяцск», «Беловожск», «Вотяцк» һәм башкорт җирләрен дә кертеп исәпли. Бу ыруларның өстен катламнары ханга якын торганнар. XVI гасыр башында Мәскәүдә ике тапкыр булып киткән Сигизмунд Герберштейн болай дип язып калдырган: «Татар патшалары мөһим эшләр алдыннан барыннан да элек дүрт киңәшче белән киңәшә торган булганнар. Аларның беренчесе—Ширин, икенчесе—Барни, өченчесе—Гаргни, дүртенчесе—Ципцан». Илдә үзәк хакимият хан кулында була. Ләкин дәүләткүләм мөһим мәсьәлә-карарларны хан диван—хан каршындагы иң вәкаләтле морзалар һәм югары катлам дин әһелләре шурасы белән килешү нигезендә генә кабул итә алган. Бу шураның аксөяк әһелләре «карачы», ягъни карауччы дип атап йөртелгәннәр. Алар арасында «олы карачы»—олы карауччы аерым вәкаләттән файдаланган. Барыннан да элек бу рәсми исемне Ширин нәселе вәкилләре йөрткәннәр булса кирәк, чөнки рус елъязмаларында әмир Булат Ширин «карача Казанский большой» дип, аның улы Нурали «большой карача Казанский» дип атап йөртелгәннәр. Күрәсең, Ширин нәселендә «олы карачы» дәрәҗәсе нәселдән нәселгә, ягъни атадан балага күчеп килгәндер. Чыннан да аерым мөһим дәүләт вазифаларын затлы татар нәсел-нәсәбенә бүлеп бирү Казан ханлыгында характерлы күренеш булып тора.

Ә инде дәүләткүләм мөһим мәсьәләләр (ханны сайлау яки төшерү, солых төзү яки сугыш игълан итү, халыкара килешүләр төзү һ. б.) җир биләүчеләр, гаскәриләр, дин әһелләре корылтае тарафыннан кабул ителеп, ул «бөтен Казан җире—корылтай исеменнән» башкарылган. Корылтайга ханлыкта яшәүчеләрнең башка катламнары катнаштырылмаган, шуңа күрә дә аны халык җыены дип атап булмас иде. Казан ханлыгында корылтай җыю гадәтен Көнчыгыш Европага монголлардан килгән традиция дип карарга кирәк.

Дәүләтнең аксөяк өскормасын хан, югары дин әһелләре һәм әмир-карачылар, алардан тыш бәкләр, морзалар, угланнар, казаклар һәм халык кул астындагы феодаллашып килүче феодал вәкилләре тәшкил иткән. Казан ханлыгының структурасында чиновниклар зур өлеш алып торганнар.

Феодаллар, дин әһелләре һәм чиновниклар халыкның өстен хокуклы, хакимият катламын тәшкил иткәннәр һәм алар «аксөякләр» яки зур кешеләр дип аталып йөртелгәннәр, халыкның төп өлешен «кара халык», «гади кешеләр» дә тәшкил иткән. Дәүләтнең имана салымын түләп яшәүчеләрнең бер өлешен һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр алып торган.

Казан ханлыгының сәяси тарихы бик күпкырлы һәм бу күп төрлелек сакланып калган язма истәлекләр белән раслана. Ләкин, кызганычка каршы, бу белешмәләрнең күпчелек өлеше Казан белән Мәскәү арасындагы мөнәсәбәтләрне, өлешчә Казан—Нугай урдасы арасындагы бәйләнешләрне ачыклауга юнәлдерелгән һәм алар ханлыкның Кырым, Әстерхан, Себер, Үзәк Азия арасындагы сәясәтен бөтенләй чагылдырмый диярлек. Бу мәсьәлә Һади Атласи, Михаил Худяков, Сәләм Алишев, Дамир Исхаков, Александр Бахтин иҗатларында яхшы ук, аерым очракларда хәтта нечкәләп өйрәнелгән. Ә башка төр язма, истәлекләр, фольклор чыганаклары, Казанның басып алынуы турындагы тарих фәне бу хакта безгә нәрсәләр сөйли соң?

Иван Грозный хакимлек иткән чорда Мәскәүдә 12 еллап яшәгән (1564—1576) немец галиме Генрих Штаден Казан ханлыгының рус гаскәрләре тарафыннан яулап алынуын менә болай кыска гына һәм бик «сурәтле» итеп тасвирлаган: «...Бөек кенәз [Иван IV] кабат куәтле көч туплый ала һәм яңадан Казанга якынлаша; казу эшләре алып бара, соңыннан шартлата. Ул шәһәрне алуга ирешә, ә хан-патша Шаһгалине *(дөресе Ядегәрне—Б. Х.)* кулга ала һәм шәһәрне табыш сыйфатында талау өчен гаскәриләргә бирә. Әйе, шәһәр талана, җимерелә. Кешеләрен үтерәләр, өстерәп йөриләр, шәрә мәетләрне зур-зур өемнәргә өеп куялар. Аннары үлгән кешеләрнең аякларын тубык турыннан бүрәнәгә аска каратып бәйлиләр дә, бүрәнәләргә 20, 30, 40, хәтта 50 [мәетне] утыртып чыгалар һәм бүрәнәләрне Иделгә ташлыйлар, мәетле

бүрәнәләр Идел буйлап ага. Алар су астында шулай бүрәнәгә асылып баралар, бергә бәйләнгән аяклары гына су өстеннән күренеп торган...» Рус елъязмасы (Новгород) бу вакыйгаларны болай сурәтли (елъязмаларны язылган телдә бирергә булдык): «О Казанском взятии, како взята бысть Казань, бесерменский град, благоверным государем великим князем Иваном Васильевичем всеа Русии. В лето 7061, месяца октября во 2 день... Князь же великий скоро посылает ко граду Казани, повелевает отволочити от града Казани снаряд стенобитный, от обоих подкопов больших, пушки единой имя Колцо, а другой имя Ушатая, и огненыя пушки и весь снаряд, такоже и Змей летячей, И Змей свертной и прочий снаряд весь отволокоша. И повеле князь великий знамя развертети. Бе бо на нем образ Господа Бога Спаса нашего, князь же великий государь слезно зряще глаголаше: «Хранителю мой и избавителю наш! Сохрани нас твоего ради святого». И тако рекрестив лице свое крестообразно и поиде ко граду, и брат его князь Володимер Ондреевичь и все воинство... И тако поиде ко граду Казани. Перешед Булак и взыде к горе и ста полком, и повеле в набаты бити и в накры многи, и в сурны играти, и в трубы трубити; яко гром велик возшуме, не бе слышати что глагола друг другу. И став противу Арских ворот, ныне же именуются Спасские, идеже ныне стоит храм Господа Бога нашего Исуса Христа Нерукотворенного образа, и вскоре посылает к туром князя Михайла Ивановича Воротынского, да велит размыслу Немчину подкоп зажещи в дву местах, и повеле приступити ко граду со всех стран. И абие загореся подкоп в первый час дни в неделю, вырваше стены много во едином месте, и после в другом месте потомуже, и нача метати стрелни и городни и древеса граднии и с землею, яко до небес меташе, и с людми, иже бе на граде стояще, готовящеся к приступу; меташе же людие Казанстии овии во град, иных на иную страну. Егда вырваша подкоп, и в той час учиниша приступ со всех стран, християнстии же людие кликнуша вси единогласно: «О Владыко! Не остави нас, буди помощник». И тако великим зуком приступиша в первый час дни, мню яко земли колебатися от обоих шума и от трескоты древяного, овии в полы места полезоша, иниии же по лестницам, иные же по прислоном, а иные на обломки полезоша; и тако чрез стену скоро взлезоша во град, бьюще по улицам Татар и катун, мужен и жен, по двором, иные же в ямы валячися из мизгитей и с полат, и секуще их и одираху до последния наготы. И тако вскоре, премудраго Бога промышлением, неколико тысящь побиша людей Казанских; и тако, Божиею милостию и его крепкою десницею, ни един Татарин Казанцов не возмогоша битися противу людей християнских, бежаша вси градом, и такоже туто побиша их и прогониша их ко цареву двору. Они же сташа о цареве дворе, хотяще битися, и абие християнстии людие со всех стран много множество приидоша, и тако биющеся и секуще их, яко крови их по удолиям течаше и телеса их невместимо по улицам проити, и такоже по улицам людие на земли лежаху. Людие же Казанские восхотеша о цареве дворе битися, и видевше они окаяннии, что невозможно стати против хрестьянских людей, и абие побегоша с царева двора за град, с стены валяющеся, за Казань за реку к лесу по Галицкой дороге побегоша; и абие ту стояше великого князя правая рука, князь Петр Михайловичь Щенятев да князь Андрей Михайловичь Курбской и с ними многие люди Московстии, и Ноугородцы, и Псковичи, тех всех людей Казанских на голову побиша, от них мало тех которые на лес утекоша. Во граде же бяше хрестьянстии людие много множество безчислено кяинь, и мурзиных жон, и девок и детей взяша, такоже рку вскоре от великих и до простых людей. И такоже начаша царя Казанского искати Аидигеря, по всем странам града: занеже бе его искаху и не обретоша, и в цареве дворе языков много пытающе, не ведяху никтоже его; и абие устремишася Палецкого княжь Дмитреевы слуги на левую страну града Казани, идеже зовутся у них Збойливые ворота, ныне же зарушены, и такоже на стене взяша царя Аидигеря, Касым Салтанова сына, и Астороханского царевича, и вневеды хотяше убити его, и абие ту с ним некии Татарове бяше сказаша о нем, яко царь есть. О предивное чюдо и великое Божие милосердие! На толикое малое время, на един час, толико тысящь побили Казанских людей, и царя из града взяша, и царство его плениша...»

Урта гасырлар татар цивилизациясенең чәчәк атып утырган бер мәркәзе

менә шулай хәрабә хәленә китерелә, сан ягыннан биш тапкыр күбрәк булган дошманына каршы аяусыз көрәш алып барган шәһәрне саклаучылар әнә шулай һәлак булалар. 1552 елның 2 октябрь дәһшәтле вакыйгалары, соңрак рус гаскәрләренең Әстерхан ханлыгын яулап алынуы нәтиҗәсендә Идел буенда VII гасырдан, Хәзәр каганлыгыннан бирле яшәп килгән төрки дәүләтчелеге юкка чыгарыла. Шулай итеп, татар халкын физик яктан юк итү, геноцид куллану, хокукын һәм иреген кысу чоры башлана, дини инану өчен җәберләнү, милли уку-укыту өчен, ниһаять, үз телеңдә сөйләшкән өчен нахак ашау— моның ачык мисалы.

Аңлашыла ки, Казан ханлыгының җимерелүе татар халкының фольклорында, риваятьләрендә, истәлекләрендә күп сакланып калган. Әйтик, мисал өчен халык риваятьларен эчтәлекләре һәм хронологик яктан барлыкка килүен болайрак тәртиптә бүлеп карарга мөмкин булыр иде: «Сөембикә тарихы», «Патша хәйләсе», «Свияжск кирмәне төзелү», «Иван Грозный Казанга ничек сугыш башлаган», «Казанның дошманнар тарафыннан яулап алынуы», «Кол Шәриф бәете» һәм башкалар.

Беренче риваятьтә, «Сөембикә тарихы»нда, (татар язучылары Рабит Батулланың «Сөембикә» һәм Мөсагыйть Хәбибуллинның «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» романнарында бу легенда мотивлары да урын алган) Казанның яулап алынуының беренче сәбәпләре күрсәтелә сыман. Имеш, Мәскәү патшасы Иван Грозный Сөембикә ханбикәгә гашыйк була һәм аны кияүгә сорап Казанга илчеләрен җибәрә. Җавап, әлбәттә, кире була. Моңа каршы рус патшасы: «Тынычлык белән теләмисең икән, сугышып тез чүктерермен»,—дип җавап кайтара. Икенче риваять («Патша хәйләсе») шул хакта сөйли: имеш, Иван Грозный Сөембикә белән сугышып арыганнан соң, мондый хәйләгә бара: «Миңа үгез тиресе хәтле генә җир бүлеп бирегез, шул чак сугышны туктатырмын»,—ди ул. Сөембикә риза була. Патшаның хезмәтчеләре үгезне суялар һәм аның тиресеннән озын тасмалар теләләр дә шуның белән хан биләмәсеннән олы гына бер өлешне бүлеп алалар, соңрак биредә Свияжск кирмәне торгызыла... Казанны басып алуда форпост ролен үтәячәк Свияжск кирмәнен салу өчен уңайлырак урын сайлау хакындагы риваять 1551 ел белән теркәлгән.

«Иван Грозный Казанга ничек сугыш башлаган» риваяте болай сөйли: Иван патша көннәр буе Казанны ничек яулау турында баш вата, имеш, шул уй белән яна. Шул чак аңа якыннарыннан берсе әйтә: «Җибәр мине Казанга, мин анда бик зур җәнҗәл чыгарырмын, аннары җавап рәвешендә сугыш ачарсың»,—ди. Бу ният патшага ошый һәм ул хезмәтчесен Казанга җибәрә, тегесе исә татар ханы һөҗрәсенә аяк басу белән үгез тиресе хәтле генә җир сорап ала. Хан, әлбәттә, моңа үз ризалыгын бирә. Мәскәү илчесе, рөхсәт алу белән, Казан базарына барып бөтен тиреләрене җыеп ала да, аларны бергә тегеп, нәкъ Казан уртасында җәеп җибәрә. Нәтиҗәдә—низаг килеп чыга, низагтан соң—сугыш. «Казанның дошманнар тарафыннан яулап алынуы» дигән риваять Иван IV нең 1551—1552 еллардагы сугышчан сәяхәтенә нигезләнә, анда казанлыларның батырларча каршылык күрсәтүләре сурәтләнә; «изгеләр житәкчесе» дип алган сәед Кол Шәрифнең батырлыгы исә «Кол Шәриф бәете»ндә ачыграк тасвирланган.

Әйтергә кирәк, Казан ханлыгының яулап алынуы күп кенә тарихи әдәбиятта да урын алган. Беренче чиратта, хаклы рәвештә, бу мәсьәлә чит ил тарихчылары монографияләрендә җентекләп тикшерелә, шулай ук кайбер татар һәм рус чыганакларында карала. Казан ханлыгы белән Русия арасындагы мөнәсәбәтләр инде XVII гасырда ук житди рәвештә өйрәнелә башлый. Әлеге проблеманы беренче өйрәнүчеләр дип А. И. Лызловны, В. Н. Татищевны, П. И. Рычковны («Опыт казанской истории древних и средних времен», 1767), М. М. Щербатовны («История Российская с древнейших времен», 1784—1789), Н. М. Карамзинны, К. Ф. Фуксны («Краткая история города Казани», 1817), М. С. Рыбушкинны («Краткая история города Казани», 1834), Н. С. Арцыбашевны («Повествование о России», 1838—1843), Н. К. Баженовны («Казанская история», 1847) һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

Шулай итеп, «Скифлар тарихы»ның авторы Андрей Иванович Лызлов:

«...7200 ел элек Дөнья яралган көннәрдән башлап Иисус Христос туган 1692 елга кадәрге көн-вакыйгаларны тәфсилләп язып барып» рус-татар мөнәсәбәтләренә, аеруча Мәскәү-Казан багланышларына зур урын бирә. Аның «Тарихы»нда 1552 елгы яулап алуга кадәр үк Мәскәүнең Казанга һәм аның олысларына гаскәрләр җибәрүе турында хәбәр ителә, ә Казанның тулысынча яулап алынуы татарларның рус җирләренә туктаусыз яу йөрүләренә җәза дип бәяләнә. Асылда «татарларның яу чабулары» дигән сафсатага корылган билгеләмә, шулай ук «Казан йорты безнең йорттан башланды» (Иван Грозный), «Казан патшалыгы һәм Казан шәһәре татарлар тарафыннан Россия дәүләте җирләрендә торгызылдылар» (Петр Рычков), XV—XVII гасырларга караган рус елъязмаларындагы тәгъбирләр, теге яки бу аерымлыклары булуга да карамастан, революциягә кадәр язылган барлык чыганакларда да кабатланып киленәләр.

Ләкин без яхшы беләбез, XVII гасырда һәм XIX гасырның беренче яртысында тарих фәне ятим хәлендә иде, чөнки аның бик күп тармаклары— язма чыганаклар белән эшләү, археологик һәм этнографик эзләнүләр алып бару чынлыкта исә туу чорын гына кичерәләр иде. Шуңа күрә дә югарыда күрсәтелгән хезмәтләрнең нәтиҗәләре шартлы рәвештә генә дөрес дип бәяләнергә хаклы. Ул чордагы рус елъязмаларының нигезенә үк салынган беркатлы идеяләргә ябышып яту көчле була—шул рәвешле фактологик материалларга нигезләнмичә генә Казан ханлыгы күп еллар буена ярымкыргый, агрессив дәүләт итеп сурәтләнеп киленә һәм, имеш, аны яулап алу һичшиксез прогрессив күренеш булып тора.

Казан ханлыгы белән Русия арасындагы мөнәсәбәтләр XIX гасырның икенче яртысыннан, ягъни фәнни әйләнешкә беренчел чыганаклар күпләп кертелә башлагач һәм тарихи өйрәнүләрнең методологиясе киңәйгәч кенә җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелә башлый. Бу чордагы тарихчылардан, беренче чиратта, С. М. Соловьев «исемен» атарга кирәк. Ул ахыр чиктә Русия тарафыннан көнчыгыштагы җирләрнең яулап алынуын күкләргә чөеп мактый һәм аны тарихи яктан прогрессив күренеш дип күрсәтә! Аның фикеренчә, колонияләштерү Русиянең икътисадын кинәт үстерүгә китерә һәм «Аурупа, христиан цивилизациясенең Шәркый мөселман дөньясына таралуы» дип бәяләнә. С. М. Соловьев артыннан Н. И. Костомаров та татар расасын славян расасына кушу Русиянең тыныч яшәвенә һәм чәчәк атуына беренче шарт булып тора дип кабатлый. Мәсәлән, аныңча, Кырым ханлыгының яшәп килүе рус халкының «гаҗәеп зур материкта акрын таралуына төп сәбәпче булып тора». «XV һәм XVI гасырларда Идел буе» (1877) китабының авторы Г. И. Перетяткович та шушындый караштa тора. Ләкин ул тарих фәнендә беренчеләрдән булып, Мәскәү—Казан мөнәсәбәтләрен тар кысаларда гына карамыйча, аны тенденциоз юллар белән булса да, Аурупа халыклары багланышлары шартларына яраклаштырырга омтыла. Шунысын да әйтеп үтәргә мәҗбүрбез, аның әлеге хезмәтендә Казан ханлыгы эчендә барган этнокультура һәм этносәяси мәсьәләләренә киң урын бирелә.

XIX гасырда, ниһаять, татар-рус мөнәсәбәтләрен өйрәнүче һәм, аерым алганда, Казанның алынуы хакында татар тарихчыларының киң колачлы, тарихны дөрес чагылдырган тәүге хезмәтләре басыла башлый. Болар, беренче чиратта, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри, Һади Атласи хезмәтләре; Риза Фәхретдиновның «Шура» журналында аерым мәкаләләре дөнья күрә. Бу тарихчылар, тарихи вакыйгаларны хакыйкый яктырту аша, «бөек рус» субъектив идеологиясенә күпмедер күләмдә чик куя алдылар. Кыскасы, аларның тикшеренүләре фәнни яктан тирән һәм объектив иделәр, чөнки аларда критик анализ илләген узган бик күп рус һәм татар чыганаклары файдаланылды. Татар авторлары һәрвакытта да Алтын Урда һәм Казан ханлыгында барган эчке таркалу күренешенә, ахыр чиктә Алтын Урда җимерелеп, аның Казан ханлыгына, Кырым ханлыгына, Себер ханлыгына, Әстерхан ханлыгына, Касыйм ханлыгына, Зур урда һәм Нугай урдасына бүленү сәбәпләренә дөрес игътибар биреп килделәр. Шул ук вакытта Мәскәү алар тарафыннан һич икеләнүсез «колонизатор», «баскынчы» дип аталды, ә 1552 елдан соңгы вакыйгалар тулысынча диярлек тискәре күренеш

булarак бәяләнде. Башкорт галиме Әхмәтзәки Вәлиди (Туган) һәм чуаш мәгърифәтчесе С. И. Михайлов та шундый караштa тордылар.

«Кызыл» революция җиңүенең беренче елларында Н. В. Никольскийның «Конспект по истории народностей Поволжья» (1919), Н. Н. Фирсовның «Чтения по истории Среднего и Нижнего Поволжья» (1920) дигән кызыклы гына китаплары дөнья күрә. Аларда Казанны яулап алуга һәм Идел буе халыкларының XVI гасыр урталарында бәйсезлек өчен көрәшен яктыртуга этрафлы урын бирелү, әлбәттә, күпмедер күләмдә «социаль заказ» хезмәтен үтәми калмагандыр. Аларның тагын бер әһәмиятле яклары—икътисади проблеманы дөрес яктыртулары—Иван IV нең Бөек Идел су юлында үз хакимиятен урнаштыруга омтылуын ачыклаулары (1556 елда Әстерхан ханлыгын яулап алу моның ачык чагылышы) әһәмияткә ия.

Тагын бер икътисади проблеманы—эшкәртү өчен җир һәм кул көче җитмәүне, хуҗалыкны экстенсив юнәлештә алып бару шунлыктан килә дип күрсәтүе белән үз мәктәбен тудырган галим М. Н. Покровский 1930 еллардан башлап совет тарихчылары тарафыннан кискен тәнкыйтьләнеп киленде. Шуның өстенә ул рус сәясәтен, шул исәптән Иван Грозный хакимиятен дә яулап алучылыкта һәм милли-колониаль сәясәт үткәрүдә ачыктан-ачык тәнкыйтьләп чыга. М. Н. Покровский шулай ук Казан ханлыгы үсешендә бәйсезлеккә омтылыш көчле булуын, Урта Идел халыкларының рус баскынчыларына каршы алып барган чыгышларын «милли азатлык өчен көрәш» дип атый.

«Кызыл» инкыйлабтан соң бу мәсьәләне җентекләп өйрәнгән татар галиме дип, һичшиксез, Газиз Гобәйдуллинны атарга мөмкин. Үзенең «Татар тарихы» (1922, 1924, 1925) дип аталган хезмәтендә һәм «Идел буе өчен көрәш тарихыннан» (1923) дигән мәкаләсендә ул XV-XVI гасырларда Урта Идел буенда барган вакыйгаларга төпле анализ ясый. Әйтик, «Татар тарихы» хезмәтендә автор «Идел буендагы татар дәүләтләренең инкыйразы» һәм «Идел өчен соңгы көрәш» дигән бүлекләр урнаштыра. Биредә Газиз Гобәйдуллин татар ханлыкларының таркалу сәбәпләрен, Алтын Урда «чәчелгәннән» соң Русия хакимиятенең татар ханлыкларына карата үткәргән «бүлгәлә һәм хакимлек ит» дигән явыз һәм астыртын сәясәтенең асылын, курчак Касыйм ханлыгындагы билгеле хәлләрне, Мәскәү агрессиясенең, шул исәптән икътисади вәхшилегенең сәбәпләрен фактик материалларда ачып бирә. Ләкин..., тарихчы фикеренчә, вакыйгалар агышы баштан ук руслар файдасына хәл ителгән була, чөнки Казан ханлыгы халкы күчмә тормыш алып бару сәбәпле, Ватан чикләре тәгаен билгеләнмәгән була!

Казан ханлыгы дәүләтенең тарихын өйрәнүдә, әлбәттә, М. Г. Худякованың «Очерки по истории Казанского ханства» (1923) дигән хезмәте аеруча күренекле урынны алып тора. Әлеге хезмәт Казан ханлыгы тарихын өйрәнү, Казан—Мәскәү мөнәсәбәтләренә бәя бирү буенча яңа бер адым булды. Шунысы әһәмиятле, биредә рус укучысы беренче тапкыр, Шамил Мөхәммәдъяровны кабатлап әйтсәк, «Казан татарлары милли дәүләте тарихы» буенча билгеле бер системага салынган материаллар белән таныша алды. Бу хезмәтнең дөнья күрүе хәтта рәсми дәүләт басмасы «Известия ТЦИК» тарафыннан билгеләп үтелә, анда болай диелә: «Мондый китап күптән кирәк иде. Татарстан республикасы үз тарихын, озак дәверләр дәвамында башка дәүләткә бәйлелеккә төшкән авыр тарихын булдырырга тиеш иде (!)».

Мәскәү—Казан мөнәсәбәтләре белән кызыксынган кешеләрнең Михаил Георгивич хезмәтләре белән яхшы таныш булуын исәпкә алып, без биредә бу рус галименең карашларын тулырак чагылдырган берничә кечкенә өземтә бирергә булдык.

*Русиянең яулап алу сәясәте.* «1540 елларның ахырларына кадәр рус сәясәте Казан ханлыгына карата территориаль яулап алу төсмерен алмый. 1540 еллар ахырларында кискен борылыш ясала һәм рус дәүләте Казан ханлыгын яулап алырга, аны рус дәүләтенең составына кертергә кирәк дигән карарга килә. Шушыңа яраклы рәвештә рус—Казан мөнәсәбәтләре схемасы төптән үзгәртелә һәм руслар чын-чынлап империалистик яулап алу сугышын башлыйлар»; «яулап алу сәясәте дворян-алпавытлар, руханилар һәм сәүдә-

промышленность капиталы карашлары белән теләктәшлек таба».

*Казанны яулап алуның нәтиҗәләре.* «Басып алынган Казан халкын вәхшиләрчә җәзалау-үтерү рус тарихында иң мәсхәрәле урыннарның берсе. Христианлаштыруны алга сөргән гаскәри-хәрби катламның казанлыларга карата ясаган «тәре походы» моңарчы күрелмәгәнчә кешеләр һәлакате— гекатомбасы *(Борынгы Грециядә корбан чалу йоласы—Б. Х.)* рус дәүләтенең территориаль яулап алу юлына аяк басуы белән тәгәлләнә. Көчләп каберга озатылган кешеләрдән тыш, Казан халкы кичергән күз яшьләре, газаплар, кайгы-хәсрәттән тыш, хәсрәтле 2 октябрь көне буыннан-буынга тупланган материаль мал-мөлкәтнең юкка чыгуына китерә һәм бөртекләп җыйналган, сакланган мәдәни-көнкүреш кыйммәтләр «халык сандыгыннан» рәхимсез рәвештә йолкып алына, аяусыз рәвештә ватыла, җимерелә, юк ителә. Меңнәрчә зиннәтле нәрсәләр, ювелир-зәркан әйберләре, тукымалар, югары осталык белән эшләнгән сәнгать әсәрләре мәңгегә һәлак була. Халык байлыгына коточкыч вәхшилек күрсәтелә, моннан соң ул, мөгаен, терелә дә алмаган булыр иде...»

1930 еллар уртасыннан башлап совет тарихы фәнендә кабаттан революциягә кадәр яшәп килгән бөек державачылык авазлары яңгырый башлый. Беренчедән, бу үзәк хакимиятне ныгытырга омтылу (ул И. В. Сталинның шәхес культына барып тоташа), икенчедән, 1941—1945 елларда «рус халкы азатлык алып килүче» дигән стереотипның калыплашуы белән бәйле. Шул рәвешле (форсаттан файдаланып) русның бөек кенәзләрен, шул исәптән Иван Грозныйны да күккә чөеп мактау башлана; моны исбатлау өчен шул елларда басылып чыккан кайбер китапларның исемнәрен атап үтү дә мәсьәләгә бераз ачыклык кертер кебек—Бахрушин С. В. Иван Грозный.—М., 1942; Смирнов И. И. Иван Грозный.—Л., 1944; Виппер Р. Ю. Иван Грозный.—М.—Л., 1944; Русь-Русиянең үткән дәверләрдәге тышкы сәясәтенә яңабаштан бәя бирелә: Огнев И. В. Войны Ивана Грозного с Казанским ханством и завоевание Казани.—М., 1948; Меркушкин Г. Я. Восточные походы Ивана Грозного.—Саранск, 1948; Шмидт С. О. Правительственная деятельность А. Ф. Адашева и восточная политика русского государства в середине XVI века.—М., 1949; Коротков И. Я. Иван Грозный. Военная деятельность.—М., 1952; Русь-Русия яулап алуларының «тарихи зарурлыгы» турындагы гипотезалар яңадан баш калкыта башлый: Нечкина М. В. К вопросу о формуле «наименьшее зло» // Вопросы истории.—1951.—N 4. Смирнов И. И. фикеренчә, Иван Грозный тарафыннан Казанның яулап алынуы «рус милли дәүләтен ныгыту һәм алга таба үстерү өчен мөһим чара» булып торган икән; ә барлык алда санап үтелгән авторларның уртак фикерен сөземтә рәвешендә китерсәк, «күпмилләтле үзәкләштерелгән рус дәүләтен торгызуның башлангыч этабы да ул». Әйтергә кирәк, мондый идеяләр совет кешесе аңына башка төр басма чыганаклар аша да, кино сәнгате кебек массакүләм чаралар аша да сеңдерелә барыла.

«Үзгәртеп кору» чорына кадәр Казанның яулап алынуы турында басылып чыккан тарихи хезмәтләр турында сүз алып барганда, аларның бик тә берьяклы һәм өстән-өстән ясалган «анализга» ия булуларына карамастан, Базилевич К. В. («Внешняя политика Русского централизованного государства. Вторая половина XV века», 1552), Шмидт С. О. («Предпосылки и первые годы «Казанской войны 1545-1549 г. г.»), Бурдей Г. Д. («Борьба России за среднее и Нижне Поволжье», 1954; Взаимоотношения России с Турцией и Крымом в период борьбы за Поволжье в 40-50-х годах XVI века», 1956), Греков И. Б. («Очерки по истории международных отношений Восточный Европы XIV-XVI веков», 1963), Тихомиров М. Н. («Российское государство XV-XVII веков», 1973) кебек галимнәрнең «эшчәнлеген» билгеләп үтмәү дөреслеккә хилафлык кылу булыр иде, мөгаен. Гомумән, рус тарихчылары арасында әле уңга, әле сулга талпынулар гадәти хәл, шунлыктан аларның әсәрләрен укыган кеше өчен орлыкны кибәктән аерып алу зарур. Әйтик, Казан татарларының этногенезына багышлап 1946 елда Мәскәүдә үткәрелгән фәнни сессиядә, агрессив болгарчылыкка каршы чыгып, татар тарихы, нигездә, Алтын Урдадан башлануын яклап чыккан хөрмәтле Михаил Николаевич Тихомиров (ул Казан тарихын өйрәнүче галим Шамил Фатих улы Мөхәммәдъ-

яровның фәнни җитәкчесе дә) фәнни әйләнешкә «Идел буе һәм Урал төбәге халыкларының Россия составына ирекле кушылуы» кебек бик тә сәер тезисны кертеп җибәрүчеләрнең берсе булды. Шулай итеп, чуаш халкының тарихи проблемаларына багышлап үткәрелгән сессиядә (1950) һәм шулай ук «Советская этнография» (1950, № 3) журналы битләрендә ул әлеге фикерләренә «Чуашстанның Россиягә ирекле кушылуы», янәсе, чуашлар өчен «казанлыларның талау нияте белән яу йөрүләреннән арынуын» һәм ясак түләүдән котылуын аңлата (!) дип тә өстәде. «Вопросы истории» (1951, № 9) журналында «К вопросу о присоединении Среднего Поволжья к России» дигән мәкалә бастырган К. Я. Наякшин да шундый «новаторлар»ның берсе булды. Игътибар итик һәм нәтиҗә чыгарыйк: К. Я. Наякшин шундый «ачышлар ясый», искитмәле: «Идел буендагы сугышлар барыннан да элек Төркия солтанатына һәм аның Кырым, Казан, Әстерхан кебек мөридләренә каршы юнәлтелгән иде (!); Казан ханлыгының төп халкы Алтын Урда ханнарыннан авыр җәфа чикте. Бу изү XV гасырда Казанны Олуг Мөхәммәд гаскәрләре яулап алгач тагын да көчәя... Казан ханлыгының җирле халыклары үзләрен Алтын Урда коллыгына төшерүчеләргә нәфрәт белән караганнар. Алтын Урдадан чыккан морзалар камыты астында көн күргән Урта Идел халкы каршында турыдан-туры Төрек солтаны кул астында калу куркынычы туа тора (!)»; «Төрек янавын кире кагу зур гөнаһ булыр иде»; «Шунысы ачык ки, Идел буе халыкларының Россиягә кушылуы, асылда, бердәнбер юл, алар өчен бердәнбер котылу юлы була» (!!!)...



*Казан Кремлендә казу эшләре алып барылган биләмә. Казан ханлыгы чорындагы таш бина калдыклары.*

Алда билгеләп үтелгән «үзгәртеп кору чоры»на кадәр үзенең фикри оригинальлеге, шәхси фидакарьлек-батырлыгы белән башка соры массадан аерылып торган галимнәр бармак белән генә санарлык иде. Казанда шундый галимнәрнең берсе минем остазым (мин моның белән чиксез горурланам) Сәләм Хатип улы Алишев булды. 1970 елда ук, Тел, әдәбият һәм тарих институтында ел йомгакларына багышланган конференциядә ясаган чыгышында мөхтәрәм тарихчы 1552 елгы яулап алуны чагылдыруда берьяклылык өстенлек ала башлавын, хәтта аны «ирекле кушылу» дип атарга омтылышлар барлыгын, шунлыктан сак булырга кирәклекне искәртеп үткән иде. Идел буе тарихын өйрәнүче галим шушы ук фикерләрен «Татария в прошлом и настоящем» дигән хезмәттә урын алган «Урта Идел халыкларының Россия дәүләтенә кушылуы» дигән мәкаләсендә дә үткәргән иде. Бу үзенә күрә бер гыйльми батырлык иде.

Ниһаять, илдә башланган җәмгыятьне демократлаштыру процессы һәм СССРның таркалуы профессиональ галимнәр һәм үзешчән тарихчылар арасында моңарчы тыелган проблемаларга карата зур кызыксыну уятты. Хәзерге вакытта тарихчылар ни хакында һәм ничек уйлауларын кычкырып әйтә алалар; ә иң мөһиме шул—алар фикерләрен яшереп маташмый, монографияләрдә, дәреслекләрдә, газета-журналларда басылган мәкаләләрдә, интернетта урын алган чыгышларда турыдан-туры киң җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итә алалар. Бу җәһәттән Искәндәр Измайловның («Казанское взятие» и имперские притязания Москвы» // Мирас, 1992, № 10), Сәләм Алишевның («Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV-XVI в.в.», 1995), Равил Фәхретдиновның («История Татарского народа и Татарстана», 1995), Индус Таһировның («История национальной государственности

татарского народа и Татарстана», 2000) һ.б. галимнәрнең фидакарь һәм нигезле эзләнүләрен билгеләп үтәсе килә.

Татар булмаган Россия галимнәреннән «Внешняя политика Руси, России и СССР за 1000 лет в именах, датах, фактах» дигән 3 томлыкның авторы Вильям Васильевич Похлебкинның исемен атап үтмәү безне кызыксындырган тема турында сөйләшкәндә, үзенә күрә бер гөнаһ булыр сыман. Хикмәт шунда ки, аның гомуми иҗаты турында, аерым алганда, «Татары и Русь. 360 лет отношений Руси с татарскими государствами в XIII-XVI в. в., 1238-1598 г. г. (От битвы на р. Сить до покорения Сибири) Справочник».—М., 2000 г.) дигән хезмәте хакында бер-ике кәлимә сүз әйтергә күптән җыенып йөри идем, менә форсат та туды. Мәскәүнең «Международные отношения» нәшрияты тарафыннан чыгарылган бу белешмә (китапка язылган кереш мәкаләгә ышансак, ул «Шәрекъне өйрәнүче белгечләр, тарихчылар, халыкара юристлар, дипломатлар һәм Ислам белән, татар халкы тарихы белән кызыксынучылар өчен атап чыгарылган»—аз да түгел, күп тә түгел!)ниләр хакында бәян итә соң? Иң беренче эшем итеп, авторның кайбер субъектив фикерләренә басым ясап үтәсем килә.

*Белешмәнең 3 нче битендә болай диелгән:* «XVI гасыр ахырына (1598) барлык татар дәүләтләре (Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары һәм Нугай Урдасы) яшәүдән туктыйлар, аларның биләмәләре һәм халкы берләштерелгән Россия составына керәләр». Алайга китсә, кушсаң каләм яза инде ул, 1812 елда руслар берләштерелгән Франция составына, ә 1939 елда Польша яһүдләре берләштерелгән Германия составына керделәр дип тә язып булыр иде...

*5 нче бит, аеруча игътибар итегез:* «Русьның көнчыгыш чигендәге беренче дәүләт Алтын Урда иде». Шушы кыска гына уйдырмасы белән автор Хәзәр каганатын да, Иделдәге Болгар дәүләтен дә тарих битләреннән «сызып ташлый». Һәм бу аңлашыла да, автор фикеренчә, ни төрки-хәзәрләр, ни төрки-болгарлар, Алтын Урда татарлары кебек, Русиягә каршы «агрессив» сугыш алып бармыйлар, ләкин автор шунысын оныта, нәкъ менә Алтын Урда Русияне католиклар коллыгыннан йолып алып кала, бертуктаусыз дәвам иткән эчке бәрелешләргә чик куя, православие чиркәве үсешенә уңайлы шартлар тудыра һәм бердәм Русь дәүләте оешуга юл ача. Ләкин В. В. Похлебкинга, күрәсең, Святослав варягларының Хәзәрияне яулап алуы һәм рус кенәзләренең тыныч тормыш иткән, ирек сөючән Болгар җирләренә ясаган күпсанлы һөҗүмнәре, аның халкының үз шәһәрләрен, нигездә, Иделнең русларга каршы як ярында (сулъяк ярында) төзергә мәҗбүр булулары хакында искә алу бер дә «кызык» түгел; хәер, ул аларны юри күрмәмешкә салыша...

*10 нчы бит:* «Чынгыз хан үлгәннән соң 1228 елда җыелган Бөек корылтай аның оныгын, Бату ханны, Җучи улын, рус тарихында Батый исемен алучыны, Дон аръягындагы көньяк рус далаларын яуларга озата». «Халыкара галимнең», революциягә кадәрге традициягә хас булганча, терминологиядә үтә дә талымсыз булуы гаҗәпләндерә, әлбәттә. XIII гасырда ул Дон аръягында нинди көньяк рус далаларын эзләп тапты икән? Шартлы рәвештә алар XVIII гасыр ахырында, Кырым татар дәүләте яулап алынганнан соң гына «көньяк русныкы» булып исәпләнәләр, ә XX гасыр ахырында бу җирләрнең күпчелеге суверен Украина составына керәләр! Күз алдына китерик: боларның барысын да булачак яшь дипломат—бөек рус милләте вәкиле укыячак һәм ачуыннан аның чигәләре кабарып чыгачак... Ләкин шунсын да искә төшерик: 1228-1229 еллардагы Сүбүдәй баһадир җитәкләгән монгол явы саксиннарга, кыпчакларга һәм Идел буе болгарларына каршы юнәлтелгән була. Шушы яу нәтиҗәсендә кыпчаклар, Кара диңгез һәм Азов диңгезе буе далаларының чын хуҗалары (бер өлеше, әлбәттә), Һунгариягә (Венгриягә) күчеп китәргә һәм католик динен кабул итәргә мәҗбүр була. 1228—1229 еллар явына эмоциональ бәһа бирсә дә кыпчак токымы-нәселе вәкилләре генә шулай бәһа бирергә хокуклыдыр...

Хәзер В. В. Похлебкинның Казан ханлыгы белән Мәскәү дәүләтенең «дошманлыгы» хакындагы фикерләренә тукталып үтик. Биредә автор, күп очракта, бөек державачылык карашларыннан арына алган. «Татары һәм

Русь...» белешмәсендәге бу тема, чыннан да, шактый дөрес позициядән торып яктыртылган. Әлбәттә, кайбер җитди «ләкин»нәргә карамастан. Беренчедән, белешмәдә билгеләп үтелгәнчә, Казан татарлары беркайчан да «Россиянең ни сәяси, ни милли автономиясенә, ни православие диненең иркенә» кул сузмаганнар. Икенчедән, галим Казан татарларының Русиягә каршы ясалган 6 явын (1439, 1444—1445, 1505—1507, 1521, 1523, 1536—1537), руслар тарафыннан татарларга каршы оештырылган 9 явын (1467—1469, 1478, 1487, 1506, 1523—1524, 1530, 1545, 1548—1549, 1549—1550) исәпләп чыгарган. Ләкин шул ук вакытта автор, бик тә хәйләкәр рәвештә, «Казан татарлары походы» исемлегенә Олуг Мөхәммәд юлбашчылыгындагы Алтын Урда татарлары походларын да (1439, 1444—1445) кертеп исәпли һәм руслар тарафыннан Казанга каршы ясалган 1495 елгы яуны һәм Мәскәү дәүләтенең Казан ханлыгына каршы оештырылган сугышчан һөҗүмнәрен (1551—1556) онытып җибәрә; югыйсә, бу чорда—1551, 1552 һәм 1553—1556 елларда—кин масштаблы өч канкойгыч бәрелеш булып ала. Шулай итеп, 1439—1550 еллар вакыйгасыннан автор нинди нәтиҗә чыгара соң? Өземтә китерәм: «Русия дәүләте Казанга дәвамлы биш хәрби яу оештыра—1469, 1487, 1506, 1524 һәм 1530 елларда. Болардан тыш, Русия 1478, 1523, 1545 елларда кыска вакытлы яулар оештыра, шул ук вакытта сугышны башлаучы, агрессор сыйфатында ул җиде тапкыр чыгыш ясый—1467, 1478, 1487, 1530, 1545, 1549, 1550 елларда... Казан дәүләте үз башлангычы белән Мәскәүгә һәм башка рус дәүләтләренә алты тапкыр яу чаба—1439, 1445, 1505, 1521, 1523 һәм 1536 елларда. Шул рәвешле, Казан ханлыгы, Мәскәү дәүләтенә караганда, чагыштырмача һәм формаль яктан тынычлык яклы була. Мәскәүне аулап алу турында аның беренинди исәбе дә булмый. Казан походларының күпчелеге яки русларның һөҗүмнәреннән саклану өчен ясалган була, яки русларның һөҗүмнәренә каршы җавап рәвешендә оештырыла» (!).

Галимнең соңгы фикере белешмәдәге мондый сүзләр белән дә тәңгәл килә: «1487-1521 елларда рус сәясәтенең яшереп тормыйча, ачыктан-ачык көч куллану сәясәте алып баруга көчүе тулысынча раслана, 1505-1507 елларда алган сабакларга да карамастан, Казан ханлыгы йомшаклык күрсәтә башлау һәм дустанә яшәү ниятен сиздерү белән алар тагын яу чабарга керешәләр. ***Татарлар Мәскәү белән тыныч яшәү мөмкин түгеллегенә тәмам ышаналар*** *(биредә һәм алга таба курсив В. Похлебкинныкы—Б. Х.)* һәм мөселман дәүләтләре булган Кырым белән Төркиягә йөз тотарга, шул ук вакытта ***үзләренең бәйсезлеген яклап Мәскәү белән дипломатик юл белән түгел, бары тик хәрби юл белән көрәш алып барырга, ягъни Мәскәү кенәзлекләре белән сөйләшүне*** алар аңлаган һәм яраткан телдә—көч куллану телендә генә сөйләшергә кирәк дигән карарга киләләр (!)».

Бу сүзләрдә нинди ачы хакыйкать һәм тирән мәгънә ята...

Яу һәм походлардан тыш, Вильям Васильевич үзенең белешмәсендә ике Көнчыгыш Европа дәүләте арасындагы «иске гадәт буенча аңлашып һәм дустанә яшәү» чорларын да күрсәтә. Минемчә, бу «дуслыкның» нигезен 1461 елгы рус елъязмасындагы түбәндәге сүзләр бик дөрес ачыклап бирә: «князь велики... хотя ити на Казанского царя... и ту прийдоша к нему послы ис Казани и взяша мир» *(ПСРЛ.—Т. 28.—М., 1963.—С. 284)*. Казан татарлары белән руслар арасында үзара тыныч яшәү турында беренче солых менә шулай төзелә. Солыхлар соңрак та берничә кабат төзеләләр. Әйтик, 1512 елның башларында Мөхәммәд Әмин белән Василий III арасында «Аллаһ кушканга кадәр» «мәңгелек солых» игълан ителә һәм күпчелек очракта тынычлык турында килешү инициативасы белән татарлар чыга. Ләкин аның нәтиҗәсе бер үк төсле тәгълләнә, аны 1529 елгы килешү мисалында В. В. Похлебкин да дөрес билгеләп үтә: «Солых турында килешү белән, үзенең һәм хәрби яктан, һәм дипломатик яктан җиңелүенә ачуы килеп, Василий III үч алу теләге белән шунда ук сугышка хәзерләнә башлый» (ул 1530 елның июнендә башланып та китә (!). Шушы уңайдан минем укучыларны оҗмахка тиң татар җирләрен көчләп тартып алу идеологиясенең танылган вәкиле Иван Пересветовның түбәндәге сүзләренә игътибарын юнәлтәсем килә: «Мондый уңайлы җирләрне» Казан белән Мәскәү «дуслыкта яшәгән очракта да» яулап

алырга кирәк булыр иде. Яхшылык, намус, хакыйкать турында һәм дин, һәм гомумкешелек тудырган кануннарны шулай бер селтәнүдә себереп түгүне күреп, мондый оятсызлыкка бары тик шаккатырга гына кала!..

Казанның өлешчә тарихы, Казанның рус гаскәрләре тарафыннан яулап алынуының тарих фәнендә чагылыш табу темасы кыскача менә шуннан гыйбарәт. Гомумән, Россиядә, өлешчә Татарстанда барган бүгенге вәзгыять үткәндәге хәлләргә эмоциональ бәя бирүдән, нинди дә булса фәнни-фәлсәфи анализ ясаудан, нәтиҗәләр чыгарудан тоткарланып, тыелып торырга мәҗбүр итә. Минем карашымча, боларның барысы да, әйтик, 1992 елда, Казанның басып алынуына 440 ел тулган көннәрдә җирле вакытлы матбугатта яхшы ук чагылыш тапты кебек. Билгеле, тормышта акыл утырткан кеше кыяфәтенә кереп, татарлар арасында элек тә, хәзер дә бердәмлек булмавы, безнең канга сеңгән куркаклык һәм тышкы куркыныч каршында көчсезлегебез һәм, ниһаять, татарларның рус дәүләтчелеген торгызуда актив катнашуы, мәңгелек интернационализм турында сүз алып барырга мөмкин булыр иде. Ләкин нигә кирәк болар? Чөнки Чыңгыз ханның тәкәббер һәм горур улларының үзара ызгышып яшәүләреннән, Җучи Олысындагы (Алтын Урдадагы) «бөек низаг»лардан безгә мирас булып калган бу гадәтләрне татар кешесенең һәр яңа буыны аңлап-сизеп яши, тик барыбер шул ук «тырмага» китереп баса бирә. Шулай да милли аң тик ятмый, менә тагын шатлыклы бер яңалык пәйда булды. Язучы Солтан Шәмси дә үзенең «Низаглы йортта» дип аталган фәнни-художестволы китабында бу хакта—Кырым ханлыгы һәм Олы Урда, Казан ханлыгы һәм Касыйм ханлыгы арасында барган низаглар, Нугай татарларының эчке интригалары һ. б. мисалында үтемле һәм гыйбрәтле итеп әйтеп бирде. Иншалла, мондый әсәрләр соңгысы булмас...

Бүгенге сүземне XVI гасырның 40 нчы елларында Казанда яшәп иҗат иткән олуг татар шагыйре Мөхәммәдъяр сүзләре белән тәмамлыйсым килә:

Кем җиһанда барча тагатдин зийад
Гадел ирер, кыйл бу сүзгә игътикад.

Бу ике юллыктагы төп фикри-идея минем тарафтан мәкаләмә эпиграф итеп алынган шулай ук Казан шагыйре Шәриф Хаҗитархан фикеренә каршы килә алыр иде. Чөнки... өметсезлеккә урын юк—без оптимистлар булырга мәҗбүрбез! Кайчан да булса барыбер хакыйкать тантана итәчәк—бәлки аны оныкларыбыз, һич булмаса оныкларыбызның оныклары күрер!

Тик моңа бик тә, бик тә ышанырга һәм көрәшергә генә кирәк!





# 29—ГАНКӘБУТ (ҮРМӘКҮЧ) СҮРӘСЕ

**Ганкәбут сүрәсе 69 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Ганкәбут—үрмәкүч дигән сүз. 41 нче аятьтә кяферләрнең мәкерле эшләре үрмәкүч пәрәвезенә охшатыла; сүрәнең исеме шуннан килә.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әлиф. Ләм. Мим.

**2.** Иман китердек *(бер Аллаһка инандык)*, дип әйткәннән соң, авырлыклар аша сыналмабыз, безне игътибарсыз калдырырлар, дип уйлыйлармы әллә кешеләр? **(3)** Хактыр ки, Без алардан элек яшәп киткәннәрне дә сынаулар аша уздырдык. Әлбәттә, Аллаһ кем дингә тугры, кем монафикъ *(иман китереп тә дин тотмаган, ялганчы)* икәнне дә белеп тора.

**4.** Яманлык кылганнар: Аллаһтан качып котылырбыз, дип уйлыйлармы әллә? Бик тә ялгыш-начар фикерле алар.

**5.** Кем Аллаһ белән кавышуга өмет баглый, белеп торсын, Аллаһ билгеләгән ул вакыт *(Кыямәт)*, һичшиксез, киләчәк. Ул бар нәрсәне дә ишетә, күрә.

**6.** Җиһадта катнашкан, бары тик үз файдасы өчен генә сугышыр. Шөбһәсез, Аллаһ бернигә дә, беркемгә дә мохтаж түгел.

**7.** Иман китереп, игелек кылганнарның хаталарын кичереп, *(кылган игелекләреннән дә артык)* әҗер бирербез. **(8)** Без кешеләргә ата-анага игелекле булуларын васыять иттек. Әгәр алар син танымаган, белмәгән башка бер нәрсәне Миңа тиңләштерсәләр *(һәм шуңа инанырга кушсалар)*, аларга итагать итмә. Сез Минем янга кайтарылачаксыз. Шул чакта Мин сез кылганнар турында хәбәр бирермен. Сез минем янга кайтарылачаксыз, шул чакта Мин кылганнарыгыз турында хәбәр бирермен. **(9)** Иман китереп, игелек кылганнарны саф мөселманнар хисабына язарбыз. **(10)** Кешеләр арасында шундыйлары да бар ки:

—Аллаһка инандык,—диләр дә, дин юлында кыенлыкларга дучар булгач, кешеләр күрсәткән җәфаларны алар Аллаһның газабы буларак кабул итәләр. Аллаһ тарафыннан берәр муллык килсә, алар:

—Без дә, хакыйкатән, сезнең белән бер юлда идек,—диләр. Аллаһ галәмнәрдә *(һәр кешенең күңелендә)* ниләр барын бик яхшы белеп торучы түгелме? **(11)** Чыннан да, Аллаһ кемнең иман китергәнен, кемнең монафикъ икәнен бик яхшы белә. **(12)** Кяферләр иманлыларга әйтер:

—Безгә ияregез, *(безнең динне тотсагыз)* без сезнең гөнаһларны да үз өстебезгә алырбыз,—диярләр. Ләкин алар ул гөнаһларның берсен дә үз өсләренә алмас. Хактыр ки, алар ялганчы. **(13)** Алар үз гөнаһларын да, *(үзләре юлдан яздырган мөэминнәрнекен дә)* үз җилкәләрендә күтәреп Кыямәткә алып килерләр. Һәм ялганнары өчен җавап тотарлар.

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

**14.** Хактыр ки, Без Нухны үз халкына *(пәйгамбәр итеп)* күндердек. Ул үз халкы арасында тугыз йөз илле ел яшәде. Аның халкы барыбер иман китермәде *(бозыклык вә гөнаһка батып бетте)* һәм аларны Туфан суы йотты. **(15)** Әмма Без аны да, көймәдәгеләрне дә сау-сәламәт коткардык вә моны бөтен дөньяга үрнәк итеп куйдык.

**16.** Ибраһимны да *(пәйгамбәр иттек)*. Ул үз халкына әйтте:

—Аллаһка гыйбадәт кылыгыз. Аннан *(җәзасыннан)* куркыгыз. Әгәр белсәгез икән, бу эш сезнең өчен гаять хәерле булыр иде,—диде. **(17)**—Сез Аллаһка тиң диеп, үзегез уйлап чыгарган потларга табынасыз һәм ялган сөйлисез. Гәрчә, сезнең Аллаһтан башка табынган сыннарыгыз сезнең өчен бер бөртек ризык бирергә сәләтсез нәстәләр. Бәс, ризыгыгызны Аллаһ хозурында табарсыз. Аңа гыйбадәт кылыгыз, Аңа шөкер итегез. Сез бары тик Аның янына гына кайтарылачаксыз; **(18)** әгәр сез боларны ялган дип уйласагыз, сездән элек яшәп киткән халыклар да *(үз пәйгамбәрләрен)* ялганчы дип атадылар *(бәс, сезне дә шул кара язмыш көтә)*. Пәйгамбәрләр өстенә төшкән вазифа бары тик *(Аллаһның әмерләрен)* ап-ачык итеп аңлату.

**19.** Әллә соң алар күрмиме, ничек итеп Аллаһ башта барлыкка китерде, аннан соң юкка чыгарыр, соңра тагын терелтер. Боларны эшләү Аллаһка бик тә җиңел.

**20.** Әйт:

—Дөнья буйлый сәяхәт итегез, багыгыз: Аллаһ ничек итеп башта барлыкка китергәнне күрегез. Аллаһ тагын Ахирәт тормышын да бирәчәк. Аллаһның бөтен нәрсәгә кодрәте җитә,—диген.

**21.** —*(Аллаһ)* ихтыяр иткән кешесен җәзалар, теләгәнен ярлыкар. Барыгыз да бары тик Аңа кайтарылачаксыз,—диген. **(22)**—Сез Җирдә дә, Күктә дә Аллаһны бичара хәлдә калдыра алмассыз. Аллаһтан башка сезнең һичбер химаячегез һәм ярдәмчегез булмас,—диген.

*(М. Алидә: и не можете вы спастись ни на земле, ни на небе.)*

**23.** —Аллаһның аятьләрен вә Аның белән *(Ахирәттә терелеп)* кавышуны инкарь иткән кяферләр рәхмәтемнән мәхрүм калачак. Аллаһның ачык газабы да аларга тияр.

**24.** Халкы аңа *(Ибраһимга)* шулай җавап кайтарды:

—Үтерегез аны яки яндырыгыз,—диде. Аллаһ аны уттан коткарып калды. Хактыр ки, иманлылар өчен монда гыйбрәтләр бар. **(25)** Һәм ул *(Ибраһим)* әйтте:

—Сез дөнья хәятендә Аллаһтан башка потлар уйлап чыгарып, шуларга барыгыз да мәхәббәт тәрбия иттегез. Ләкин ахырда, Кыямәт көнендә сез бер-берегездән ваз кичеп, бер-берегезгә ләгънәт орачаксыз. Сез барачак җир—утлы тәмугтыр. Анда сезнең һичбер ярдәмчегез булмас,—диде.

**26.** Шуннан соң *(Ибраһимның туганнан туган энесе)* Лут иман китерде. *(Ибраһим)* әйтте:

—Хактыр ки, мин Раббым ягына һиҗрәт итәчәкмен *(Аллаһ кушкан җиргә күчеп китәчәкмен)*. Шик юктыр ки, һәрвакыт җиңүче, хөкем вә хикмәт иясе—Улдыр,—диде.

**27.** Без аңа Исхак илә Ягъкубны багышладык. Пәйгамбәрлек һәм Китапларны *(Тәүрат, Инҗил, Зәбур, Коръәнне)* аның токымына васыять иттек. Дөньяда ана бүләкләр бирдек. Хактыр ки, ул Ахирәттә дә һәрхәлдә изгеләрдән саналачактыр.

**28.** Лутны да Без *(үз халкына пәйгамбәр итеп күндердек)*. Хәтерлисенме, ул халкына болай дигән иде:

—Сез мона кадәр дөньяда һичбер халык кылмаган нәҗес эш эшлисен *(егетләрне хатын итеп кулланасыз)*,—диде. **(29)** —Сез һәрвакыт ирләрне *(хатын итеп)* кулланачаксызмы, юлбасарлык кылырсызмы, өерелешеп, шәригатьтә булмаган бозыклыклар кылырсызмы?—диде. Халык болай җавапланды:

—Әгәр дә син дөрес сөйлисең икән, *(хаклы икәнеңне исбат итәр өчен)* өстебезгә Аллаһның җәзасын индерт,—диделәр.

*(Народу Лотову приписываются три порока—противоестественный грех, разбой на дорогах и свершение злодеяний на сборищах их. Поэтому неверно сводить все их прегрешения, описанные в истории Лота, лишь к противоестественному греху, якобы единственной причины их виновности.*

Мөхәммәд Али тәфсиреннән.)

**30.** *(Лут ялварып)*:

—Йа, Раббым, бозык халыкка каршы көрәшергә көч бир,—диде.

**31.** Илче *(фәрештә)* ләребез Ибраһимга *(угыллары булачагы турында)* сөенче алырга килгәч, әйттеләр:

—Без бу төбәкнең бозык халкын һәлак итәчәкбез. Чөнки, чыннан да, ул залимнәр гөнаһка кереп батканнар. **(32)** *(Ибраһим әйтте)*:

—Алар арасында Лут та бар бит,—диде.

—Без анда кем булганлыгын бик тә яхшы беләбез,—диделәр.—*(Һәлакәткә дучар гөнаһлылар һәм)* хатыныннан башка, аның үзен һәм якыннарын, һичшиксез, коткарачакбыз.

**33.** Илчеләребез *(фәрештәләр)* килгәч, Лут хафага тарды *(аның өенә килеп кергән фәрештәләр бик тә чибәр егетләр рәвешендә иде. Лут аларны хатын итеп файдаланырлар, дип курка калды)*. Шул сәбәпле аның йөрәге кысылып куйды.

—Курыкма син, борчылма,—диде *(егет кыяфәтендәге фәрештәләр)*,—без сине дә, якыннарыңны да коткарачакбыз. Әлбәттә, *(һәлак булачак)* хатыныңнан башка; **(34)** һичшиксез, бу төбәкнең халкына, кылган гөнаһлары өчен, Күктән хәтәр җәза индерәчәкбез.

**35.** Хактыр ки, акылы башында булганнарга Без шушы вакыйгаларны сабак булсын, дип калдырабыз.

**36.** Үз кавеменә—Шөгаебне *(күндердек)*, ул әйтте:

—Әй, кавемем, Аллаһка гыйбадәт кылыгыз. Ахирәт көненә өмет баглагыз *(ахирәт көнендә Аллаһ каршысында әҗер алыр өчен, гөнаһ кылудан сакланыгыз)*. Җир йөзендә фетнә чыгара торган бозыклыклар таратмагыз,—диде. **(37)** Ләкин аны ялганчы дип атадылар. Шуна күрә, аларны хәтәр зилзилә тотты һәм аларның барысы да үз өйләрендә муеннары аска килеп, *(йөзтүбән)* харап булды.

**38.** Гад белән Сәмуд кавемнәрен дә *(һәлак иттек)*. *(Алар белән ни булганын)* сез хәрабәләргә калган өйләреннән күреп белерсез. Аларның яман эшләрен шайтан яхшы итеп, бизәп күрсәтте һәм азлырды. Юкса, алар дөньяга ачык күз белән бага иде.

**39.** Карунны, Фиргавенне, Һамәнне дә *(һәлак иттек)*. Хактыр ки, Муса аларга ап-ачык дәлилләр китерде, ләкин алар дөньяда тәкәбберләнделәр. Газаптан котыла алмадылар.

**40.** Менә шулай итеп, Без аларның һәммәсен дә гөнаһларына күрә җәзага тоттык. Кайсысының түбәсенә *(таш яудырган)* давыл белән *(Лут халкын)*, кайсысын коточкыч бер үкерү *(Сур быргысы)* тотты *(Мәдьян, Самуд кавемнәрен)*, кайсысын җиргә уптырдык *(Карунны)*, кайсысын суга батырдык *(Фиргавен һәм Нух токымнарын)*, Аллаһ аларга золым китермәде, алар үзләренә-үзләре золым китерде.

**41.** Аллаһтан башка илаһлар уйлап табынучыларның гамәле пәрәвез корган үрмәкүчнекенә охшаш. Әгәр алар аңлый торган затлар булса, үрмәкүч оясы—пәрәвезнең никадәр дә чыдамсыз икәнен белерләр иде! **(42)** Аллаһ Үзеннән башка нәрсәләргә табынганнарын, һичшиксез, белә. Ул—һәрвакыт кодрәтле җиңүче һәм хикмәтләр иясе.

**43.** Менә без бу мисалларны, гыйбрәтләрне кешеләр сабак алсын өчен китерәбез. Аларны фәкать белемле, зиһенле кешеләр генә аңлар.

*(«Кураешнең җаһил, башсыз адәмнәре: «Мөхәммәднең Раббысы, чебен-черки,*

*урмәкүчләрдән мисаллар китерә»,—дип мыскыллы көлделәр. Бу мисалларның мәгънәсен наданнар, хайван дәрәҗәсендәге мәхлук җаһилләр аңламас, әлбәттә».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.)

**44.** Аллаһ күкләрне һәм Җирне чынбарлык буларак яратты. Хактыр ки, монда *(Аллаһның бу могҗизалы эшләрендә)* иманлылар өчен гыйбрәт алырлык нәрсәләр бар.

**45.** *(Рәсүлем Мөхәммәд)* үзеңә вәхий ителгән Китапны укы һәм намаз кыл. Хактыр ки, намаз бит бозыклыклардан, акылга һәм шәригатькә сыймаган нәрсәләрдән саклый. Аллаһны зикер итү, әлбәттә, *(гыйбадәтләрнең)* иң әһәмиятлесе. Аллаһ ни кылсагыз, шуны белеп торучы.

**46.** Залимнәреннән башка, китаплылар *(яһүдләр)* белән бозылышмагыз, әдәпле сөйләшегез, матур мөгамәләдә булыгыз.—Үзебезгә иңдерелгәнгә *(Коръәнгә)* дә, сезгә иңдерелгәнгә дә *(Тәүратка да)* иман китердек. Безнең Тәңребез дә, сезнеке дә—бер Аллаһтыр. Һәм без аңа итагать иттек,—дип әйтегез.

**47.** Шулай итеп, Без сиңа *(алда иңдерелеп тә, соңра кешеләр тарафыннан бозылган изге китапларны дөресләүче)* бу Китапны иңдердек. Шуңа күрә, китап әһелләре *(яһүдләр дә)* моңа иман китерде. Тегеләре арасында да аңа иман китергәннәр бар. Безнең аятьләребезне кяферләрдән башкасы, белгән көенчә, беркем дә инкарь итмәс. **(48)** Син моннан әүвәл һичбер китап укымадың. Кулың белән дә китап язмадың. Әгәр шулай булган булса, мөшрикләр *(аятьләрне ялган дип)*, әлбәттә, шикләнер иде.

**49.** Юк шул, ул *(Коръән Аллаһ тарафыннан бирелгән һәм)* гыйлем ияләренең күңелләрендә яктылык булып саклаучы ап-ачык аятьләрдән тора. Безнең аятьләребезне галелсез залимнәр инкарь итә.

**50.** Мөшрикләр әйтте:

—Аңа *(Мөхәммәдкә)* Раббыдан *(аның пәйгамбәрлеген исбат итә торган)* могҗизалар иңдерелсә иде *(без иман китерер идек)*,—диделәр. Әйт син аларга:

—Могҗизалар фәкать Аллаһ ихтыярында гына. Мин бары тик Аның әмерләрен җиренә җиткезеп кисәтүче генә,—диген. **(51)** Сиңа иңдерелгән һәм укып аңлатыла торган Китап аларга могҗиза түгелмени? Аңа иман китергән кавем өчен, әлбәттә, киң рәхмәтләр вә гыйбрәтләр бардыр. **(52)** Әйт син:

—Минем белән сезнең арада Аллаһның, чыннан да, шаһит икәнлеге бик җиткән,—диген.—Күкләрдә, Җирдә ни булса, Ул шуларны белеп тора. Ялганга йөз тотып, Аллаһны инкарь итеп, кяфер булганнар байтак. Менә шулар инде зыян күрәчәк.

**53.** Алар синнән газап килүне *(өстебезгә таш яудыр, дип)* ашыктырыр. Әгәр дә махсус билгеләнгән вакыт булмаса, ул *(җәза)* әллә кайчан килеп тотар иде. Ул *(җәза)* аларга абайламаганда, һичшиксез, кинәттән киләчәк. **(54)** Әйе, алар җәзаның тизрәк килүен телиләр. Гәрчә, чынлыкта исә җәһәннәм кяферләрне уратып алган бит инде. **(55)** Шул көндә газап аларны өсләреннән дә, аяк асларыннан да тотачак. Аларга әйтеләчәк:

—Кылган гөнаһларыгызның җәзасын татып карагыз,—диелер.

**56.** Әй, иман китергән колларым, хактыр ки, Минем җирем киңдер. Шулай булгач, бары тик Миңа гына гыйбадәт кылыгыз. **(57)** Һәр җан иясе үлем әчесен татыр. Аннан соң һәркем хозурыбызга кайтарылыр. **(58)** Иман китереп, игелек кылганнар да байтак. Без аларны арыкларыннан чишмәләр агып торучы җәннәтнең иң түренә урнаштырырбыз. Алар анда мәңгегә калыр. Игелек кылганнарның әҗере ничек гүзәл.

**59.** Алар *(кяферләр, мөшрикләрнең кыерсытуларына түзүчеләр)* сабыр итүчеләр һәм бары тик Раббыга гына инанганнар. **(60)** Үзләренә ризык табалмаган никадәр җанлы мәхлук бар бу дөньяда. Шундыйларга да, сезгә дә Аллаһ ризык бирә. Ул чыны белән ишетүче һәм мөкаммәл белеп торучы. **(61)** Алардан:

—Күкләрне һәм Жирне кем яралткан? Кояшны, Айны буйсындырып йөртүче кем?—дип сорасаң, алар мотлак:
—Аллаһ,—дип җавап бирер. Шулай булгач, нигә соң алар *(тормыш мәшәкатьләре белән мавыгып, иманнан)* йөз чөерәләр?

**62.** Теләгән кешесенең ризыкларын Аллаһ киң итәр. Бәгъзе колларының өлешен киметер. Шик юк ки, Аллаһ һәрнәрсәне дөресе белән белеп тора.

**63.** Алардан:
—Күктән су иңдереп, корыган туфракны тергезгән кем?—дип сорасаң:
—Әлбәттә, Аллаһ,—дип җавап бирерләр. Әйт син аларга:
—Әлхәмдүлилләһ, бөтен мактаулар да Аллаһка гына булсын, диген. Ләкин аларның күбесе шуны аңламый.

**64.** Бу дөнья хәяте уен гына, күңел ачу гына—башка түгел. Чын тормыш—ул Ахирәт тормышы, бу турыда шик булырга мөмкин түгел. Алар шуны белсә *(фани дөньяда гөнаһ кылмас)* иде.

*(«Имам Галидән сораганнар, имеш: дөнья ни-нәрсә ул?—дигәннәр. Хәзрәти Гали әйткән: сине Аллаһтан аерып торучы нәрсә,—дигән».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**65.** Көймәдә барган чакта *(куркыныч янаганда)* алар чын мөселман кебек, Аллаһка ялвaралар. Аларны исән-сау килеш коры җиргә чыгарып бастыргач, Аллаһтан башкаларга табыналар. **(66)** Үзләренә биргән нигъмәтләргә шөкер итмиләр, кәеф-сафа коралар. Ләкин алар озакламый *(эшләренә ни кыләсен)* белер. **(67)** Мәккәнең тирә-ягында кешеләрне тотып үтерәләр иде, Мәккәне Без *(җинаять кылу)* харам ителгән иминлек урыны итеп ясадык. Алар шуны күрмәс дәрәҗәдәмени? Ялганга ышанып, Аллаһның нигъмәтләренә көферлек кылырлар микәнни?

**68.** Аллаһ турында ялган сөйләгән *(Аңа тиңдәш эзләүче)* яки үзләренә Хакыйкать *(Коръән, пәйгамбәрләр)* килгәннән соң да аны ялганга чыгарганнардан да залимрәк кем бар? Җәһәннәмдә кяферләргә урын беткәнме?

**69.** Безнең юлда тырышканнарга *(Җиһадта катнашканнарга)* Без, әлбәттә, тугры юлны күрсәтербез. Шик юктыр ки, Аллаһ бары тик игелек кылганнар белән генә бергә.

## 30—РУМ (РУМ) СҮРӘСЕ

**Рум сүрәсе 60 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Иран гаскәрләре белән сугышта җиңелгән Рум гаскәрләре турында сөйләнгәнгә күрә, шушы исемне алган.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әлиф. Ләм. Мим.

**2.** Румнар җиңелде; **(3)** якын үзәндә. Гәрчә алар шушы җиңелүдән соң җиңүче булачак; **(4)** берничә елдан соң. Алдагысы да, соңгысы да Аллаһ хөкемендә булыр. Ул көнне мөэминнәр дә куаначак; **(5)** Аллаһның кодрәте илә. Ул теләгәненә ярдәм итәр. Ул мотлак кодрәтледер. Ярлыкаучыдыр.

*(«Китаплы кешеләр румлылар (бизанслар) мәҗүси Иран гаскәре тарафыннан җиңелгәч, Мәккә мөшрикләре бик сөенде. Алар мөселманнарга әйтте: әгәр дә Аллаһыгыз, сез әйткәнчә бердәнбер җиңүче булса, китаплы халыктан булган бизансларны җиңүче иткән булыр иде, диделәр. Шуннан соң Коръән, бер могҗиза буларак, киләчәктә булачак вакыйга турында хәбәр бирде: өч яки тугыз ел эчендә бизанслар иранлыларны тар-мар итәчәк һәм мөэминнәр дә сөенәчәк. Чыннан да, 624 елда бизанслар Иранга басып керделәр һәм җиңделәр. Шул ук елда мөселманнар Бәдер сугышында зур җиңүгә иреште».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**6.** Бу—Аллаһның вәгъдәседер. Аллаһ вәгъдәсеннән кайтмас. Ләкин кешеләрнең күбесе бу турыда белми. **(7)** Алар дөнья тормышының өске катын гына күреп беләләр. Ахирәт мәсьәләләрендә алар—наданнарның да наданы.

**8.** Аллаһның күкләрне, Җирне вә алар арасындагы барлыкларны Хакыйкать буларак яралтып, Үзенә генә мәгълүм вакыт биреп, аларның тәкъдирләрен алдан билгеләгәнлеге турында алар үз башлары белән уйлап карамадылармыни? Инсаннарның күбесе *(үлгәннән соң терелеп, Кыямәт көнендә)* Аллаһ хозурына киләчәкләренә ышанмыйлар.

**9.** Дөнья буйлап йөреп, үзләреннән элек яшәп киткәннәрнең язмышы ничек беткәне белән кызыксынмадылармы? Алар *(Гад, Сәмуд кабиләләре)* тегеләреннән гаять куәтле иде. Иген иктеләр, җирнең астын өскә әйләндерделәр *(су эзләп кое казыдылар, каналлар төзеделәр)*, Болар *(Мәккә кяферләре)* корган биналардан да яхшырак биналар кордылар. Пәйгамбәрләре аларга байтак кына дәлилләр, кисәтүләр белән килде. Аллаһ аларга золым итмәде, *(гаделсезлекләре, кылган гөнаһлары белән)* алар үзләренә-үзләре золым итте.

**10.** Аллаһның аятьләрен ялганга чыгарган вә аларны мәсхәрә итеп көлгән һәм гаделсезлек кылганнарның ахыры бик тә яман булды. **(11)** Аллаһ башта җанлыларны юктан бар итәр. Аннан соң үтерер һәм янадан тергезер. Иң соңында барысы да Аның хозурына китерелер *(кайсысына—җәннәт, кайсысына җәһәннәм бирер)*. **(12)** Кыямәт купкан көнне гөнаһкярлар телсез-тавышсыз калачак. **(13)** *(Аллаһка тиң күрелгән)* ясалма илаһлары аларга һичбер ярдәм күрсәтмәячәк. Соңыннан алар ясалма илаһларыннан да баш тартачак. **(14)** Кыямәт купкан көн—*(мөэминнәр белән инкарьчыларның)* бер-берләреннән аерыла торган көн.

**15.** Иман китереп, игелек кылганнар җәннәттә нигъмәтләр һәм куаныч эчендә яшәрләр. **(16)** Инкарьчылар, аятьләребезне вә Ахирәт көнен ялганга чыгаручылар исә рәхимсез газап эчендә калдырылачак. **(17)** Бәс, шулай булгач, кич житкәч тә, иртән дә Аллаһка тәсбих тартыгыз *(намаз укыгыз)*.

**18.** Күкләрдә *(фәрештәләр)* һәм Җирдә *(мәхлукат)* бары тик Аңа мактау җырлый. Көндезен *(икенде намазында да)*, төш турында *(өйлә намазында)* да *(Аллаһны зикер итегез. Аңа мәдхия әйтегез)*. **(19)** Ул җансыздан җанлыны *(шәһвәттән кешене, йомыркадан кошны)* чыгаручы. Үлгәннән соң терелтүчедер. Менә шулай итеп, сез дә *(үлемегездән соң каберләрегездән)* чыгарылачаксыз.

**20.** Сезнең туфрактан яралтылуыгыз Аның кодрәтенә дәлилдер. Соңра сез үрчеп, Җир йөзенә таралдыгыз.

*(Соңгы җөмлә М. Алидә: соңыннан сез әҗәлле булдыгыз, череп таралдыгыз, дип бирелгән.)*

**21.** Үзегездән хатыннарны яралту да, ул хатыннар белән *(ләззәтләнеп)* бергә яшәвегез дә, ир белән хатын арасындагы мәхәббәт һәм наз, бер-береннең хаталарын кичерә белү, һичшиксез, Аллаһның кодрәтенә ачык дәлилләрдер. Хактыр ки, бу эшләрдә фикерле белүче кавемнәр өчен гыйбрәтләр бар.

**22.** Аның күкләрне һәм Җирне юктан бар итүе дә, Ана телләрегезне, тән төсләрегезне төрле-төрле итеп яралтуы да—Аллаһның бәхәссез дәлилләредер. Хактыр ки, боларда хәбәрдарлар өчен гыйбрәтләр бар.

**23.** Төннәрен йокы ләззәтен татуыгыз да, көндезләрен ятып хәл алу һәм *(өлешегезгә тигән)* ризыкны табуыгыз да—Аның могҗизаларына ачык дәлилләр. Хактыр ки, бу хәлләрдә дә *(күңел колагы)* саңгырау булмаганнар өчен гыйбрәтләр бар.

**24.** Ул яшен яшьнәтеп, сезгә *(яшен сугар дип)* курку һәм *(яңгыр явып, иген мул булыр дигән)* өмет бирә. Ул яңгыр яудырып, корып үлгән туфракка җан өрә. Хактыр ки, фикерле белгәннәр өчен гыйбрәтләр бар.

**25.** Күк белән Жирнең Аллаһ ихтыярына буйсынуы да—Раббының могҗизасы. Ахырда ул сезне чакырыр, һәм сез шундук каберләрегездән кубып, Аның янына җыелырсыз. **(26)** Күкләрдәге һәм Җирдәге барлыкларның һәммәсе дә—Аныкыдыр. Барысы да Аңа гына буйсынган. **(27)** Ул иң башта юктан бар итеп, аны *(үтергәннән соң яңадан)* тергезүчедер. Аның өчен бу эшләр бик тә ансаттыр. Күкләрдәге һәм Җирдәге иң югары сыйфат *(әхлак, миһербан, гафу итә белү, сүзгә тугры калу)* Аллаһның Үзендәдер. Аллаһ—һәрвакыт җиңүче, кодрәт иясе һәм хикмәтләр хуҗасы.

**28.** Ул сезгә *(мөшрикләргә)* үзегезнең тормышыгыздан мисал китерә:
—Сезнең әмерегездә булган коллар арасында сезгә Без биргән ризыкларны тигез итеп бүлешергә теләгәннәре бармы? Һәм сез алар белән тигез булып *(малыгызны тигез бүлеп)*, үзегезне хөрмәт иткән кебек, аларны хөрмәт итәрсезме *(тиңнәрегездән курыккан кебек, куркасызмы)*? Акыл белән эш итүчеләр өчен Без аятьләребезне менә шулай аңлатабыз.

**29.** Юк шул, *(алай итмәделәр, малларын колларына бирмәделәр)* алар, ни кыланганнарын да белмичә, үз нәфесләренә буйсындылар. Аллаһ Үзе юлдан яздырганнарны кем тугры юлга кертә алыр икән? Аларга һичкем ярдәм итә алмас.

**30.** Бәс, син *(ий, Мөхәммәд)* Аллаһка тугры буларак йөзеңне тугры дингә туры тот. Ул инсаннарны шушы дин өчен яралтты. Аллаһның диненлә үзгәрешләр булмас. Бу дин—нык һәм иң дөрес диндер. Ләкин инсаннарның күбесе бу турыда белми. *(Шуңа күрә алар иман китерми.)* **(31)** Барыгыз да Аңа юнәлегез, Аңардан куркыгыз, намазны дөрес укыгыз, мөшрик булмагыз.

**32.** Диннәрен фирка-фиркага бүлгәләп, аерып, таркатып бетерүчеләр кебек булмагыз. Аларның һәрберсе үз фиркасы белән *(безнең дин—иң яхшы дин, дип)* мактана.

**33.** Кешеләрнең башына берәр бәла килсә, Раббыга, бары тик Аңа баш орып, дога укыйлар. Аллаһ аларга рәхмәт *(нигъмәт, муллык)* бирсә, күреп торыгыз, аларның бер кавеме тагын Аллаһтан башкага табынырга тотына; **(34)** биргән нигъмәтләребезгә шөкранә итмәстән. Әйдә, кәефләнегез, ләкин сез озакламый ни буласын беләчәксез. **(35)** Юкса, Без аларга Аллаһның тиңдәше барлыгы турында дәлилләр китермәдек. *(Без аларны мөшрик булырга өндәмәдек.)*

**36.** Инсаннарга рәхмәт *(байлык, ләззәт, шөһрәт)* иңдерсәк, алар куана. Гөнаһларына күрә, башларына афәт төшсә, шундук өметсезлеккә биреләләр. **(37)** Әллә соң алар күрмиләрме, Аллаһ ризыкны теләгәненә мул итеп бирә, кайсыларына кимете. Шик юктыр ки, иманлылар өчен монда гыйбрәтләр бар.

**38.** Туганнарыңа, ярлыга, сәяхәттәгеләргә тиешлесен бир. Аллаһның ризалыгын казанырга теләгәннәр өчен моннан да игелеклерәк эш юк. Менә шулар инде *(җәзадан)* котылып, *(Сәгадәткә)* ирешәчәк.

**39.** Байлыгыгызны күбәйтер өчен, арттырып кайтару шарты илә алган керемнәрегез Аллаһ катында артмас *(сезнең файдага булмас)*. Аллаһ ризалыгы өчен зәкят бирсәгез, *(савапларыгыз, малларыгыз)* кат-кат арттырылыр.

**40.** Аллаһ сезне бар итүче, соңра ризыкландыручы; ахырда җансыз итеп, тагын терелтер. Сез табынганнарның берәрсе шушы эшләрнең, ичмасам, берәрсен башкара аламы? Аллаһ аларның уйдырма илаһларыннан пакь һәм бөек.

**41.** Кешеләрнең кылмышлары *(фәхешлекләр)* аркасында коры җир өстендә дә, диңгездә дә тәртип бозылды. *(Сугышлар, янгыннар, чирләр, рәхимсез талаулар аркасында урман, дала, елгалар пычрана бара).* Кылмыш гөнаһларына күрә *(Ахирәттә)* бирелә торган җәзаларның бер өлешен *(бу дөньяда)* татытыр. Бәлки, алар тәүбә итәрләр!

**42.** *(Ий, Рәсүлем Мөхәммәд)* әйт син:
—Дөнья буйлап йөрегез һәм сез әүвәл яшәп киткәннәрнең ахыргы

язмышы ничек булганын күрерсез. Аларның күбесе мөшрик иде,—диген.

**43.** Бу дөньяга кире кайтарылмый торган Көн *(Кыямәт)* килгәнче син йөзеңне хак дингә бор. Ул Көнне кешеләр аерым-аерым төркемнәргә бүленер.

*(Мөселманнар—җәннәткә; кяферләр, мөшрикләр, монафикълар—җәһәннәмгә).*

**44.** Кем инкарь иткән, инкаре үз башына булыр. Игелек кылганнар үзләре өчен җәннәт хәзерләде. **(45)** Иман китереп, игелек кылганнарга Аллаһ үз тарафыннан әҗер бирер. Шик юк ки, Аллаһ имансызларны сөйми.

**46.** Нигъмәтләремне татысыннар, Аның әмере илә йөри торган көймәләргә утырып, насыйп ризыкларын казансыннар дип, шуларга шөкер итсеннәр дип, сөенечле хәбәрләр китерсен дип, җилләрне истерү галәмәте дә Аллаһның барлыгына, чиксез кодрәтенә бәхәссез дәлилләр булып тора.

**47.** Хактыр ки, Без синнән элек тә халыкларга үзләре арасыннан чыккан пәйгамбәрләр күндердек һәм аларга да ачык дәлилләр бирдек. *(Ул пәйгамбәрләргә ышанмыйча)* гөнаһка батканнарны тиешле җәзага тарттык. Мөэминнәргә ярдәм итү—Безнең эш.

**48.** Җилләрне истереп, болытларны кудыручы—Аллаһ. Болытларны, Үзе теләгәнчә, Күк йөзенә таратучы да, кисәкләп-кисәкләп яңгыр яудыртучы да—Аллаһ. Аллаһ, яңгыр яудырып, теләгән колларына куаныч иңдерә. **(49)** Юкса, озак яңгыр яумый торса, алар хафага төшә.

**50.** Бак син Аллаһ Тәгаләнең нигъмәтләренә! Корып, үлгән туфрак ничек яңадан терелә? Шик юктыр ки, Ул мәетләрне дә шулай тергезәчәк, Аллаһның бар нәрсәгә дә кодрәте житә. **(51)** Хактыр ки, әгәр дә Без коры җилләр истереп, бөтен әтрафны саргайтсак, шуннан соң да алар Аллаһка иман китермәс, шөкранә кылмас.

**52.** *(Рәсүлем)* әлбәттә, син *(тере)* мәетләргә *(хак сүзне)* ирештерә алмассың, *(Аллаһтан килгән хак сүзләреңә ышанмастан)* арка биреп китеп барган *(күңеле)* чукракларга *(Аллаһның чакыруларын)* ишеттерә алмассың. **(53)** Син тугры юлдан язган *(күңел күзе)* сукырларны да һидаяткә илтә алмассың. Син бары тик аятьләребезгә иман китереп, мөселман булганнарга гына *(хак сүзне)* ишеттерә алырсың.

**54.** Аллаһ сезне хәлсез *(бала)* итеп яралткан. Аннан соң хәлсезлектән хәлләндереп, куәт биргән; куәт артыннан тагын сезне хәлсезләндергән *(картайткан)*. Ул үзе теләгәнне башкара. Ул—һич шик юктыр ки, барысын да мөкәммәл белеп торучы кодрәт иясе.

**55.** Кыямәт купкан Сәгатьтә гөнаһкярлар *(фани дөньяда, кабердә)* бер сәгатьтән дә артык тормадык, дип ант итәчәкләр. Менә шулай, алар *(фани дөньяда алданып)* бозылганнар.

**56.** Гыйлемле һәм иман китергәннәр шулай әйтер:
—Хактыр ки, Аллаһның китабында язылганча, сез яңадан терелү көненә *(Кыяматкә)* кадәр яшәдегез. Менә бүген *(Кыямәт сәгате сукты, сез)* яңадан терелдегез. Ләкин сез моңа ышанмадыгыз. **(57)** Ләкин ул көнне акланырга тырышулары аларга файда китермәс. Һәм алардан Аллаһ ризалыгын казанырга маташулары да таләп ителмәс.

**58.** Хактыр ки, кешеләр *(гыйбрәт, сабак алсын)* өчен Без Коръәндә төрле мисаллар китерәбез. Ләкин *(ий, Мөхәммәд)* син аларга бер аять китерсән, кяферләр мотлак әйтәчәк:
—Сез ялган сөйләүдән башканы белмисез,—диячәкләр. **(59)** Менә, белмәгәннәрнең *(итагать итәргә теләмәгәннәрнең)* күңелләренә Аллаһ шулай итеп мөһер суга.

**60.** *(Ий, Мөхәммәд)* син хәзергә сабыр ит. Шик-шөбһә юк ки, Аллаһның вәгъдәсе хактыр. Сак бул! Моңа инанмаганнар синең иманыңны какшатмасын!

**Сергей Кляшторный**

# ТАТАРЛАРНЫҢ ҮЗӘК АЗИЯДӘГЕ ДӘҮЛӘТЛӘРЕ

## МОНГОЛЛАРГА ХӘТЛЕ ЧОР

*Бу язманың авторы Сергей Григорьевич Кляшторный—профессор, борынгы төркиләр турындагы тикшеренүләре белән дөньякүләм танылган галим; «Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средний Азии» (1964), «Гуннская держава на Востоке» (1982), «Государства татар в Центральной Азии» (1995), «Степные империи Евразии» (1994, Д. Г. Савинов белән берлектә) дигән китаплары галимгә шөһрәт китергән хезмәтләрдән саналалар.*

*С. Г. Кляшторный хәзерге вакытта Россия Фәннәр Академиясе карамагындагы Шәрекъне өйрәнү институтының Санкт-Петербург филиалында тюркология һәм монголистика бүлеге мөдире. Сергей Григорьевич соңгы елларда Казанда үткәрелгән күп кенә халыкара конференцияләрнең, шул исәптән Татарстан Республикасы башкаласы Казанның 1000 еллыгына багышланган конференциянең кураторы, «Татарларның һәм Татарстанның тарихы» дигән күптомлы уникаль хезмәтнең консультанты. Ул басманы Татарстан Фәннәр Академиясенең Тарих институты, Татарстан китап нәшрияты һәм «Рухият» нәшрияты әзерли.*

*Түбәндә журнал укучыларга тәкъдим ителә торган язма беренче тапкыр «Mongolica» (1993) җыентыгында дөнья күрә. Аның тарихи әһәмияте Үзәк Азия татарларының дәүләте яшәгәнлеген реаль яктыртуда гына түгел, ә бәлки «татар», «татарлар» дигән этнонимның килеп чыгышын киң тарихи яссылыкта карауда да. Бу ике мәсьәлә безнең халкыбызның этнополитик тарихына турыдан-туры кагыла. «Өстән» ризалык белдереп, Төрки һәм күрше халыклар арасында башланган аңлашылмаучылыклар, «җир» һәм «тарих» бүлешүләр вакытында бу мәсьәлә аеруча актуаль булып тора.*

Үзәк Азиядә яшәгән халыкларның монголларга хәтле һәм монголлар чорындагы тарихын чагылдыручы бу хезмәткә Рәшидэтдиннең «Җәмигъ әт-таварих» әсәре төп нигез булып тора дип әйтсәк хата булмастыр, мөгаен. Анда, аңлашылса кирәк, Монголлар империясен төзүче халыкларның тарихи язмышы турында сөйләнелә, ләкин башка чорлар һәм башка халыклар-кабиләләрнең язмыш-тарихы да теге яки бу күләмдә «ачык тамгалар» белән билгеләп үтелә. Татарлар турында да байтак мәгълүмат бирелгән. «Җәмигъ әт-таварих» авторы карашынча: «Татарларның исемнәре дөньяга борынгыдан ук мәгълүм. Алардан бик күп тармаклар таралган... Аларның күченеп йөрү, туплану, торлак урыннары һәм юрта-йортлары Кытай белән чиктәш өлкәләрдә туган-тумачалык, ырудашлык билгеләре буенча тәгаенләнгән була. Төп яшәү урыннары, юрта-йорт куйган төшләре Буир-Наур дип атала. Алар күршекүлән дошманнары белән генә түгел, үзара да ызгышып һәм талашып яшәгәннәр, кабиләләр арасында шулай ук озакка сузылган сугыш һәм бәрелешләр дә булып торган» *(Рәшидэтдин. Җәмигъ әт-таварих, 100 б).*

Шулай итеп, татарларның төп йорты Көнчыгыш Монголиядәге Буир-Наур күле тирәсендә урнашкан дип әйтә алабыз. Анда, шулай ук, югарыда әйтелгәнчә, үзара күптән ызгышып һәм талашып яшәгән башка йортлар һәм татар кабиләләренең тармаклары турында телгә алына. Шуннан соң аларның Чыңгыз ханга кадәрге монголлар өстеннән хакимлек урнаштырулары хакында тарихи чигенеш ясала: «Әгәр алар үзара килешеп яшәсәләр, шундый күпсанлы булып та дошманлашып яшәмәсәләр, кытайлар һәм башка кабиләләр һәм, гомумән, бер генә җан иясе дә аларга каршы тора алмаган булыр иде. Шуңа да карамастан, алар бик ерак үткәндә үк башка кабиләләр һәм өлкәләр өстеннән үзләренең хакимлеген урнаштыралар—алар көч-куәтләре һәм абруйлары белән башкалардан аерылып торганнар. Шул сәбәпле, башка төрки кабиләләр дә, исем-атамалары, яшәү рәвешләре төрлечә булса да, тарихта шул атама белән билгеле һәм алары да татар дип аталып йөртелә башлыйлар». Аннары Рәшидэтдин тагын болай дип өсти: «Хәзер, ягъни XVI гасырларда, шул сәбәпле төрки кабиләләр үзләрен монголлар дип атыйлар, «гәрчә борынгырак дәверләрдә алар бу исем-атаманы кире кагып килсәләр дә» (102 б.). Ниһаять, Үзәк Азиянең Чыңгыз хан дәверенә чаклы тарихыннан бер хәтерләү: «Үзенең аерым гаскәре һәм хакиме булган данлы һәм шанлы татар кабиләләре—алты. (103 б.).

Рәшидэтдин монголларга чаклы Үзәк Азиянең, дөресрәге, аның күпчелек төрки кабиләләр яшәгән дала өлешенең этнонологик схемасын да тәкъдим итә. Схеманың «конструктив» структур төзелешен алты татар дәүләте тәшкил итә («аларның үз хакиме булган»), шулар арасында Буир-Нуар йорты өстенлекне саклаган. Ерак үткәндә дә татарлар, кабиләара бәрелешләр һәм ызгышлар булып торуга да карамастан, «кытай чикләрендә яшәгән» барлык кабиләләрне һәм өлкәләрне үз кул астында тотканнар. Басып алынган кабиләләрнең күпчелеге, әлбәттә, «төрки токымнар» булалар. Алар басып алган кабиләләр атамасыннан чыгып татарлар дип атала башлыйлар. Бу вакыйгалар шул кадәрле борынгы дәвергә карыйлар ки, монда монголларның эзе дә күренми, чөнки алар тагын өч йөз елдан соң гына, ягъни IX—X гасырларда гына мәгълүм булалар. Шунысын да искәртеп үтик, Рәшидэтдиннең әйтүенә караганда, «борынгы дәверләрдә монголлар далада яшәүче бик күп төрле төрки кабиләләрнең берсе генә була» (103 б.).



*Профессор С. Г. Кляшторный (сулда) Татарстан Республикасының Тарих институты директоры Р. Хәким (уңда) һәм Б. Хәмидуллин. «Татарларның һәм Татарстанның тарихы» дигән күптомлыкны тикшерү вакыты. 2001.*

Күргәнебезчә, Рәшидэтдин Үзәк Азия даласының этнополитик тарихын хронологик яктан төп өч этапка бүлеп карый: а) дала төркиләре кабиләләренең вакыт параметрлары ягыннан билгеләнмәгән чикләрдә өстенлек итүе; б) төрки кабиләләрнең татарлар тарафыннан басып алынуы, татар этнонимының гомуми политонимга әверелүе; вакыт кысалары ягыннан караганда—ерак үткәннәрдән татар-монгол яуларына кадәр (XII гасыр); в) монголларның өстенлеккә ирешүе, татарлар тәмам җиңелгәннән соң, монгол этнонимының гомумимперия политонимына әверелү этабы (XII—XIII гасырлар).

Шуның белән бергә, Рәшидэтдин билгеләп үткәнчә, татарларның йогынтысы вә куәте шулкадәрле дәһшәтле була ки, «әле хәзер дә, ягъни XIV гасыр башында да Кытайдан Дәште-Кыпчакка һәм Мәгрибкә чаклы барлык төрки кабиләләр дә татарлар дип аталалар» (103 б.).

Әгәр «төрки эпоха», «монгол эпохасы» дигән терминнар куллану гыйльми хезмәтләрдә күптән гадәткә әверелгән булса, Үзәк Азия тарихын өйрәнүдә «татар дәвере» дигән термин үзәк урынны алып тормый. Киресенчә, ул «татар-монгол эпохасы», «монгол-татар яулары» дигән ясалма, стереотип кысаларга кысрыклап

кертелгән. Шуның белән бергә, Рәшидэтдин «татар» һәм «монгол» чорларын вакыт ягыннан бик ачык тәгаенли, аера һәм каршы куя.

Күренә ки, Рәшидэтдин тарафыннан тәкъдим ителгән историографик концепция фактик яктан җентекләп өйрәнелүгә мохтаҗ. Кызганычка каршы, аның хезмәтендә читләтеп яки ишарә рәвешендә әйтелгән урыннар да байтак; «Җәмигъ әт-таварих» та күпләп очраган этник терминнарны, топонимнарны, кеше исемнәрен укыганда да икеләнү-юраулар күп кенә аңлашылмаучанлыкларга китерә; күренеш-вакыйгаларга вакыт һәм пространтво ягыннан чыгып бәя биргәндә кыенлыклар тудыра. Әйтик, Буир-Наур биләмә-йортыннан башка татар йортлары кайсы тирәгә урнашкан булган, болары сер булып кала бирә. Шуңа күрә, монда борынгы татарлар турындагы башка чыганакларга да мөрәҗәгать итү урынлы булыр.

С. И. Вайнштейн 1960 елда Хербис-Баары (Тува) тирәсендә фәндә моңарчы билгеле булмаган руник язулы кыргыз балбалын тапты. Соңрак бу язулы таш турында А. М. Щербак дигән галим дә ике тапкыр язып чыкты *(Щербак А. И. Новая руническая надпись на камне.—УЗНИИЯЛИ. Вып. IX., 1961; Щербак, 1964).* Таш һәйкәл Кюлюг Йиге дигән атаклы хәрби полководецка атап куелган. Язуда әйтелгәнчә, аның төп батырлыгы татарга каршы яу чабуда булган икән: «Егерме сигез яшемдә мин, үз дәүләтемне яклап, тугыз татарларга каршы яу чаптым».

1976 елда Л. Р. Кызласов тарафыннан Хакасиядә, Уйбат елгасы үзәнлегендә руник язулы тагын бер таш һәйкәл (тәртип саны буенча тугызынчысы) табылды һәм укылды, соңрак бу истәлекне мин дә үз фаразлавымда укып чыктым. Бу язуның беренче юлында «дошмани татар иле» хакында әйтеп үтелә һәм татарлар тарафыннан ясак түләнүе хәбәр ителә.

Енисей кыргызлары татарларга каршы кайчан уңышлы яу йөргәннәр соң?

Татарлар турында тәүге тапкыр (утыз татар турында) руник язулы иң зур һәйкәлләрнең берсендә—Күл Тәгин хөрмәтенә куелганында хәбәр ителә: ягъни төрки каганнарны күмү уңае белән, XI гасырның икенче яртысында булып узган вакыйгалар уңаеннан искә алыналар. Икенче тапкыр исә алар шул ук исемдә (утыз татар сыйфатында), шул ук язуда Күл Тәгиннең атасы Ильтерес каганның дошманы сыйфатында билгеләп үтеләләр. Ул чакта татарлар төркиләр белән сугыш алып барган (кыргызлар белән берлектә) тугыз-угызларны яклап чыгыш ясыйлар. 723-724 елларда татарлар (тугыз-татарлар) тугыз-угызлар белән берлектә Билге-Каганга каршы көрәш алып баралар, бу хакта Күл Тәгиннең олы абыйсы хөрмәтенә куелган истәлектә—кабер ташында сөйләнә. Соңгы вакыт татарлар (тугыз-татарлар) турында Могон Шине Усу руник язмаларында уйгурлы Элетмиш Бильге-Каган кабер ташында (760 ел) телгә алына. Татарлар, угыз кабиләләре белән берлектә, VIII гасырның 40 нчы елларында уйгур каганатына каршы баш күтәрәләр һәм җиңелүгә дучар ителәләр. Шул рәвешле, VII гасыр ахырларында, VIII гасырның беренче яртысында татарлар, кыргызлар кебек үк, сәяси юнәлештә, икенче төрле әйткәндә, аларның турыдан-туры эвентуаль (кайсыбер вакыйга-күренешләргә мөмкин булган) арадашчылары булып торалар.

Әйткәнебезчә, VI—VII гасырларда татар кабиләләре арасындагы мөнәсәбәтләр орхон язмаларында утыз-татар исемендә чагылыш таба, ә VIII гасыр урталарында Хербис-Баары Енисей язмаларындагы кебек үк, алар тугыз-татар дип аталалар. Атамадагы мондый үзгәрешләр татар кабиләләренең башлангыч төркемнәре арасындагы таркалуны чагылдыруы да мөмкин, ләкин безнең өчен шунысы әһәмиятле, Енисей язмаларында искә алынган вакыйгалар VII гасырның икенче яртысыннан иртәрәк башланмаган булырга тиеш. Тагын шунысын да искәртеп үтү зарур, VIII гасыр белән билгеләнгән әлеге кыргыз ташлары, палеографик үзенчәлекләре ягыннан да, әлгәре Енисей истәлекләреннән әлгәррәк булып саналмыйлар.

Хәзер татарлар турында кытай чыганакларына мөрәҗәгать итик. Татарлар уйгур каганаты составында (744-840) вассал кабилә союзын тәшкил иткәннәр; XII гасырда яшәгән кытай авторы—Ван Минцзи аларны «татарлар уйгурлар кул астында сыер көтүе көттеләр» дип билгеләп үтә *(Кычанов Е. И. Очерк истории тангутского государства. М., 1968).* Кыргызлар исә, 756 елда уйгурлар тарафыннан Саян аръягына алып ташланганнан соң, 840 ел тирәләрендә Танну-Оладан көньяктарак пәйда булалар. Шул рәвешле кыргыз-татар бәрелешләренең соңгы чиген билгеләргә мөмкинлек туа. 842 ел вакыйгалары уңае белән татарлар кытай истәлекләрендә—Кытай дәүләт эшлеклесе

Ли Дэюй хатларында—беренче тапкыр кыргызларның дошманы һәм соңгы уйгур каганының дусты буларак телгә алына *(Пеллио, 1929)*.

Уйгурлар исә, Төньяк Монголиядә кыргызлар тарафыннан тар-мар ителгәннән соң, Ганьсу һәм Көньяк Төркестан юнәлешендә чигенәләр. Дөресрәге, нәкъ менә кыргызлар аларны шушы юнәлештә чигенергә мәҗбүр итәләр. 842 елда чик буендагы Тяньдэ кирмәне янында кыргыз илчелеге белән сөйләшүләр алып барган Ли-Дэюй болай хәбәр итә: илчелекнең башлыгы—Табу-хэцзу «генерал» сүзләренә караганда, кыргызлар Хэлочуань елгасы буендагы «иске уйгур җирләренә», ягъни Эцзин-гола елгасының югары агымына килеп чыгалар һәм аларга Аньси (Куча), Бэйтин (Бишбалык) һәм дадалар (татарлар) да буйсыналар. Бу Ганьсу яки Көньяк Төркестан тирәсендәге кыргызлар белән татарлар арасында булган хәрби бәрелеш турында бердәнбер истәлек һәм ул татарларның, хәзерге тел белән әйткәндә, кыргызларның суверенитетын тану—ясак түләү белән тәгаллләнә *(Цай Вэньшэнь, 1967)*. Икенче елда (843) Табу-хэцзу император сараена тәгаенләнгән кыргыз илчелеген җитәкли.

1915 елда Б. Я. Владимирцов Төньяк-Көнбатыш Монголиядәге Тес елгасы үзәнлегендә таш кыяга уеп язылган руник язуларга юлыга (1975 елда аны өйрәнү һәм кабаттан уку безнең бәхеткә дә туры килде). Язмада Төрек Alp Sol исемле кешенең исеме телгә алына—1989 елда кабат өйрәнгәннән соң мин аны шулай укыдым *(Кляшторный С. Г. Наскальные рунические надписи Монголии.—Тюркологический сборник 1975 г.—М., 1978)*. С. Е. Яхонтов сүзләренә караганда, кыргыз хәрби җитәкчесе Табу-хэцзуның кытайча әйтелеше, ул берни дә түгел, төрки Törük Alp Solның беркадәр дөрес булмаган транскрипциясе генә. Язманың эчтәлегеннән чыгып (ул IX гасырга караган булырга тиеш), бу тирәләрдә, уйгурларны куганнан соң һәм алар Төньяк Монголиягә килеп урнашкач, кыргыз аксөякләренең, илчеләренең яңа йорт-биләмәләре булган дип әйтә алабыз. Шулай итеп, кытый дипломаты истәлекләре белән кыргыз таш язуларындагы мәгълүматлар сүзгә-сүз диярлек тәңгәл киләләр. Сүз арасында шунысын да әйтеп үтик: кыргызлар Тарим бассейнындагы «уйгур юлын»—Бөек ефәк юлындагы мөһим тармакны кулларында озак тотып тора алмыйлар—875 елга кадәрле үк ганьчжоу уйгурлары биредә үзләренең хакимлекләрен урнаштыралар *(Малявкин А.Г. Уйгурские государтва в IX—XIII вв.—Новосибирск, 1983)*.

Татарларның көнбатыштагы биләмәләре, Көнчыгыш Монголиядәге төп яшәү җирләреннән еракта урнашуга да карамастан, Уйгур каганаты җимерелүгә кадәр үк барлыкка килә. Ничек кенә булмасын, 825-832 елларда Турфанда күчереп язылган пехлевий-анихей «Махр-намаг» әсәрендә җирле аксөякләр белән беррәттән tatar apa tekin дигән татар аксөяге исеме дә аталып үтелә *(Мюллер, 1913)*.

Моннан күпкә соңрак, уйгурларда Кытай илчесе булып торган Ван Яньдэ Турфанда башка кытай чиновниклары булуын да хәбәр итә—димәк, уйгурларга караганда татарларга илчелек алданрак җибәрелгән дип әйтә алабыз *(Малявкин А. Г. Материалы по истории уйгуров в IX—XII вв.—Новосибирск, 1974)*. Дипломатик мөнәсәбәтләр еш булмый, ләкин ул ике яклап та хәрәкәт итә. Шулай да 958 һәм 1084 елларда, тангутларга каршы хәрби берлек төзү максатыннан чыгып, ганьчжоу уйгурлары һәм ганьсуй татарлары тарафыннан төрле кытай сарайларына илчелек җибәрелгәнлеге мәгълүм *(Малявкин, 1974; Малявкин, 1983)*. Дуньхуадагы мәгарә китапханәсендәге кытай манускриптларында (алар 965 һәм 981 елларга карыйлар) моңарга өстәмә мәгълүматлар саклана. Анда татар дәүләтенең үзәге Сучжоуда, ягъни Ганьсу белән Көнчыгыш Төркестан чикләрендә урнашкан дип турыдан-туры күрсәтелә. Шушы ук татарлар турында IX—X гасыр хотано-сак чыганакларында да хәбәр ителә *(Бейли, 1939; Бейли, 1949.)*. «Худуд ал-алам» дип исемләнгән X гасыр аноним фарсы географиясендә татарлар тугыз-угызларның, ягъни уйгурларның күршеләре дип, Көнчыгыш Төркестан «тугыз-угызларның һәм татарларның торган җире» дип күрсәтелә. Дуньхуанда саклана торган төрки һәм согди телләрендәге IX-X гасыр язмаларында» татарлардан килгән түрәнең—амганың телгә алынуы да әһәмияткә ия—бу хакта 1987 елда Лондонда үткәрелгән Үзәк Азия халыкара конференциядә Дис Гамильтон һәм Симс-Вальямс тарафыннан ясалган докладта хәбәр ителде.

Ганьсудагы, ягъни Көнчыгыш Төркестандагы татар дәүләте турында күрсәтелгән чыганаклар белән бергә эпистоляр чыганаклар да яшәп килә (XI гасыр). Тангут хакиме Юань-хаоның 1039 елда Суннар сараена җибәргән хатында, гәрчә алар хакыйкатьтән ерак торсалар да, Тангут дәүләтенең яңа чикләре турында хәбәрләр

саклана. Анда Юань-хао мактанчык рәвештә туфанның (тибетләрнең), таталарның (татарларның), чжаньның (ганьчжоу уйгурларының) һәм цзяохэларның (турфан уйгурларының), ягъни Ганьсуда һәм Көнчыгыш Төркестанда урнашкан барлык Си Ся биләмәләренең үзенә ирекле рәвештә буйсынулары хакында хәбәр итә *(Качанов В. И. Очерк истории тунгутского государства.—М., 1968).*

Кыскасы, монгол яулап алуларына чаклы, һәрхәлдә X-XII гасырларда ук, «татар» этнонимы Урта империядә генә түгел, хәтта Урта Азиядә һәм Иранда да яхшы таныш була. Әйтик, танылган фарсы шагыйрьләренең шигырьләрендә, караханид төркиләре белән бергә, татар исеме дә еш телгә алына. XI гасыр Газнави шагыйре Әбу-н-Нәҗми Манучихри «төрек-татар кыяфәтле» чибәр егет турында тасвирлый; аның башка замандашлары өчен «мең татар мускусының хуш исләре» метафорасын куллануы гадәти булып саналган; ә имам Садретдин Харрамабади (XI-XII) Искәндәр солтанга багышланган касыйдәсендә ниндидер бер «татар улы» турында искә ала *(Ворожейкина З. Н. Диван Манучихра.—Письменные памятники Востока.—Ежегодник, 1968.—М., 1971).*

Шулай итеп, IX-XII гасырларда Ганьсуда һәм Көнчыгыш Төркестанда кытай дипломатларына һәм мөселман сәүдәгәрләренә яхшы таныш булган татар дәүләте яшәп килгән. Шулай да көньяк сун галиме һәм түрәсе Ли Синьчуань тарафыннан (1166—1243) бу дәүләт турындагы мәгълүмат аңлашылмаучанлык буларак кабул ителә һәм аңа болай дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: «Көнчыгышта да, көнбатышта да ике дәүләт яшәп килде, ике дәүләт тә бер-берсеннән берничә мең ли ераклыкта урнашкан иде. Нинди сәбәптән чыгып һәм ни өчен алар бер исем белән аталып киләләр, без белмибез» *(Кычанов Е. И. Монголы в VI—первой половине VII в.—Дальний Восток и соседние территории в средние века.—Новосибирск, 1980).*[1]

Шулай да Рәшидэтдин тарафыннан телгә алынган башка татар дәүләтләренең урнашкан урыннарын дөрес, тәгаен генә билгеләү хәзергә мөмкин эш түгел[2]. Ләкин аның бу мәгълүматка ия булуы, В. В. Бартольд шикләнүләренә карамастан *(Бартольд В. В. Татары.—Сочинения.—Т. V.—М., 1968),* бәхәссез. Мәхмүт Кашгари (XI) Төньяк Кытай белән Көнбатыш Төркестан арасындагы җирләрне юкка гына «татар далалары»—Дәште Кыпчак дип атамый (башка мөселман авторлары тарафыннан да көньяк урыс һәм казакъ далалары шулай аталып йөртеләләр). «Татар даласы» атамасы татарларның IX—X гасырларда яшәү урыннары хакындагы башка мәгълүматлар белән дә тәңгәл килә, күп еллардан соң шул тирәләргә килеп чыккан монголлар төрки һәм мөселман дөньясында, шул исәптән Кытайда да, татарлар дип атала. Менә шуңа күрә Урта Азиядә дә, якын Көнчыгышта да, Русиядә дә, Көнбатыш Европада да Монголларны төркиләр дип атау гадәткә кереп киткән, гәрчә монголлар үзләрен беркайчан да «татарлаштырмасалар да»[3].

---

[1]Ли Синьчуаньнан китерелгән өзеккә беренче тапкыр бөек кытай галиме Ван Говэй (1877 - 1927) игътибар итә. Ли Синьчуанның «Цзян-янь и-лай чао-цзи» дигән хезмәтенә («Цзян-янь чорына караган рәсми һәм рәсми булмаган язмалар»га) искәрмәләре Н. Ц. Мункуев тарафыннан тәрҗемә ителә (1975).

[2]X—XII гасырларда татарлар яшәгән башка урыннарны билгеләүгә Ли Синьчуаньның «татарларның чикләрен» көнчыгышта Линьхуаннан алып (хәзерге Сира-Муренга) кадәр, Көнчыгышта Си Ся чикләренә кадәр һәм көньякта Цэинчжоудан алып (Суйюандагы Гуйхуанчэн шәһәре тирәләре), киданнарга кадәр (Мэн-да бэй-лу.—Пер. с китайского, введ., комментарии и прил. Н. Ц. Мункуева—М., 1975) дип күрсәтүе, мөгаен, моңа ачкыч була алыр иде. Әгәр мәгълүматлар хак булса, Рәшидэтдин тарафыннан билгеләп үтелгән «алты татар йорты» Монголиянең һәм Төньяк Кытайның дала һәм таулы-дала зоналарында киң биләмәләрне биләгән.

[3]Кытайның сәяси һәм историографик традицияләре нигезендә, сүннәр чорыннан башлап, монголларны татарлар дип атау тулаем гадәткә керә. Хәтта сүннәрнең хәрби һәм дипломатик даирәләре өчен империянең күршеләрен ничек дип атау хаҗәте булмаган очракта да, текстлар кирәгенчә җайлаштырып редакцияләнгәннәр һәм монгол этнонимы яки «да-да» («татарлар»), яки «мен-да» («монгол-татарлар») дип кабул ителгән. Бу нәүбәттән Ли Синьчуань тарафыннан китерелгән факт аеруча игътибарга лаеклы: «Монголлар («мэн-жэньнар») Цзинь дәүләтенә бәреп кергәннән соң, [алар] үзләрен Бөек Монгол дәүләте дип («да мэн-гу го») дип атап йөртә башладылар. Күршеләре дә аларны Монголия («мэн-чу») дип атауга күчәләр».

# ЗАМАН КЕШЕСЕ

*Мосафир кем җиһанга басты ботны,*
*Аҗгырып биетте аны замана...*
Дәрдмәнд.

Нәшриятта редактор булып эшләгән елларымда, көннәрдән бер көнне өстәлемә «Яшьлек яме» дигән кульязма китереп куйдылар. Гариф Ахуновның беренче зур әсәре икән ул. Бераздан Гариф үзе дә күренде. Дулкынланып торган кара чәч, текә маңгай, көләч йөз, чыгынкы күзләр, таза гәүдә, нурланып торган ачык чырай. Пулеметтан аткандай тиз-тиз сөйләшә. Ул бу повестеның «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында басылып чыгуын, әмма үзе белән укыган бер яшь язучының әсәргә карата дәгъвалар белдереп йөрүен сөйләп алды, өлкән язучылар тегене бик тиз артына утырттылар, ди.

Китап басылып чыкты. Ләкин Гариф Ахунов үзе никтер күренмәде. Соңрак кына мин аның гаиләсе белән Әлмәткә—нефть чыккан якларга күчеп киткәнен ишеттем. Татарстан Язучылар оешмасы аны шундагы язучылар белән эшләргә җибәргән икән.

Әлмәт төбәгендә бик зур нефть ятмалары табылуы хакында газетлар көн-төн язып торалар. Җәй көне мин дә Әлмәткә якын гына булган туган авылыма кайттым. Ис китәрлек хәлләргә тап булдым. Урам тулы зур йөк машиналары, иләмсез мөгезборыннар шикелле, үкерә. Авылның дүрт ягына да озын-озын нефть вышкалары утырталар икән. Нефть көнкүрешкә дә керә башлаган. Аш пешерү өчен казан астына ягу беткән. Ике керосинка янып тора. Бензинга тоз кушып та керәчингә экономия ясыйлар икән.

Төнлә ишек алды яп-якты. Буровой утлары яктырта. Безнең бакча артындагы үр өстенә өч манара тезеп, җирне тишә башлаганнар. Иртән мин тизрәк шунда ашыктым. Йа, Ходаа, нинди могҗиза бу! Бер скважинадан нефть бәреп тә чыккан. Нефтькә ияреп менгән газы йөз метр арырак зур ут-ялкын чүмәләсе булып янып тора. Күрергә килгән хатын-кыз, карчык-корчык, иреннәрен кыймыл-кыймыл китереп, белгән догаларын укый. «Әстәгъфирулла, тәмуг утымы әллә бу?»—диләр. Мин тимер баскычлы озын манара астындагы буровойга таң калып карап торганда, кемдер исемемне әйтеп дәште. Борылып карасам, буровой ишек төбендә Газизов Галим басып тора. Яшьтәш. Без аны «карачутыр» дип йөртә идек. Ул ком гарәбе төсле кара-кучкыл чырайлы, гаҗәп ипле, җайлы егет. «Помбур булып эшлим»,—диде. Рөхсәт ителмәсә дә, ул мине буровойга алып керде. Әле измә килеп җитмәү сәбәпле, бораулау туктаган чак икән. Галим мина биредәге төрле инструмент, приборлар турында сөйли.

Икенче көнне килгәндә буровой ишеге төбендә саргылт курткалы бер кеше чалкан егылып ята иде. Нәрсә бу? Аның башы-чырае тирәсендә берәү нәрсәдер эшли. Борынына нашатыр спирты иснәтә, учы белән колакларын уа. Шунда «Ашыгыч ярдәм» машинасы килде. Анын җуйган бурильщикны носилкага салып алып та киттеләр. Сөйләделәр, бораулау вакытында скважинадан газ чыгып, аны агулаган икән. Измә куучы насосларның нинди басым белән эшләвен дә шул вакытта күрергә туры килде. Кыскасы, тау токымнарын бораулау бик катлаулы, хәвефле эш икән.

Күпмедер вакыттан соң, мина Гариф Ахуновның «Хәзинә» дигән романын редакцияләргә куштылар. Ул әсәр нефтьчеләр тормышы турында булып чыкты. Минем нефть эшләре буенча бераз «ликбез» үтүем ярап куйды тагын. Гадәттә, кульязманы эчке рецензия-бәяләмә белән бирәләр. Әмма рецензия юк иде. Моның хикмәте бераз соңрак беленде.

Әсәр кул тимәгән өр-яңа тормыш чынбарлыгы турында икән. Бездә сәнәгать темасы бөтенләй юк диярлек. Аның үзенә хас тәгъбирләре, сәнәгатькә кагылышлы татарча исем-терминнары да ташка үлчим генә. Шуңа күрә автор барча сүрәтләү тәгъбирләрен, үзенчәлекле бирә торган сүзләрнең татарча әйтелешләрен тулысынча үзе иҗат итә. Әсәр тукымасында бу яңалыкларга образ-характерларның бик үк гадәти булмаган төсмерләрдә янача, тотылмаган итеп тасвирлаулар өстәлә.

Әсәрнең үзәгендә бурильщик Кәрим Тимбиков. Киң җилкәле, таза, гөрес-мәрес гәүдәле, төксе чырайлы, кырыс холыклы туры кеше. Җайлашуны белми. Эштә үзенә дә, иптәшләренә дә бик таләпчән. Бу вакытларда тау токымнарын бораулау эшендә рекордлар кую модага кереп бара иде. Башлыклар ашыктыра. Йөз миллион тонна нефть чыгару өчен бораулау бригадалары ярыша. Тимбиков иптәшләре белән карусыз эшләп җиңүләр яулый. Аның булдыклы, эшчән һәм омтылышлы холыклы булуын тиз чамалап алалар. Бурильщиклыктан мастер итеп күтәрәләр. Аның вак-төяк гөнаһларына да күз йомалар. Чөнки ул эшне тиешле темплар белән алып барырга сәләтле. Аны газетларга мактап язалар. Радиодан да хуплау сүзләре яңгырап тора. Башлыклар Тимбиковны герой булырга лаек дип саныйлар. Һәм бу бик нигезле, урынлы. Чөнки аның бригадасы токым бораулау буенча рекорд арты рекорд куя. Ана юл ачып торалар... Чыннан да Тимбиков эш процессыннан дәртләнеп көч-илһам ала. Бу халәт аны бар көчен беткәнче эшкә бирергә рухландыра. Юк, бу башны җуеп, дан-шөһрәт артыннан куу түгел. Ник дигәндә, Тимбиков ихластан һәр эшне булсынга эшли. Хәйләсез, арткы исәпсез. Эчкерсез хезмәт белән тормышны яхшыртырга, тәрәккый иттерергә омтылыш булуына ышанасың. Биредә эш ул—көч һәм тир түгү генә түгел, авыр эшне яратып эшләүдән кеше канәгатьлек таба. Зур осталык, виртуозлык эшне җиңеләйтә. Эш авырлык чыганагы гына түгел, ә шатлык, күтәренкелек чыганагы да. Шулай хезмәт поэзиясе төсмерләнә. Гадәттә эстетиканы сүз нәфислеге, табигать күренешләренең матур сүрәтләнүендә күрәләр. Әмма бу әсәрдә автор хезмәт процессы эстетикасын тудыруга ирешә.

Буровойда таза, көчле кешеләр эшли. Алар арасында ихлас, чын кешеләрчә иптәшлек яши. Авыр эштә кешелеклелек бик мөһим. Бер-берсенә салынмыйлар, берсе хисабына икенчесе җиңелрәк яшәү турында уйларына да килми. Шәхси мәнфәгатьләрен берсе дә алга чыгармый. Мастер Тимбиков аларны авыр хезмәт кимәлендә сынаган, тәрбияләгән. Бер-берсенә ипләнеп эшлиләр. Шул сәбәпле, эш көйле тәгәри. Әмма табигать сюрпризлар ясарга һәвәс. Турбобур каты токымны җай гына тишеп барганда, кинәт токым ишелә һәм инструментны кыса, сыта. Күпме генә тартсалар да җибәрми. Моны нефтьчеләр телендә «прихват» диләр. Кыскасы, авария. Бу аварияне төзәтү бик мәшәкатьле, айга сузылуы мөмкин. Өмет иткән



*Алгы рәттә (сулдан уңга): Ш. Маннур, М. Әмир, Г. Ахунов, Л. Ихсанова, Ә. Еники. Икенче рәттә: Р. Нәфиков, А. Расих, Ш. Галиев, Р. Мостафин, Г. Халит. 1970 еллар.*

рекордларын—тү-тү! Нишләргә? Бер әмәл кулланып карыйлар, юк, токым инструментны ычкындырмый. Икенче ысулны худка куеп сыныйлар, әмма нәтиҗә юк. Өченче, дүртенче әмәлләр дә берни бирми. Тимбиков тәвәккәллеккә барырга карар кыла. Батыр йөрәкле булуы, җаваплылык хисе аны шуна этәрә. Барча иптәшләрен буровойдан чыгара. Идарә пульт-тормоз рычагы артында үзе генә кала. Дизель-моторларны соңгы чиккә хәтле эшләтеп, бер ыргым ясап инструментны тартып алырга итә. Юк. Аннары барча мотор көчләрен бергә кушып, тарттыра... Вышка, станоклар дыр-дыр килеп тора. Тимбиков үзе турында уйламый, бары эш, рекорд турында борчыла. Бу югары әхлаклылык билгесе түгелмени? Үзеннән-үзе хәтергә килә: дошман доты ут бөркеп һөҗүмне туктата. Шунда бер тәвәккәл йөрәклесе, алга ыргылып, ут ноктасын күкрәге белән каплый. Һөҗүм дәвам итә. Тимбиков батырлыгы да шуңа тиң бит! Тимбиков тагын бер омтылыш ясый. Артык көч килүдән корыч та чыдамый. Бер инструмент детале өзелеп, тормоз рычагы артына баскан Тимбиковның башына килеп төшә һәм...

Әмма Тимбиковны корбан дип әйтергә тел әйләнми. Юк, ул авария корбаны түгел. Чөнки бу адымга намус кушуы буенча, иптәшләренә җиңеллек китерү өчен аек аң белән бара. Ил-халык алдында изге бурычын үтәр өчен бара. Иҗтимагый мәнфәгатьне үзенең һәлак булу ихтималыннан өстен куя. Бу—физик батырлык белән бергә бөек әхлакый фидакарьлек, кешелеклелек! Бу—заман образы, шул билгеле заманның үзенчәлекләрен үзендә туплаган, заманны аңлатучы образ иде.

Андый хәлләр аз булмады. Катлаулы хезмәт, яңа техника. Ә җир асты каты токымнары, җир асты дөньясы көтелмәгән хәлләр тудырып кына тора. Шушы куркыныч эштә кешеләрнең үзләрен ничек тотуларын, нинди булып ачылуларын тасвирлаганда язучының эчке рухы, күренеп тормый торган дөньясы да чагыла. Чөнки кеше икенче кеше турында фәкать үзеннән чыгып кына фикер йөртә. Үзеннән чыгып кына икенче кешегә бәя куя. Гариф үзе кыю, батыр, тәвәккәл кеше булганга күрә генә Тимбиковның халәтен аңлаган һәм җете итеп тасвирлаган. Ә үзе куян йөрәкле, сакчыл, ватанпәрвәр булмаган кеше Тимбиковның тәвәккәллеген бары ахмак тәвәккәллек, кирәксез эш дип карар иде. Һәм, язучы буларак, бу һәлакәтле хәлне тасвирларга алынмас иде. Алынган очракта да бары факт буларак теркәп кенә үтәр иде. Үзе батыр, кыю булмаган язучы батырлыкның, тәвәккәллекнең эчке рухын аңлый алмый. Андый нәрсә аңа бирелмәгән. Ни хәл итәсең... Һәр авария әлбәттә эшчеләргә сабак була. Алда ялгышлар ясамаска кисәтә. Әмма тәвәккәл таш яра, дигәндәй эштә кыю, зиһенле булу лазем. Һәр эштә кыюлык, тәвәккәллек булмаса, ачышлар булмас иде, прогресс туктар иде. Патриотлык ул тыныч тормышта да бик кирәк сыйфат. Гариф, язучы буларак, шуны дәгъва итә. Аның эчке рухы кыю, һәрчак прогресска омтылучан. Шушы теләк-идеясен ул ышандырырлык, җанлы образлар аша тасвирлап бирә.

Гариф Ахунов беркемнең кулы тимәгән яңа сәнәгатьнең нигезләрен иҗат итә. Күпме өр-яңа тәгъбирләр, сүзләрне әдәби әйләнешкә кертә. Яңа эшче образлары тудыра. Үзләренең эчке рухлары, кайгы-шатлыклары белән... Авторның ихлас тәвәккәллеге, бөтен җанын биреп эшләү нәтиҗәсе бу! Моны ничек җиңү, димисеңме? Мин, «Хәзинә» романы турындагы бәямне: «Гариф, син җиңүче!»—дип язып җибәргәнмен. Гариф моңа бик сөенгән, чөнки романга эчке рецензия язган бер өлкән язучыбыз әсәрне тар-мар иткән булган. Бу хакта Гариф «Йолдызлар калка» дигән әсәрендә дә телгә алып үтә.

«Хәзинә» Гарифның бик бәхетле әсәре булды. Эчтәлеге, язылышы белән заман рухына туры килде. Кимчелекләрне куертмавы, образлар психологиясен заман таләп иткән шәкел буенча сурәтләве, барча дикъкатьне хезмәт ярышына юнәлтүе заманга аваздаш иде. Хәер, әтисенең кулаклар тарафыннан үтерелүе аны бала чагыннан ук үзенә хас холык-табигатьле итеп формалаштыргандыр. Бу—язмыш гамәле. Моны беркем дә җайлашу, карьера өчен кызылрак холыклы булгандыр, дип гаепли алмый. Билгеле инде, әсәр язу—намус эше. Ләкин заманга ярақлашу-иплэшү өчен Гарифка шәхси намусын богауларга туры килмәгәндер. Чөнки аның эчке рухы, шат-күтәренке характеры заманга бик туры килә иде. Бу җәһәттән, аның холык-фигылендә берниндн каршылык юк. Гарифның һәр эштә һәркем белән ярышучан һәм узучан табигате һәм иҗтимагый шартлар аны әдәбиятта каршылыксыз сукмактан китәргә этәргәндер. Ул юл әдәби унышка һәм дәрәҗәгә китерә. Гарифның якты акылы моны дөрес чамалаган булырга тиеш.

Шушы юлдан читкә тайпылмаганнар гына иҗтимагый дәрәҗә-бәхеткә ирешә. Гариф башта ук заман кешесе иде. «Хәзинә» романы белән ул заман кешесе

булуын тагын бер кат раслады. Ул иҗтимагый дәрәҗәләрне дә җитәрлек татыды. СССР Югары советына депутат булды. Бер мөддәте тулгач икенче мөддәткә сайланды. Әлбәттә, мондый дан-дәрәҗә ана үзен һич аямый көн-төн язучылык эше һәм иҗтимагый эшләрдә кайнаганга бирелде. Гариф дан-дәрәҗәдән төшмәде, бәхетле мул тормыш белән яшәде. Бик популяр булды. Ничә еллар буе президиумнарда утырды, чәче дә шунда агарды.

Нинди югары дан-дәрәҗәгә ирешсә дә, Гариф иптәшләренә, каләмдәшләренә, таныш булмаган гади кешеләргә булышудан туктамады. Киресенчә, депутатлыгын да шул эшкә җикте. Судларга барды, инстанцияләр ишеген какты. Аның бүтәннәргә ярдәм кулы сузарга әзер торган юмарт холкы үзгәрмәде. Кимсетелгәннәргә булышудан җан азыгы таба, эчке канәгатьлек кичерә, үзен чын кеше итеп тоя иде. Берәрсен бәладән йола алса, шуңа балаларча сөенә, чыраенда бәхет нурлары балкый иде.

Ул үз каләмдәшләрен, язучыларны авыр хәлләрдә коткара иде. Чөнки язучы, күпме генә сәләтле булмасын, ул яклауга мохтаҗ була. Хикмәт идеологик четереклектә генә түгел. Күп каршылыклар шунардан килсә дә, хикмәт шунда, иҗат әсәре—ул иң яклаучысыз әйбер. Аны теләсә кем бетереп ташлый ала. Моңа белем дә, хәбәрдарлек тә кирәк түгел. Ә физика, химиядә андый иркенлек юк. Анда катгый формула, кагыйдәләр. Нәфис сүз продуктын ышыклаучы, аралаучы кагыйдә-тәртип эшләнмәгән. Теләсә ничек анла, теләсә ничек фикер йөрт. Хәреф таный торган, бүтән бернинди белеме булмаган кеше әсәрне укый да пыр туздыра. Аның сүзенә колак салучылар табыла. Мондый ситуация өстән әдәбиятка басым арткан, фикерле сүзне кыскан вакытларда килеп туа... Җитмешенче елларда сталинизмны тергезү көчәйде, кайбер яшь, кыю язучыларны, дөреслекне әйтергә маташучыларны, диссидент дип атап, аларга халык нәфрәтен төбәлдерүләр китте. Бездә дә шул шаукымга бирелеп, кульязмаларны тоткарлый башладылар. Аерым язучыларны идарә утырышында тикшерү, талку ешайды. Әдәбият күгендә болытлар куеруын шуннан чамалыйсың, яшь язучы әсәрләре өчен Гариф күп көрәште.

Язучылар арасында төрле кеше бар. Әнә, берсе күзлек артына посып, зәһәр елмаеп, кемнәр беләндер чышын-пышын килгән була. Әләк язарга да шул этәргеч сүз әйткәндер. Көнчелеге йөзенә чыккан. Аның да президиумда түрдә утырасы килә. Берәүләр өчен ул ярыйсы кеше, икенчеләр өчен—хыянәтчел зат. Әмма яраклаша, җор сүзләр әйтеп көлдерә. Рәхәтләнеп яши. Астыртын эшләрен күпләр белә, әмма фаш итә алмыйлар. Чөнки төп йорт белән тыгыз элемтәдә ул...

Менә чираттагы корбан. Бер язучыны, әсәренә сюжетны фәләннән алгансың, дип талкыйлар. Иптәшен батырырга дигәндә, татар инде ударник. Моның сере нәрсәдә соң? Бер сере шунда, татарга өстән басым бик көчле. Аны кысалар, үткәне белән котын алалар һәм каләмдәшенә ташланырга мәҗбүр итәләр. Биредә зур язучылар да төймәдән дөя ясыйлар, тегене әллә нинди гөнаһларда гаеплиләр. Язучыны кичәге дуслары да якламый, куркып, авызларына су капкандай утыралар. «Язучылар союзыннан чыгарырга» дигән сүзләр яңгырагач, монарчы чыдап торган Гариф күтәрелә: «Мин судта утыраммы, әллә язучыларның иҗади утырышындамы?»—дип башлый ул сүзен каты итеп. Хөкемчеләрнең сабын куыгы кебек «дәлилләрен» берсе арты берсен юкка чыгарып ташлый. Охшаш сюжетлар була ул. Ләкин шул сюжетны язучы ничек үзенчә җанлы образлар белән баета, тәэсир итәрлек художество әсәре тудыра. Бөтен хикмәт шунда. Сюжетларның кабатлану теориясе бар. Сюжетта охшашлык гаеп санала алмый. «Анна Каренина» романының сюжет сызыгы «Красное и черное» романында шәйләнә. Икесе ике төрле, бер-берсеннән нык аерылып торган классик әсәрләр...

Гариф тагы бик күп мисаллар китерә. Язучының бер гаебе булмавын исбат итә. Өстәгеләргә ялагайланып, кайберәүләрнең вакчыллануын, Гариф йөзләренә бәреп әйтә. Тегеләр шым була. Язучы өстенә өелгән нахак гаеп алып ташлана.

Каләм ияләре нәзберек халык. Индивидуалистлар. Бик тиз хәтерләре калучан, сүз күтәрә алмаучан. Лениногорск шәһәрендә яшәп иҗат итүче яшь язучы үз әсәренә бер өлкән язучының начар бәяләмәсен алгач, бик нык ачуы килә, күтәрелеп бәрелә. Тегене сүгеп, хурлап язып җибәрә. Моны идарәдә тикшерәләр. Өлкән язучы үзен мәсхәрәләгән яшь әтәчкә җәза бирүне таләп итә. Бу инде яшь язучыга киләчәктә юллар бикләнә дигән сүз. Әмма һәрчак ярдәмгә ташлана торган, кыю Гариф бар. Ул тора да: «Мин ул яшь язучыны беләм, бик өметле ул, шахтада эшләгән, күпне күргән. Моны ул ачулы минутта белештерми язып ташлаган. Мин яшь язучы өчен рецензенттан түбәнчелек белән гафу үтенәм...»—ди-ди, ихлас күңелдән

сөйли. Гарифның эчкерсез сүзләрен кем аяк астына сала алсын? Өлкән язучы да йомшый, тегене гафу итә. Кем шулай, барча гаепне үз өстенә ала-ала, кешене бәладән йола алыр иде? Гариф Ахуновның хатыны Шәһидә ханым әйтер иде: «Андый дурак бер Гариф кына!»—дип. Чөнки безнең тигез булмаган тормышта яхшы кеше булу—кимчелек. Берәрсенә яхшылык эшләсәң, үзенә бәла булып төшә. Мондый хәлләрне Гариф күп кичерде. Ләкин аның һәркемгә игелекчән холкы һаман яхшылык эшләргә омтылып торды. Әйтерсең лә, аның эчендә якты кояш, ул шуның нурын бүтәннәргә өләшергә ашыга иде.

Мине дә язмыш тарафыннан кыерсытылган санады ул. Һаман кагып-сугып йөрткәннәрен күреп, мине үзенең химаясенә алды. Сугыш турында язган әсәрләремне чыгарырга булышты. Түрәләр алдында үзенең ныклы сүзе белән яклады. Идеологик киртәләрне үтү җайларын тапты. Язганнарыма шикләнеп карап, энә күзеннән үткәрәләр иде. Әйткәнемчә, әдәби әсәр—иң яклаучысыз җисем, җирдә үсеп утырган үлән кебек. Теләсә ничек тапта! Күпләр минем белән сөйләшергә, минем янга утырырга курыкканда, Гариф искиткеч кешелеклелек күрсәтте, минем әсәрләргә унай бәя бирде. Бу зур батырлыкка тиң чыгыш иде.

Без күп аралашмадык. Җәйләрен бакчада йортларыбыз янәшә генә, шунда бер-ике тапкыр утырыш уены уйнап ала идек. Гариф кайчак ихласланып: «Син киребеткән, җайлаша алмыйсың, шуна бәхетең юк»,—дип ачуланып та ташлый иде. Мин каршы бер сүз әйтә алмыйм. Чөнки дөрес әйтә, шайтан алгыры!

Без үзара мөнәсәбәтләрдә артык тирәнгә үтүдән сагая идек шикелле. Чөнки кешене төбенә чаклы белсәң, анардан суына башлыйсың. Сыналган нәрсә. Кәефләнеп утырганда кан кайнарлана, тел чишелә, баштагы фикерләр тышаудан ычкына, ничектер яшьлек дәрте кайткан күк була.

Гарифның шундый дәрәҗәләргә ирешүендә Шәһидә ханымның да тырышлыгы зур булырга тиеш. Гариф исә бик еш: «Шәһидәдә тимер логика, ул хәлләрнең астарын алдан күрә белә!»—дип сөйли иде. Шәһидәне гел мактый иде.

Бакчада ауган койманы рәтләгәндә, такта-токта кадаклап маташканда, Гариф шунда ук булышырга кереп җитә. Ул безгә генә түгел бөтен күрше тирәгә булыша иде. Аның кулы тимәгән йорт, каралты калмагандыр. Дөнья булгач, арада кайвакыт төрле каршылыклар да килеп чыга иде. Ләкин без аны озакка сузмыйбыз, берни дә юк кебек, тагын табындаш уенына керешәбез. Тагын тирәнгә кермәскә тырышып сөйләшәбез. Сүз четерекле чытырманнарга юнәлмәсен өчен Гарифның сыналган әмәле бар. Ул җыр суза. «Көмеш тояк тулпар атым»ны һәрчак яратып җырлый. Аңа ярдәмгә Шәһидә кушыла. Аннары «Хан кызы, ишегең ач!» китә. Яки шаяруга күчеп: «Минем әти төлкече, төлке аулап йөрүче...»не сызды ра. Ул да түгел рус халык җырларының кылын тарта: «Миленкий ты мой, возьми меня с собой, там в краю далеком назовешь меня женой... Милая моя, взял бы я тебя, в том краю далеком есть у меня жена...» Җырның азагы фаҗигалы, ләкин аһәңе белән өмет уята.

Соңгы вакытларда Гариф, авыру булуга карамастан, язды да язды. Әллә ничә документаль повесть бастырып чыгарды. Аның эшчәнлегенә гаҗәпләнмәгән кеше юк иде. Андый карусыз эшчән кешене: эштә янды, диләр.

Утыргычта утырганда, мамык төргәгедәй ап-ак чәчле башын ике учына алып, тын гына уйга кала. Тирән, авыр итеп сулап куя, уфтана... Шул минутларда үзенә якынлашып килгән Газраилнең аяк тавышы колагына ишетелде микән әллә? Бу пошаманлы кыяфәте белән ул дөнья кайгысын үзе белән алып китәргә торган ниндидер әүлияне хәтергә китерә иде.

Бер тымызык иртәдә дөньядан әүлия кебек тын гына китеп тә барды ул.

Аның вафатыннан соң ачык тойдым: күңелемдә ниндидер бушлык хасыйл булды. Нидер җитми, ниндидер үкенеч сава эчемне. Барып җитте: Гариф үзенең кешелеклеге, җан юмартлыгы, эчкерсезлеге белән күңелдә урын алган икән. Менә шул эчтә, үзәктә сулкылдап тора икән...

Алыштыргысыз кеше булмый, диләр. Юк, дөрес түгел! Мәрхүм Гарифны беркем дә алыштыра алмый инде. Гариф кебек, һәркемгә яшәү өмете өстәп торучы әүлия зат бүтән булмас, юк булмас! Андый затлар кабатланмыйлар.

*P.S.* Мин, билгеле, барысын да яза алмадым, язган кадәресендә ялган юк!

**Хисам КАМАЛОВ,**

*Татарстанның халык язучысы.*

## Nuri Arslanov

(1912—1991)

TƏRLE YILLARDAN

### Tərcemәi xәlem

Tərle xəllər kiçte baştan—sabır qıldım,
Başqalardan qalışmadım—safta buldım;
Qağılsam da, suğılsam da awır yulda,
Bireşmədem min, abınğan sayın tordım.

Küralmadı qayberəwlər kəlüemne,
Telədelər waqıt citmi sünüemne,
Ə qoyaşım minem haman nurın sipte,
Üç itmədem, çənki gel uyınğa bordım...

İl qarşında abruy eçen qərəştem min,
Başqalarday borçıldım, kənləştem, ləkin,
Qızıqsam da kürep minnən estennərne,
Tübənnərgə qarap kütərmədem bornım.

Tırışmadım citdi bulıp qılanırğa,
Yazmağannı sıqtanırğa-soranırğa,
Yəşəməwem eçen qaş-qabağım təyep—
Ğomerlekkə min saqallı sabıy buldım.

*1960*

### Şağirgə

Bulsa sində Əflətunnıņ aqılı,
Sadəlege kersez sabıynıņ,
Dərwişlege Xuca Nasretdinnıņ,
İsərlege Məşrəp safinıņ,
Telgə osta bulsaņ Çiçən kebek,
Uyğa—yegerek, dala atıday,
Ğədellektə Nəwşirwannan ğədel,
Yumartlıqta bulsaņ Xatom-Tay...
Anda da sin kamil tügel, şağir!
Citmi əle Xəyam kasəse,
Hərdəm tulı şatlıq şərabına!
Bar əle, bar kükrəp-yəşnəse,
Salawat küpere salıp künellərgə
Qoyasıņ bar xislər ləysənen,
Kirək siņa Məcnün məxəbbəte
Həm ilhamı güzəl Ləylənen!..

Sin qərwanbaş nar dəyəgə oxşaş—
Küpme yəklər siŋa artıla!
Tik istə tot: iŋ meqətdəs yəgeŋ—
Tuğrılıqlı bulu xalqıŋa.

*1969*

## Minem məktəbem

Şiğer mine, təpi basqan çağımda,
Citəklədə bəyek Səğdi bağına.

Totalmadı Rafael'lər də canım,—
Əsir buldı şiğergə ixtıyarım.

Awız ittem Ğəmər Xəyam camınnan,—
Sabaq aldım yaratılmış cayınnan.

Ğazəlləren uqıp miŋa Şirazi
Məxəbbət surın erde,—məŋge razıy.

Alişerlar, Babur, Məxtüm-Qolıylar
Güzəl qıllarda çaldı tərki moŋnar.

Yıraq Qolğəlilər, yaqın Tuqaylar...
Qaranğı təndə buldı tulğan aylar.

Ə ber yaqta: Blok, Puşkin, Beranje,
Yesenin, Geyne, Bayron, Gyəte, Dante...

Tatar xalqı elek ike arada
Küper bulğan. Xəzer yaŋa zamana.

Şulay da min yərim iske küperdən;
Barın şunda işetkən, şunda kürgən!

Totaştırğan şəreq belən ğərepne,
Dəres yulğa yünəltkən min ğəripne.

Şuşı küper miŋa xəzer də iple,—
Şuşı məktəp mine zur yulğa iltte!

*1972-1973*

## Uylata

Hawa, Oslan tawı, İdel... zəp-zəŋgər.
Küŋel sərxuş—mində ğəcəp şəp xəllər,

Təmam riza, rəxət tabam tirəmnən,—
Tabiğətem rizalıqqa əyrəngən...

Kinət serle ber ən kilə İdeldən:
—Əy Arslan, sin batırlar ilennən!

Bat tirəngə, təş sularım astına,
Tu yaŋadan—qaytı yaŋadan asliŋa.

İ xıyallar!—tua qaya qarama.
Sin üzeŋne küpme azat sanama,

Qol itə aŋ,—üz qulında uynata,
Fəlsəfəle tərle uylar uylata:

Bolıtlarda, küktə genə yərmə, di,
Təşkələ, şağir, qaytı çaqta cirgə!—di.

Ber ən kilə ənə zəŋgər İdeldən:
—Əy, xıyalıy, sin batırlar ilennən!

Bat tirəngə, təş tə dulqın astına,
Cir ulı bul, qaytı yaŋadan asliŋa!

*1974*

## *Юмор-сатира*

# Илфак Шиһапов

### Бүләк

Гамир шәһәр урамы буйлап җил-җил атлап барган хәлдә, кесәсен капшап куйды. Анда күнелгә жылы кертә торган кыштырдауны тойгач, ул үз-алдына елмаеп куйды—хатыны Гөлназ белми торган милек үз урынында иде. «Тә-әк, нәрсә алырмын икән соң?—дип куйды ул шәһәр үзәгендәге базарга якынлашкач.—Илле тәңкәгә генә артык кыланып булмас шул».

Дөресен әйткәндә, хатыны белән инде унбиш ел торса да, Гамирнын беренче тапкыр гына бүләк алуы иде әле. Гөлназ белән начар яшәмәсәләр дә, йорт кирәк-ярагы, азык-төлек, гомумән, яшәеш кайгырткан Гамирның бүләк-мазар алу турында мона кадәр уйлаганы да булмады. Ә менә бүген бүләк кирәк. Нәрсә генә алырга соң? Инде ике атналап бер тамчы да аракы эчкәне булмагангамы, яисә бүтән берәр сәбәп аркасындамы, Гамирның уйлары төрлесе-төрле якка йөгерешә иде.

Базарны, якынча унсигез тапкыр әйләнгәч, ир, ниһаять, кесәсендәге иллелеккә алырдай бүләк тапты. Чәнтеки бармак башы хәтле генә ислемай белән ялтыравык кәгазьгә төрелгән өч чәчәк—төп-түгәл илле сумлык булды. «Шатландырыйм әле бүген Гөлназны»,—дип уйлады ул, өйләренә таба атлый-атлый. «Нәрсә, мин бүләк алмаслык кешеме әллә?»

Ләкин үз уйларына үзе елмаеп атлаган Гамирның кинәт башына: «Ә бүләк алуыма Гөлназ ни әйтер?»—дигән уй килде. «Хатын-кыз шундый зат бит ул, иркәләгән саен иркәләнә. Аннары нигә әлек бер нәрсә дә бүләк итми идең. Ни булды сиңа?..»—дип сораша башласа? Яратам бит сине,—дияр идең, ә әлек яратмый идеңмени, дисә». Гамирның болай да таркау уйлары бөтенләй чуалды. Хәзер ул өенә таба җил-җил атлап түгел, ә аякларын кузгатыйммы-кузгатмыйммы дигәндәй, сөйрәлеп кенә кайта иде.

Уйга чумган ир кесәсендәге ислемай тартмасын капшап карады, кулындагы чәчәкләргә күз салды. «Шушы шухыр-мухырны алганчы, бер килограмм май алсам, күпме файда буласы иде бит»,—дип уйлады ул. «Акчасы чукынсын да әле аның, менә Гөлназ ни дияр? Бер йомшаклыгыңны сизеп алса, хатын-кыз җилкәңә менә дә менә инде ул. Аннан бәйрәм саен бүләк сорый башласа? Тора-бара савыт-саба юарга да калуың бар. Аннары өй җыештыру, кер юу китә».

Гамирның кәефе бөтенләй төште. Чыннан да, хатынга бүләк бирүдән кер юуга кадәр ара бик кыска булып тоелды аңа. Колагына каяндыр кер юу машинасының гөжелдәвек тавышы да килеп киткәндәй булды. «Машинадан алгач, керләрне юыну бүлмәсендә чайкыйсы була»,—дип уйлады ул. Аннары суын сыгып, балкондагы кер бавына эләсең». Гамир күз алдына үзенең ничек итеп кер бавына Гөлназның эчке киемнәрен элүен китерде. Ә бу вакыт күрше Хәмит балконында тәмәке пыскытып тора... Икенче көнне эшкә барып, көлә-көлә егетләргә сөйли... Аннары... аннары...

Гамир нәфрәт белән кулындагы чәчәкләргә карады. Үз өйләренә кайтып җиткән иде инде ул. Ир, әз генә уйланып торды да, чәчәк бәйләмен нинди-дер эчке бер ләззәт белән чүп савытына ташлады. «Үзең юарсың керләреңне бәгырькәем»,—дип уйлады ул, Гөлназын күз алдына китереп. «Керләреңне дә, идәнне дә, савыт-сабаны да». Шул ук ысул белән кесәдәге ислемайдан да котылгач, Гамир башыннан олы кайгы төшкән кеше кебек, җил-җил атлап подъездларына кереп китте.

## Редакциягә хат

«Исәнмесез, хөрмәтле редакция. Элек мин сезнең гәҗитне бик яратып укый идем. Дөресен генә әйткәндә, махмырдан интеккәндә, хәрефләр жемелдәмәсен өчен бер күзне кысып, гәҗитегезне, өчәр кат укып чыккан чаклар була иде. Төзелештә эшли идем мин ул чакта. Акчаны күрәп ала идем, өч-дүрт яртылыктан башкасын, тиенена кадәр хатынга кайтарып тоттыра идем. Хатын да мине ярата иде кебек. Соң, салгалаганга сукмәсен, дип, кер юарга да әзер булган ирне нинди хатын яратмасын ди инде. Ә баш авыртканда бер яртылык сорап хатынга әйткән матур сүзләр? Андыйларны татар теле буенча диссертация яклаган галимнәр дә әйтә алмас иде. Хатын өйдә патша иде ул вакытта. Теләгәнчә киенә иде, мине теләгәнчә сүгә иде, теләгәнчә иркәләнә иде.

Дүрт-биш ел элек, сезнең редакциягә аракы эчүчеләрне бә-әк каты яратмаучы хезмәткәр килде, ахры. Чөнки газетыгызның һәр санында аракы эчүнең нинди афәт икәнен аңлаткан, аннан котылу чараларын тасвирлаган язмалар чыга башлады. Шуларны озак укый торгач, мин чын күнелемнән эчүне ташларга карар кылдым. Дөрес, бу адым мина җиңел генә бирелмәде. Ләкин сезнең гәҗиттә басылган киңәшләр ярдәме белән, ниһаять, мин эчүне ташлау бәхетенә ирештем. Ул чакларда ниятләрем авыл мулласыныкы кебек изге, күңелем яшүсмер егетнеке кебек саф иде минем.

Хөрмәтле редакция. Айныгач кына, мин бу дөньяның бөтен матурлыгын күрүгә ирештем. Тирә-юньдә нинди гүзәл хатыннар, бу дөньяда нинди тәмле ризыклар, матур киемнәр бар икән бит! Беренче эш итеп мин эшемне алыштырдым. Айнык кеше төзелештә эшләп йөри алмый бит инде. Яна эшемдә хезмәт хакы әзрәк булса да, эчмәгәч житәр әле дип уйладым. Аннары үз гомеремдә беренче тапкыр кәчтүм-чалбар алып кидем. Элек каты-котыга да риза булган тамагыма, тәмле-томлы ризыклар да эләгә башлады. Тора-бара гүзәл, бөтен нәрсәләре дә үз урынында булган яшьрәк хатыннар да мина күз салгалый башлады. Мин, юләр, торганмын икән шулкадәр гомер бер имән түмәре белән. Рәхәт тормышка чыктым мин. Барысы да яхшы иде кебек тә, тик хатын гына мине аңламады. Дөресрәге, акчаны житәрлек кенә бирә башлавым, ничә сумны кая туздырганын сораштыруларым ошамады, ахры. Аннары элеккe кебек матур сүзләр дә сирәгәеп китте, дөресрәге, безнең өйдә алар бөтенләй кулланыштан төшеп калдылар. Шул сәбәпләр аркасында, ике баласын ияртеп, хатын миннән китеп барды. Аннары элек эчкән чакта баскыч төбендә бергә кочаклашып йоклый торган иптәшем Актүш тә каядыр чыгып югалды. Ә бит ул мине элек шулкадәр ярата иде. Мине дөньяга китергән әнием дә аның кебек яратмагандыр.

Хөрмәтле редакция хезмәткәрләре. Соңгы вакытта сезнең гәҗитегезне укымасам да (айныгач минем өчен аның кызыгы бетте), элеккегe даими укучыгыз буларак, сездән киңәш сорыйм: нишләргә мина? Мин бит хәзер тома ялгыз ир уртасы кеше. Аннары теге имән бүкәнедәй таза хатыным да сагындыра башлады. Минем тормышым борылуга да сез генә гаепле бит. Сездән үтенеп сорыйм, берәр киңәш белән булса да ярдәм итегез мина. Эчә башлыйммы икән әллә? Кәчтүм-чалбарны сатып эчеп, киредән төзелешкә эшкә кучсәм, сөекле хатыным белән яраткан этем Актүш кире кайтмаслармы икән? Алардан башка мина бу дөньяда яшәүнең кызыгы калмады лабаса.

Сездән ярдәм көтеп элеккегe даими укучыгыз:

*Сәлим Сарыймов»*

# Ринат Мәннан

## ҮРТӘМЕШЛӘР

### Синең исем

*Мин тоярмын шунда сөю хисен,*
*Миңа бәхет—*
*Иснәү синең исең...*

Марс Шабаев

**Чыгып киттем урманнарга...**
**Шуңарга китте исем:**
**Бәхет миңа тәтемәде—**
**Анда юк синең исең.**

**Хатынны да иснәп карыйм—**
**Кая сиңа җитәргә!—**
**Синең исне табар өчен**
**Инде кая китәргә?!**

**Чыгып киттем комлыкларга...**
**Бөтенләй китте исем:**
**Бәхет миннән баш чөерде—**
**Юк анда синең исең!**

**Кереп киттем трамвайга**
**Җәй көне... Китте исем!—**
**Менә бит минем бәхетем,**
**Менә бит**
**Синең исең!**

### Күзләрем

*Кышкы тәрәзәдә кыш бизәге,*
*Кышкы озын юлда... ат тизәге...*

Салисә Гәрәева

**Аптырадым, аптырадым**
**Нишләде бу күзләрем?—**
**Чиста гына тәрәзәдә**
**Күрәм... чебен эзләрен!**

**Туган якка ялга кайттым,**
**Рәхәт, юк ла һич эшем!**
**Ни күрим—кибән төбендә**
**Ята... сыер «бәлеше».**

**Кышлар җитте. Табигатьнең**
**Иң чиста вә пакъ чагы.**
**Чыгып киттем урманнарга,**
**Анда... куян «борчагы»!**

**Аптырадым, таңнар калдым—**
**Ни күрә бу күзләрем?**
**Югыйсә мин бу дөньяда**
**Гел матурлык эзләдем!**

## Син кирәк

*И бәгърем! Сиңа ашкынуым*
*Ташып югалырмы гарешләргә?*
*Юк, оҗмахта кирәкмисең миңа!—*
*Син кирәксең монда, шушы җирдә!*

Зөлфәт

**Он илә, симез ит тура—**
**Булсын бәлеш табында.**
**Син оҗмахта кирәкмисең,**
**Син кирәк миңа монда.**

**Утын ташы, мунчага як—**
**Кайнасын су казанда.**
**Син оҗмахта кирәкмисең,**
**Син кирәк миңа монда.**

**Прастинаны үтүклә дә**
**Бер ятып ал янымда.**
**...Син оҗмахта кирәкмисең,**
**Син кирәк миңа монда!**

## Кайтаваз

*Тау өстеннән—йолдызлар да якын,*
*егылсаң да, кеше күзендә...*
*Таулар—гадел. Ни дип кычкырсаң да,*
*кайтавазы кайта үзеңә!*

Равил Фәйзуллин

**Таута карап кычкырдым мин бүген!**
**«Син биек» дип Тауның үзенә.**
**Таулар—гадел икән:**
**«Син бөек!»—дип**
**Кайтавазы кайтты үземә.**

## Тамыр

*Әй шатланам! Кара җирне ярып*
*Татлы матдә эзлим алар өчен.*
*Мин бит тамыр! Миңа бар дөньяга*
*Күрсәтергә кирәк чәчәк көчен.*

Гәрәй Рәхим.

**Кара җирне ярып төшәм...**
**Өскә түгел! Гел аска!**
**Бу эш белән шөгыльләнми**
**Беркем дә миннән башка!**

**Тынгы бирми бер мәсьәлә,**
**Кемнән белешим икән?—**
**Мин гади тамыр гынамы,**
**Әллә соң жень-шень микән?!.**

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Тагын дүрт елдан, ягъни 2006 елда **Муса Җәлилнең тууына 100 ел** тула. Шул уңайдан Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевнең махсус Указы чыкты. Анда мондый юллар бар:

Хәрби әсирләрнең фашистларга каршылык күрсәтүен оештырган өчен татар халкының 1944 елда җәзалап үтерелгән баһадир улы, патриот-шагыйрь һәм интернационалист, Советлар Союзы Герое, Ленин бүләге лауреаты Муса Җәлилнең (Җәлилов Муса Мостафа улының) иҗаты һәм дөнья мәдәниятенә тиңдәше булмаган зур өлеш кертүен исәпкә алып һәм 2006 елның 15 февраленә туына 100 ел тулуны бөтенхалык бәйрәме итеп уздыру хакында җәмәгать оешмалары башлангычын хуплап, карар бирәм:

1. 2006 елның февраленә Муса Җәлилнең туына 100 ел тулуга бәйле чаралар уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына өч ай эчендә:

Муса Җәлилнең туына 100 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

шул исәптән аның әсәрләрен һәм аның турында әдәбият нәшер итүне, музей экспозицияләре төзүне, патриот-шагыйрьнең тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле объектларны ремонтлауны һәм төзекләндерүне күздә тотып, әлеге чараларны финанслау күләмен һәм чыганакларын күрсәтеп, Муса Җәлилнең туына 100 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча төп чаралар планы эшләп тапшырырга.

## «БӨЕК ИДЕЛ ЮЛЫ» ХӘРӘКӘТТӘ

6-14 августта **«Бөек Идел юлы» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция**нең икенче этабы узды һәм ул Санкт-Петербургның 300 еллыгына багышланды.

Конференция Петербург-Таллин-Һельсинки-Рига-Стокһольм маршруты буенча узды.

Аның беренче этабы узган елның август аенда Казан-Болгар-Ульян-Самара-Сарытау-Волгоград-Әстерхан маршруты буенча үткәрелгән иде һәм аның материаллары бернинчә том булып басылып та чыкты.

Бөек Идел юлы урта гасырларда ук сәүдә магистрале булып хезмәт итә һәм Европа, Азия халыкларының мәдәни, икътисадый бәйланышларын җайга сала, Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында мөһим икътисадый һәм сәяси роль уйный. Бүген Идел су юлы 90 шәһәрне һәм дөньяның 35 илен берләштерә. Шуңа күрә Бөек Идел юлын яңарту тарихи, экономик, экологик һәм мәдәни яктан зур роль уйнаячак, илләр, шәһәрләр арасында бәйләнешләрне ныгытачак.

Фәнни-гамәли конференция ЮНЕСКО, Европа Советы һәм ИРСИК (Ислам тарихын өйрәнүче халыкара үзәк) булышлыгы белән уздырыла. Аның эшендә Русия һәм Татарстанның бик күп министрлыклары, Русия һәм Татарстан хөкүмәте, шәһәр мэрлары һ. б. катнаша. Конференциядә Бөек Идел юлы: формалашу һәм үсеш тарихы; мәдәни һәм этноконфессиональ бәйланышлар; сәүдә-икътисад элемтәләре; Идел буе регионының экологик проблемалары һ. б. тикшерелде.

## КОНФЕРЕНЦИЯ КАРАРЫ

Татарларның Казан шәһәре конференциясе «Сабантуй» милли бәйрәмен ЮНЕСКОның дөнья халыклары рухи мирасы җәүһәрләре исемлегенә тәкъдим итү турында карар чыгарды һәм Казан шәһәре хакимиятеннән Россиянең ЮНЕСКО эшләре буенча милли комиссиясенә һәм ЮНЕСКОның секретариатына кирәкле документларны һәм күрсәтмә материалларны әзерләп тапшыруны сорады.

## ПОЛИГРАФИЯ БЕЛГЕЧЛӘРЕ ӘЗЕРЛӘҮ

Быелгы уку елыннан башлап Казан дәүләт технология университеты яңа белгечләр—полиграфия производствосы инженер-технологлары әзерли башлаячак.

Әлегәчә Татарстанда мондый төр белгечләр беркайда да әзерләнми иде. Университет ректоры Сергей Дьяконов әйтүенчә, экспериментның асылы сәнәгатьне югары уку йортларындагы укыту процессы белән бәйләүдән гыйбарәт. Шул уңайдан «Идел-Пресс» нәшрияты технология университеты белән килешү төзеде. Быел яңа белгечлек буенча студентлар кабул ителде.

## КОНКУРСТА ҖИҢҮЧЕЛӘР

Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы каршындагы жюри «Авыл: кеше һәм хезмәт» дигән исем астында 2002 елның гыйнварыннан июнь аена кадәр дәвам иткән конкурска йомгак ясады. Җиңүчеләр арасында безнең язучылар да бар. Алар—**Марсель Зарипов** (Казан), Тәлгат Нәҗмиев (Саба), **Рафаэль Сибат** (Киров өлкәсе). Җиңүчеләргә бүләкләрне ТР Премьер-министр урынбасары—Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры **Марат Әхмәтов** тапшырды.

## ЗУР ҖИҢҮ

П. И. Чайковский исемендәге XII Халыкара вокалчылар конкурсында утыз мең доллар күләмендәге беренче премияне һәм лауреат исемен жырчы **Михаил Казаков** яулады. Ул Казан консерваториясен тәмамлаган, әлегә М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет академия театрында эшли.

## ОЛУГ ЖУРНАЛИСТ ИСТӘЛЕГЕНӘ

27 август көнне күренекле журналист һәм җәмәгать эшлеклесе **Шәмси Хәбибулла улы Хамматов** (ул озак еллар буе «Социалистик Татарстан» газетасының редакторы һәм Татарстан Журналистлар берлегенең рәисе булып эшләде) **яшәгән йортка мемориаль такта куелды**. Горький урамының 21 а йортында эленгән бу мәрмәр тактада татар һәм рус телләрендә мондый сүзләр язылган: «Бу йортта 1952-1988 елларда танылган журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Ш. Х. Хамматов яшәде».

## ЗИНДАННАРДА СЫНАЛГАННАР

Быел дөнья күргән «Сүнмәс мәхәббәт уты» дигән китап язучылар **Кави Нәҗми** һәм аның хатыны **Сәрвәр Әдһәмова**ның 100 еллыкларына багышланган. Уллары Тансык Нәҗметдинов белән киленнәре Сания Әхтәмова төзегән бу китапта Кави һәм Сәрвәрнең 30 нчы елларда бер-беренә язган 120 дән артык хатлары урын алган.

## ГЫЙЛЬМИ ДӘРӘҖӘЛЕЛӘР АРТА

Казан дәүләт университетының филология фәннәре буенча диссертацияләр яклау советы утырышында **Илһам Фәттахов** «XX гасырның 80-90 нчы елларында татар повесте (чор һәм автор образы)» дигән темага (җитәкчесе филология фәннәре докторы Т. Галиуллин) филология фәннәре кандидаты дигән дәрәҗәгә диссертация яклады.

## ЛИТВА ТАТАРЛАРЫ МИРАСЫ

Вильнюс университеты нәшриятында Галина Мишкененның «Литва татарларының борынгы кулъязмалары (графика, транслитерация, тәрҗемә, текстларның структурасы һәм эчтәлеге)» дигән китабы дөнья күрде.

Китап 262 биттән тора һәм аның өчтән ике өлеше литва татарларының урыс, литва телләренә тәрҗемә ителгән кулъязмаларын тәшкил итә.

Литва татарларының бу рухи байлыгы халыкның динен, гореф-гадәтләрен тергезергә ярдәм итәр дигән нияттән, «Литувос тоторяй» («Литва татарлары») газите әлеге китапка кергән кайбер кызыклы шәмаилләр һәм текстларны бастырып чыгарырга карар кылды.

## ПОЛЬШАДА «МИЛЛӘТ» АЛЬМАНАХЫ

Польшада «Милләт» дип аталучы альманах дөнья күрде. Аны нәшер итүдә дүрт мөстәкыйль дәүләтнең татар җәмгыятьләре катнаша. Баш мөхәррире—Сәлим Хазбиевич (Польша), шулай ук Гомаульдас Макаваускас (Литва), Ибраһим Конопацкий (Беларусь), Кәнәфия Хөснетдинов (Украина).

Альманах зур форматлы 223 битле, поляк телендәге басмадан гыйбарәт. Аны нәшер итү Польшаның Мәдәният министрлыгының матди ярдәме белән гамәлгә ашырылды. Польша дәүләтенең төрле милләтләргә, бигрәк тә татарларга теләктәшлек күрсәтүенең ачык дәлиле бу.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстанның халык рәссамы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты **Илдар Зарипов**ка дәрәҗәле яна исем өстәлде: ул хәзер Россиянең халык рәссамы да.

* * *

Әдәбиятны үстерүдәге казанышлары өчен язучы, Татарстан Республикасы язучылары җәмәгать оешмасы (Татар ПЕН-үзәге) башкарма директоры **Мушинский Әхәт Хәй улына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# КАЗАННЫ САГЫНУ

1990 елларда Казан җирлегендә инде беркадәр идеологик штамплардан арынган, ниһаять, милләт мәнфәгатьләрен көн кадагына куйган, татар рәвешенең һәм тарихының үзкыйммәтен, самимилеген фаразлаган, аның онытылып, яисә тыелып, ертылып-тапталып калган сәхифәләрен, күләмле гыйбарәләрен, мифларын кабат торгызырга омтылган «яна сәнгать»—tat-art күренеше туып чыкты. Милли романтизм тойгылары белән күпертелгән, кайнарлыгы йә күтәрелеп, йә үзгәреп торган бу процессның оешу урыны нәкъ менә Милли мәдәни үзәк, биредә төзелеп килгән беренче Татар музее, аның залларында барган дөньякүләм һәм гомуммилли акцияләр, илнең төрле почмакларында яшәп тә, үзен «татар итеп тойган» рәссамнарыбызның бертуктаусыз үткәрелгән күргәзмәләр ташкыны булды.

Сюрреализм, абстракционизм, наив сәнгать һәм башка шундый плюралистик чорда туып чыга торган юнәлешләр тарафдарлары халыкка мул итеп үзләренең иҗат җимешләрен тәкъдим иттеләр... Һәм, шулай итеп, Татарстанда, чын мәгънәсендә, үзендә меңъеллык шәһәр культурасы алымнарын-шәкел ягыннан радикальрәк, кыюрак булган элеккеге дала регионнарының иҗат концепцияләре белән тоташтырган яна бербөтен—Дәшти-Кыпчак—Алтын Урда «сәнгать империясе» калкып чыкты. Аның иң үткен, әһәмиятле компоненты—Уфада яшәп иҗат итүче рәссамнар төркеме «Чыңгызхан» булды. Милли этнография, эстетика шаукымнарын җантетрәткеч геометрик сызымнар, орнамент табышмакларына буйсындырып, ниндидер катгый зарурилык, фәлсәфи купсыешлылыкка омтылган рәссамнар, кайчандыр бөтен Европа цивилизациясенә сөрән салган бабалары Чыңгызхан сыман, аңа яңа тизлек, төсләр, буяу, матурлык төшенчәләре вәгъдә иткән «гүзәллек экспансиясе» игълан иттеләр.

Бу хәрәкәтнең башында зур сәләт һәм интеллект иясе, тирән теоретик һәм пафослы шәхес, чын мәгънәсендә, әйдәп баручы лидер—Башкортстанда тәрбияләнеп, сәнгатьтә татарча эш йөртеп житлеккән яшь рәссам—Наил Латфуллин торды. Иҗаты—Русиянен, Американың, Австриянең дәрәҗәле сәнгать мәйданнарында кискен конкуренция шартларында формалашкан, үз карашын иң экстремаль, киеренке шартларда да яклап чыга алырлык гайрәтле бу егет—XX гасыр татар рәссамчылыгының төп принципларын итеп: миллилек, илаһилылык, модернлык, яңалык сыйфатларын атады. Татар сәнгатенең туу тамырына—шәҗәрәсенә омтылган «Чыңгызхан», шул ук вакытта, милли тоемнарның, образ-бизәмнәрнең, гомумән, төрки-татарлар тудырган мирасның дөнья сәнгате панорамасындагы абруйлы урыны өчен дә «көрәш ачты». Бу идеяләр чыңгызханлыларның, һәм, беренче чиратта, Н. Латфуллинның үз иҗатында ачык чагылыш тапты. Аның «мәһабәт җайдагы»—әллә атасы юнып эшләгән агач атка атланган ярсу яшүсмер—шук малай, әллә ниндидер кызыл-яшел, зәңгәр-сары, ай нурларына уралган космик гигант—нурлы фантом, халык идеалы—«татар дөньясы».

«Су юлы» әсәрендә ул бу төшенчәне тагы да гомумиләштереп, аңа гава рухы индерде. Җилкәсенә көянтәсен элеп, айдан төшеп килгән татар кызының образы һәртөрле сентиментальлектән куптарылган, арынган—аның гәүдәсен рәссам әллә-ничек үзенә бормалаштырып, яна ракурслар өстәп, галәм җилләренә төреп, галактика тирәлегендәге йолдыз итеп сурәтләгән. Алдыбызда—әкиятләрдән төшеп күңелне изалаган таныш образ лабаса... Ләкин Н. Латфуллин версиясендә ул—кешелек һәм «мәңгелек» категорияләрен эченә алган—әллә архаик Полинезия

әкиятенең дуамал бер матуркае, әллә мәжүсилек алиһәсе, әллә сугыштан соңгы татар авылы тудырган тормышчан хатын-кыз тибы.

Месс-Америка сәнгатенең беренчел гүзәллегенә табынган рәссам, бөек латин Америкасы язучысы Борхеска гашыйк иде. Аңа ияреп, ул халкыбызның рухи башкаласы Казанны да—күз камаштыргыч төрлелекне берләштергән гүзәл цивилизация, Бабил манарасы, илаһи Китапханә итеп сурәтләде. Бишләп варианттан торган паннонын «Омтылу» дигән нөсхәсендә ул Казан сурәтенә—бөек шәһәрнең мәңгелегенә инандыручы гаҗәп төсмерләр, күрәзәчел мистика шомнары өстәде.

Н. Латфуллинның—сугышчан алтын башлык,күкрәгенә хәситә, гәүдәсенә яугир каһарманның көбәсен хәтерләткән кием кигән яшүсмер «Сөембикә»се дә шулай күп планлы. Ул сәнгать инерциясе буенча инде калыплашкан нәүмиз ягымлы назбикә түгел, ә кискен холыклы яу батыры, яисә 80 нче елларда бөтен Казанны куркытып торган группировка әгъзасы—«ПТУшник»!

Татарстан язмышы өчен хәлиткеч чорда—1990 нчы елның референдумы көннәрендә рәссам үзенең иң гыйбрәтле, эчке мәгънәле, тарихи милли тукымасын—«Дүрт сенел» әсәрен иҗат итте. Казанны сагыну, хөрмәт итү, ата-бабалар, әти-сенелләр кичергән бөек тарихны олылау хисләренә күмелгән әсәр бу елларда халкыбыз кичергән Хөррият, гүзәл һәм илаһи бәйрәм таңы атмосферасын гәүдәләндерде... Мондагы «шакмак-шакмак» яссы куе төсләр, киртә-киртә ак сызымнар, әйтерсең, тукымага өреп, тап булып язылган бәйрәм гөлләре... Өстәл тирәли урнашкан, басып торган кызыл калфаклы туташлар,—әллә гасыр башындагы рухи күтәрелештә катнашкан мөгаллимәләр, әллә халыкның киләчәге турында хәбәр бирүче изге фәрештәләр... Аларның йөрәк тибеше, әйтерсең, бүгенге көнне узган гасырлар белән бәйләп, картинаның төбеннән безгә таба килгән ургылыш халәтен сурәтләп бара. Киләчәккә инандыра...

Бүгенге көнне риваятькә әйләндергән рәссам Н. Латфуллинның сулышы 1992 елның ноябрендә, кырык яшендә, сәләте күкрәп торган чакта көтелмәгән рәвештә киселде.

**Розалина ШАҺИЕВА**,
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрь Рим Идиятуллин.

# ЯҢА КИТАПЛАР




СИБӘГАТОВ Р. Г. **Башкортстан татарлары.** Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре.— Казан:—Мәгариф, 2002.—191 б. Тиражы—5000 данә.

Радик Сибәгатов татар-башкорт дөньясында мәгълүм шәхес. Ул—тел галиме һәм политолог, Уфа дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасы житәкчесе, филология фәннәре докторы, профессор, Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе.

Киң жәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителүче әлеге гыйльми-публицистик хезмәт Башкортстан татарларының этник тарихы, тел статусы һәм милли-мәдәни үсеше проблемаларына багышлана.

Татарлар ничә төрле, аларны ничек саныйлар? Типтәрләр, «яңа башкортлар», йомышлы татарлар яки мишәрләр, керәшеннәр—кемнәр алар? Әлеге атамаларның килеп чыгышы тарих агымының кайсы чорлары, нинди процесслары белән бәйле? Бүгенге Башкортстандагы «татар проблемасы»ның асылы нәрсәдә? Китапта әлеге сорауларның күбесенә фәнни яктан нигезләнгән җаваплар урын алган. Шулай ук биредә Башкортстанда яшәүче милләттәшләребезнең татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү өчен алып барган көрәше дә чагылыш тапкан.

Китапның «Татар-Башкорт проблемасы рәсми документларда һәм материалларда» дигән кушымтасы, шул исәптән, соңгы чорда башкорт милләтенә күчерелгән татар авыллары исемлеге аерым игътибарга лаек. Биредә 1920 елдан башлап безнең көннәргәчә Совет хөкүмәтенең, Башкортстан житәкчелегенең шушы мәсьәләгә кагылышлы карарлары, күрсәтмәләре, төрле иҗтимагый оешмаларның белдерүләре, халыкның милли составын чагылдыручы таблицалар, күренекле җәмәгать эшлеклеләре, фән әһелләре белән интервьюлар туплап бирелгән.

Индекс 73210



Рим Идиятуллин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)